# Казан утлары

5

май

1969



ИБРАҺИМ МИНГАЗИЕВ
(Ибраһим Гази)



АЙРАТ АРСЛАНОВ

# ТАТАРСТАН АССР МИНИСТРЛАР СОВЕТЫНДА

Г. Тукай исемендәге республика премияләре комитеты утырышы булды. Комитет 1969 елга Г. Тукай исемендәге республика премияләрен әдәбият өлкәсендә — өч кисәктән торган «Онытылмас еллар» романы өчен Ибраһим Зариф улы Мингазиевка (Ибраһим Газига), башкару эшчәнлеге өлкәсендә — «Күңелем Ленин белән сөйләшә» һәм «Туган җирем — Татарстан» дигән әдәби концертлар программасы өчен Айрат Гәрәй улы Арслановка бирү турында карар кабул итте. Татарстан АССР Министрлар Советы Г. Тукай исемендәге республика премияләре комитетының бу карарын раслады.

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

**5**

МАЙ
1969


## Бу санда:


ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

**Ә. РӘШИТОВ.** Исәнме, Ленинград! Пролетарийлар юлдашы. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . 3

**Е. ДЬЕРКЕИ.** Кремльдә Ленин белән очрашу. . . 6

ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬ

**Э. КАСЫЙМОВ.** Көмеш язулы кылыч. Повесть. . 10

**С. СӨЛӘЙМАНОВА.** Әй, солдатлар. Күзләр якты быел. Ни белән үлчәнә. Кермим кеше биләмәләренә. Авыл урамы. Ялгызым дип уйласам да. Каен. Шигырьләр. . . . . . . . . . 42

**Н. АРСЛАНОВ.** Изге теләк. Көчле дә син. Синең төсле. Сәйдең — көйдердең. Мәхәббәткә рөхсәт сорамыйлар. Чыраемны сыттым исә. Халык әйтте. Бер тәнкыйтьчегә җавап. Күзге моңнар. Адым саен әкият. Кинешма бәете. Идел такмаклары. Шигырьләр. . . . . . . . . . . 45

**Р. ФӘЙЗУЛЛИН.** Алмазга. Мин зур түгел. Яз төсе бу күздә. Үлемнәре белән. Өндәде. Җанга якын. Миңа бары бер җыр кирәк. Шигырьләр. 50

**Х. САРЬЯН.** Паку! Хикәя. . . . . . . . . . . 53

**С. САБИРОВ.** Дустымның үлеме. Хикәя. . . . . 63

**ЗӨЛФӘТ.** Ильич өмәдә. Көрәш сөлгесе. Ориенткр. Әни. Кандалый турында баллада. Беләктә — көч. Чабышкыда безнең җиз йөгән. Яңа Сәет. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . . . 68

ДУСЛЫК БУКЕТЫНА

**Ш. АБДЫРАМАНОВ.** Солдат. Хикәя. . . . . . . 74

**М. ГАПАРОВ.** Наташа Ростованың беренче балы. Хикәя. . . . . . . . . . . . . . . . . 84

ПУБЛИЦИСТИКА

**Г. ӘПСӘЛӘМОВ.** Без һәрвакыт Ленин белән. . . 89

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

**А. МӨСЛИМОВ.** Ленин «Искра»сы һәм Казан. . . 109

**И. НАДИРОВ.** Халыклар шигърияте Ленин образы. . . . . . . . . . . . . . . . 112



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ТАТАРСТАННЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

С. ФӘЙЗУЛЛИН. Ленинны тәрҗемә иткәндә. . . 118

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Ж. РӘХИМОВ. Дуслык тау күчерә. Очерк. . . . 124

ӘДӘБИЯТ ФӘНЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

И. НУРУЛЛИН. Иҗат методыбыз турында уйланулар. . . . . . . . . . . . . . . . . 133

ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА — ШАГЫЙРЬ

З. НУРИ. Тормыштан һәм тормышчан. . . . . . 143

БАТЫРЛАР КИТАБЫНА

З. ӘХМӘТҖАНОВ. Алтын йолдызлы лачын. Очерк. 152

ИҖАТ ОЕШМАЛАРЫНДА

С. ЧЕРВОННАЯ. Туган җир җылысы. . . . . . . 165

ИСТӘЛЕКЛӘР, ЯЗМАЛАР

Г. ГАЛИЕВ. Безнең Кутуй. . . . . . . . . . . 171
А. СУРКОВ. Җирдә яшәү хакына. . . . . . . 179

ЯҢА КИТАПЛАР

Ф. МАКАЕВ. Ачык ишек. . . . . . . . . . . 183

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ

Ш. ГАЛИЕВ. Әнкәй белән бәхәс. Балта. Бергәләп торыйк. Мәхәббәт уставы турында. Шигырьләр. 185
Г. РӘХИМ. Иптәшләр үзебезнеке, бәлки гаеп итмәсләр. Эпиграммалар. . . . . . . . . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. . . . . . . 188

**Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый**

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор —2-68-21, җаваплы секретарь —2-39-52, бүлекләр —2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Производствога бирелде 12/III-1969 ел. Басарга кул куелды 23/IV-1969 ел. ПФ 09011. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 82746 экз. Заказ В-147. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1969 ел.




# ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

*Төрле илләрдән, төрле телләрдән*

**Әхмәт Рәшитов**

## Исәнме, Ленинград!

*Октябрьда туганнарның*
*Ленин була бабасы.*
**Татар халык җыры.**

Яңа тәпи баскан сабый ничек
Сөерсенеп бакса бишегенә,
Мин дә шундый гаҗәпләнү кичереп
Керәп киләм синең ишегеңнән.

Европага тәрәз... дип аталган
Бөек Петр ачкан шушы ишек.
Горур да син, матур да син, кала.
Мин сокланып карыйм исем китеп.

Син бик якын миңа декабристлар
Ялкын кабыза алган очкын белән,
Расстрелли белән,
Росси белән,
Чайковский белән,
Пушкин белән.

Син бик якын миңа «Аврора»ның
Дөнья алкышлаган залпы белән,
Илнең кичәгегә,
Бүгенгегә
Һәм иртәгә яшәү хакы белән.

Очраклыдыр бәлки бу тууым,
Тик очраклы түгел гомерем җирдә,
Октябрьда тудым,
Бабам — Ленин,
Тормышыма Ленин виза биргән.

Революция бишекләре моңын
Җирдә бер мин генә ишетмәдем:
Һәрбер континентның баласына
Ача бүген Ватан ишекләрен.

Негр килә сиңа,
Монгол килә,
Болгар килә,
Килә папуаслар...
Һәр тарафтан сине сәламлиләр,
Чал Невага назлы караш ташлап.

Саумы, Ленинград!
Бишегемә
Кагылган бит синең иркә җилең;
Язмышыма виза син биргәнсең —
Октябрьда тудым,
Бабам — Ленин.

## Пролетарийлар юлдашы

Сыйнфый көрәш кызган ул елларда
Күпме Себер киткән башлар бар.
Петропавел равелиннарында
Бабам каны тамган ташлар бар.

Йөрим-йөрим аның эзләреннән,
Шаһитларын эзләп үткәннең.
Хәтерлимсең әле дә, урам, синнән
Бер юлаучы узып киткәнне?

Ләгънәт укып туган туфрагыңнан
Ул чак ничек читкә таймыйсың:
Ул да бәхет эзләп килгән монда,
Төенчегенә төйнәп кайгысын.

Патша хәзрәтләренең аналарын
Туксан катлап искә алганга,
Петропавел зинданына аны
Таш капчыкка илтеп салганнар.

Эшче бистәләрдән килгән халык,
Олы бәйрәм итеп бер көнне,

Һәм кулларга кызыл байрак алып,
Сәламләгән бөек Ленинны.

Менә музей. Тыныч заллар саклый
Тарихларның яңа дәвамын.
Ә мин уйлыйм, уйлыйм гел шул чакны
Ниләр кичерүен бабамның.

Белгәндерме өндәү ташлап җәйгә
Коеп ләйсән яуган ул кичне,
Яңгырыйсын тиздән Россиягә
«Апрель тезислары» Ильичның?

Ул кушылып сикәлтәле юлда
Көрәшләрнең көчле давылына,
Тулы вәкаләтле илче булган
Чабаталы татар авылыннан.

Сорыйм-сорыйм мәрмәр плиталардан:
Үткәннәргә бармы кадерең?
Пролетарийларга юлдаш булган
Гаделшинның кайда кабере?

Алар дәшми,— бары як-ягыма
Мәрмәрләрдән кайгы-моң ага.
Матәм маршы сыман, тып-тын гына
Мәңгелек ут яна уртада.

**Енё Дьёркеи,**

венгр язучысы

# КРЕМЛЬДӘ ЛЕНИН БЕЛӘН ОЧРАШУ

*Гражданнар сугышы. 1919 ел. Яшь Совет дәүләте дошманның утлы боҗрасы белән уратып алынган. Октябрь ватанының тарих битләренә алтын хәрефләр белән язылган башлангыч юлы социалистик илләр әдәбиятында дулкынландыргыч темаларның берсе булып тора.*

*Енё Дьёркеиның «Фрунзе янында» исемле китабы Советлар Россиясендә гражданнар сугышына катнашкан венгр сугышчыларының истәлекләреннән алып язылган. Автор бу китабында атаклы Совет полководецы М. В. Фрунзе һәм венгр интернационалистларыннан торган сакчы отрядның сугышчылары турында сөйли. Без укучыларга шул китаптан бер хикәя тәкъдим итәбез.*

1919 елның җәендә, Кызыл Армиянең барлык фронтларда диярлек уңышлы үткәргән берничә зур операцияләреннән соң, Колчак гаскәрләре тар-мар ителде.

Операцияләргә әзерлек барган вакытта Фрунзе штабында тормыш чишмә кебек кайнап тора иде. Фронтлардан командармнар, корпус командирлары, комиссарлар, элемтәчеләр һәм хәбәрчеләр әледән-әле килеп кенә тордылар. Операцияләр сизелерлек нәтиҗәләр бирде. Уралда аклар бик каты җиңелүгә дучар булдылар һәм чигенә башладылар. Чигенүче ташкынның бер төркеме Үзәк Себер юнәлешенә ургылды, ә икенче төркем Урта Азия юнәлешендә тәгәри башлады.

Августның башларында Фрунзены Мәскәүгә чакырдылар. Моңа кадәр дә Фрунзены Мәскәүгә чакырган очраклар булгалый иде, әмма бу юлы солдатлар үзләренең зур вакыйгалар алдында торганлыкларын сизделәр.

Сыек болытлар белән капланган күк йөзе яктырып китте. Фрунзеның килүен хәбәр итеп, сәгать дүртләрдә быргычы сигналы яңгырады. Команда сүзләре ишетелде һәм сакчы отрядының командиры Мартон Шаркези, поездның китәргә әзер икәнлеген белдереп, рапорт бирде. Рапортны тыңлап бетергәннән соң, Фрунзе кузгалырга рөхсәт итте.

Алда мең километрга сузылган юл ята. Хәзер дә бу якын ара түгел, ә моннан 40 ел элекке техника өчен бигрәк тә инде. Состав яшел урман һәм таулар тирәсеннән чаба. Паровозга утын, су алыр өчен юлда еш кына тукталып торырга туры килә.

Икенче көнне төш турларында Мәскәүгә килеп җиттек. Поезд йөрешен акрынайтты, әледән-әле стрелочниклар очрый. Сугышчылар кар-

шыга чабучы зур шәһәргә исләре китеп карыйлар. Поезд Мәскәүнең эче буйлап бара. Унда Гужон заводының дәү корпуслары күренә башлады.

— Карагыз әле, нинди гигант,— диде Геза Рабикар.

— Завод завод инде,— диделәр сугышчылар.

— Аның үз тарихы бар. Унжиденче елны, марттан алып ноябрьга кадәр, хәрби әсирлектә мин шушы заводның слесарьлык мастерскоенда эшләдем. Бөек Октябрь социалистик революциясен без шунда каршыладык, шунда Фридеш Карикош белән таныштык. Ул безне заводтан Мәскәү баррикадаларына алып китте.

Геза Рабикар 1917 елның ноябренда Мәскәү пролетариатының урам сугышлары турында үзенең кичерешләрен уртаклашкан арада, поезд әкрен генә Казан вокзалы платформаларына якынлашты.

Паровоз, куе пар бөркеп, чаш-чош килеп туктады, сакчы солдатлар составның ике ягында үз урыннарын алыр өчен вагоннардан сибелделәр. Бөтенроссия Реввоенсоветы Көньяк җыелма армияләренең командующиен алырга ике машина җибәргән иде. Фрунзе һәм Сиротинскийдан башка Игнац Агоштон һәм Пал Вайда иптәшләр дә поездан төштеләр.

Ачык түбәле «форд», Кызыл мәйданны үтеп, Кремль капкасына килеп керде һәм бер зур сары йорт каршысына килеп туктады. Фрунзе белән Сиротинский эчкә кереп киттеләр, ә озатып килүче ике кеше аларны Кремль бакчасында көтеп калды.

— Кара әле, дускай. Ә без нәрсә эшләрбез? — дип сорады Вайда үзенең иптәшеннән.

— Синең монда кадәр Кремльдә булганың юк идеме?

— Юк, ләкин Кремль турында күп ишеткәнем бар.

— Бик әйбәт фикер килде әле минем башка.

— Нindирәк фикер?

— Киттек карарга!

— Өлгерербезме?

— Әйе. Иптәш Сиротинский, аз дигәндә бер сәгать торырбыз, диде. Шулай булгач, без Кремльне карап йөри алабыз. Әгәр син теләсәң, смирно басып тик торырбыз. Бу да начар эш түгел, әлбәттә.

— Әй усал да кеше син, туганкай!

Икесе берьюлы елмайдылар, аннан Агоштон шаяртып команда бирде.

— Урынны күзәтергә шагом марш! Бер-ике!

Алар, сызгыра-сызгыра, зур парк буйлап киттеләр.

— Әнә зур-зур суганнарга охшаган теге сырлы гөмбәзләрне күрәсеңме? — диде Вайда, исе китеп.— Кара әйбәтләбрәк, көн саен күрә алмыйсың андыйларны.

— Сәлам, картлач! — дип исәнләштеләр алар паркта нидер эшләп йөргән бакчачыга охшаш бер ир кеше белән.— Эшлисеңме?

— Минме?.. Мин... әйе, ә менә сез монда ни эшләп йөрисез һәм кем буласыз?

— Без кызылармеецлар, интернационалистлар. Иптәш Фрунзеның шәхси сакчылары.

— Бу, әлбәттә, эш. Кремльдә карарлык әйберләр бар. Әйдә, карагыз, күрегез.

— Карарга әйбер күп, тик менә күрсәтеп йөрүче генә юк.

— Әгәр телисез икән, мин сезгә ярдәм итәргә риза,— дип җавап кайтарды бакчачы һәм шундук аңлатырга кереште:— Сез Кремльдә йөрисез. Мондагы һәрнәрсә — үзе бер тарих. Һәрбер таш рус халкының данлыклы үткәннәре турында сөйли. Болар барысы да рус мастерлары көче белән салынган. Ә патшалар Кремльдәге һәрбер хәзинә аларның үз исемнәрен мәңгеләштерер дип уйлаганнар.

Кремль, башкалабыз Мәскәүнең үзе кебек үк, бик борынгы. «Кремль» сүзе ныгытма дигәнне аңлата. Бу ныгытма дошманнардан саклану өчен төзелгән. Аны инде берничә тапкыр яңартканнар.

Бүгенге көнгә кадәр үзенең баштагы төсе белән сакланган Кремльнең манаралары һәм стеналары үтә алмаслык киртә булып торганнар. Кремльнең эчке корылмалары, сарайлар һәм чиркәүләр — бу мәһабәт соборлар болар барысы да бөтен бер архитектура чeлтәрен хасил итә. Патша-кыңгырауга дикъкат итегез,— дип дәвам итте сүзен бакчачы.— Андый кыңгырауны сез башка беркайда да күрмәссез. Аның да тарихы бар. Без, руслар, аны патша-кыңгырау дип йөртәбез. Беренче кыңгырау Борис Годунов патшалык иткән дәвердә коелган булган, ул кыңгырау йөз утыз тоннага якын авырлыкта булган. Мәскәүдәге зур янгын вакытында кыңгырау төшеп ватыла. Ул патша-кыңгырауның бабасы була. Соңыннан рус осталары иске кыңгырауның кисәкләреннән яңа кыңгырау коярга керешәләр. Монысы инде — дөньяда иң зур кыңгырау, аның авырлыгы ике йөз тоннадан артыграк, яннарының калынлыгы алтмыш сантиметр, биеклеге алты метрдан артыграк.

Бу яңа кыңгырау коелган урынында махсус агач терәк өстендә торган. 1737 елны Мәскәүдә тагын янгын кабынган.

— Мәскәүдә янгыннар бигрәк тә күп булган икән,— диде Агоштон.

— Дөрес сүзгә җавап юк. Элек башкалада йортлар гел агачтан булган, шуның аркасында мәскәүлеләр янгыннан гел җәфа чиккәннәр.

Сүземне дәвам итәм... Кыңгырау астындагы агач терәүләр янып авалар. Кызган кыңгырау сулы чокырга килеп төшә. Шунда ул ярыла һәм бер кисәге уелып төшә. Менә хәзер сез карап торган шушы кыңгырау туксан тугыз ел чокырда яткан. 1836 елны гына аны, чокырдан чыгарып, нигезгә куялар.

Патша-кыңгырауның тарихын сөйләгәннән соң, бакчачы үз эшен дәвам итте.

Венгрлар бакчачыга чын күңелдән рәхмәт белдереп саубуллаштылар да 1586 елда коелган патша-туп янына киттеләр.

— Чынлап та гаҗәп туп. Көпшәсенең генә озынлыгы биш метр чамасы булыр,— дип сөйләнде Пал Вайда.

Патша-тупка сокланып торганда, парк аркылы аларга табан иптәш Фрунзеның килгәнен күрделәр. Аның белән янәшә очлаеп торган сакаллы, кечерәк буйлы тагын бер кеше атлый иде. Аларны Сиротинский һәм венгрларга таныш булмаган тагын ике ир кеше озатып килә.

— Кара әле! Бу иптәш Ленин бит! Фрунзедан уңда килгәне. Мин аны шунда ук таныдым,— дип пышылдады Агоштон.

Ленин белән Фрунзе килеп җиткәч, венгрлар хәрбиләрчә оста итеп честь бирделәр. Аларның яңа формаларына Ленинның күзе төште: кара хром итек, кызыл төстәге китель һәм ал чалбар.

— Бу иптәшләр кем? — дип Фрунзега мөрәҗәгать итте Ленин.— Кайсы частьтан?

— Минем сакчылар, Владимир Ильич...— дип сүзен башлады Фрунзе.

— Нәрсә? Шәхси сакчыларыгызмы? Сез шаяртасыз...

— Бер дә шаяртмыйм. Штаб каршында комендант взводы бар, дип мин сезгә кайчандыр әйткән идем бит.

— Әйе, әйе, хәтерлим, ләкин алар кемнәр соң? — Ленин хәйләкәр елмаеп куйды һәм кызыксынып сугышчыларга карады.

— Бу венгрлар,— дип аңлатты Сиротинский.

— Венгрлармы? — дип гаҗәпләнде Ленин.— Чынлап та венгрлармы? — Ул Вайда белән Агоштон янына якын ук килде.

— Әйе, иптәш Ленин.

— Ә нигә монда сугышасыз? Йөрәк кушуы буенчамы?

Венгр иптәшләр бу көтелмәгән сораудан аптырап калдылар. Беренче булып Агоштон үз-үзен кулга алды.

— Әлбәттә, йөрәк кушуы буенча. Безнең бирегә килү юллары җиңел булмады. Йөрәк кушмаса, тормышын куркыныч астына кем куйсын, иптәш Ленин. Мин гади венгр эшчесе һәм политиканы ул кадәр тирән аңламыйм. Ләкин уникенче елның егерме өченче маенда, Венгриядә эшчеләр баш күтәргәч, мин алар белән киттем. Эшчеләр күтәрелешендә катнаштым. Төрмәгә яптылар. Яшерми әйтәм, анда миңа шактый эләкте. Имгәтеп бетерделәр. Төрмәдән барсы өчен дә үч алырга дигән нык теләк белән чыктым. Моны мин унҗиденче елның октябрендә, Октябрь социалистик революциясенең җиңүе өчен көрәшкәндә, искә төшердем, аннан унсигезенче апрельдә, өченче Оренбург интернациональ полкы сугышчысы булганнан соң, искә алдым.

— Мин сезнең турыда, венгр интернационалистлары турында ишеткән идем,— диде Ленин.— Сез яхшы сугышасыз. Аңлагыз: сез монда рус эшче һәм крестьяннарының иреге өчен генә түгел, үз халкыгызның азатлыгы өчен дә сугышасыз.

Агоштон үткән елның язында Венгриядә республика игълан итү турындагы хәбәрне нинди зур күтәренкелек белән каршы алуларын хәтерләде. Аннан соң алар туган илне һәм бергә сугышып йөргәннәрен ешрак искә ала торган булып киттеләр. Комиссар Йошкой Шабори һәм сугышчылар белән бу турыда алар ничәмә тапкыр гына сөйләшмәделәр!..

Ленин Агоштонның иңбашына кулын салды, күзләрен хәйләкәр итеп кысты һәм елмаеп:

— Сезгә уңышлар телим, иптәшләр! — диде.

Ленин һәм аның ике юлдашы парк сукмагы буйлап китеп бардылар. Фрунзе белән Сиротинский венгрлар белән калды.

— Иң зур большевик сөйләште сезнең белән. Ленин...— диде Фрунзе.

**Булат СӨЛӘЙМАНОВ тәрҗемәсе**

## Эдуард Касыймов

# КӨМЕШ ЯЗУЛЫ КЫЛЫЧ

ПОВЕСТЬ

БЕРЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

Авылыбызда аның турында бертөрле легенда герое сыманрак итеп сөйли торганнар иде. Сугыш алдыннан да, сугыш елларында да... Хәер, бүген дә әле олырак кешеләр торып-торып аны искә алгалыйлардыр. Кешесе онытырлык түгел иде шул...

Аның исеме Гыйлаҗетдин иде, ягъни безнең ише малай-шалай өчен Гыйлаҗ агай. Ә болай халык телендә, үзенә атап эндәшмәгәндә, «Адыады» дип кенә йөртерләр иде, ник дисәгез, авылыбызда Гыйлаҗетдиннар, Гыйлаҗлар бер ул гына түгел, алар күбәү...

Гыйлаҗ агайның Бари исемле бер малае бар иде. Миңа яшьтәш. Без икебез бергә беренче класска барып кердек, аннары икебез, бер партада утырып, дүрт ел буена бергә укыдык. Әкәмәт үткен, тапкыр малай иде... Әйтик, арифметика дәресләрендә теләсә нинди мәсьәләне «әһ» итмичә чишеп тә куяр иде.

Кышын да без бергә, җәен дә... Кайсыдыр, теленә чуан чыккыры, безнең дуслыктан көнләшептерме: «Агылый белән Тагылый ич алар»,— дип әйтеп куйган бит бер мәлне. Шул нәрсә икебезгә дә, сарык койрыгына сырылган тигәнәк күк, ябышты да калды. Ләкин безнең аңа әллә ни исебез китмәде: Агылый икән Агылый, Тагылый икән Тагылый булыйк, тик арага кыл да кыстыра алмасыннар...

Безнең әниләр дә үзара бик дус, бик тату яшиләр. Безнең өй алардан өч-дүрт йорт аша гына, шунлыктан вак-төяк йомышка алар безгә, без аларга чабабыз. Әниләребезнең эшләре дә охшаш: минем әни больницада санитарка булып эшли, аның әнисе Мәчтүрә апай без укыган башлангыч мәктәптә җыештыручы. Үз өйләре булмаганга күрә, алар мәктәп ишек алдындагы өч тәрәзәле тәбәнәгрәк кенә өйдә торалар.

Җәйге елларын аның әнисе дә, минем әни дә бер вакытта — август аенда алалар. Хикмәт шунда, авылыбызны һәр яклап чолгап алган калын кара урманнарда, иксез-чиксез сазлыкларда бу айда кара җиләк, нарат җиләге һәм мүк җиләкләре өлгерә. Менә шуларны җыярга йөрибез. Ә алар, ул җиләкләр, безнең тирәдә кайсы елларны күктән яуган шикелле була. Баринын әнисе Мәчтүрә апайны «саз башлыгы» дип йөртәләр. Чынлап та, ул үзенә иң якын, иң ышанычлы хатыннардан бәләкәй генә бер «әтрәт» туплый да җиләкле сазлыкның иң шәп төшенә алып бара...

Җиләкне безгә, Бари белән икебезгә, ярыштыра-ярыштыра җыйдырталар: муеннарга бау белән асылган калай савытларны кайсыбыз тизрәк тутыра да, кайсыбыз әниләрнең зур кәрзиненә күбрәк бушата. Кайчакны ул уза, кайчакны мин.

Кайтырга чыкканда, без генә түгел, олылар да сазлык түмгәкләре арасында, исерек кешеләр шикелле, алпан-тилпән, ава-түнә атлый. Менә шул чакны Бари дус көннең нинди булуына яки урман-сазлыкларның нинди җирләрендә йөрүебезгә карамастан, һич саташмыйча, безне кергән юлыбызга чыгарып куя. Каян белә, каян килә диген шундый зиһен?.. Алалар, таныш юлларына чыккач, Бариның бу сәләтенә исләре китеп сөйләнә-сөйләнә тамак ялгарга утырышалар, ә Мәчтүрә апай:

— Гәүдәсе минеке, зиһене әтисенеке шул аның,— дип, Бариның мактарга тотына...

Икенче көнне урманга бармыйбыз. Тын алабыз, хәл җыябыз. Барилар җыйган җиләкләрен бездән уналты-унҗиде чакрымдагы тимер юл станциясенә илтеп саталар. Монысын Бариның бердәнбер апасы Мәдинә эшли. Мәдинә апа үзе Глазов дигән зур кала җирендә укый, фельдшер булырга әзерләнә. Җәйләрен ял итәргә өенә кайта. Хәер, кая ул монда ял! Дөрес, ул безнең белән урманга бармый, өйдә әтисе янында кала. Бик барыр иде дә, җиләкне бик жыешыр иде дә, озынборыннардан курка. Шул әрсез бөҗәкләр сарып алып, бер тешләргә-имәргә тотынсалар, Мәдинә апаның минутында бите-йөзе, беләк-балтырлары бүртеп чыга. Димәк, ярамый аңа. Үзе ул шундый чибәр, шундый сөйкемле: бит урталары янып пешкән алмадай, күз-кашларына шомырт карасы иңгән, куллары шундый йомшак, нәфис, моның өстенә тагы, тез асларына тиклем җиткән калын-калын ике толымы да бар.

Ул таң тишегеннән тора да, әнисе белән энесе җыеп алып кайткан җиләкне, кәрзиннәре-ниләре белән иңбашларына көянтә итеп асып, станция юлына чыгып китә. Озын чәч толымнарын тирбәлдергәләп, нечкә билләрен сыгылдыра-сыгылдыра кәз-кәз атлый ул... Озакламый укуын тәмамлап, фельдшер булырга йөри, шулай булгач, кеше арасына кимсенмичә барып керер өчен, өс-башын юнәтергә кирәк түгелмени аңа?

Ә без җиләкне сатмыйбыз, бездә бүтәнчәрәк эш итәлә: алып кайтканның икенче көнендә әнием, олы мичне ягып, как коярга яисә җиләкне киптерергә тотына. Кышын аның монысы да тансык бит, инде бик интеккәндә, базарга чыгарсаң, акча... Безнең алай станция юлларында йөрергә кешебез дә юк. Әтием көне-төне сельпо эшендә, товар ташый, ике сеңелемә эш кушарлык түгел әле — аларның бар кайгысы курчакчүпрәктер, ә бердәнбер әбиебезнең андый сәфәрләрдә йөрергә җегәре дә, теләге дә булмаганын, үзе ярып әйтмәсә дә, беләбез.

Ә тегеләрнең эше көйләнгән. Мәдинә апа сатып алган нәрсәләр турында әйтмим дә, бер заман минем дусым Бариның аягына шыгырдап торган күн итек, өстенә әллә нәрсә тиресеннән теккән һәйбәт якалы, бумази тышлы — кыскасы, патша малайлары көнләшерлек бишмәт кидермәсеннәрме! Ул да түгел, әтиләре Гыйлаҗ агайның такыр башына күз явын алырлык кара бәрхет кәләпүш тә менеп утырды.

Сугыш алды елларында колхозларның кодрәтле чагы, урак өстендә авылыбыз халкы ябырылып басуга эшкә чыга, чөнки бик күпләр, урман-сазлыкларда, хода биргән нәрсәгә өмет итеп, эзләнеп йөрүгә караганда, үзләре тир түгеп эшләп алганны, ягъни ишек алларына йөкйөк булып кергән ашлыкны артыграк күрә. Бригадирлар, безнең ише җиләкче яисә гөмбәчеләргә кырын карасалар да, әлегә сүгенмиләрнитмиләр, хәер, без аларның күзләренә чалынмыйчарак, посып кына йөрибез, авыл Советы да бәйләнеп матәшмый. Тик әйтелгән көнне, әйтелгән сәгатенә басуга яисә ындыр табагына большевистик өмәгә чыга бел, совет эшеннән читләшмә...

Шулай итеп, без ике якка да өлгереп, әмма үз җаебызны күбрәк карап, үз ирегебездә, дөнья рәхәтендә кара урманнарның, яман исле сазлыкларның сукмакларын таптыйбыз да таптыйбыз... Шуңа күрә дә мин, дусым Бари яки аның әнисе, апасы турында гына түгел, авылыбызда бик күпләр өчен сәер һәм сер булып тоелган Гыйлаҗ агай турында да әллә ниләр беләм.

* * *

Ничә яшьләрдә булгандыр ул — кырык биштәме, илледә яисә илле биштәме — анык кына әйтә алмыйм, әмма карар кыяфәткә Гыйлаҗ агай шактый олы күренер иде: киң ияреннән асылынып төшкән каба сакал, чылгыйлары бөтерелеп торган хәтәр мыек, яссы маңгай астында бергә кушылып үсә язган яман да калын кашлар, һәм болар һәммәсе дә сумаладай чем-кара төстә, тик сакал-мыегында гына көмеш төкләр күренгәли... Мондый сакал-мыек безнең авылда беркемдә дә юк, карткорының җыенысында диярлек минем чәнти бармагымнан да нәзегрәк мыек белән кәҗә сакал гына... Җомга көннәрендә бездә уздырыла торган базарга кыяр-суган, кишер-шалкандыр сатарга килеп йөрүче Ләксәй дәдәйдә генә андыйрак сакал-мыек бар, әмма аныкы кара түгел, җирән...

Гыйлаҗ агай безнең Кәкре Наратта туып үсмәгән, каяндыр Пермь якларыннан килгән, дөресе, гражданнар сугышы бетеп барганда, Мәчтүрә апай читтә йөргән җиреннән ияртеп кайткан аны. Шуңа күрә авылыбызның яман телләре:

— Мөселман татарыннан тумагандыр ла ул. Урыс дияр идең — охшамаган... Нәсел-нәсәбе чегән булырга тиеш аның,— дип сүз болгатырга яраталар.

— Язгыннан курыкмыйча, ник алай дисез? — дип сораганнарга теге тел бистәләре:

— Ә күзләрендә татар нуры бармы соң? Бармы соң?! — дип, тагын бөтенләй чүп нәрсәне дәлил итеп, бәйләнергә тотыналар...

Я инде, күз нуры да тегенеке яки моныкы дип аерымланып йөртелсен, имеш...

Аның чи татар икәнлеген күрсәтеп торган бик тә әһәмиятле бер сыйфатын әйтмичә ярамас: ул, авылыбызның бүтән агай-энесе шикелле үк, чәч үстерми, башын тап-такыр итеп кырдырып йөртә. Өс киеме тагы: озын җиңле, кысынкы җилкәле кәзәки, тар балаклы чалбар, аякларында киез ката яисә кәвеш булыр, урамга уң кулына йомры башлы шомарып беткән таяк тотып чыгар. Авылыбызның карт-корысы да нәкъ шулайрак итеп йөри ләбаса... Инде бу да җитмәсә, Гыйлаҗ агайның тәкъвалыгы тагын. Ярый, монысы хакында соңрак...

Үзенең кемлеге, каян, ничек килгәнлеге — гомумән бөтен язмышы хакында Гыйлаҗ агай мәчет чатында яисә кибет алдында ләчтит сатып утыручы авылдашларына, мөгаен, бик рәхәтләнеп, бик тәмләп сөйләп бирер иде дә, булдыра алмый шул...

Бөтен бәла шунда: телсез ул. Туры мәгънәсендә телсез. Улы Баринең ипи белән ант итеп сөйләвенә караганда, Гыйлаҗ агайның телен, пленга эләккәч, сер бирмәгәне өчен, колчакчылар кисеп алганнар. Шуңа күрә сөйли дә, сөйләшә дә алмый ул. Бик теләсә дә... Тагылган кушаматы да шуңардан... Кулында акка кара белән язылган берәр документы булгандырмы-юкмы, белмим, әмма аның сугышта кылган батырлыгына авылыбызда берәү дә шикләнеп карамый. Аның бит теләсә нинди документларыннан да көчлерәге бар: күкрәген йолдызлы җәрәхәт бизәгән һәм — аннан да бигрәге — өендә кылыч тота. Ул кылыч аларның стеналарында төрле чәчәкләр чигелгән чүпрәк келәмдә эленеп тора. Аның янәшәсенә Бари «пертүпәй» дип атаган бил һәм

җилкә каешлары эленгән тагы. Кылычның сабындагы ялтыравык тимер кисәгенә бик матурлап, уеп, Гыйлаҗ агайга сугышта зур батырлык эшләгәне өчен гомерлеккә бүләк ителүе хакында язылган. Хәтта нинди полк штабы икәнлеге дә куелган... Авылыбызда тагын кемдә бар мондый нәрсә, тагын кемгә чын сугыш коралын өендә тотарга рөхсәт ителгән? Юк бит алар.

Бари ничектер, әмма мин, үз этиемнеке булмаса да, әлеге кылычка кул тидереп алсам, дулкынланудан әллә нишләп китәм һәм Гыйлаҗ агайның кара сакаллы кырыс йөзенә сокланып карыйм...

* * *

Авылыбызда Ады-адының сугышта күрсәткән батырлыгына шикләнүче юк дигән идем. Булган икән...

Бер көнне кич соң гына Барилардан кайтып киләм. Мәчетне узып, пожарный турысына җитсәм, ни ишетим, тегендә, пожарный эчендә, кемнәрдер шаркылдашып көлешәләр. Арада малай-шалай тавышы да ишетелгәндәй булды. «Әһе, мәйтәм, Заһидулла абзыйның әкият капчыгы тагын чишелгән икән, тагын җыелганнар икән», дим. Әкият тыңларга үлеп яратам мин. Түзмәдем, тычкан утына карап борылдым. Көз башының җилле һәм ямьсез бер киче иде. Ишекне шыпырт кына ачып кердем дә бер почмакка барып постым. Тар, тәбәнәк түшәмле бүлмәдә ярым караңгыда кешеләрне танырлык түгел, шулай да абайладым: минем яшьләрдән берәү дә юк. Пожарник Заһидулла абзый белән Хәкимҗан агайдан кала барысы да никрут егетләр. Кайсы сәкедә аяк бөкләп утыра, кайсы идәндә буш стена буйларына чүгәләгән. Колак салып, тыңлап карасам, сөйләгәннәре җыен тузга язмаган вак-төяк нәрсә. Эчем пошып чыгып китим дигәндә генә, түр сәкедә тәрәзәгә табанрак кырын яткан Хәкимҗан агай:

— Әһә, авыл Советында да тычкан уты кабынды... Ай, рәхәт тә соң бу Ады-адының эше: каравылда ялгыз башы, тыныч колагы. Бер кем мишәйтләми,— дип куйды.

Гыйлаҗ агай, алган пенсиясе өстенә иш янына куш булыр дип, байтак еллардан бирле авыл Советында каравылда тора иде. Мин алардан чыгып киткәндә, кечке биләмгә урамга сызарга торган Барины сабагына утыртып, үзе каравылына барырга җыенып калган иде.

— Таптың кызыгыр кешесен... Менә безнең күк авыз тутырып сөйләшеп тә утыра алмагач, әллә рәхәттер дисеңме аңа! — диде Заһидулла абзый, Хәкимҗан агайга төрпәрәк бер караш ташлап, һәм сүнгән трубкасын суырырга тотынды.

— Аның каравы, мәшәкате кимрәк. Телефоннан шалтыратсалар да, исе китми: «ады-ады» ди дә бетте китте, вәссәләм! Каладагы башлыклар да белеп бетергән инде, шуңа күрә төннәрен шалтыратып маташмыйлар да...— дип кеткелдәде Хәкимҗан агай, кәҗә сакалын учлап.— Колагын телефон трубкасына куя да тик тыңлап утыра радионы. Дөньядагы бар хәбәрне белеп тора, ичмаса... Пожарга чабасы да юк, безнең күк труддингә дә исе китми, акча сугып тик утыра... Рәхәт булмый ни!

Стена буена чүгәләгән никрутлардан берәү кепкасын чигәсенә таба янтайтып батырды да Хәкимҗан агайга күзләрен тасрайтып:

— Ә сиңа монда рәхәт түгелме? Пожар дип бик исең китте инде! Арба күчәрләрен майлап-нитеп торсаң, мичкәләрең тишек булмаса, атларны вакытында ашата-эчертә белсәң, шуннан ары ни кайгың бар? Ә пожарда син аяк астында буталудан бүтәнне белмисең дә,— диде һәм мыскыллы көлемсерәп ике аягы арасына идәнгә төкерде.

Монысы чын-чынлап хак сүз иде: Хәкимҗан агай, янгын чыга-нитә калса, артына ут капкан шикелле, кәкре аяклары белән яман чатан-

лый-чатанлый, бер тиен файдасызга бугазын ертып, халык арасында буталып тик йөри. Бер мәлне аның насосына хәтле көйләнмәгән булып чыкты, һәм ярсыган халык аның үзен чак кына утка салмыйча калды. Ләкин никрут абый әйткән сүзләргә Хәкимҗан агай мыек очын да селкетмәде, тәрәзәдән авыл Советының тонык утына караган шәйгә:

— Тел сөяксез лә ул, ни лыгырдамас,— дип кенә куйды. Аннары, бер кавым тын торгач, ярым пышылдап шыңгырдарга кереште: — Тел дигәннән ни... Шикләндерә әле мине. Имеш, аклар кисеп алган, ди. Булмастыр ла. Андый явызлыкка барырмы соң адәм баласы? Ат өстеннән егылып төшеп, телен тешләгәндер яки анда тел очына чуан чыга башлагандыр да, духтырлар...

Мин, үз-үземне белешмичә: «Аклар кисеп алган шул! Гыйлаҗ агай батырларның батыры ул!» — дип акырып җибәрмәкче булдым, ләкин, сулышыма буылгангамы, тамагымнан аваз чыкмады...

Ә Заһидулла абзый тегеңәргә әйтеп бетерергә ирек бирмәде, кәкре башлы имән таягы белән идәнне дыңгырдатып аңа җавап кайтарды:

— Тфу диген! Авылыбызның бер изге җанына тел тидерәсең, иблис токымы! Телен кисеп алуларына ышанмасаң, көмеш язулы кылычны тикмәгә биргәннәрдер дисеңме? Ә күкрәгендәге кызыл йолдызы? Ишеткәнең бармы, кемнең тагын күкрәк тиресен бизәгәннәр йолдыз белән, ә?!

Хәкимҗан агай, очлы ияген алга таба сузып:

— Ә синең Гыйлаҗ күкрәгендәге ул йолдызны үз күзең белән күргәнең булдымы? Ә минем юк! — дип чинап җибәрде.— Бәлкем, анысы да... болай гынадыр.

Шул мәлне Заһидулла абзый, чепи күзләрендә ялкын кабындырып һәм җәйрәп утырган җирендә авыр кузгалып, кулындагы таягын югары күтәрде. Мин аны теге кәҗә сакаллы чатан агайның башына бик шәплән кундырыр инде бу дип көткән идем. Ләкин Заһидулла абзый алай итмәде, калтыранган тавышы белән:

— Сиңа, миңа ишмени ул!.. Син ни акларга, ни кызылларга кушылмыйча, мич башында хатыныңның итәге астында посып яткан чагында, кеше кан коеп йөргән, телсез калган, кылыч астына күкрәген, йөрәген куйган...— дип, Хәкимҗан агайга бик нык ачуы килеп, кызып сөйләп китте. Миңа хәл кергәндәй булды, әмма шулай да, гарьлегемнән күз төпләрем чыланган килеш, пожарныйга бүтән аяк атламаска булып, күзгә караңгыда өйгә кайтып киттем.

Гыйлаҗ агайның күкрәгендәге чи кызыл йолдызга ышанмасыннар әле!

Ә мин ул йолдызны бер генә күрмәдем, хәтта бармагымны тидереп караганым да булды.

Пожарныйда ишеткәннәремне мин, әлбәттә, Барига әйтмәдем. Нигә инде дусыңны тиктомалга рәнҗүгә салырга? Әтисенә дә тишеп куйса тагы...

Шуннан миңа бер уй килде. «Тукта, мин әйтәм, Хәкимҗан агайның төпчек малае Садрины үзебез белән иярттергә кирәк», дим. Садри ул бездән бер генә класска югарырак укый. Әтисе шикелле үк кәкре аяклы булганга, чатанлабрак йөри. Әмма бик үткен нәрсә. Безнең арада баш булырга тырыша. Караңгы төшеп, дөнья тынычланып калгач, берәрсенең алма бакчасына керү яки колхоз яшелчәлеген басу кебек хәтәр эшләрдә ул — безнең юл яручыбыз. Базарга сату итәргә килгән Ләксәй дәдәйнең капчыкларын үткен пәке белән ярып, шалкан чәлдерүдә дә аңардан оста, аны уза алган малай юк. Тик шул ягы яман шайтанның: тел бистәсе булганга күрә, төкерекләрен чәчә-чәчә тузга язмаган нәрсәләр сөйләп, аптыратып бетерә.

Бер көнне дәрестән чыгуга, мин Садрины бер кырыйга алып киттем дә, сүзне кыек-мыеклатып тормыйча:

— Без бүген Ады-ады белән мунча керәбез. Аның күкрәгендәге йолдызны бик күрергә теләсәң, әйдә! — дидем.
Моның очлы иякле тар битe шундук җәелеп китте:
— Кемнәргә килим, сезгәме, Бариларгамы?
— Безгә кил. Мунча бит безнеке,— дидем мин эре генә.
Мунчага чит бер малайны да ияртүебезгә Гыйлаҗ агай ачуланмады, тик бераз сәерсенгән кебек башын гына селкеп алды. Мунча җене кагылган бәндәләрдән ул безнең Гыйлаҗ агай. Ул хуш исле каен саберкесе белән чабынган чагында, Мәчтүрә апай әйтмешли, зил-зилә бураннары уйнап тора. Аңа тагылып йөргәнгә күрә, Бари белән мин дә үзебезчә чаж-чож чабынып азапланган булабыз. Ә Садри чабыну дигән нәрсәне бөтенләй яратмый икән. Мунча мичennән чыжлап-выжлап эссе болыты күтәрелгән чагында ул, каш-күз җимереп, тупса янынарак идәнгә сузылып ятты. Ләкин аңа алай ансат кына котылырга язмаган икән. Без, Бари белән мин, ләүкәдә кирәк кадәренчә селтәнгәләгәч, мукәйләп мунча алдына чыгып барганда, Ады-ады безгә иярергә торган Садрины, аяк-кулларыннан эләктереп, ләүкәгә җилле генә сузып салмасынмы? Менә сиңа эссенең шәбе, менә сиңа каен себеркесенең иң татлысы!.. И тотынды Садриебыз чинарга, и тотынды бакырырга — чучка суялармыни! Ә Гыйлаҗ агай колагына да элми, гүя ул пожарныйда Хәкимҗан агайның ниләр лыгырдаганын ишеткән дә хәзер менә шуның үчен малае Садридан ала иде...
Ниһаять, мунча ишеге ачылып китте, һәм Садриебыз, ухылдап-чинап, безнең янга да тукталмыйча, бакчага атылды. Без шаркылдап көлеп җибәрдек. Ә ул, кишер төсле кызарынган Садриебыз, баш өстеннән умарта кортларын кугандай селтәнгәләп, бакчада әрле-бирле йөгергәләде дә чатанлый-чатанлый инешкә табан элдертте. Инде сентябрь бетеп килә, салкынча вак яңгыр сибәли иде. Без шәп-шәрә килеш тышта чабып йөргән иптәшебезгә:
— Әй, кызлар күрсә, рисвай буласың бит!
— Инде хәзер чабынмыйбыз, юынабыз-коенабыз да чыгабыз, әйдә кил, йөрмә анда,— дип дәшеп алдык.
Мунча идәнендә кара-каршы утырышып юынган чагында, Садри, үз ахмаклыгы үзенә үк көлке тоелып, ахрысы:
— Минем үз гомеремдә беренче тапкыр бит әле бу... Әкәмәт кызык икән! — дип пырхылдап җибәрде.
Бари да, мин дә, аңа кушылып, көлешеп алдык, Гыйлаҗ агай исә:
— Эһәй-эһәй! — дип, бик ягымлы төстә каш кына сикертте.
Шул чакны, ни күрим, Садриебызның йөзе-кыяфәте үтә җитдиләнеп, утлы күз карашы Гыйлаҗ агайның киң күкрәгендәге бурлат йолдызга кадалды да калды...
Шуннан соң ни? Шуннан соң мин инде суына төшкән сукмагымны яңартып, янәдән пожарныйга ат эчерергә яисә кичләрен, өйдән ычкына алсам, әкият тыңларга йөри башладым. Ләкин ничә барсам да чатан Хәкимҗан агайның Ады-ады турында бүтән сүз кузгатканын ишетмәдем. Димәк, Садри аңа мунчада күргәнен әйтмичә калмагандыр. Монысы бик әйбәт булды.
Ләкин минем күңел һаман да тынгылык таба алмады. Ярый, авылыбызда Ады-адының батырлыгына шикләнеп караучылар калмады, ди. Ләкин гражданнар сугышында ул нинди батырлык эшләгән, аның телен кисеп алулары, күкрәк тиресен умырып, йолдыз ясаулары ни өчен һәм ничек булган? Менә болар хакында ялгансыз-нисез, төп-төгәл беләсе килә бит...
Дөрес, Бари әтисе турында бер генә сөйләмәде. Әмма аның авызыннан ни чыкмас? Баш әйләнерлек нәрсәләрне борчак урынына сиптерә дә тора бит ул.

Авылыбызда Ады-ады турында чын дөресен сөйләп бирердәй кеше — бердәнбер Мәчтүрә апай. Ул да бит, ут эченә үк керергә туры килмәсә дә, гражданнар сугышының бер читендә азмы-күпме катнашкан. Ире Гыйлаҗ агай турында барын да ул гына текмә-тек белә, диләр... Ләкин Мәчтүрә апай безгә тел сүтеп утырырга теләрме, вакыты булырмы? Аның һәрчакны эше муеннан була бит: көндезләрен дежур тора — безгә дәрескә керергә, дәрестән чыгарга звонок бирә,— ә класслар бушап калгач, без туздырган, без пычратка户ннарны җыештырырга тотына. Моның өстенә тагын өендәге эшләре... Аннан килеп, аның да, бик күп бүтән апалар шикелле үк, кичләрен күрше-күләндә кабада сүс яки йон эрләгәндә, тәмләп сагыз чәйни-чәйни, ләчтит сатып утырасы килмимени?

Шулай да, көтә торгач, монысының да бик әйбәт бер җае килеп чыкты...

* * *

Бер вакыт, кышка кереп, чана юллары төшкәч, авыл Советының ишек алдына унмы, уникеме йөк шыңгырдап торган каен утыны китереп аудардылар. Авыл Советы елның елында ул утынны яллап кистертә. Бу юлы Гыйлаҗ агай бер каен утынына, бер үзенең беләкләренә күрсәтеп:

— Ады-ады,— дигән.

Авыл Советы председателе Сәетгәрәй абыйның аптырабрак калуын күреп, өстәлендәге кәгазь кисәгенә: «Үзем кисәм, читкә бирмә», дип язып та куйган. Искечә, ягъни гарәп хәрефләре белән бик шәп укый да, яза да белә иде ул Гыйлаҗ агай.

Сәетгәрәй абый, авызын ерып, шундук риза булган. Шуннан соң ябыштылар болар. Бари дәрестән чыгу белән төшке ашларын ашыйлар да китәләр. Мәчтүрә апай белән Бари, әниле-уллы, кисә, ә Гыйлаҗ агай алар кискәнне, чикләвек ваткандай гына итеп ярып, өеп бара. Кайчакларда Мәчтүрә апай үз эшенә мәктәпкә ашыкканлыктан, болар аталы-уллы икәү генә дә калгалыйлар.

Бер көнне шулай урамнан, дусым Бари юклыкка пошынып, каңгырап барган чагымда, каршыма Садри очрады. Кулына кәшәкә таягы тотып, юлда катып яткан йомры нәрсәләрне бәргәләп йөрүе. Күренеп тора: уйнарга иптәше юк. «Шәп булды әле моның очравы, ичмаса, бераз уйнап алырбыз», дип куандым мин үзем дә. Ләкин уенны башлап җибәргәнче, Садри, кәшәкә таягын иңбашына салган килеш, миңа каш астыннан гына карап:

— Ә ник үзең генә бүген? Агылыең кайда? — дип сорап куйды.

— Ычкына алмый әле. Эше муеннан,— дидем мин һәм Бариның кайда, нишләп ятканлыгын аңлатып, уфтанып алдым.

— Һе, алайса, әйдә йөгер, үзең өчен дә, аның өчен дә! — дип, аяк астындагы йомрыны ат юлы буйлата тәгәрәтеп җибәрде бу.

Юк, мин ул бәреп тәгәрәткән нәрсә артыннан йөгермәдем. Чөнки шул мәлне зиһенемә капылт кына бер уй килеп төште. Уй килеп төште дә Садриның таягыннан тотып, әллә пышылдап кына, әллә кычкырып ук әйтеп салдым:

— Карале, Садри, монда тик йөргәнче, әйдә барып булышабыз үзләренә!

Нәзек муены шундук җилкәсенә батты моның:

— Әй лә... Әни дә озак олагып йөрмә дигән иде...

Ләкин мин аның таягын кулымнан ычкындырмадым. Авызымны кыйшайтып, зәһәр мыскыл белән йөзенә текәлдем:

— Барып булышсам, кулым черер дип куркасыңмы әллә? Эх сине! Дус булып йөргән буласың тагы!

Иң шәбе шул. Садрием бер ара гына ык-мык итеп торгачтын:

— Ярый алайсам... Дуслык хакына дисәң генә инде,— дип, инбашларын турайтты.

Киттек.

Авыл Советының ишек алдына барып керүебез белән үк, икебез бер авыздан, олыларча иттереп:

— Алла куәт бирсен сезгә! — дидек.

Бари дәү бияләенең баш бармагын авызына капты, Ады-ады бөгелгән жиреннән гәүдәсен турайтты да каба сакалына ябышты, ә Мәчтүрә апай, станга салынган каен кискәсенә таянган килеш, кояштай балкып:

— Әйдүк, оланнар! Матур сүзегезгә рәхмәт! — диде һәм тигез кашларын уйнатып алды.— Менә бит ходай булышчыларның нинди шәпләрен жибәргән!

Без дә төшеп калганнардан түгел, бик тә эшлекле кыяфәт белән:

— Әйе, булышырга дип килдек.

— Аз булса да ярдәмебез тияр,— дидек.

Куанычлары йөзләренә бәреп чыкты. Барины әйтмим дә — аның ерык авызына бияләй тыгарлык иде. Гыйлаж агай хәтта:

— Ады-ады,— дия-дия аркабыздан каккалап алды.

Без, Садри белән мин, шундук ике куллап пычкыга ябыштык. Бари каен кискәсенә менеп атланды, ә Мәчтүрә апай ваклап туралган утынны өяргә кереште.

Бергәләп тотынсаң, эш берәгәйле була инде ул: кичке караңгы төшкәнче, без утынның калган хәтлесен кисеп-ярып, әрдәнәгә өеп тә куйдык — вәссәләм!

Һәм менә без хәзер Бариларның җылы өендә табын артында утырабыз. Тай ите салып пешергән бәрәңге исе борыннарны яра, каршыбызда чиләк ярым сыешлы ак самовар чыжлап утыра. Утын кискәндә дә сынатмаган идек, ашаганда бигрәк тә... Садри кай арада, тәмле ит калҗасын чәйнәргә дә онытып, стенадагы чәчәкле келәмгә эленгән кылычка карап ала. Сизәм мин: көмеш язулы кылычкайны җылы кулына тотып, селтәнеп карыйсы килә аның... Юк, ашыкма, дускай, алай ансат кына тәтеми ул... Ә хуҗа үзе, Гыйлаж агай, тәмле итле бәрәңгене аннан-моннан гына капкалады да чәйгә ябышты. Үлә ул такта чәй дип — кояштыр, җанын фида кылырга риза. Бер мәлне, мунчадан чыккач, юри санап утырдым, Гыйлаж агай унҗиде чынаякны каплады да куйды, исе дә китмәде, тик азактан «уф» диеп, авыр иттереп сулап кына алды. Ә без, ни хәтле тырышсак та, сигез-тугыз чынаяктан арттыра алганыбыз юк. Ләкин бу кичне Гыйлаж агай безне ярыштыра-ярыштыра чәй эчертмәде, үзе дә җиде-сигез чынаякны гына бушатты да каба сакалын сыпыргалап дога кылды. Аннары тавыш-тынсыз гына безнең аркалардан сөйгәч, сәке башына китеп, кун сумкасына бәрәңге тутыра башлады. Димәк, каравылына ашыга... Ә бәрәңгесе нигә дисәгез, галәмәт ярата ул көлдә тәгәрәткән бәрәңгене, авыл Советының мичен шуның өчен генә яга, диярсең.

Ул чыгып киткәч, без дә табын артында озак утырмадык. Мәчтүрә апайга рәхмәт әйтә-әйтә, чынаякларны каплап куйдык та иякләребезне сыпырып алдык. Шул чакны, ни ишетим, Садри дусым, мин һич уйламаганда кисәк кенә:

— Мәчтүрә апай... Син ни... теге... Гыйлаж агайның әнтерә кылычы... Ул кылычны ни өчен бүләк иттеләр аңа? Аннан тагы күкрәгендәге йолдызы да... Шулар турында син безгә сөйли алмассыңмы, ә? — дип, пышылдап кына сорап куймасынмы! Табын артында тикмәгә генә муен боргалап, тирән-тирән сулаштыргалап утырмаган икән!..

Мәчтүрә апай, барыбызга да күз йөртеп чыккач, көлемсерәп кенә каш сикертеп алды:

— Ә нигә, Бариның сөйләгәне булмадымыни сезгә?

— Булса да... ул бит... ул бит...

Мин, Бари дусыбызны бөтенләй чупкә чыгарып ташламас өчен, аннан да бигрәк үземнең күңелем кытыкланып киткәнгә, Садрига ярдәмгә ашыктым:

— Бари ул һаман да әйтә: «Әти турында безнең әни генә текмә-тек белә» ди...

— Алар мин сөйләгәнгә бик ышанып та бетмиләр әле. Я инде, ялындырма инде, бер иркенләп сөйләп бир инде, әни,— дип, башын кыңгыр салып пышылдады Бари да.

Без тыннарыбызны кыстык. Елтыр күзләребез Мәчтүрә апайга төбәлде. Ә ул, өстәлдәге чынаякларны бер төшкәрәк өеп куйгач, кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә:

— Шулай дисезме? Ярый алайсам,— диде һәм бер арада уйчанланып торгач, юка иреннәрен чак кына кыймылдатып, әйтә куйды: — Анысы дөрес, текмә-тек белүче мин генә шул... Заманасында шул сугышта катнашкан бер иптәше барын да сөйләп бирде миңа. Аннан ары, госпитальдә яткан чагында Гыйлаж агаегыз, язып кына булса да, аз-маз төшендереп азапланган иде. Ул чактагы бер гәҗиткә дә язганнар иде аны... Әйем, сандыкны актарып, иң әүвәл шуны күрсәтием әле үзегезгә...

Без, өч кыбырсык малай, лампа филтәсен күтәрә төшеп, сандык тирәсенә идәнгә утырыштык. Мәчтүрә апай да, кулына зур ачкыч тотып, безнең янга тезләнде. Бер мизгелдән сандык йозагы матур музыка уйнап алды.

Ниһаять, җитте татлы, бәхетле минутлар...

Бариның миңа ул газет турында әллә ничә тапкыр әйткәне бар иде. Алдашмаган икән. Менә ул дүрткә бөкләнеп, чит-читләре ертылгалаган саргылт газет кисәге... Мәчтүрә апай идәндә аяк сузып утырган җиреңдә аны җәеп салды да бик пөхтәләп сыйпаштыргалап алгач, бармагын кәкре-бөкре хәрефләр өстеннән йөртә башлады. Әмма апайның борын өстендәге күзлеге дә, без урындыкка күчереп утырткан лампа да ярдәм итмәде, ул адым саен төртелә иде.

Бераз азаплангач, ул башын күтәрде дә гаепле кеше сыман моңсу гына келемсерәп:

— Элегрәк әйбәтрәк укый торган идем. Ярый, оланнар, телдән генә сөйлим инде. Минем бит барысы да хәтердә,— диде.— Ах, искә төшерүләре генә!..

Аның күз төпләрендә ике яшь бөртеге ялтырады...

Мин дә менә, Мәчтүрә апайның ул кичне сөйләгәннәре барысы да төп-төгәл хәтеремдә ныгып калмаганга күрә, күңелемә сеңгән хәтлесен үз телем белән генә хикәяләп бирим инде сезгә...

* * *

Вятка елгасының түбәнге агымында унтугызынчы елның язында була бу хәл.

Бирге якта кызыллар, аргы якта аклар, уртада бозлары куерып һәм шарт-шорт ярылгалап торган елга агып ята. Табигать кемгә булышырга кирәклеген бик әйбәт шәйләгән кебек: акларның кара үлем чәчеп килгән юлларына үтә алмаслык киртә салган... Инде хәзер һәр ике як дәһшәтле һөҗүмгә әзерләнә: аклар, Казан — Мәскәүләрне алып, Советларны буып ташлар өчен, кызыллар, җир өстенә хөррият байрагын кадау өчен, кара көчләрне мәңгегә себерергә дип... Илнең пычакка пычак килеп ике өлешкә бүленгән чагы... Ә күктә ягымлы, алтын нурлы кояш — дөньяда исерткеч яз...

Әнә шул дәһшәтле һәм исерткеч матур көннәрнең берендә Мамадыш каласының зур бер сәүдәгәрендә, асрамага алынып та, асралмыйча,

кара хезмәтчегә әверелгән Мәчтүрә апа, ул чагында әле буй җиткезеп, өлгереп килгән ятим кыз бала, чем-кара мыеклы, көләч карашлы, елгыр хәрәкәтле бер кызылармеец белән таныша. Танышып та ала, моеннан гашыйк та була. Теге дә шулай... Үзе яшь кенә булса да, шахта базларында да эшләп алырга өлгергән, герман сугышында ут эчендә дә булып кайткан, ул да түгел, Вятка каласының үзендә губернатор хәтле губернаторны бөтен өере белән кулга алуда катнашкан. Шунда инде ул атаклы Азин отрядына килеп кушылган да, ди... Үзе, җитмәсә тагы, мөселманча ару гына укый-яза да белә икән. «Бәхеткәем шушыдыр инде минем»,— дип уйлый Мәчтүрә кыз-бала. Ничә кат очрашканнардыр, ничә күрешкәннәрдер, әмма вәгъдәләрен бик шәпләп ныгыталар болар. Күз алдында туплар шартлаганда, алдында ут өермәсе бөтерелергә тотынганда, озакка сузып буламыни андый эшләрне?

— Мин Колчакны кырып ташлыйк та кайтып алырмын мин сине,— ди егет.— Көтәрсең, яме! — ди.

— Көтәрмен... Гүремә кергәнче көтәрмен,— дип ышандыра чишмә суыдай саф күңелле кыз.

Ул арада мәһабәт Вятка, бозларыннан арынып һәм хәтәр зур ташу булып, күз күреме җитмәс болын-тугайларны, әрәмә-урманнарны басып ала. Мондый дәрьяны халыкның әллә ни гомерләр инде күргәне булмый. Ә яз һаман кыздыра, яздан бигрәк фронт хәлләре кыздыра: кызыллар, йодрыкларын йомарлап, хәлиткеч һөҗүмнәрен менә-менә башларга тиешләр...

Гыйлаҗ-сугышчының эскадронын каядыр елга буйлап күчерәләр, әмма ул сөеклесе Мәчтүрә апайга:

— Һөҗүм алдыннан бер күрешеп, бәхилләшеп китәрмен әле,— дип ышандыра.

Көтә кыз, көтә, инде дәһшәтле һөҗүм дә башланып китә. Ә егет юк та юк. Таза-сау килеш күрергә насыйп булмаган икән шул аңа сөйгән егетен...

Ә Гыйлаҗ-кызыл көрәшче мондый хәлләргә дучар була. Һөҗүм башларга бер-ике көн калып килгәндә, бер мәлне моны һәм моның бер иптәшен полк штабына чакыртып, гаять әһәмиятле һәм куркыныч йомыш кушалар:

— Менә сез икегез дә безнең иң кыю сугышчыларыбыздан... Сез дошман тылына чыгып, аның оборонасын тикшереп кайтырсыз: кай төштә ныграк, кай җирендә йомшаграк, туплары, пулемет ишесе күпме, гаскәре ни хәтле,— диебрәк...

— Беренче кат түгел, сынатмабыз,— ди болар.

Шуннан, җиде төн уртасында бәләкәйрәк кенә көймәгә утыралар да, тавыш-тын чыгармаска тырышып кына, елга аша китәләр болар. Су җәелгән киң болын һәм куе әрәмәлекләрне шыпырт кына үтәләр, аннары инде, кыр песиләре шикелле берни сиздермичә, биек ярга үрмәлиләр. Шулай итеп, ике дус, дошманның куены аша узып, артына ук барып чыгалар. Барып чыгалар да тотыналар исәнергә-күзләргә... Кача-поса әллә нихәтле җирләрен әйләнәләр, әллә никадәр нәрсәләрен беләләр. Күргәннәрен шундук кәгазь битенә төшереп, язып баралар. Кызыл көрәшче Гыйлаҗның иптәше дә үзе шикелле үк бик тә гаярь егет була. Саня исемле. Вятка ярында губерна каласының үзендә туып үскән эшче малае. Грамотасы да ярыйсы гына шәп булган. Менә шул егет инде күргән нәрсәләрен теркәп, язып барган.

Йөри-әйләнә торгач, болар бер чокыр буйлап зур гына рус авылы янына килеп чыкканнар да кырыйдарак торган әвенгә кереп посканнар. Әвеннең салам түбәсен тишеп, бик әйбәтләп күзәтеп яталар. Шуннан, ни күрсеннәр болар, авыл уртасындарак таш кибетләр, зур өянкеләр тирәсендәге мәйданда аклар ишшләптер ыгы-зыгы килә башлый: әллә туп өстериләр, әллә ни... Атка атланып чабучылар да күренгәли.

«Зуррак штаблары түгел микән шунда?» дип шикләнә болар. Саня түземсезләнеп кыбырсылый башлый.

— Барыйм әле, үз күзем белән карап, күзәтеп карап кайтыйм әле,— ди ул, кәгазен Гыйлаҗ дусына тоттырып.— Алай-болай булса, апкайтып төшендереп бирерсең,— ди.

Гыйлаҗ дусының моны җибәрәсе килми:

— Йөрмә, ди, кичкә тикле моннан карап та ни барын белә алырбыз,— ди.

Мылтыгын беләгенә салган килеш, әвен яныннан шуыша-шуыша китеп бара Саня. Ә Гыйлаҗ салам түбә ярыгыннан, йөрәген учына тотып, карап кала. Шуыша торгач, дусы арт бакчаларга барып җитә, этем дә сизми. Бер бакчадан икенчесенә, өченчесенә күчә. Шулай җайлы гына барган чагында, тыкрыкта торган бер ак солдат Саняны күреп алмасынмы... Күреп алуы була:

— Тукта, атам, тукта! — дип йөгерә дә башлый, аның тавышына әллә каян гына иптәшләре дә килеп чыга. Һаваны мылтык тавышлары гөрселдәтә.

Гыйлаҗ-күзәтченең йөрәге тибүеннән туктагандай була.

Ә Саня дусты, хәленең мөшкеллеген һәм бүтән чара юклыгын шәйләп, койма төбенә ята да үзе дә атарга тотына. Берне ега, икене, өчне... Әмма аны бакча эчләреннән төрле яклап кысрыклый башлыйлар, һәм егет алпан-тилпән килеп басуга таба элдерә. Анда ерак та түгел, тирән чокыр барлыгын һәм аның сыртларында вак чыршылар үсеп утырганын чамалаган, ахрысы. Әвенгә таба чапмас бит инде... Ләкин Саня әллә ни ерак китә алмый, дошман ядрәсе куып җитә, һәм егет, гәүдәсе кисәк сынган шикелле, чайкалып ала да: «Хуш, бәхил бул, дустым!» дигән кебек, һавада кул изәп, җиргә йөзтүбән капланып төшә... Аклар аның кесәләрен актарып карыйлар, аягындагы итекләрен салдырып алалар. Киткән чагында берсе, яңадан терелә күрмәсен тагы дип курыккангамы, егетнең гәүдәсенә штык чәнчә... Саня комлы басу битендә, якты кояш нурларын да сизмичә, япа-ялгызы ятып кала...

Ә Гыйлаҗ-көрәшче нишләргә дә белми. Ул инде күптән мылтыгын ак солдатларга төзәп, калтыранган имән бармагын мылтык чакмасына куйган. Тотынса, берничәсен шалт-шолт чүпләп кенә алыр иде югыйсә... Ярсынып иреннәрен чәйнәсә чәйни егет, шулай да ихтыяр көче җиңә, атмый. Саня дусты язып калдырган кәгазь кисәге ирек бирми аңа атарга...

Гыйлаҗ-күзәтче караңгы төшкәнен көтә хәзер. «Ничек тә үзебезнең якка алып чыгармын, монда ак бандитларга калдырмам сине, Саня дустым»,— ди.

Ләкин аңа кояш баеп, эңгер-меңгер таралганны көтәргә туры килми. Бер вакыт, ни күрсен, дустының гәүдәсе өстендә козгын бөтерелә башлый, ул да түгел, килеп тә куна.

— Дустымның күк йөзедәй зәңгәр күзләре... күзләре,— дип пышылдый Гыйлаҗ.— Юк, бирмәм мин сиңа дустым күзләрен, бәдбәхет,— ди.

Әвеннән чыгып шуыша да башлый. Сугышчан дустының гәүдәсе өстендә кукраеп як-ягына карангалап торган козгын, моны күргә, каркылдап очып китә... Барып җитә Гыйлаҗ. Җитә дә дустының зәңгәр күзләрен йомдырып, читкә өстери башлый.

Яман кош козгынны куып җибәрә ул, әмма шул чакны аны тагын да явызрак, кансызрак козгыннар сагалап, көтеп торганнар икән...

Гыйлаҗ-күзәтче бер вакыт ат кешнәгән тавыш ишетеп, башын күтәреп караса, йөрәге жу итеп китә: тегеннән, авыл тыкрыгыннан, кулларында кылычлар елтыратып һәм баулар селкеп, биш-алты җайдак чыгып килә. Үлгән кызылармеецны ачык басу түрендә калдырып китүләре мәкерле ау кору булган, күрәсең...

Нишләсен, дустын ташлап, мылтыкка ябышырга туры килә моңа да...

Атлыларның бер-икесен шундук мәтәлдерә, әмма көчләр, ай-һай, тигез түгел, тегеләр инде хәзер бакырышып бөтенләй якынлашалар. Гыйлаж-күзәтче дә, дусты Саня кебек үк, вак чыршылы чокырга барып сыенмакчы булып йөгерә. Әмма артык ерак китә алмый, ике җайдак, ике яклап куып җитеп, өстенә элмәк ыргыталар. Терелэй тотып алырга теләгәннәр икән...

Аннан инде, таш кибет янындагы зур бер өйдә, аклар штабында, кансызланып сорау ала башлыйлар...

Күпме вакытлар җәфалаганнардыр, Гыйлаж-солдат белмәгән, хәтеренә сеңдерә алмаган. Арка тиресе суелып-телгәләнеп чыкканчы камчы сукканнар — эндәшмәгән, өстенә менеп таптаганнар — эндәшмәгән, күкрәк тиресен тунап, чи йолдыз ясаганнар — анда да эндәшмәгән, ахырда ярсуларыннан тәмам шашкан алтын погонлы җәлладлар кан эчендә аның жуеп ятучы кызыл сугышчының эндәшмәс телен кисеп үк алганнар... Тәнендә җаны ничек сакланып калгандыр?..

Җиде төн уртасында һушына килә бу. Астында юеш лайлалы идән, әйләнә-тирәсе дөм-караңгы, үзе анадан тума шәрә... Капшана-кармалана башлый. Куллары нинди-дер сәкеләргә, мич кырыйларына тиеп ала, аннары мүкле стенадан бәләкәй генә тәрәзә уентысы таба, ләкин ул тышкы яктан бик шәплән томаланган була. «Мунча икән» ди. Әйе, авыл побының караңгы төрмә базы ителгән ак мунчасы була бу...

Кармаланып, миченең казанын табып ала. Бәхетенә, казан төбендә аз гына су бар икән. Комсызланып эчә бу. Эчүенә бөтен авыз эченең уттай янганлыгын тоя, тик шул мәлне генә ярты теле юклыгын аңлап ала. Гәүдәсендә дә ватылмаган, авыртмаган төше юк. «Бетүем шушы икән»,— дип ачы сыкранып-сыкранып, калтыранып куя. Гәүдәсеннән дә бигрәк җаны әрни. «Шундый йомышны үти алмыйча китәргә туры килә бит, нәгъләт»,— ди. Тагын су эчеп, битен-башын чылаткач, бераз хәл кергәндәй була. Беләкләрендә җегәр дә бетмәгән икән әле, мунча миченнән саллы гына бер ташны кубарып ала. «Әҗәлемне тезләнеп тә, ятып та каршы алмам, аягүрә басып, берегезне дөмектереп китәрмен»,— ди. Шулай ди дә ишек катына ук килеп чүгәли. Көтә хәзер. Ә тегеннән, тыш яктан, ара-тирә ат пошкырган, кеше сөйләшкән авазлар ишетелгәндәй тоела. «Колчаклылар таң беленгәндә, кояш чыгар алдыннан атарга ярataлар, мәлгуньнар» дигән сүзләрне исенә төшерә Гыйлаж-күзәтче... Әйе, аңа озак көтәргә туры килми. Томаланган тәрәзә ярыкларыннан тоныкы кына яктылык сибелгәндә, тышкы яктан берәүнең аяк өстерәп килгәнен сизә. Сизә дә кулындагы корымлы ташны бар җегәре белән кысып, аягүрә баса. Шалтырап ишек бикләре ачыла, һәм караңгы мунча эченә кара револьвер тоткан кул сузыла. Ак офицер:

— Эй, кызыл сволочь, дөмекмәдеңме әле! — дип акырып та җибәрә, үзе шул мизгелдә, башы ярылып, капланып та төшә.

Гыйлаж-солдат, аның коралын эләктереп, ишек алдына атыла. Каян көч-җегәр килгәндер үзенә, җәһәт кенә болдыр төбендә торган атка менеп атлана һәм ишек бусагасында күренгән алтын погонлыга револьверыннан утлы сәламен калдырып, атның кабыргасына тибеп җибәрә...

Тоныкы таң яктысында, аклар аңга-миңгә килгәнче, урам буйлап җилдәй үтеп китә егет. Чем-кара ат өстендә канга баткан шәп-шәрә кешене күреп, өрәк дип уйлаганнардыр, ахры, тегеләр...

Ирек... Ирек... Ат та шуны белгәндәй, куе томанга өртелгән Вяткага таба җан-фәрманга чабуын гына белә. Биек яр өсләтә сузылган окоплар, тагын әллә нинди ныгытмалар аша да кош булып очып үтәләр. Аклар, акылларына килеп, дуамалланып ут ачканда, Гыйлаж-күзәтче түбәнгә, су баскан яшел әрәмәлекләргә житеп, томан эченде юк та була... Бәхетенә, атның шәбе эләккән, бәхетенә, мәрхәмәтле табигать су буйларын яңа сауган сөттәй йомшак томан белән каплап

алган... Шул атына тагылып, шул ук томан эчендә судан суга, утраудан утрауга үтә, аннары Вятканың үзен дә кичә. Ләкин үз якларына чыгуга, аягына басып, атына атланырлык хәле калмаган була, атын ычкындыра да, яр читенә чалкан яткан килеш, үзе турында хәбәр белгертү өчен, һавага атып җибәрә. Шул атуыннан аңын да җуя...

Полк лазаретында гына аңына килә Гыйлаж-солдат. Күзләрен ачып җибәрсә, янына полк командиры үзе килгән. Торып утырыр иде, хәле юк, башыннан кичергәннәрне сөйләп бирер иде — теле юк... Ә болар, кызыл командир да, бүтәннәр дә җибәргән күзәтчеләренең ни хәлгә дучар булганлыгын бер карауда ук аңлап алганнар.

Гәүдәсендә калган соңгы җегәрен җыеп, Гыйлаж-күзәтче ишарәләп кенә кәгазь-карандаш сорап ала да дусы Саня төшергән сызымны ясап, тырмап-нитеп булса да, акларның оборонасын аңлатырга тотына. «Менә монда туплары, менә бу төшләрдә пулемет, ә менә болайга тимер чыбыклы окоплар сузылган» дип... Сурәтен дә төшергәндәй итә, янына язып та куя. Шул күргән-белгән нәрсәләрен көченнән килгәнчә төшендереп бирүенә, егет янә һушыннан яза...

Икенче көннең таңында бөтен фронт буйлап башланган һөҗүмдә бу полк, елганы әйбәт кенә үтеп һәм артык зарар-югалтулар күрмичә, дошманның оборонасын өзә дә кара дәһшәтне, сулыш алырга да ирек бирмичә, үкчәсенә баса-баса, Урал тауларына таба куып алып китә.

Гыйлаж-сылу егет, сафтан чыгып, ятып кала...

— Яман хәбәрен ишетеп, лазаретларына барып керсәм, үзем дә һушымны югалта яздым,— дип, исенә төшереп утырды Мәчтүрә апай, сандыкка таянып, авыр сулый-сулый.— Исән дисәң, исән түгел, үле дисәң, үле түгел — үзе ап-ак кәфен эчендә ята... Тик нурлы күз төпләрендә яшь кенә елтырый... Яныннан китмәдем. Башта безне олау белән Кукмарага озаттылар, аннан инде тимер юлда Казан госпиталенә... Көннәрем төнгә, төннәрем көнгә әверелде. Йоклап китсәм, Гыйлаж-егеткәем җан бирер дип курыктым. Казан госпиталендә һаман да янында булу өчен, ялынып-ялварып санитарка-җыештыручы булып кердем. Шуннан башланып китте дә инде минем кәсеп... Ә ул көннәнкөн рәтләнә-сихәтләнә торды, үзенә мыек үстереп җибәрергә дә рөхсәт иттеләр хәтта...

Бу сүзләрне әйткәндә, Мәчтүрә апайның тавышы-сулышы беркадәр җиңеләеп киткәндәй тоелды.

— Ә кылычны кайчан, ничек бирделәр аңа? — дип сорады Садри, тоныклана төшкән лампа яктысында да стенадан нур чәчеп торган көмеш язулы кылычка карашын төбәгән килеш.

— Полк командиры үзе килеп бүләк итте... Менә ничек, оланнар! — дип җавап кайтарды Мәчтүрә апай, кыяфәтенә горур бер төс кертеп.— Аларның гаскәре Колчак яуларын Урал тауларының аръягына олактырган да тукталып калган. Имештер, иң зур командирлары Азин Колчакны бүтән яклап куып килгән икенче гаскәр командирына әйткән ди: «Себер урманнарында үзегез дөмектерерсез инде. Ә мин гаскәрем белән тагы да яманрак янарал Деникинны, капчыкка тыгып, Кара диңгездә батырырга китәм»,— дигән ди... Шуннан болар, пароход-баржаларга төялешеп, Кама — Идел буйлап төшеп тә китканнәр. Менә шул чакны, юл уңаенда, полк командирлары Казанга килеп чыккан да инде. Юри минем Гыйлажны күрер өчен... Госпитальне ничек эзләп тапкандыр. Кочаклашып күрештеләр. Кылычны да бөтен госпиталь кешеләре алдында бик тә хөрмәт күрсәтеп бирде. Барыбыз да җылаштык. Фамилиясе ничек иде әле ул кызыл командирның? Үзе төскә-биткә дә бик яшь иде. Әллә Чайкин, әллә Чаев, әллә... Юк, оныткanмын инде, җаннарым...

Хәзер уйлыйм менә: гражданнар сугышында Азин гаскәрендә бик яшьләй полк командиры булып сугышып йөргән, соңыннан маршал

дәрәҗәсенә күтәрелгән атаклы Чуйков булмады микән ул? Бик тә ихтимал... Ә ул чакны мин андый маршал буласын белми идем әле, тынымны кысып һәм сорау бирергә дә уңайсызланып, Мәчтүрә апайга йотылып карап утырдым.

— Әтине син әнә шул Казандагы госпитальдән алып кайткансың бит, неме? — дип сорады Бари. Ул сандык кырыенда әнисенә сыенып ук утырган иде.

— Әйе, улым... Соң, кая барыйк? Мин үзем дә шыр ятимә, аның да туганнары кайсы кая таралышып беткән. Тоттым да, кыен булса бу-лыр, үлмәбез әле дип, мәнә монда үземнең туган авылым Кәкре Нарат-ка алып кайттым әтиеңне...

Тонык лампа яктысында узган бу кич, бу сөйләшүләрдән соң, күңе-лемдә инде әллә кайчаннан бирле зур бер каһарман рәвешендә сурәт-ләнеп килгән Гыйлаҗ агай белән янәшәгә Мәчтүрә апай үзе дә әллә ничек бик нык үсеп, гаҗәеп олы бер җан булып килеп басты. Һәм мин Ады-ады турында сүз чыга калса, Мәчтүрә апайның да искитмәле фидакарьлеге хакында әйтмичә калмый торган булдым...

### ИКЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

Әйе, безнең яшь күңелләр Гыйлаҗ агайның үткәне белән горурлана да, аңа соклана да иде, һәм без, Бари белән икәү, үзебезнең иптәшләргә гражданнар сугышында иң зур батырлык күрсәткән кеше турында сөй-ләп, авыз суларыбызны аз корытмаганбыздыр...

Әмма, шуның белән бергә Ады-адының кайбер сәер гадәтләре мине, аптырашта калдырып, уйланырга да мәҗбүр итә торган иде.

Сәер гадәтләре дигәннән, мин аның көмеш самовардан соңгы тамчы суы тамганчы, шабыр тиргә батып чәй эчүләре яисә көлдә бәрәңге тәгәрәтә-тәгәрәтә яну-пешүдән каезланып беткән бармак битләре ту-рында гына әйтмим. Болары алай аптырарлык түгел дә... Кемдә булмас диген андый гадәтләр?

Яки мәнә Ады-адының ялгызы гына калырга яки бер ялгызы гына йөрергә яратулары...

Авылыбызда инвалидларның атасы саналса да, Гыйлаҗ агай, буын-нары әле нык, куәт-җегәре әле шәп булганлыктан, колхоз эшеннән читләшми, хәтта, әйтер идем, чир-сырхауны бөтенләй белмәгән кайбер ир-атны хезмәт көненең күплеге ягыннан егып та салгандыр. Колхозда әле эшче кулларга алай кытлык сизелми, шуңа күрә аны даими эшкә кушмыйлар, ул үзе, эш сорап, бригадирга бара. Әлбәттә, күңеле теләсә, җанын тартырдай эш чыкса гына, ягъни аңа ялгызы гына эшләрдәй хезмәт булсын, аның тирәсендә бүтәннәр чуалмасын... Клевер яки борчак чапканда, ул җирне үзенә аерым бүлеп ала; инеш буендагы якын болынны аның исеме белән атап йөртәләр дә, чөнки елның елын-да Гыйлаҗ агай шул тугайның печәнен берүзе чабып, безнең, ягъни Бари, аның әнисе һәм минем ярдәмдә җыеп, кибән итеп өеп куя. Бүтән эшләрдә дә шулайрак. Ат җигеп, берәр кая барасы булса да, ул бүтәннәргә кушылмый, я алдан элдертә, я бик артка кала... Ник алай? Юлдашлары күңелле гәп корганда, әйтәсе сүземне әйтә алмыйча ин-текмим дипме? Әллә үзалдына уйланып-хыялланып йөрергә яратамы?

Ләкин аның иң яратканы җиләк өлгерер алдыннан урман-болын-нарны гизү. Җилкәсенә почтальоннарда гына була торган галәмәт зур сумкасын элә дә таң тишегеннән чыгып китә, кояш батып килгәндә, ягъни авыл Советына каравылына барыр вакыт җиткәч кенә, кайтып керә. Кайчакны без дә аңарга иярергә теләбез, ләкин ул безгә, «ялгыз башым — тыныч колагым» дигәнрәк мәгънәдә йөз чытып, кулын гына селти. Нишләп йөри ул анда, ниләр күзәтә — белмибез. Кайткан ча-гында букчасына иртә җитешкән усак, каен гөмбәләре тутырган була, ә җилкәсендә уникe-унбиш кием бәйләрлек каен себеркелеге. Кара

урманнарны, яман исле сазлыкларны гизеп йөрүенең файдасы тагын шул: Гыйлаҗ агай алдан ук кайда җиләк шәп буласын күзәтеп белеп кайта һәм кәгазьгә язып-нитепме Мәчтүрә апайга аңлатып бирә. Менә ни өчен Мәчтүрә апай безнең «саз башлыгы» булып йөри дә инде...

Гыйлаҗ агайның бу гадәтләре сәерен сәер, ләкин аңламаслык түгел.

Мине хәйран аптырашта калдырганы, еш кына уйланырга мәҗбүр иткәне бөтенләй икенче нәрсә иде. Аның артык тәкъва булуы хакында бер әйтеп киткән идем инде. Менә шул...

Кеше авыл Советының үзендә утыра, колхоз эшләреннән читләшми, авылыбызга радио кертүендә, иң күп багана утыртучы ул булгандыр, кич-төннәрен колагын шул шәп нәрсәкәйдән алмый, моның өстенә, еш кына улы Барины каршысына утыртып, яңа китап-журналларны укыттыруы тагы... Кайчакны мин үзем дә китап укуга катнашып киткәлим. Ә Гыйлаҗ агай без укыганны баш селки-селки бик игътибар белән тыңлый да, рәхмәтен белгертеп, иңбашыбыздан сыйпап куйгалый.

Бер тапкыр Бари миңа:

— Ипидер, минем әти коммунист буласы булган, тик теле булмаганга гына кермичә калган,— диде һәм мин аның белән шундук килештем, чөнки мин: «Коммунист ул эше белән генә түгел, сүз белән дә таш яра белергә тиешле кешедер»,— дип уйлый идем.

Бер яктан әнә нинди иде ул безнең Гыйлаҗ агай, ә икенче яктан нәкъ шуның киресе — дин тота.

Кара урманнарга барган чагында, ни өчен җилкәсенә иләмсез зур букча асып йөрүенең дә хикмәте бар икән, моны миңа зур сер итеп кенә Бари аңлатып бирде:

— Әти теге зур букчасын гөмбә җыяр өчен аладыр дип уйлыйсыңмы? Булмагае!.. Букчасына ул шешә белән су ала, намазлыгын тыга... — диде.

Бу минем өчен хикмәтле бер табышмак иде. Әмма уйлана, баш вата торгач, үземчә җавабын тапкандай булдым мин моның...

Без совет мәктәбендә укыйбыз, безгә табигатьнең әллә нинди серле нәрсәләрен дә бик аңлаешлы итеп төшендереп бирәләр, әбиләрнең теге дөнья, җәннәт, җәһәннәм турында сөйләгәннәрен без әкият итеп, кызык итеп кенә тыңлыйбыз, ә инде табын артында, ашап туйгач, бит сыпырып алабыз икән, бусы аның ризык хөрмәтенә һәм туендырганнары өчен әти-әниләребезгә рәхмәт йөзеннән генә үтәлә. Дөрес, безне дә дин юлына авыштыру ягыннан бөтенләй үк кысып карамыйлар түгел, булгалый андый хәлләр, әмма без алай ансат кына бирешердәйләр рәтендә йөрмибез. Бер вакыт минем әбкәй, дин сугышлары һәм пәйгамбәрләрнең изгелеге турында җыен тузга язмаган нәрсәләр сөйләве өстенә, минем күңелне иләсләндерү нияте белән:

— Бала чакта укылган догаларның савабы кырык өлеш күбрәк була аның... Менә мин сиңа бик тә кирәкле бер доганы өйрәтим әле, җеннәр якын да килә алмас шуны укысаң,— дип сайрарга тотынган иде, мин:

— Пионер башым беләнме? Үзеңә булсын... Мин үзем җен! — дип кырт кистем.

Сеңелемнең киез итегенә олтан салып утырган әтием исә, минем җавапны хуп күреп, ахры, бик рәхәтләнеп кеткелдәп алды да әбкәйгә кырыс кына итеп:

— Ярар, әнкәй, юк белән сабыйларның күңелен болгатма! Хәзер аларның үз тормышы, үз җайлары,— диде.

Ә Гыйлаҗ агайның? Бала чагында аның шулай яклаучысы булганмы? Мәдрәсә дисәң, ансында укырга-язарга өйрәтеп кенә калсалар, бер хәл, аларның башларына аннан әллә нинди чүбекләр тутырып чыгарганнар лабаса.

Гыйлаҗ агайга искечә язылган китапларны әллә кем түгел, авылыбызның иң олы карты, инде бер аягы белән гүргә баскан ак сакаллы Мөхәммәтҗан бабай биреп тора. Үз вакытында безнең авыл мәдрәсәсендә әйбәт кенә хәлфә булган, диләр, җәдитчә укытып азапланган, диләр. Булса да булгандыр, әмма Бари белән минем аңа үпкәбез дә, ачуыбыз да зур: үзе яшел мәчеттә ник кунып ятмый, ләкин нигә инде аңа безнең Гыйлаҗ агайны да үз артыннан ияртергә?

Аерата ураза вакытларында эч поша торган иде. Шундый олы, шундый таза гәүдәле кеше юк өчен, пүчтәк өчен көне буе интегеп ач ятсын әле!

...Без Гыйлаҗ агай турындагы бу уйларыбызны Мәчтүрә апайга да әйттек. Ул иң әүвәл, баш селкеп, сәер иттереп көлемсерәде генә. Аннары, үтә җитди бер кыяфәттә, Гыйлаҗ агайның ни өчен шулай дин тотуының сәбәбен без бөтенләй уйламаган рәвештә аңлатып бирде:

— Тикмәгә түгел шул, түгел... Егет чагында шахта базларында эшләгәндә, җир убылып төшеп, бөтенләй томаланып калган ул. Капкарангы, тирән баз эчендә ничектер япа-ялгызы... Менә шунда, улларым, иң әүвәл көткән ул кешеләрдән ярдәм, булмаган ярдәм. Аннан инде, тәмам тончыгып үләм дигән сәгатендә, аллага ялвара башлаган, нәзерләр әйткән... Үзен кемнәр, ничек казып алганнарын белми дә ул... Соңыннан, якты дөньяга чыгаргач, көч-хәл белән генә сихәтләндерә алганнар...

Бусы безнең өчен баш әйләндерерлек яңалык иде. Бари миңа, мин Барига, күзләребезне шар ярып, карашып алдык...

Шулай да без Гыйлаҗ агай хакында уйланудан туктамадык. Һәм бер дә бер көнне Бари белән икәү, аңа ярдәм итәргә теләп:

— Иске китаплардан туйгансыңдыр бит инде. Хәзергечә укый-язарга өйрәтикме үзеңне? Телисеңме? — дип сорадык.

Ләкин Гыйлаҗ агай безгә, чем-кара күзләрен зур ачып, бер ара текәлеп торды да мыек астыннан көлемсерәп:

— Әһәй-әһәй! — дип йөнтәс кулын гына селтәде.

Аннан ул көмеш язулы кылыч эленеп торган стена почмагындагы дәү шүрлектән юка катыргы тышлы ике-өч китап табып алды да өстәл янына килде. «Безгә үч итеп, юри дин китапларына ябышты», дип уйладым мин. Әмма аның исәбе бөтенләй икенчедә икән: кулына карандаш тотып, бер кәгазь кисәгенә бик тә азапланып нидер язды да, әлеге юка тышлы китапларга таянган көенчә, язуын безгә бирде. Ни күрик: нәкъ безнеңчә иттереп, таракан йөргәндәге шикелле кәкре-бөкре рус хәрефләре белән: «Болары Тукай шагыйрь белән Шәриф Камал китаплары булыр бу, улларым», дип язылган иде анда...

Күзләребез шар булды. Менә сиңа мә!..

Димәк, авыл Советында кичләрен гомерен тиккә уздырмаган, өйрәнеп яткан! Бер кемгә ялынмый-нитми, үзлегеннән генә, ә син аны эч пошканнан, юаныр өчен генә газет-журнал актарып, сурәт карый торгандыр бу дип йөрисең... Дәү шүрлектә барысы да дин китапларыдыр дип уйлавыбыз тагы... Эх!

Гыйлаҗ агай куе сакал-мыек арасыннан рәхәтләнеп авызын ерган да тик тора басып...

Юк, чиертмәде, әмма таза буынлы, юан бармаклары белән зиһеннәребез чатнап китәрлек итеп кундыргандай булды бу...

* * *

Гыйлаҗ агайдан без ару гына курка да торган идек. Кайчакны артык каты куллы булганы өчен... Ләкин ул һич кайчан да тиктомалга, бер гаепсезгә кагылмас иде.

Авыл урамыннан тәмәке пыскытып барырга ярамыймы? Ярамый.

Әмма бер төрле яшь-җилкенчәк моны үтәми, киресенчә, авызына папирос кабып, төтен бөркеп йөрүне егетлеккә саный иде. Менә шундый тинтәк башларга эләгә торган иде инде аңардан: каравылда утырган жиреннән ялт кына атылып чыгар да: «Тыңлый белмәсәң, менә сиңа, ишәк!» дигәндәй, йомры башлы таягы белән теге егетнең муен тамырына шап кенә кундырыр иде. Гомерлеккә сабак... Авыл Советы турысына якынлашкан чагында, кечке дөньяны ярып, тамак ертып килгән исерекләр дә шып тыналар иде. Ул йортта власть урнашканлыгы өчен генә түгел, бәлки анда сакта утырган Ады-адыдан шүрләп шулай итәләр иде.

Кайчакны безнең үзебезгә дә — Барига гына түгел, миңа да, хәтта Садрига да — әйбәт кенә төшергәләп ала торган иде.

Берсендә Садри аркасында ару гына эләкте безгә. Дөресе, күгәрченнәр аркасында: «Кала җирендә генә булмасын, без дә асрап карыйк әле күгәрчен!» — дип җенләнде бит бу. Аның җене, билгеле, безгә дә күчми калмады... Ә күгәрченне каян тотасы? Әлбәттә, яшел мәчеттән. Аның да чормасыннан түгел, манара нигезендәге эчке кәрниз тактала-ры арасыннан тотуы ансат.

Бергәләшеп ясаган күгәрчен оясын Садриларның лапас өстенә урнаштырдык. Инде бөгенесе дә көйләнгән, бары да кала малайларыныкы шикелле иде. Тик безнең тоткан бер күгәрченебез, читлектән һавага чыгару белән, кире үзенең мәчетенә китә дә бара, китә дә бара. Шуннан, бу хәлгә яман да ачуыбыз чыгып, бер көнне:

— Болай булмас, берьюлы җиде-сигезне тотып кайтыйк та ай буена чыгармабыз каһәрләрне,— диештек һәм, култык астына арыш капчыгы кыстырып, кача-поса яшел мәчет ишегеннән кереп югалдык.

Артыграк комсызланганбыз, ахрысы, кояш баеганын сизми дә калганбыз. Менә бер заман, ни ишетик, баскычны таягы белән тукылдатып, тамагын кыргалый-кыргалый, мәзин Нуретдин бабай менеп килә... Нишләргә? Чормага шыларга да җай юк. Аптырамадык, манараның ян терәкләре артына постык. Үзебез постык посуын, әмма аяк астыбызда калган арыш капчыгында унга якын күгәрчен шопыр-шопыр канат кагынып азаплана... Ул да түгел, Нуретдин карт безнең турыга менеп житүгә, без, тузанга чыдый алмыйча, төчкереп җибәрмикме! Мәзин абзыебыз, кечке эңгердә безне күрмичә, баскан баскычында катып калды, укына-төкеренә башлады, аннан, без тагы төчкереп җибәрүгә, коты алынып, дөбер-шатыр килеп түбәнгә тәгәрәде...

Шуннан ни? Без «җеннәрне» түбәнгә мәчет картлары каршысына төшереп бастыручыбыз әллә кем түгел, үзебезнең Гыйлаж агай булды. Бүтәннәрнең югарыга «җеннәр» янына менәргә кыюлыгы житәр димени? Торалар шунда калтыранып, яман да укынып. «Шома таяклары белән башларыбызны яралар инде»,— дибез. Юк, мәчет кебек изге бер җирдә сабыйларга андый катылык күрсәтергә китап кушмаган, ахры, мәзин берәм-берәм колакларыбызны борырга кереште. Бармаклары әле һаман дер калтыраса да, колакны шап кенә бора белә икән... Аннары Гыйлаж агай мәчет ишегеннән иң әүвәл капчыктагы күгәрченнәрне очырып җибәрде, алардан соң артыбызга тибеп үзебезне очыртты. Ләкин моның белән генә безнең күгәрчен асрау теләгебез бер тамчы да кимемәде.

Кырык беренче елның Май бәйрәмендә булган бер хәлне дә сөйләмичә китәргә ярамас. Вакытында бик ачы тоелган иде, хәзер инде ул күптән онытылган, шулай да искә төшерүләре кызык бит.

Укып яткан жиреннән бәйрәмгә Бариның апасы да кайткан иде. Матур бәйрәмнең мул сыеннан авыз итәр өчен генә түгел, зур йомышы төшкән: бу елны техникумны тәмамлыйлар икән, тәмамлагач, төрлесен төрле якка эшкә җибәрәселәре икән. Ә моның әллә кая еракка китәсе килми, ди, үзенең туган авылында эшләргә исәп тоткан икән. Шуңа

күрә, әтисенең гражданнар сугышы инвалиды булуы хакында тиешле документларны җайларга-нитәргә дип кайткан да...

«Әйе, бик әйбәт, кайтсын, үзебезнең авыл халкын дәвалап йөрүгә ни җитә!» — дип без куанычтык кына.

Әмма эшнең яшертен ягы да бар иде: Мәдинә апа менә елдан артык инде Хисам абый белән гыйшык-мыйшык тота, хатлар языша, ә читкә җибәрә калсалар, хәлләре ай-һай мөшкелләнә бит инде аларның... Ә Хисам абый ул авылыбызның урта бармак егетләреннән санала, үткен дә, чая да. Әтисе дә төшеп калганнар рәтендә йөрми, авылыбызның бәләкәй генә май заводында олы бер директор. Җитмәсә тагы, Хисам абый үзе дә җиде класс белеме өстенә хисапчылыкка укып кайткан, колхоз идарәсендә исәп-хисапны син «ых» иткәнче кушып та, алып та, сугып та бирә.

Инеш буена чыбык чылатырга төшкәч, Бари миңа зур бер сер итеп кенә:

— Күзлектә туйлары булыр, ахрысы... Әкәмәт,— диде.

Шундый җизнәсе буласына ул сөенеп бетә алмый иде. Әтисе белән әнисе дә шулай: кояштай балкып йөриләр. Мәдинә апа кайткач, җитмәсә, бәйрәм шатлыгына өстәп шундый куанычлы йомыш белән дә кайткач, өйләрендә чыж да пыж коймак пешә, урамга итле бәлеш исләре тарала.

Кичләрен авыл урамнары, клуб тирәсе яшьләр кулында. Гармун тарталар, җыр, көлеш яңгырый... Галәмәт инде! Буй җиткән кызлар арасында барыннан да чибәррәге, барыннан да көяз киенгәне, тезләреннән ашкан кара толымлысы безнең Мәдинә апа булыр. Бөтен авылга ямьле нурлар сибәргә чыккан сыман. Егетләрнең күзләре ут яна, Хисам абыйныкы бигрәк тә...

Ә без, малай-шалай, урамда тыз-быз чабып йөрибез. Безнең үз шөгылебез...

Бүтән җирләрдә булды микән, юк микән, әмма сугыш алды елларында безнең авылда шундый бер гадәт бар иде: яз-җәй башларында кечкенә эңгердә без, җыен малай-шалай, урам йөргән яисә клуб тирәсенә, инеш ярына тугайлыкка җыелган буй җиткән кызларның аягына тал чыбыгы белән сугып-сыдырып йөрибез. Кызыл тал чыбыгы, һавада селтәнсәң, чыжлап куя, искәрмәстән кызлар аягына бер сыдырып алсаң, балтыр итләре янып-бүртеп чыга... Ә тал чыбыгына без юри Торна болынына барабыз, чөнки чыбыкның иң шәбе, иң сыегы шунда үсә, аннары, алып кайткач, вакыты җиткәнче кипмәсен, әйбәт чыжлардай булсын дип, кызлар сизмәслек җирдә суда чылатып тотабыз.

Урам-тыкрык чатларында безнең кыланышны күзәтеп торучы карт-коры да күренсә, безнең гайрәткә чик-чама булмый: янәсе, сез, кызый-лар, дөнья ямен җибәреп, оялмыйча йөрмәгез балтыр күрсәтеп, йөрмәгез егетләр белән култыклашып... Кызларның бер төрлесе, күреп өлгерсә, балтырларын күлмәк итәге белән капларга тырышып, шундук чүгәли-тезләнә дә тасма телләнеп:

— Әй, җаным, зинһар өчен тия күрмә... Прәннек, конфет бирермен үзеңә,— дип ялына, ялвара башлый.

Икенче төрлесе, усалрагы:

— Кит дим, җүнсез! Әтиеңә әйтеп, кирәгеңне бирдертәм бит, билләһи! — дип куркытып-янап ысылдарга тотына, хәтта үзебезне эләктерергә тырышып, талпынып та ала.

Ләкин без беренгә карамыйбыз...

Сугыштан соң әзсез югалды бу гадәт. Әллә безне котыртып-иләсләндереп торган карт-коры үлеп бетте дә малай-шалайга икенчерәк акыл керде — белмим...

Ул кичне без, Бари белән мин, артык кызып киткәнбез, күрәсең, авыл Советы турысыннан үтеп баручы ике кызны чырылдатып кычкыртып

җибәрүебезгә, һич искәрмәгәндә, кемнәрдер арттан килеп, безне эләктереп алмасыннармы! Үзебезнекеләр икән: Бари әтисе кочагында тыпырчына, ә мин Мәдинә апа кулында... Гыйлаҗ агай безнең бу шәп кәсепне яратмавын беләбез, әмма Мәдинә апага ни калган инде?

Җилтерәтеп авыл Советына алып керделәр. Шунда яктыда карасак, кайсыдыр юньсезе безнең чибәр апабызның да балтыр итләрен кызартып-күгәртеп бетергән икән. Болардан ычкынырга чама юк, инде хәзер мескенләнеп, ыңгыр-шыңгыр торабыз.

Иң әүвәл Барины: ыштанын төшереп, тар эскәмиягә сузып салдылар да үзебезнең тал чыбыгы белән йомшак төшенә чаж-чыж, чаж-чыж суктылар... Бари шүрәледән дә болайрак акырды.

Нихәтле катырак кычкырсаң, шул хәтле тизрәк ычкынасың, дигәндер инде.

Аннан соң мине... Кызлар шәрә балтырларына сыдырганда ничек түзә торганнардыр, сыек тал чыбыгы ай-яй әче икән!.. Җитмәсә, Адыады чыжлатып суккан саен, баш очымда, ачуны китереп, Мәдинә апа чыркылдап тора.

— Бүтән азып йөрмәскә сабак булсын, сабак булсын! — ди.

Ә мин: «Ярар, үзеңне дә буш итмәм, техникумыңны бетереп, авылга кайткач, туеңа хәтле балтыр итләрең чиләнеп бетәсен белеп тор!» — дип ярсудан иреннәремне кысып ятам...

* * *

Садриның әтисе Хәкимҗан агай соңгы вакытларда бик инсафланып киткән, хәтта чилем тартуын да ташлаган иде. Пожарныенда, кем әйтмешли, балта эләрлек төтен эчендә чилем сасысында борын да җыермыйча түзеп утыра, үзе янәдән тәмәкегә ябышмый иде. Җитмәсә тагы, үзендә булмаган акылны бик әйбәтләп, бик арзанга гына бүтәннәргә сатучан булып китте. Мәчет картлары тирәсендә, тәкъваланып, ышкынып йөрүләрен әйтәсе дә юк. Тикмәгә булмаган икән...

Бер дә бер көнне һади картны, ягъни авылыбызның бердән-бер мулласын, яртылаш паралич сукты. Телен югалтмас борын һәм үз акылында чагында әйткән ди мулла: «Имамлыкны һич шөбһәләнминитми мулла Нуретдин үз өстенә алсын, ә мәзин вазифаларын, кем, Хәкимҗанга йөкләсәгез дә ярар — булдырмастай бәндә түгел кебек»,— дигән, ди. Менә бит ничек! Хәкимҗан агай әнә нине күңеле белән сизенеп йөргән икән, кәҗә сакал!

Изге урын буш тормый, диләр, пожарныйга аның урынына Гыйлаҗ агайны күчереп утырттылар.

Безнең дус Садри әтисенең мәзин булуына үтә гарьләнеп, байтак вакытлар сөмсере коелып йөрде. Тик торганда, бер гаепсездән кемнең инде мәзин малае буласы килсен, ди? Ни кылырга аптырап йөргән дусыбыз бер көнне Бари белән миннән акыл алырга теләп:

— Әллә, дим, манарага менә торган баскычны бер төшеннән кисеп куябызмы? — дип сорады.— Егылып төшеп, аягын имгәтсә, йөрмәс аннары...

Яшел мәчетнең яңа мәзиненә үзебезнең дә ачу бәләкәй түгел иде, ник дисәгез, Хәкимҗан агай мәчет ишеген зур гына йозак белән бикләп ала да ачкычын кесәсендә йөртә, димәк ки, күгәрчен тотарга исәп итсәң, мәчет эченә тәрәзәдән бүтән керер юл калмаган.

Шулай да, чатан мәзингә ачуыбыз зур булып, аңардан берәр ничек үч алу теләге белән янсак та, Садрига без:

— Юк, ни дисәң дә, әтиең бит ул, ярамас алай. Синең үз юлың, аның үз юлы... Төкер башына! — диебрәк киңәш бирдек.

Ләкин Садри безнең киңәшне тыңлардай малаймы соң! Тәки үзенекен каерган: берсендә, әтисенең тәһарәт комганына бакалар тутырып,

тегенең котын алган, икенче тапкырында, әтисе мунча кереп яткан чагында, тыштан мунчаның ишеген бикләп, тегене кичке азаннан мәхрүм иткән иде.

Көлкесен көлке... Ләкин андый көлкеләр ясап йөрерлек хәлгә төшмәсәң, әйбәтрәк, билгеле. Дөресен әйткәндә, көлүдән бигрәк, кызгандык без дусыбызны.

Ярый, анысы әле бер хәл, безнең үзебезнең Гыйлаҗ агай турында: «Моңарчы белмәгәнбез, Ады-ады авылыбызның тере әүлиясе икән ләбаса», — дигәнрәк сүз тараттылар. Имештер, авылыбызда аннан да тәкъва, аннан да изге җан юк, аңа юраган һәр нәрсә шөбһәсез тормышка аша... Кайсы юньсезе уйлап чыгаргандыр? Шуннан, китерә башладылар үзенә хәер, ява башлады сәдака! Мәктәп ишек алдында яши дип тә тормыйлар, дәресләр бетеп, укытучылар таралганын гына көтеп яталар. Хуҗаларның аяк-кул терәп каршы торачагын белгәнгә күрә, китергән нәрсәләрен ишек астына тыгалар яисә болдыр почмагына куеп китәләр. Үзебезнең авылның карт-карчыгы яки сабыйлары гынамы, күрше авылның ахмакларыннан да хәер тотып килүчеләр булгалый. Өйләрен ташлап качар дәрәҗәгә җиттеләр болар.

Бари иң якын дусым булганга күрә, минем дә күңелем рәнҗи, мин дә кеше күзенә карарга оялып йөрим... Бер кичне үзебезнең әбкәй:

— Тыңлачы сүземне, Рифгать улым, җыеп куйган бер дистә күкәем бар иде, шуны гына Гыйлаҗетдин агайларыңа илтеп тапшыр әле, акыллым... Саваплы булырсың,— дип сайрарга ябышкан иде, мин, ачуымнан шартларга җитеп:

— Алар муеннан гарык булганнар инде. Илтмим!.. Китер, берәмберәм эчеп бетерим җыйган күкәйләреңне, юк, стенага бәреп чәлпәрәмә китерәм! — дип, әбкәйнең котын алдым. Шундук «әстәгыфирулла»сын тезә башлады...

Инде нишләргә, ни кылырга безгә?

Бер вакыт без, ягъни мин, Бари һәм Садри, мәктәп капкасы төбендә утырабыз. Берәрсенең сәдака тотып килгәнен күрсәк, тозлап-борычлап тиргәргә дә кире борып җибәрергә исәп. Каршыбызда, бераз гына арырак, яшел мәчет, баеп барган кояш нурларында манараның көмеш ае елтырый... Күрәсебез дә килми. Манара әйләнәсендә бөтерелгән күгәрченнәргә дә кызыкмыйбыз. Тотам дисәң, әнә колхоз амбарлары тирәсендә дә күп алар... Эх, дөньялар, кәкре-бөкре моржалар!.. Шулай каңгырап утырган чагыбызда, Садри болай да кызган канга тоз сибеп:

— Гыйлаҗ агай үлгәч, аның да каберен изге итәрләр микәнни? Ә кабер ташы ел саен бер илле үсеп, күтәрелеп торыр микәнни? — дип пышылдады.

Менә ахмак! Без, Бари белән икәү, аңа яндырып карап алдык. Хәер, аның болай дию е тиктомалдан түгел: безнең күрше авылда гына Чыршылы мазарында бер әүлия кабере бар, диләр. Үзебезнең авылның карт-корысы да баргалый анда. Менә шул әүлия каберен кемнәрдер, ис-акыллары китеп, күзәтеп торалар икән: әүлиянең кабер ташы елның-елында өскә таба үсеп, калкып бара, имеш...

— Их, сине! Үзең пионер җитмәсә! — дидем мин, дусым Садрины чәйнәп ташлардай булып.— Үзенең күкрәгендә чи кызыл йолдыз булсын, үзе әүлия булсынмы, җүләр! Аннары, синең ул кабер ташының ничек үскәнлеген карап, үлчәп торганың бармы, я? Җыенысы суган әкияте...

Бари, авызын кыйшайтып, мин әйткәннәргә зәһәрле мыскыл да өстәп җибәрде:

— Әйе, таш харап та шәп үсә инде ул. Әмма ләкин безнең әти кабергә куелачак таш еллап түгел, көнләп үсәчәк... Көн саен бер карыш! Аннан, үсә-үсә күкләргә җитәр дә, менә Садри кебек мәми авызлар өстенә авып, изеп ташлар...

— Ә мин чынлапмыни? Ышаныпмыни? Болай гына бит,— дип мыгырданып алды Садри, иреннәрен турсайтып.

— Алайса, авызыңда кибәк әвәләмә, белдеңме!

Бераздан без, татулаша төшеп һәм өчебез бер баш булып, туган авылыбызга үпкә-зар түгә башладык. «Нишләп шулай икән, дибез, авылыбыз каладан да, тимер юл станциясеннән дә әллә ни ерак түгел — гел кара урман эчләрендә үк тә утырмыйбыз, әмма бездә генә җыен юк-бар нәрсәләр һаман-һаман булып тора? — дибез. Бу картларны, бу әби карчыкларны нишләтергә инде? — дибез. Әмма ни генә булмасын, безгә Гыйлаҗ агайның исеменә тагылган ямьсез койрыкны кисеп алмыйча һич тә ярамас, дибез. Моның өчен иң әүвәл, әлбәттә, хәер-сәдака ташучыларның юлын корытырга кирәк»,— дибез... Ләкин ничек?

Менә шул чакны инде минем зиһен тагын капылт кына яктырып китте.

— Әйдәгез, берәр усал эт табып алып кайтабыз да шуны, Бари, сезнең баскыч төбенә бәйләп куябыз,— дидем мин.

— Әйе шул,— дип кычкырып куйды Бари.

Шундук урыныбыздан купдык. Ләкин ул кичне дә, аннан соң да юлыбыз уңмады: бер генә авылдашыбыз да безгә хәтта картаеп беткән йолкыш этен дә бирергә теләмәде.

Әмма безгә һич уйламаганда Гыйлаҗ агай үзе булышты.

Без сизеп тора идек: Гыйлаҗ агай бу хәлләрдә ни кылырга белмичә, аңгырайган бер кыяфәттә йөри, ул хәтта яшел мәчеткә сукмагын да беркадәр суыта төште шикелле. Ул хәзер, кич-төннәрен пожарныенда уздырса да, көндезләрен анда тик ятасы килмичә, кул астындагы бер атны җигеп, инешнең текә ярыннан төзүчеләргә таштыр, ком-балчыктыр ташый иде. Анда инеш аръягындагы тигез тугайда өр-яңа больница салырга керешкәннәр иде. Гыйлаҗ агайның менә шул яңа төзелешкә катнашып китүе япа-ялгызым ат каулап йөргән чагымда, кешеләрнең ачы-төче сүзләреннән колагым тынып торыр, ичмаса, дип, омтылуыннан булгандыр, ахры... Аннан килеп, ул яңа больницада аның үз кызы Мәдинә апа кайтып эшләячәк ләбаса!..

Гыйлаҗ агай без теләгәннең тап өстенә баскандай итте: хәер, ул үзе дә шундыйрак ук теләк-омтылышта йөргәндер әле — бер кичне ул Кругловкага тегермән тартырга барган җиреннән, ачыклап әйтсәк, безнең авылга килеп кишер-шалкан сатучы әлеге Ләксәй дәдәйдән, менә дигән бер эт алып кайтты. Бозау кадәр үк булмаса да, олы сарык хәтле бар үзе. Бер өреп куйса, котың ботыңа җитәр... Мәчтүрә апай көрсенеп кенә Гыйлаҗ агайның бу этне берме-икеме пот онга алмашып алуы хакында әйтеп маташса да, без ул ягын төпченеп тормадык.

— Инде хәзер килеп карасыннар! — дип, Бобикны болдыр янына тимер зынҗыр белән бәйләп куйдык (мәктәптә укулар беткәч, зынҗырны капкага хәтле диярлек суздык). Аннары, явызрак булсын, усалрак, катырак өрсен дип, койрык һәм сырт йоннарын ризыкка кушып ашата башладык.

Файдасы тиде. Бариларга сәдака ташучылар бердәм азайды. Монысы булды. Ярый. Әмма кеше теленә кергәнне нишләтергә менә? «Безнең Гыйлаҗ агай бернинди дә әүлия түгел, юкны лыгырдамагыз, безнең иң олы каһарманыбыз ул»,— дип, диндар авылдашларыбызның кыеш авызына берәм-берәм сугып чыкмассың ич.

Шулай бер мәлне, күгәргәнче су коенгач, инеш ярындагы комда, аръякта больница нигезен салучыларга күз төшергәли-төшергәли, корсакларны кояш җылысына куеп, рәхәтләнеп яткан чагыбызда, Садри борынын ыңкыш-мыңкыш итте дә авызыннан яңа хәбәрен сыгып чыгарды. Нәрсә ди? Имеш, авылыбызның бер иш бетчәле телләре сөйлиләр ди: «Болай булгач, май заводы директоры Шакир коммунист башы

белән Ады-әүлиягә кода булырга теләмәс тә инде, улы Хисаметдиның да күңеле Мәдинә чибәркәйдән кайтырга тора, ахрысы»,— дип сөйлиләр, ди... Садри әнисе ягыннан Хисам абыйга карендәшрәк тиешле, шуңа күрә ул безнең алда әллә чынлап, әллә юри генә:

— Мәдинә апага өйләнмичә генә карасын, нишләтәсен үзем белермен мин аны! — дип тешләрен шыгырдатты, әмма нишләтәсен генә анык әйтеп бетермәде.

Бари ярсынып кайнар комга төкерде, ләкин шундук кулын селтәп:

— Өйләнмәсә соң! Бик исебез китте... Кызыкканнар ди шул аю табан Хисам абыйга. Аны бит армиягә дә алмадылар... Мәдинә апа исән-сау бетереп кайтсын гына, үзенә егетләрнең иң асылын таба белер,— диде.

Аның белән мин дә килештем. Шулай да без четерекле бу нәрсә турында баш ватмаска, аңа хәзергә «төкереп торырга» булдык.

Ләкин шул арада башланып киткән сугыш барын да үз бизмәненә салып, барын да үзенчә хәл итеп куйды...

### ӨЧЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

Сугыш...

Ни әйтим?

Бик мәгълүм...

Әйе, бик мәгълүм: аның яман дәһшәте һәм әҗәл ачысы бездән соң да, каннарыбыз аша күчеп, бик күп буыннарга җитәр...

Күз алдымда...

Юк, барын да сөйләмим эле, Гыйлаҗ агайдан читләшмичә, сугыш башлангач, авылыбызда булып үткән бер-ике вакыйга турында гына хикәяләп бирәсем килә сезгә. Андый хәлләр тик безнең авылда гына булгандыр дип уйлыйм мин.

Дәһшәтнең беренче көне.

Ут эченә барып керергә тиешле беренче төркем егетләр.

Авыл Советы каршындагы урам чатын халык басып алган. Бәхилләшәләр: кайсылары үксеп елап җибәрә, күбесе кайгы-хәсрәттән мыңгерәүләнеп, мыштым гына балавыз сыга, кемдер өздереп гармун сузып ала... Бер читтә, койма буенда җигүле атлар көтә. Ямь-яшел печән түшәлгән арбаларда китүчеләрнең кирәк-яраклары: бәләкәй-бәләкәй киндер капчыклар, төрле биштәрләр. Әҗәл давылына каршы күтәрелгәндә кешегә күп кирәкмени?

Сәетгәрәй абый төсе уңа төшкән яшькелт гимнастерка белән кызыл йолдызлы фуражкадан, билен каеш белән буып алган. Ул китүчеләрне вакытында озатып җибәрү ягын кайгыртып йөри. Кыяфәте кырыс, тик сүзләре генә йомшак, кайчакны әйтәсен әйтә алмыйча тотлыгып та тора.

Менә ул китүчеләрне бер сафка тезәргә тотынды. Ләкин, ни хәтле тырышса да, сафны турылый алмады. Әле кичә генә армиядән кайткан егетләребез тәртип дигәннәрен бөтенләй онытканнар сыман. Иңнәрен иңгә терәп, дугайланып бастылар. Күзләр дымлы, иреннәр кысык... Дуга эчендә урталыкта Сәетгәрәй абый. Кулын фуражкасы козырегына тидергәләп, бик кыска, әмма бәгырьгә үтәрлек итеп ни әйтте соң әле ул? Әйе:

— Йортыбызга ут төртте фашист. Шакшы аягы белән барыбызны изеп-таптап китмәкче яисә кол итмәкче була. Юк, бирешмәбез! Үз өненә барып дөмектерербез аны! Шулай бит, туганнарым? Шулай!.. Бүрәнә чапкан балталарыгыз чабылган килеш калсын, җиргә кадаган чалгы-тырмаларыгыз кадалган килеш калсын, бәйләгән дилбегәләрегез бәйләгән көе торсын, без күтәреп алырбыз, без чишәрбез, хафада китмәгез: торкан әйберләрегез суынмас та, күгәрмәс тә... Белегез: монда ышанычлы куллар кала, монда ярсулы йөрәкләр кала... Без сезнең

янда, без сезне көтеп торачакбыз. Ә сез, фашист дигән аждаһаны тиз заман тураклап, туган йортыбызны басып алырга теләгән ул ямаи афәтне мәңгегә юк итеп кайтыгыз... Изге сәгатьләрдә! Янадан күрешергә насыйп булсын, дусларым-авылдашларым! — диде.

Китүчеләр тирән сулашып алдылар. Әмма алар баскан җирләреннән чәчелергә өлгермәделәр, Сәетгәрәй абый янына безнең Гыйлаж агай килеп басты. Мин шаккаттым. Юк, мин генә түгел, бүтәннәр дә...

Гыйлаж агайны танырлык түгел иде: өстендә күн тужурка, зәңгәр галифе, аягында күн итекләр, ә башында зур йолдызлы шлем. Күкрәгенең сул ягына кызыл тасма да кадаган. Киемнәре иске, әмма чиста. Итекләре ялт иткән... Баринын миңа бер әйткәне бар иде: бу киемнәргә Казан госпиталеннән чыккан чагында киендергәннәр аны. Ләкин минем Гыйлаж агайны бу киемнәрендә күргәнем юк иде әле. Көне килеп житкәнне көткән, күрәсең... Тагы: күкрәгән аркылы-торкылы тар каеш, билен яссы каеш кыскан. Билендәге яссы каешта көмеш язулы кылычы асулы!.. «Әллә китүчеләргә ияреп, сугышка бармакчы микән?» — дип уйладым мин. Юк, мин генә түгелдер...

Менә ул, каба сакалын як-якка борып, китүче егетләр йөзеннән утлы карашын кичерде һәм кинәт җәһәт бер хәрәкәт белән кыныннан кылычын тартып чыгарды да кулын югары күтәрде. Аннары, шундый ук кискенлек белән, кылычны күкрәк турысына аркылы тотты.

Кинәт тып-тын булып китте.

Бер мизгелдән Гыйлаж агай калын күкрәк тавышы белән:

— Ады-ады,— дип китүчеләргә кул ишарәләде.

Дугайланып торган егетләр арасыннан алга иң әүвәл избач Мәҗит абый чыгып басты. Гыйлаж агай кылычның сырт ягыннан үпте дә егеткә сузды. Мәҗит абый башын түбән иеп, кылычның елык иткән салкын йөзенә кысык иреннәрен тидерде.

Эшне бүтәннәр дә аңлап алды.

Берәм-берәм чыктылар, берәм-берәм көмеш язулы кылычны үптеләр...

Әйе, тып-тын иде. Куркыныч тантаналы бу тынлыкта сулышлар да күкрәк тирәнлегендә кысылып тора иде. Тик:

— Буласызмы инде анда, тизме инде?! — дигән сыман, дугасына матур чигүле озын сөлге уралган колхоз айгыры гына, тынлыкны ярып, түземсезләнеп кешнәп куйгалый иде...

Киттеләр.

Авыл капкасы янында ничек булгандыр, урамда елау-сыктау тавышы ишетелмәде. Тузан кубарып арба тәгәрмәчләре дыңгырдап узды, тузан эчендә ак яулыклар айкалып торды.

Гыйлаж агай мәһабәт сыны белән чат башында очлы кылычын җиргә кадаган килеш басып алды. Ә без кылыч янында...

Икенче, өченче, дүртенче төркем егетләр киткән чагында да кабатланды бу хәл... Аны күзәтеп, сулыш алырга да онытып торган чагында: «Эх, сигез-ун ел элегрәк тумаганбыз, ичмаса... Без дә шулай, кылыч үбеп, явыз дошманга каршы сугышка чыгып китәр идек!» — дип кызыгып та, көрсенеп тә куя идек без, ягъни мин һәм минем ишләр...

...Хәзер уйлыйм инде: безнең авылдан избач Мәҗит абый белән комбайнчы Ислам абыйга Ватан сугышында Герой исеме бирелгән икән, тикмәгә түгелдер, дим...

* * *

Без хәзер, Сәетгәрәй абый бик белеп әйткәнчә, «трудбатальон солдатлары».

Малай чагыбыз, үтмәс чалгы белән чабылган үләндәй, йолкынып, тапталып, шиңеп артта калды.

Без хәзер кинәт кенә олыгаеп китеп, зурларга тыңлаштек.

Сугыш кушты.

Анарчы безгә «мәми авыз» яисә «яфрак кортлары» дип кенә карыйлар иде, анарчы безне «кызыл тал чыбыгы шикелле сыек әле болар» дип саныйлар иде. Сугыш зәхмәте алай димәде, «чыбыкларны бергә кушып бәйләсәң, себерке була», диде.

Юк, без сугыш уты эченә барып кермәдек, ләкин без дә тормыш-яшәеш өчен барган дәһшәтле көрәш ялкыныннан чыкмадык. Безнең арадан да авып, егылып калучылар аз булмады. Ләкин без барыбыз бер булып, олы максатыбызга ирештек — беләсез...

Беренче җәйдә үк төрле эшләрдә йөрергә туры килде. Мин:

— Кара, бәләкәй бит әле, булдыра алмас,— дигән сүзне бөтенләй ишетмәдем, киресенчә, һаман да:

— Булдырмастай егет түгел,— диярләр иде.

Колхоз атлары безнең кулларга күчте. Мактанып әйтсәм дә, ярый торгандыр: уникке яшь тулар-тулмаста ук мин җир тырмалау гына түгел, сукага ябышып, кулларыма сөялләр катырдым. Әйе, инбашларына авыррак йөк салсалар, буыннар тиз ныгый икән.

Безнең атларны Гыйлаҗ агай карый торган иде. Ул сугыш башлану белән үк диярлек, пожарныен ташлап, колхоз атларын тәрбияләүгә күчте. Тегендә торган чагында дуамал гайрәтен янгын сүндерүдә күрсәтә алмаган булса да, анда сөрсенеп ятуының файдасы шул: аның күңелендә «ат җене» кузгалган иде. Колхоз атларын ул бик әйбәт, җирәнә бик җиткереп карар иде. Берәрсе атын өшәндереп яки чиләндереп кайтса, игелек көтмә: күп сөйләшеп тормас, шул кешенең кулыннан чыбыркысын тартып алып яисә йөгән каешы белән, кемлегенә карамыйча, бик шәплә сырт буыннарын санап бирер иде. Ә инде атыңны иплэбрәк йөртеп, әйбәт хәлендә алып кайтсаң, Гыйлаҗ агай, каба сакалын селкеткәләп, кояштай балкып:

— Ады-ады,— дип, хәлсезләнгән кулбашларыңнан аталарча сыйпап җибәрер иде.

Гыйлаҗ агайның бөтен тормышы, бөтен барлыгы атлар янына күчте. Көннәрен дә, төннәрен дә шунда. Көл бәрәңгесен дә кәнүшни өенең мичеңә генә тәгәрәтә. Тик кайчакны гына, шабыр тиргә батып, көмеш самоварын бушату өчен генә, үз өенә кайтып килгәли... Азмыни тегендә эш! Әллә вакыт дигәне тамчы да булмаганга күрә, әллә күңелендәге бар нәрсәне атлар кайгысы басып киткәнлектән, ул җәйнең җәй буена кара урманнарны, җиләкле сазлыкларны, ичмаса, бер генә тапкыр да айкап кайтмады. Хәер, сугыш — нәләт төшкере — безнең үзебезгә дә күгәрченкәйләрне генә түгел, җиләк-гөмбә юлларын да онытыбрак торырга кушты шул.

Садри бездән аерылды. Аның этисе Хәкимҗан агайны, кәкре аяклары белән көчкә өстерәлеп йөргән кешене, әллә нинди авыр эшләргә җигеп булмас, алай да сугыш кызган көннәрдә мәзин булып кына бер тиен файдасызга каңгырып йөрмәсен әле дип, колхозның яшелчә бакчасына каравылчы итеп куйдылар. Әлбәттә, аның үзеннән рәт юк, бакчаның төп хуҗасы безнең дус Садри булды. Бәхете басты малайның! Җитмәсә тагы, этисе кемнәндер теләнеп, бер көпшәле иске генә мылтык алып тоттырган үзенә. Шуны иңеннән төшерми Садри. Алланың кашка тәкәсе булдым дип, инеш буенда күкрәк киереп кенә йөри хәзер. Гүя әле былтыр гына үзе безне колхозның яшелчә бакчасын басарга котыртып та йөрмәгән...

Әнә шундый шәп эшкә урнаштырганлыгына күрә, ахры, Садри дусыбыз элгәрерге дошманлыгын онытып, этисе белән татуланып китте. Ул аның яшелчәлек белән мәчет арасында буталып йөрүләренә тамчы да пошынмый, хәтта, киресенчә, Хәкимҗан агайның мәчет эшләренә күбрәк игътибар итүен үзенчә аклап та маташа иде.

Без Садри белән артык сүз куертып бәхәскә кермибез. Аның белән сүз көрәштерсәң, әйткәннәрен «ә-ә» дип җупләп тормасаң, ул сине корсагың шартлаганчы колхоз яшелчәсе белән сыйлар ди бик, сыйламагае! Кайчакны Садри дусыбыз, күңеле йомшап китеп:

— Кеше-кара күрмәгәндә, мәгез, тизрәк тыгыгыз! Күрсәләр шәп булмас: бриме баенный,— дип, кыяр-кишер-помидор ишеннән кесәбезгә дә салып җибәрә һәм һәр чакны диярлек: — Иң шәбен, иң зурысын Гыйлаҗ агайга бирерсез... Карагыз аны, миннән икәнен әйтергә онытмагыз! — дип кисәтеп тә куя.

Сиздегезме, эшне ничек югарыдан тота башлады безнең дус?! Юкса, Гыйлаҗ агай белән алай эшнәләнергә әллә ничә пот тоз ашасы бар бит әле үзенең! Шулай да без бик күндәм төстә:

— Ярар, онытмабыз,— дип ышандырабыз, әмма кичке эңгердә яшелчә бакчасыннан кача-поса кайткан чагыбызда иң әүвәл ул әйткән нәрсәләрне ашап куябыз, чөнки без Гыйлаҗ агайның, мондый күчтәнәчләрне күрсә, зур күзләрен агартып, яман иттереп тамак кырасын бик яхшы беләбез...

* * *

Август башлары булгандыр, ахры, әйе шулай — минем әни белән Баринын әнисе җәйге ялларында куналмашка алган арыш җирләрен урып бетереп, бодайга керешмәгәннәр иде әле — бер кичне күптәннән инде зарыгып көткән Мәдинә апабыз кайтып төште. Озакка түгел, бер-ике көнгә генә... Алар техникумнарын әйбәт кенә тәмамлауга хәрби хезмәткә алынганнар һәм, фельдшерлык белемнәре өстенә сугыш эшенә дә өйрәтү өчен, шунда укыган калаларында ук бер ара вакытка калдырылганнар иде. Җибәргән хатында шуларны аңлатып һәм, җай чыкса, кайтып киләчәге турында да әйтеп хат язган иде инде ул.

Мин пошынып:

— Бигрәк аз вакыт биргәннәр икән...— дидем.

Дусым Бари минем шикелле үк авыр сулап:

— Нишлисең, фронтта аларны яман да көтәләр икән. Болай да, булган нәрсәләремне, китапларым белән дипломымны туганнарыма калдырып килим инде дигәч кенә җибәргәннәр. Аннан, кешегә сугыш утына барып керер алдыннан авылына кайтып, бәхилләшергә дә кирәк ич, ансын да уйлаганнардыр,— дип төшендереп бирде. Мәдинә апаны танырлык та түгел иде: өстендә яшел гимнастерка, тар итәкле юбка, аякларында исә брезент куңычлы итекләр. Билен дә ул чын солдатларча киң каеш белән буып алган. Сумаладай кара чәч толымнары да юк: чәчен кып-кыска иттереп кистергән дә башына кыеклап кызыл йолдызлы пилотка киеп җибәргән. Әкәмәт сәер. Безнең чибәр Мәдинә апабыз кебек тә түгел... Тик түгәрәк алма битләре, шомырт кара күзләре һәм көлгән чагында матур елтыраган энҗе тешләре генә тап үзенеке...

Кайткан кичендә алар өйләрендә лампа кәрәчиннәре беткәнче утырганнар.

Икенче көнне дә зур кунакка өйдә сый-хөрмәт күрсәтү өчен Мәчтүрә апай урагына, ә Бари дус көлтә ташырга бармаска иткән булганнар да, әмма Мәдинә апа:

— Юк, өйдә тончыгып ятканчы, арыш жирегезне бетереп кайтыйк... Үзем дә ичмаса, бер туйганчы басу-кырларыбызны карап кайтырмын,— дигән.

Шуннан соң җыйнаулашып киттеләр болар. Минем әни дә алар белән... Тик мин генә көлтә арбамда бер апа белән ындырга арыш көлтәсе ташып азапланам. Без бер басуда, шунлыктан миңа, йөк өстенә менеп утыргач, алар урган җир башы бик әйбәт күренә. Нишләсәм дә, күзем алар ягына карый да тора.

Мәдинә апага алай бил авырттырып урак урырга әллә ни туры килмәде дә. Арыш басуы да, бодай кыры да халык белән тулган. Мәдинә апаны тегендә дә чакырып алалар, монда да дәшәләр, һәм ямь-яшелдән киенгән чибәр апабыз салмак җилдә сумала чәчләрен тузгытып, кулындагы пилоткасын һавада селки-селки, ягъни авылдашларын ерактан ук сәламләп, теге якка да йөгерә, бу якка да чаба. Кай араларда туктый да озаклап һәм тәмләп сүз сөйләшеп ала... Басуда сокланмаган кеше калмагандыр. Ни дисәң дә, авылыбыздан чыккан иң беренче фельдшер, ни дисәң дә, хатын-кызларыбыз арасыннан фронтка китүче иң беренче кешебез...

Әбәт вакытында мин алар янына бардым. Бергәләп тамак туйдырып утырдык. Нишләптер, сүзне бик аз сөйләштеләр. Мәдинә апа, алсу иреннәре арасына камыл саламын кыстырган килеш, авыз эченнән генә бик тә моңлы бер көй көйләп утырды. Шулай озак кына үз көйләнеп утырды да, инде торып эшкә ябышырга дигәндә генә, еракта басу башында күгелҗемләнеп торган урманга шомырт күзләрен төбәгән килеш:

— Нарат җиләге дә, торна җиләге дә өлгереп килә торгандыр инде. Юк, аларына ул хәтле исем китми... Их, салкын сөткә кара җиләк салып ашасаң иде менә! — дип уфтанып куйды.

Шул җитә калды.

— Ә нигә, якын сазлыкка гына керәбез дә чыгабыз... Качмас әле, бер килеп бетереп кайтырбыз җиребезне,— дип, безнең әниләр урыннарыннан да куптылар.

Мәдинә апаның:

— Әйттем исә кайттым, кешедән уңайсыз бит, ярамас,— дип, кирегә сукалап азаплануы да файда итмәде.

Бари да аларга иярде. Тик мин генә, җигелгән атыңны кая куясың инде дип, бармадым, җүләр...

Салкын сөткә салынган җиләк... Белмим, дөньяда аңардан да тәмле нигъмәт бармы икән! Соңыннан Мәдинә апабыз сугышка керер алдыннан язган хатында: «Салкын сөт белән ашаган кара җиләкнең тәме әле дә авызымда минем», дип исенә төшергән иде бит...

Кичке эңгердә ул моңсу һәм нәүмиз бер кыяфәттә авыл урамнарыннан, инеш аръягында салына башланып та, инде ташланган больница яннарыннан әйләнде, аннары клуб тирәләренә барып кайтты. «Ичмаса, сөйгән егете Хисам да авылда түгел, Мәдинә апаның китәр алдыннан күңеле бу кадәр сынык булмас иде», дип сөйләндек без Бари белән икәү. Яшьтәшләре күптән инде ут эчендә йөрсә дә, Хисам абый, юк, армиягә алынмаган иде әле. Ул сугыш башлангач кына, ничектер абайламыйча, бер аягын бүрәнә арасына кыстырып бик хәтәр имгәткән иде, һәм аны үзебезнең кала больницасына илтеп салганнар иде. Шул уңайдан авылыбызда төрле имеш-мимешләр дә таралды. Ләкин без, ягъни Бари белән мин, имеш-мимеш сүзләргә ышанучылардан түгел:

— Юрамалый нишләп аяк имгәтеп, үз-үзен бозып йөрсен ди кеше? Куркакмыни ул... Булмаганны? Хисам абый савыгып кына чыксын, аннары сугышка киткәч, күрсәтер әле фашистларның күрмешен! Билләһи менә! — дип, кеше өчен ант итеп, үз ишләребезне ышандырырга тырышып азаплана идек.

Ә бу хәлдә исә: «Хисам абый авылда булса, Мәдинә апага болай ук күңелсез булмас иде әле», дип уйладык.

...Станциягә Мәдинә апаны өчәүләшеп, ягъни Гыйлаҗ агай һәм Бари белән мин, озата бардык. Мәчтүрә апай:

— Булмас, чыдый алмам! — дип, күкрәген тоткан килеш авыр ыңгырашып, кыр капкасының баганасына сөялеп калды. Безнең авыл-

ның бар хатыннары да, якыннарын сугышка озатканда, шунда гына басып кала торганнар иде...

Без колхоз айгырын куаламыйча гына җиңел арбада селкенеп барган чагында, Мәдинә апа кырый-кырыйлардан чәчәкләр җыя барды. Бу юлдан, көянтә-кәрзиннәрен асып, станциягә җиләк сатарга ничәмәничә тапкыр үтмәгәндер ул? Әле быелтыр гына...

Барып кергәндә җыйган чәчәкләре бер кочак иде инде.

Ләкин станциядә безгә озак кинәнергә насыйп булмаган икән: Мәдинә апабыз, беренче килгән поездга ук әләгергә теләп, безнең белән саубуллашырга тотынды. Гыйлаҗ агай аны, тамак төбеннән ниндидер сәер авазлар чыгара-чыгара, озак, бик озак киң күкрәгенә кысып торды. Үзенең көмеш укалы каба сакалы селкенә, үзенең зур кара күзләреннән мөлдер-мөлдер яшь ага. Гыйлаҗ агайны мондый хәлендә беренче күрүем.

Аннары ни? Вагондагы солдатлар иң әүвәл фанер чемоданны суырып алдылар, шуның артыннан Мәдинә апаның үзен. Эшелон борылышта күздән күмелгәнче, теплушка ишегеннән чәчәкләрен селкеп барды. Минем хәтер түремдә Мәдинә апа әнә шулай, фронтка чәчәк бәйләме селкеп киткән рәвешендә сеңеп калды.

— Ай күрде, кояш алды апакаебызны,— дидем мин, тамак төбендәге төеремне йотып.

— Ашыкты бит... Җае чыкса, үзебезнең калада төшеп, бульничкә дә сугылырмын бәлки, дигән иде ул әнигә... Чәчкәләрне дә Хисам абыйга дип җыйгандыр әле,— дип, яшь аралый төшендереп бирде миңа Бари дусым.

Ә Гыйлаҗ агай, аның сүзен әллә дөресләп, әллә шиккә алып, басынкы гына:

— Ады-ады,— дип куйды.

Өендә бәхилләшкәндә, бүтән авылдашлары шикелле, этисенең көмеш язулы кылычын үбеп, ант иткәндерме, юктырмы — мин күрмәдем. Тик өйләренең түр стенасындагы чүпрәк келәмдә көмеш язулы кылыч белән янәшәдә аның калын чәч толымы гына, ядкәр булып, эленеп калды. «Төсем итеп сакларсыз», дигән...

* * *

Мәдинә апа китеп, озак та үтмәде, Хисам абый кайтып төште. Әйтteләр: «Шулай икән, сугыш заманында бульнич түшәгендә бик иркенләп ятарга ирек юк, анда хәзер авыруларны, аякка тиз бастырып чыгарып җибәрәләр икән...»

Авыл Советы председателе Сәетгәрәй абый әйткән ди тагы:

Сугыш барыбызга да бер. Этисе оборона заводына эшкә алынганда, нишләп малае симулянт булып йөрсен, ди. Башына тай типмәгән лә аның, дигән ди.

Хисам абыйның этисе хакында белә идек инде без: аны, май заводындагы урыныннан кубарып, өлкә каласындагы зур гына заводка бәләкәйрәк кенә булса да башлык итеп күчергәннәр иде. «Май производствосында әйбәт кенә эшләдең, сынатмадың, инде хәзер, давай, снаряд ясаганда да ярдәм итеш», дигәннәр ди. Монысына исебез китмәде. Сәетгәрәй абый әйткән «симулянт» сүзе генә башыбызны катырды: «Ни икән?» дибез. Аны безгә, сугыш башланса да, әле һаман пожарныен саклап ятучы «әкият капчыгыбыз» Заһидулла абзый төшендереп бирде:

— Улмы? Ул безнеңчә әйткәндә, ягъни мәсәлән, Саламторхан була инде. «Алма, пеш — авызыма төш» дип ятучы... Инде фырунт шәулә-

сенә борып карасак, болай: берәүләр тегендә кан коеп жан бирергә йөргән чагында, монда, кулэгэгэ посып кына жиңү килгәнен көтеп ятучы... Барып життеме, оланнар?

Шул тиклем шәп аңлатсын да, барып житмәсен ди!

Бәлки безнең Хисам абый Саламторханнарның сынары түгелдер. Әнә бит ул, аягындагы авыртуы бик үк басылып житмәгән булса да, жиргә ничек нык, ничек өздереп басып йөри. Велосипедына атланса, авыл урамыннан да әүвәлгечә жилдәй узып кына китә.

Бер кичне, ындыр табагыннан кайтышлый, без, Бари белән икәү, кызыл помидор яисә, һич югында, шалкан эләктерү өчен, яшелчә бакчасына сугылдык, һәм менә шунда дусыбыз Садри, Хисам абый турында сүз чыккач, ярып салды:

— Мин әйтте дип әйтерсез: Хисам абый кавалерист була ул! Аяклары да шуңа гына көйләнгән, аннан килеп, малай чагында сабан туенда атлар чабышында аңардан да зәһәр йөрүче булмаган ла...

Әмма Бари дусым аның белән килешмәде:

— Хәзер инде кавалерия заманы түгел... Беләсезме, кем булыр ул? Артиллерист — менә кем! Ник дисәгез, исәп-хисапка башы галәмәт шәп эшли бит аның. Артиллериядә нәкъ менә шул ягын карыйлар да икән, диде.

— Иштең! — диде Садри, помидор түтәлләренә таба сузылган юлыбызга аркылы басып.— Бик беләсең килсә, сугышта баштан да бигрәк йөрәк кирәк!.. Менә шул бармы икән Хисам абыйда?

Садри безне барыбер помидор түтәлләренә таба жибәрмәде, үзе алга чыгып, турнепслар ягына таба алып китте. Ярый, тансыкка бусы да начар түгел аның...

Садри дусыбыз пешә төшкән помидорларын бездән кызганса да, шул кичне үк яшелчә бакчасының адәм карарлыгын калдырмаганнар. Әллә кемнәр түгел, озакламый сугышка китәсе үзебезнең авыл егетләре, ди. Алдан басып керүчесе дә әлеге Хисам абый, ди. «Шәп иткәннәр, йөрмәс Садри борынын чөеп, бер-ике помидорын жәлләп!» дидек без Бари миңа, мин Барига күз кысып.

Ул арада Хисам абыйларның китәр вакытлары да килеп житте. Ул үзеннән дүрт-биш яшькә кечерәк егетләр белән бергә алынган иде, шунлыктан алар арасында баш булыбрак кылана. Үзе әче балны да житәрлек куйдырган икән, чөнки никрут егетләр гармун тарткан шәйгә кара-каршы басып, жырлашып урам әйләнергә алар йортыннан кузгалып киттеләр...

Озатучылар байтак жыелды. Үзләре дә аз түгел иде алар: унлап егет. Хисам абыйдан кала бүтәннәренә әле юньләп мыек та чыкмаган. Без дә ул көнне «саннар калмады инде, ичмаса, бер генә көн ял итик әле» дигән булып, эшкә бармаган идек. Авыл Советы янына озатышырга килдек. Бу юлы Сәетгәрәй абыйның дәшүен дә көтмичә, Гыйлаж агай, тиешенчә киенеп, ягъни күкрәгенә кызыл тасмасын бәйләп һәм биленә кылычын асып, үз белдеге белән килеп житте. Бик тә аңлашыла: бердән, китүчеләр байтак кына, икенчедән, алар арасында үзенә кияү булачак егет тә бар...

Шуннан ни? Сәетгәрәй абыйның, озатучыларны елау-сыкраудан тыелдырыбрак, китүче егетләргә «изге көрәштә жан аямыйча сугышып та исән-сау әйләнеп кайтуларын» теләп әйткән жылы, туганлык сүзләре һәм егетләрнең Гыйлаж агай кылычын, баш иеп тын гына үбүе... Бәхилләшү...

Әмма безнең күз күрмәгән, колак ишетмәгәне дә булды.

Көмеш язулы кылычны үбәргә иң азактан чак кына чатанлый төшеп Хисам абый чыкты. Аның какча бите тагын да ябыграк, ә күз төпләре артык дымлы булып күренде миңа... Хисам абый күгәргән иреннәрен

кылыч йөзенә тидердеме-юкмы, кисәк ул Гыйлаҗ агайның күкрәгенә капланды да яман бер тавыш белән:

— Их, Гыйлаҗ абый, җан кисәккәем, белмисең лә, их, белмисең лә... дип үксеп җибәрде.— Бәхетем булып, бу афәттән генә котылыйк, бал-майда йөздерермен әле мин сине... Нәзерем сиңа, Гыйлаҗ абый, шул: исән калсам, йон костюм бүләк итәрмен үзеңә...

Гыйлаҗ агай аның дерелдәгән иңбашларыннан сыйпый, үзенең дә каба сакалы селкенеп тора, ә зур күзләренә мөлдер-мөлдер яшь бәреп чыкты. Станциядә Мәдинә апаны озатып җибәргән чактагы шикелле...

Җыелган халык: «Эх, бу тәмуг утларында яндырасы Гитлерны!..» дип бердәм уфылдап-ыңгырашып куйды.

Аннары, арба тәгәрмәчләре, урамдагы күлләвекләрне изеп, алга тәгәрәде, һавада ачы һәм моңлы җыр яңгырый башлады.

Гыйлаҗ агай әүвәлгечә, кылыч очын җиргә тидергән килеш, чат башында басып калды, ә без Бари белән икәү кылыч янында...

Дусым Бари ни кичергәндер, әмма шул минутта минем күңелемне Хисам абыйның бәхилләшкәндә әйткән нәзере биләп алды.

Нәзер...

Зур сынау, зур эш алдыннан кешеләр әйтә инде аны. Безнең авылда сугыш башлангач та, бик күпләр нәзерләрен нигәдер Гыйлаҗ агайга әйтә торган булды. Кайберәүләр хәтта, әйткән сүзләренең ныклыгын күрсәтергә теләпме, нәзер әйбереннән бер өлешне, үзенә күрә аванс рәвешендәрәк итеп, алдан ук биреп куялар иде. Июль аенда ук әле Ташлар ягыннан кемдер Бариларның ишек алдындагы коймага бер сарык бәрәне бәйләп киткән, һәм Гыйлаҗ агай аны, нәзер әйбере икәнлеген белеп алгач, ике уйлап тормастан, ерак болындагы печәнчеләрнең «общий» казанына илтеп салган иде.

Озакламый минем үз әтием дә нәзер әйтте. Иртәгә китәсе дигән кичендә, без барыбыз да бер табын артына утырышкач, ул, күзләрендә чиксез моң-хәсрәт чагылдырып, әмма тавышын көррәк чыгарырга тырышып: «Исән-аман гына калыйм, Гыйлаҗ агаегызга биш такта менә дигән грузин чәе алып кайтып тоттырырмын»,— диде. Гүя ул безне мәңгегә ятим калдыру өчен, Идел ярында Сталинград каласы төбендә ятып калырга китми, гүя данлы Грузия илләренә кунак булып кайту өчен, җиңел бер сәяхәткә генә җыена иде.

Ни генә димә, нәзер күңелдәге өмет һәм теләкнең бер төрле чагылышы инде ул, һәм кеше аны гадәттә үз эченнән генә, күңеленнән генә атап, беркетеп куя, әйтсә дә, иң якын җаннарына гына әйтә, фаш итми. Тик менә Хисам абый гына ни хәтле халык алдында үксенеп ярып салды. Хәер, сугышка китәсе кеше шулай итсә дә гаҗәпмени?

Дин һәм алла ишесенә кырын күз белән карасак та, без — Мәчтүрә апайның тирән шахта базында Гыйлаҗ агай кичергән фаҗига турында сөйләгәннәре күңелебездә тирән сеңеп калганга күрә микән — нәзерне серле һәм сихерле бер нәрсә рәвешендәрәк күреп, аның көченә ышанырга тырышабыз, шунлыктан аның тормышка ашуын без бар күңелебез белән тели торган идек.

Ләкин дөнья дигәнең, нәзер-наз кебегенә тамчы да исе китмичә, әллә нинди хәтәр һәм яман хәлләр дә китереп чыгара икән шул...

* * *

Ул җәйне безнең авыл тирәсендәге урман-сазлыкларда җиләкнең төрлесе хәйран уңган иде. Гөмбәне дә ярыйсы гына күп дигәннәр иде. Гыйлаҗ агай алдан йөреп, күзәтеп кайтмаса да, теләсә кайсы урман-сазлыкка кереп, кәрзин-тубаларыңны төшкә хәтле үк тутыра алыр идең. Ләкин без ул җәйне юньләп йөри алмадык. Торна җиләге белән нарат җиләгенә бер, аннан соң юкә гөмбәсенә бер барып кайта алдык.

Вакыт юк. Карурман юлларын без һәм безгә ияреп бүтәннәр дә тап-тарга керешсә, сугышка киткән абыйлар урнына кем басар, басудагы игеннәрне кем җыяр да ипи заданиесен кем үтәр? Авыл Советында Сәетгәрәй абый бу мәсьәләне бик каты, «кабыргасы» белән куйды, диделәр.

Аннан килеп, кара урманнарга, ерак сазлыкларга баруы да бик хәтәр булып китте. Җәй азакларында сүз таралды: имештер, безнең ерак урман эчләренә ниндидер качкыннар ияләшкән, ди, менә шулар кулына төшсәң, ычкынуы бик ансат түгел, ди. Эләксәң, тамчы да кызганып тормыйлар, ди... Шунлыктан урман эчләренә алай ерак кереп йөрүчеләр булмагандыр да... Барсалар да, өелешеп-укмашып йөриләр, үзләре белән, кылтый-мылтый гына булса да, ир-атны ияртергә тырышалар.

Без баштарак:

— Элекке заманнарда патшадан качып, боярларны, бай сәүдәгәрләрне талап ятучы качкыннар безнең карурманнарда аз булмаган инде анысы. Ә хәзер кемнән качарга, нидән качарга, аннан килеп, кемне таларга соң? — диебрәк, ул сүзләргә суган әкияте итеп кенә карый идек.

Ләкин бер-бер артлы:

— Әнә Ак Чыршының бер танасын урман кырыенда гына суеп-тунап алып киткәннәр ди инде...

— Ә үзебездә соң? Кырда тукталып калган комбайнның ярты бункер бодаен, бөртеген дә калдырмыйча, бушатып киткәннәр ләсә,— дип, тәгаенләп сөйләүләр күбәеп киткәч, ышанмыйча чарабыз калмады.

Алай да пошаманга төшмәдек:

— Сугыштан качып, халыкны талап йөрүләре үз башларына булыр. Кар гына яусын, эзләренә басмый калмаслар әле,— дип куркына башлаган күңелләребезне тынычландырырга тырыштык.

Ләкин кемнәр, нинди бәдбәхетләр ул?

Тора-бара сугыш заманының хәтәр өлгер чыбыксыз телефоннары безнең исләрне китәрерлек хәбәр ишеттерде.

Октябрь башлары булгандыр, ахры, әйе шулай. Без бер айга сонга-рып, укырга ябышкан гына идек әле,— бер көнне маңгаебызга балта түтәсе белән суккандай булды.

Безнең авылның Шакир малае Хисам да шунда карурманда бер дезертир булып качып ята, ди. Армиядә түгел, ди, юлда эшелоннан төшеп калган, ди...

«Ах» иттек. Зиһенебезгә сыймады.

— Ничек инде, ничек?

— Әле кайчан гына: кавалерист була, артиллерист була дип, баш ватып яткан идек, әле кайчан гына озатып җибәргән идек, ә ул дезертир?!.

Йөрәкләребез урыннарыннан купты. Адәм ышанмаслык хурлык — бөтен авылыбызны дегеткә буягандай итте кабахәт җан... Ничек шуңа «абый» дип эндәшеп йөрдек микән?

Аның яман күләгәсе хәтта чыбык очы карендәше Садрига да кагылмыйча калмады. Яшелчә бакчасыннан бушагач, Садриның кикриге болай да шәлпәя төшкән иде, хәзер инде тәмам беткән, изелгән кыяфәттә йөри. Ул үзе дә ни әйтергә, ни кылырга белми.

— Бугазыннан чәйнәп кенә ташлыйсы калган мөртәтне! Сиздермәде шул нәгъләт! — ди, тешләрен шыгырдаткан була.

Без, аның ныклыгын сынарга теләп, үртәгән сыманрак иттереп:

— Син алай дигән буласың да, менә бер вакыт җиде төн уртасында килеп керер әле ул сезгә... Ризыгын да, кием-салымын да бирми чыгармассыз,— дибез.

Ә ул каш-күз җимереп:

— Аңамы? Килеп кенә карасын! Мин әллә ничә патронны бүре ядрәсе белән корып куйдым инде, килеп керсә, маңгаена шалт! — дип ант итәргә үк тотына.

Садри дусыбыз гынамы, аның этисе чатан Хәкимҗан агай да, бөтен мәчет картлары да «Хисам-нәҗескә» бәддога әйткәннәр. Бары бер булып: «Үлсә дә, туган туфрагында урын таба алмас, бер гүрдән икенче гүргә күчеп йөрер ул мөртәт», дип каргаганнар ди.

Әлбәттә, Хисам-дезертир карурман сазлыгында качкын булып озак яталмас, өлешенә тигән көмешен бик тиз алачак — бу безгә төн артыннан көн килүе шикелле үк ап-ачык иде.

Безнең йөрәкләрне әчеттергәне Мәдинә апа булды. «Сугыш хәлләре ай-һай яман, теш кысып булса да түзәбез, чигенергә исәп юк: артыбызда бит Мәскәү»,— дип язган иде ул соңгы хатында...

Инде хәзер сөйгән ярының ил язмышына төкереп, изге көрәштән качып ятуы хакында ишетсә, күңеле рәнҗүләренә түзәрме? Юньләп сугыша алырмы? — дип пошаманлы уйларга биреләдек.

Ләкин сөекле сөягебез Мәдинә апага андый яман хәбәрне ишетергә дә, күңел рәнҗүләренә чумарга да насыйп булмаган икән: Хисам-мөртәтнең яманаты таралганнан соң, атна-ун көн үттеме-юкмы, фронттан: «Кызыгыз үз постында батырларча һәлак булды», дип язылган җан өшеткеч кәгазь килеп, безнен үзебезне янар утларга салды... Мондый кайгы авылыбызның Ташлар ягында да, үзебезнең Яшелләр ягында да кайберәүләрнең йортына кунып, кара канатын җәяргә өлгергән иде инде, әмма бу бит...

Тамагыбыздан ризык өзелде.

Мәчтүрә апай илереп яшь түгүдән бушанмады. Бари дусымның шул арада ике күзе генә утырып калды. Башын түбән иеп, күкрәк төбе белән үк ухылдап-ыңгырашып йөргән Гыйлаҗ агайның исә каба сакалында көмеш төкләр ишаюен әйтәсе дә юк, аның авыз кырыйлары, елмаю дигәнне бөтенләй онытып, кырыс зәһәрлектә катты...

Әмма күрәселәребез әле алда икән.

Әнә шул кара хәсрәткә чумдырган поскак яңгырлы көннәрнең берсендә кинәт Гыйлаҗ агаебыз юкка чыкты. Җиде төн уртасында...

Ни уйларга белмичә, тәмам аптырашта калдык: кәнүшнидә колхоз айгыры юк, аркасына асып йөртә торган зур букчасы да юк, әмма иң шиклесе — өендә көмеш язулы кылычы күренми. Түр стеналарындагы чүпрәк келәмдә Мәдинә апаның ядкәре булып калын чәч толымы гына япа-ялгызы эленеп тора...

Сыгылдык та калдык.

Станциягә дә, каланың үзенә дә, якын тирәдәге авылларга да шалтыратып карадылар — файдасыз: беркем күрмәгән, беркем белми...

— Акылына зыян килеп, шул хәлендә сугышка фашистларны кырмага китте микән әллә? — дип юраудан бүтән әмәлебез калмады.

Шулай аптырашта ике-өч көнебез үтүгә, кайтты бу...

Кыяфәтенә карарлык түгел: өс киемнәре ертылып беткән, сакалмыегы уралып, чуалып, йөзендә зур күзләре генә утырып калган. Колхоз айгыры да эштән чыгып ябыккан, ди.

Биленә кылыч тагып, кайларда, нишләп йөргән ул? Теле булмагач, эндәшми, язып аңлатмый... Аның «әһәй-әһәй!» дип каш-күз җимерүләреннән генә, бар, белеп кара...

«Чынлап та юләрләнде микән әллә?» — дибез. Мич башыннан төшми, эшенә бармый, һаман намаз да намаз...

Бу хәл безгә тирән бер сер булып калыр иде, бәлкем. Ләкин озак та үтми, тагын да хәтәррәге булды...

Бер дә бер вакыт җиде төн уртасында килеп керә боларга Хисам-дезертир. Үз аягы белән. Шыпырт кына. Кием-салым сораргамы, ризык теләнергәме...

Аның килеп керүе була, Гыйлаҗ агай, стенадан кылычын алып, яман авазлар белән үзенчә сүгенә-сүгенә, моның өстенә ташлануы була. Эләктерә якасыннан. Тавыш куба. Шул чакны яман куркынып Бари да уянып китә. Мәчтүрә апай илереп елап җибәрә. Юк, Гыйлаҗ агай бер нигә карамый, Хисам мөртәтнең ялваруларына төкерми дә... Бер эләктерсә, ычкындырамы соң ул! Җилтерәтеп урамга алып чыга. Әмма урамга чыккач, теге ычкынып котылырга ниятли...

Аннары ни? Аннары Гыйлаҗ агай туп-туры авыл Советы председателе Сәетгәрәй абый өенә киткән. Җиде төн уртасы дигәндә. Барып кергән дә, йөзен куллары белән каплап бер ара сулкылдап торгач, канлы кылычын өстәлләренә аркылы сузып салган һәм калтыранган бармаклары белән бер кәгазь кисәгенә: «Энем, урман-сазлардан ничә көн эзләдем, таба алмадым. Өемә үзе басып керде... Буйсынмады, илен саткан эт җанны чапкалап ташладым. Гәүдәсе капка төбендә, әйт, барып җыйсыннар... Инде мине теләсәң нишләт, энем»,— дип язып, телсез-өнсез катып калган Сәетгәрәй абыйга тоттырган...

Бөтен авылыбыз янәдән «ух» итте, янәдән ут йоттык...

Көне-сәгатендә каладан тикшерүчеләр килеп төште. «Нинди партизанщина бу, ниткән башбаштаклык бу?» — дип, бик тә усалланып тикшерергәябыштылар. Сугыш заманының законнары үтә кырыс — икенче көнне үк Гыйлаҗ агаебызны сак астында калага алып киттеләр. Анда инде хөкем һәм хөкем карары...

Каладан кайтып кергән чагында, Гыйлаҗ агайның сакал-мыеклары гына түгел, хәтта кашларына тикле көмеш кырау суккан иде...

...Хәзер аның кылычы кала музеенда саклана, диләр.

## Сажидә Сөләйманова

●

Әй, солдатлар, тигез, кыю басып,
Үтмәгезче безнең урамнан.
Кирза итек, иңбашларда мылтык,—
Артыгыздан калмый оланнар.
Яңартмагыз утлы еллар жырын,—
Улым үсеп килә, улым...

Әй, солдатлар, сез атлаган чакта
Тынып торсын шаулы урамнар.
Адым тигез, балкый кызыл йолдыз,—
Сезгә тигезләнә оланнар.
Һай күп әле жирдә жәбер-золым...
Улым үсеп житте, улым.

### Көзләр якты быел

Көзләр якты быел, язлар сыман!
Гел үзенчә ямьле көз яме,—
Сабан туйгамыни жыелганнар
Табигатьнең бөтен төсләре,
Ак каеннар сары шәл бөркәнгән,
Кызыл чулпы таккан усаклар.
Яшь миләшләр мәржәннәрен кигән,—
Бәйрәм, туйлар чоры бу чаклар!
Көзләр якты! Нурлы кояш төсле
Кайнар икмәк бизи өстәлне.
Баллы, майлы мул табыны белән,
Ил байлыгы белән көз ямьле!
Дулкын-дулкын иген кырларыннан
Амбарларга күчкән арышлар.
...Төсләргә бай, хисләргә бай көздә
Әллә нинди генә сагыш бар.
Кызыл төймә таккан яшь миләшләр,
Ак алъяпкыч япкан каеннар
Шәлләренең сары чугын сүтеп,
Таралыша сабан туеннан.
— Язга чаклы! Сау бул! — дигән сыман
Чылтыр-чылтыр чулпы тавышы...
Су өстендә казлар тавышы да,
Ахры, аерылышу сагышы.
Бай хисләре, ай йөзләре белән
Ник көзләрнең ямен азсынам?
Кояш тулы күзләр таптым быел,
Көзләр якты быел — яз сыман!

●

Ни белән үлчәнә үткән гомер?
Йөргән юллар белән.
Уй чаткысы булып йөзгә төшкән
Юл-юл сырлар белән.

Ни белән үлчәнә үткән гомер?
Менгән үрләр белән.
Үзән-үрләрендә йөргәнендә
Белгән серләр белән.

Ни белән үлчәнә үткән гомер?
Калган эзләр белән.
Кеше күңеленә орлык итеп
Салган сүзләр белән.

Ни белән үлчәнә үткән гомер?
Чәчтә бәсләр белән.
Башлар бераз җиңеләймәсме дип
Түккән яшьләр белән.

Һәм өметләр белән! — Я табылган,
Я тапталып калган.
Гомерең алда — үлчәүләргә сыймас
Хыялларың барда.

●

Кермим кеше биләмәләренә.
Бәлки анда мәңге җәйдер дә...
Ил күрергә чыксаң, азмыни ул
Күзне камаштырыр әйберләр.

Кермим кеше биләмәләренә.
Дөрес, таулар анда мәһабәт!
Күңел омтылышы гел биеккә,—
Каян килгән аңа бу гадәт?

Кермим кеше биләмәләренә,
Чикләр аша яулык болгама.
Ике ярдан икәү карап йөрик
Ташып, шашып аккан елгага.

Бер йөзәсе иде колач салып!
Кулларымны бәйлим ни белән? —
Ниятләрем яулап алу булса,
Төзәми дә туры тидерәм.

Кермим кеше биләмәләренә,—
Яклаучысы аның кылычсыз...
Күп җаннарга хаким булган саен,
Илбасарның төше тынычсыз.

Кермим кеше биләмәләренә,
Үз җиремдә ташка таш өям,—
Мәһабәт тау түбәсенә басып,
Мәхәббәткә шуннан баш иям.

## Авыл урамы

Бу урамның һәр түмгәге таныш.
Тәгәрмәчләр эзе көзгедәй.
Көз буена икәү йөргән идек
Ат юлының ике эзеннән.

Нинди сүзләр сөйләп йөрелгән дә
Ничә язлар алда күрелгән?
Без атлыйбыз. Тәгәрмәчләр эзе
Тояк эзе белән бүленгән.

Куллар гына кайчак очрашалар,
Сикереп чыксак яңгыр күзеннән.
Сүзләр тынып кала, курыккандай
Әллә синнән, әллә үземнән.

Ә бер кичне никтер син булмадың.
Юк-бар сүзләр шунда ишетеп,
Озаттырдым күрше егетеннән
Бары сиңа, сиңа үч итеп.

Капка төбендә дә торган булдык,
Мин гел юлга карап уфтандым.
Кинәт атың, йөгең белән үзең
Безнең турыга килеп тукталдың.

Ул чакларда атлар арык иде.
Көзге юлда син дә җәл идең.
Әллә нәрсә булды телгә генә,
Сорашмадым хәтта хәлеңне.

Ә син кирелэнгэн ат тирәли
Бер әйләндең, ике әйләндең.
Безнең турыда гына кырт өзелгән
Камыт бавын ялгап бәйләдең.

Тешләреңне кысып куасыңдыр
Әллә миннән, әллә үзеңнән...
Көзге юлда тәгәрмәчләр эзе
Калмый бара тояк эзеннән.

●

Ялгызым дип уйласам да,
Язмышым булды бугай...
Ничаклы сөенеч алып,
Һавадан төште тургай.

Кайларга җитә бер очы
Салават күперенең?
Шул аллы-гөлле юлларда
Җитәкләп йөртер идең.

Мин китәм әле. Күперем —
Очланмый калган җырдай.
Җирдән бер сөенче алып
Менәр бит әле тургай.

Күкләргә өмет баглаучы
Болай да күптер инде,—
Төшерим җиргә бер очын
Салават күперенең.

Күпернең ике очында,
Җирдә, күктә — без икәү!
Ялгызым дип уйлап йөрдем,
Язмышым булган икән.

## Каен

Бүлешик әле кайгыны,
Ак каен, сары толым.
Саргая торган аең бу,
Сагына торган елым.

Кем өчен сүтеп тарадың,
Ак каен, алтын чәчең?
Иренемә төшеп эреде
Гәрәбә кебек яшең.

Җилләр дә сиңа елыша,
Һай зифа, сылу каен.
Башыңны идерсәләр дә,
Сынма син, сылукаем.

Сөйләшик әле серләрне,
Ак каен, сары сагыш.
Сагынуны басар җырларны
Син табыш әле, табыш.

## Нури Арсланов

### Изге теләк

Тумаганнар тусын бәхете белән,
Иреклеләр җирдә ишәйсеннәр;
Туганнары имин яшәсен:
Баш өстендә кылыч яшьнәмәсен,
Татулыкта дөнья яшәрсен.

Кайтмаганнар кайтсын илләренә,
Бәгырьләргә бәллүр булып яткан
Сагыш төере, яшьләр эресен.
Ленин рухы иңсен күңелләргә —
Йөрәкләрдә ташлар эресен.

Үлгәннәрнең урыны тыныч булсын,—
Табутында сыкрап кыйналмасын
Яшәүчеләр эшенә наразый.
Бездәй генә түгел, камил булып
Үссен иде барлык нарасый.

*1969*

### Көчле дә син

*Ф... га*

Көннең көлеп туар иртәләре,
Айның аерылалмас кичәләре,
Даланың давылы,
Атның асавы,
Бәйгенең бүләге,
Ярның ялкынлысы
Инде миңа түгел...

Ләкин
Өмет өзәме соң күңел! —

Ап-ак тешләрең,
Ахак иреннәрең,
Ачык күз карашың:
(Бер — олы син бу чагында,
Бер — сабый баласың),
Сулыш алышың,
Саф, яшь тавышың,
Иркә атлауларың...
Бер чынлап,
Бер шаярып
Мине мактауларың...
Көнемне көләч итәр төсле,
Аемны сердәш итәр төсле,
Атның асавына атландырыр,
Даланың давылына ташландырыр,
Бәйгенең бүләген алдырыр,
Сөю ялкынында яндырыр —
Мәңгегә тынгысыз калдырыр төсле.
Я, көчле дә син, сылу, көчле!

*1968*

## Синең төсле

Күк йөзе ачык, аяз, зәңгәр —
Синең күзең төсле.
Таң җиле йомшак, ягымлы, саф, рәхәт —
Сүзең төсле.
Көн көләч тә, якты да, нурлы да —
Шат йөзең төсле.
Син охшамаган бер кемгә дә,
Фәкать үзең төсле.
Мәҗнүнең сөю шәрабын бер генә тамчы эчте
Һәм исерде айнымаска! —
Инде гел сәрхүш бу башка
Бар дөнья синең төсле!

*1969*

## Сөйдең—көйдердең

Башларымның, акылын җуеп, әйләнгән чагы,
Яшәреп җаным егеткә әйләнгән чагы.
Тел сөяксез — сөйләсеннәр, ни сан аларга!
Бүген минем кәлисәмдә бәйрәмнәр чаңы!

Сөйдең — көйдердең йөрәкне, ут икән җаның,
Мәңге айнымастай итеп исерттең, ярым,
Иярсез, йөгәнсез килеш, бәхетле таңда,
Алып очтың далаларга, чая толпарым.

Кайда тынгы, кайда ирек? — күр, мин богаулы,
Әгәр дә син әмер итсәң — аударам тауны!
Тәңресеннән вәхи алган пәйгамбәр сыман
Кояш инде күкрәгемә, йолдызлар яуды!..

*1968*

●

Мәхәббәткә рөхсәт сорамыйлар,
Мәхәббәткә рәхмәт әйтмиләр,—
Ул бүләк тә һәм бурыч та түгел.
Мәхәббәтне гаеп итмиләр
Сөя белгән, сөелә белгән җаннар.
Шулар белән бергә атладым:
Сөймәгәннең сөюен теләдем мин,
Сөйгәннәрнең бәхетен якладым.
Туфрак диләр кеше яралышы,
Мин яралган, ахры, нәкъ уттан!
Мәхәббәтем!
Әгәр килсәң мине озатканда,
Түзә алмас идем мин анда да,
Сикереп чыгар идем табуттан!

*1969*

Чыраемны сыттым исә
Үң кабагым тартыша:
Сырхавым да, ахры, миңа
Көләч булырга куша.

Сырхавым да үзем кебек
Дивана бугай минем,
Тик якты чырайда гына
Үзенә таба имен.

Врачлар «теңкәдән» диләр,
Теңкәсен теңкәдер дә,—
Көләч чагымда кабагым
Алай тартышмый бер дә.

Кашыңны җыерма, Нури,
Сырхаулар үтәр әле.
Үзеннең дә, кешенең дә
Күңелен күтәр әле.

*1968*

●

Халык әйтте:
— Мин ташкын,— диде,—
Ярларны ишәм!
Кеше әйтте:
— Мин тамчы,— диде,—
Ташларны тишәм.

Булсын гына мәйдан киң безгә! —
Тамчылардан тора диңгез дә.

*1968*

## Бер тәнкыйтьчегә җавап

Син: «Вак-төяк җырлар язма,— дисең,—
Син яз,— дисең,— өндәп көрәшкә.
Мәхәббәт-дәрт белән азма»,— дисең,
Битәрлисең күңелем көләчкә.

Ә бит канлы сугыш кырларында
Көләчлегем мине саклады,
Шул «вак-төяк» җырлар фронтларда
Бизәделәр солдат хатларын.

Шул көләчлек белән окоплардан,
Көрәшләрдән исән чыгалдым,
Алга үлем килгән минутларда
Дәртем белән аны егалдым.

Тик «яшәсен» белән яшәп булмый,
Тик «алга»дан алга китмәк юк,
Тирән хисләр белән өртелмәсә —
Бу сүзләрдә берни хикмәт юк!

Мәхәббәтем белән яшәдем мин,
Һәм рухландым аның нурыннан:
Мәхәббәттән мәхрүм булсам әгәр,
Нәрсә килер иде кулымнан!

Син вак-төяк борчуларың белән
Хисләремә юкка кагылма:
Мин һаман да калам Беранжедай
Шул «вак-төяк» җырлар ягында.

*1968*

## Көзгә моңнар

Алтын көз, алтын көз!
Яз ярып, көзен шиңәргә
Сары яфрак түгелбез;
Моңайтмый көзгә җилләр дә —
Тумыштан шат күңелебез;
Ә урамда алтын көз.

Нинди тылсымлы бу хәят,
Язын да, көзен дә шәп,—
Эх, яшәү нинди гаҗәп!
Шул матурлык кочагында
Мәңге булсачы яшәп,
Мәңге булсачы яшәп!

*1967*

## Адым саен әкият

Сембер, Самар, Сарытау, Сарай
Якларын карап,
Төшәм түбән, юлдашым — Ай,
Шәп бара кораб.

Барам элекке җирләрдән,
Иске эзләрдән;
Ярлар, сулар, кешеләр дә,
Барысы үзгәргән.

Үзгәргән кайтмаска бер дә
Кабатланмаска.
Тик иске төшә хәтергә,
Уй килә башка:

Даһи да, шагыйрь дә имәс[1],
Мамай — хан гына.
«Мамай-Курган» дигән үлмәс
Исем калдыра.

Ул сунарга чыккан бары
Шушы курганга.
Әмма Алман фашистлары
Дулаган анда,

Бөтен дөнья белә моны.
Күр нинди эшләр:
Хәзер дингез — Идел суы,
ГЭСлар, төзелешләр!

Мамайны кабереннән ал да,
Торгызып шунда,
Илт кенә Мамай-Курганына,
Я бер шлюзга.

Элеккедәй ат уйнатып
Килгәндә җилеп,
Туктар иде, тезген тартып,
Кинәт чигенеп,

Шашар иде аптыраудан:
«Идел буылган!»
Яки һәйкәл-батырлардан
Өркер иде хан.

Ләкин рәхмәт әйтер иде
Ул фашист яуга:
«Күтәргәнсең кабат мине
Мәңгелек данга.

Тик безнең язмыштан харап
Язмыш юк, аңла,
Акылың булса килмә кабат
Минем курганга».

Җәйрәп ята Идел-елга,
Ярлар, утраулар...
Күпме сулар аккан монда
Һәм күпме яулар...

Һавада хыялый аем,
Кич шундый әйбәт.
Идел буйлап адым саен
Елъязма, әкият.

*1968*

## Кинешма бәете

Җил өрә, дулкыннар уйный,
Җилкәннәр түш киергән.
Киләләр агымга каршы
Көймәләр кем иленнән?

Кызыл күлмәк, билдә кушак,
Унлы-суллы пистолет,
Көмеш саплы кәкре хәнҗәр...
«Кунакларны кыста!» дип,

[1] Имәс — түгел (*Себер һәм Урта Азия татарларында*).

Ул айкап жибәрә кулын,
Ә кулында ятаган.
Туй итә бүген корабта
Стенька Разин — атаман.

Сул кулы белән кочаклап
Утыра сөйгән ярын.
Ә яры бик сылу, моңсу,
Ватаны Иран аның.

Жай чыгып, бер көнне чит ил
Корабын талаганда,
Атаман күргән сылуны,
Бер төбәп караган да,

Гашыйк булган. Алам, дигән,
Үземә хатынлыкка.
Ашыкма, атаман, алай,
Язмыш нишләтер, тукта!

Степан утыра кочаклап,
Сылудан алмый күзен.
Каш астыннан яраннары
Күзәтә аның үзен.

Теләмиләр атаманның
Кыз белән булашуын.
Менә җыр башланып китә,
Басып мәҗлес шау-шуын.

«Алыштырды хатын белән
Безне — дус-яраннарын.
Бер генә төн маташты да
Ирлеге бетте аның».

Күк күкри кинәт, болытлар
Каралып каш җыера,
Шактый кәефле атаман
Сикереп урыныннан тора.

Күтәреп ала сылуны
Ул көчле кулларына,
Карчыга карашын ташлап
Киң Идел суларына,

Әйтә: «Волга, туган анам,
Әй изге анам минем,
Моңарчы Дон казагыннан
Бүләк алмаган идең,

Инде ал...»
Яшен ялтырый,
Болыт суга тоташа.
«Кинешь мя?!..»[1] дип,
өзгәләнеп,
Кыз соңгы тапкыр дәшә.

Дулкыннар ала сылуны —
Иделгә күмелә мәет.
Шул була туйның язмышы,
Шушында бетә бәет.

Кинешма дигән бер кала
Иделдә бар бүген дә.
Шул кала каршында сылу
Ята ди су төбендә.

*1968*

## Идел такмаклары

Акчарлак та, пароход та,
Болытлар да ап-аклар...
Моңаюдан, шаярудан
Чыгадыр бу такмаклар.
Акчарлагым, акчарлагым,
Канатың тия суга.
Акчарлак булсаң да миңа,
Мин балык түгел сиңа.
Ансат кына тотармын дип
Җәтмәләрең кордыңмы?
Моторлы көймәләр кебек
Бик күтәрмә борыныңны.
Акчарлакның, мескенкәйнең,
Тамак ялгау нияте.
Ә балыкның ни языгы?
Ул да бит җан иясе.
Мин Идел, син ярым булсаң,
Ташыр да тулыр идем.
Акчарлагым, янда булсаң
Балык та булыр идем.
Суның аргы ягы бар,
Суның бирге ягы бар.
Берсе син, берсе җырларым —
Җанның ике яры бар.
Пароход узып бара,
Үзе ак, язуы кара.
Нигәдер берсе миңа да
Гел карап-карап ала...
Палубада җилләр уйный,
Ни икән ниятләре? —
Күтәрә шуклар болай да
Бик кыска итәкләрне.
Акчарлакка җимгә икмәк
Атасым килә минем.
Иделгә түгел, бәхеткә
Батасым килә минем.
Иделдә бәхет янәшә —
Оят булыр күрмәсәң,
Ул үзе куна кулыңа,
Авыз ачып йөрмәсәң.
Әстерханның чикләвеген
Әстерханнан тапмадым.
Чикләвек бирмәсәң бирмә,
Сиңа булсын такмагым.

*1968*

---

[1] Кинешь мя (борынгы славянча) — кинешь меня, ташлыйсыңмыни, ыргытасыңмыни мине?! дигән сүз.

## Равил Фәйзуллин

### Алмазга

*Аталар*
*улларына калдыра*
*васыять итеп*
*эшкә ашмаган хыялларын,*
*кыла алмаган зур эшләрен.*

*Гел шулай.*
*Буыннан буынга.*

*Кабул итәләрме уллары, юкмы,—*
*аталар калдыра...*

Саумы, улым,
чыгышым һәм баешым минем!
Исәнме, син,
Яңа Кеше!

Дөнья инде шушы була!
Я, нинди ул?

Сиңа әле күпме төс күрәсе!
Күпме уй-хис кичерәсе!
Күпме мәгънә төшенәсе
һәм беләсе...
Бер әйтерсең үз сүзеңне
дөньяга.
Исәнме, улым!
Син гел мин дә,
мин дә түгел.
Бу күз-кашлар — ул син.
Бу аяк-кул — ул син.
Ә шулай да, беләсеңме,
син — мин!
Тәнеңдәге һәр күзәнәк
минем өмет белән тулы...

Мин дөнья бирдем сиңа,
һәм соралыр синнән
дөнья кадәр!

Менә шушы, безнең бу җир.
Әйдә таныш!
Күр, сөен, кайгыр, яшә!
Үз иманың булсын.

Тик ул иман
сызып ташламасын минекен.
Мин — әтиең.
... Әгәр ялгыш
миңа якын кешеләрдән йөз чөерсәң,
мин сокланганнардан җирәнсәң,
мин табынганнарга сырт куйсаң,
мин сөйләгән телне,
мин көйләгән көйне онытсаң...

Юк, юк!
Болай уйларга әле хакым юк!

Хыялларың минекеләрдән баш алыр дим,
юлда калган арбамны син күкрәк белән
этәрсең дим,
күңелең минекеннән күп аграк,
һәм сафрак булыр дим,
кешеләрне яратуың күпкә артык,
кешелегең минекеннән зур булыр дим,—
шуңа ышанып,
дулкынланып һәм куанып,
«Саумы, улым!», дим.

●

Мин зур түгел. Мин —
үзем кадәр генә.
Тезләнмә!

Бәләкәй түгел мин. Мин —
үзем кадәр әле!
Кизәнмә!

●

Яз төсе бу күздә!
Күренәме күзгә?..
. . . . . . . . .
Үсмерчактагыдан
дөнья шактый үзгә!

Табигатьтә яз-көз
элеккечә кана!

...Еллар үткән саен
язлар җитми кала.

●

Үлемнәре белән үлемсезлек
яулап ала чын-чын
шагыйрьләр.
Кемдер сорар: кая дәлилең?
Мин дәшмим.
Каберләре әйтсен
Бабич,
Кәрим,
Кутуй,
Җәлилнен...
Үлеп күрсәттеләр безнен
уллар...
Гомерләре булды, һай, кыска!
Ә бит үлеп үлемсезлек
яулау —
бердәнбер юл түгел
тормышта...

●

Өндәде,
чакырды,
әйдәде
кычкырып, я үксеп...
Ишетмәделәр.
Гомер кичте
жирдә ялгыз җирсеп.

...Җеназасында халык күп:
урам — тоташ агым.
Аңларга теләүдә шәхесне
иң беренче адым.

●

Җанга якын җаннар китә тора.
«Яшәгез, яшьләр! Афәрин!» диючеләр,
җилкәдән кагып, безгә юл бирүчеләр
китә тора.
Күбрәк —
килүчеләр,
килүчеләр,
килүчеләр...

Суксаң тимер өзсәң дә,
бассаң бакыр изсәң дә,
үзеңне Салсал батырдай,
я Алыптай сизсәң дә,
юл чыкканда изге теләк
теләүчеләр кирәк икән.
Аталарча фатихалар
бирүчеләр кирәк икән!

Җанга якын җаннар китә тора.
Килүчеләр, килүчеләр, килүчеләр...
Без аларны каршы алганда
сөенешеп һәм кул биреп,
искә төшә безгә фатихалар биргән
аксакаллар, ил картлары.
Боекканнар, имеш, пышылдыйлар кебек:
«Фатиханың ахыры бәхиллек,
фатиханың ахыры бәхиллек...»
Кылган эшләр бәхилләрлекме?
Җанга якын җаннар китә тора...

●

Миңа бары бер җыр кирәк.

Әйдә, көн дә мине үксетсен ул,
ярсытсын, изрәтсен,
я тетрәтсен.
Әйдә, көн дә
утерсен һәм терелтсен ул —
тик көрәшкә генә әйдәсен,
тик яшәргә генә әйдәсен!

Бары бер җыр кирәк миңа
бу тормышта,
бары бер җыр...

## Хәсән Сарьян

# ПАКУ!

хикәя

*Фирузәгә*

Алар икесе бер көнне чирләп егылдылар.

Ноябрь иде. Җылы, яңгырлы октябрьдан соң кинәт суытып җибәрде. Атна эчендә җир туңып, Агыйдел читләрен боз тотты. Кистереп кар җилләре исә башлады. Ләкин кар үзе һаман юк — көннәр ямьсез, салкын иде.

Җәй буе тышта, ишек алдында уйнап, иркен, яктыга өйрәнеп калган улыбыз, иртә-таң җиттеме, тыш дип буынга төшә башлый. Бу жил, бу салкында өйдә генә утырсын өчен ниләр генә кылмадык без! Алмаган тәти, уенчык калмады! Тик Салават берсе белән дә озак юанмый — көн аз гына ачылып, кояш күренеп китү белән, тыш исенә төшә дә, җәй буе сөйрәп, ватып бетергән сөекле самосвалын күтәреп, ишек төбенә барып баса:

— Нәнәй, ты-ыш!.. Нәнәй, ты-ыш!..

Шулай тотына бер көйгә. Без:

— Ух, тышта суык, өш-өш!..— дип карыйбыз.

— Тышта усал маэмай! Бохар песие!..— дип куркытабыз. Ләкин малай берсенә дә карамый — аның саен үз сүзләнә генә:

— Ты-ыш!.. Ты-ыш!..

Ахырда сузып елап җибәрә: аның башкача теле юк.

Без Гөлдәр белән икебез дә институтта укытабыз. Мин икенче, Гөлдәр беренче генә елын укыта. Безнең эш көне, менә моннан монда хәтле дип, кисеп кенә куелмаган. Эшнең күбесе өйдә. Әйтергә кирәк, иң авыры өйдә. Көн тудымы, икебез ике өстәлгә утырып лекциягә әзерләнәбез, контроль эшләр, курсовойлар тикшерәбез. Алары бетсә, беребез минимумга, икенчебез диссертациягә тотына — бил язарга да вакыт тими иде. Шундый чакны, житмәсә, бу Салаваты!.. Ахырда безнең сабырлык бетә: икебез ике яктан балага кычкыра башлыйбыз.

Шунда әби аны тын гына киендерә дә, «Әйдә, улым»,— дип, йөрергә алып чыгып китә. Алар көн саен үзебезнең Тукай урамындагы юкә аллеясында йөриләр: аскы якка китсәләр, Агыйдел өстендәге Салават бакчасыннан, өске якка китсәләр, үзәктәге Матросов паркыннан әйләнеп кайталар иде.

Ул көнне Салават йокысыннан ук әллә ничек көйсезләнеп уянды. Үзе алай, башка вакыттагы кебек, тыш дип тә йөдәтми — өзлексез мыжгып, тик нервыга тиеп тора.

— Туктамас инде бу бала! — Гөлдәр китапларын ук читкә этәреп куйды.

— Гел генә кычкырып торгач...— дип мин дә эшемнән туктадым.— Әйдә, ичмасам, әзрәк күңелен күрик, мавыгып китмәсме.

Без аякларны аерып идәнгә кара-каршы утырдык та үзе йөри торган бер машина белән, Гөлдәр миңа, мин аңа таба җибәреп, уйнарга тотындык.

— Ух, нинди йөри!.. Карале, Салават, кара...

Салават әйләнеп тә карамады, сандык өстендә оекбаш бәйләп утырган әбисе янына барып, җиңеннән тарта башлады.

— Нәнәй, ты-ыш... Нәнәй, ты-ыш...

— И йөрәккәем, кара нинди тарта! — дип, әби сандык өстеннән төште.— Әйдә инде алайса, әйдә. Оекбашыңны бәйләп бетерим инде дип кенә утыра идем. Ярар, кайткач бетерермен әле, керен дә алып куярмын. Иртәгә, алла бирсә, аякларың майда йөзәр.

Малай, аның һәр сүзен аңлаган бер кешедәй, елмаеп ук җибәрде. Без — унбишәр ел укыган ике укытучы — ике яше дә тулмаган бер баланы ни сөеп, ни почмакларга бастырып көйли алмаганда, им өчен бер ел да укымаган әби аның көен шундук таба иде.

— Син дә гел шуның көенә генә торасың, әни,— дип, Гөлдәр каты гына бәрелеп алды.

— Йөреп керик әле,— диде әби.— Сабый бит: әллә ниләр уйлыйдыр да — әйтергә теле юк...

Ул үзе дә нидер әйтеп бетермәде шикелле... Үпкәләде, ахры, дип уйладым мин.

Алар киенеп, Салават иске калтырчадай самосвалын сөйрәп, чыгып киттеләр.

Ләкин, бер ярты сәгать үттеме-юкмы, әйләнеп тә кайттылар.

— Бу мәгәзиннән генә урадык,— диде әби.

Аның бер кулында ипидер, шикәрдер тулы сетка, икенче кулында малай, ә малай кулында уенчык самосвалы иде. Әби уфылдап Салаватны идәнгә төшерде.

— Шулай нәнәйдән күтәртеп кайталармыни, ә? — дип, Гөлдәр малайны шелтәләп алды.— Син бит инде зур. Их сине!

Әби монысын яратмады.

— Күрмисеңмени баланың йөзен? — диде ул.

Мәгәр мин, баладан бигрәк, аның үзенә карап куркып киттем: аның болай да ябык озынча йөзе тартылып, күм-күк булган, сулышы капкан, тавышы да ничектер тоныкланып кипкән иде. «Томау гына дип йөргән иде дә, ай-һай, томау гына микән?..» — дип уйладым мин. Ул арада әби аягыннан, өстеннән салды.

— Хәзер үк гәрчичнәй ванна ясарга кирәк. Кызым, син бар урын әзерлә, мин су куйыйм,— дип сөйләнә-сөйләнә кухняга кереп китте. Анда газ плитәсен кабызып җибәрде.

Эш кайгысы түгел иде инде. Гөлдәр эчке бүлмәдә матрас, мендәрләрне каккалый-каккалый урын җәя башлады. Мин Салават белән ишек төбендә калдым. Салават карышмый гына чишендертте. Башка вакыт булса, үзем дип, хәзер кулга ябышыр иде, әле тик кенә тора — чире күзенә үк чыккан иде. Чишендереп кулыма алу белән, башын иңемә салды. Мин аның бәләкәй генә йомшак гәүдәсен күкрәгемә кыстым. Су җылынганчы шулай тордык. Әби таска су таманлады да:

— Бир инде, кияү,— дип балага үрелде. Аның биленнән еш кына радикулит китереп тота, иелеп эш эшләү аның өчен авыр иде.

— Тукта, әби, Гөлдәр килсен инде,— дидем мин.

Алар башта, биш-ун минут, Салаватның аякларын горчицалы суга тыгып тоттылар. Аннары битен-кулын юып, йомшак сөлге белән ышкый-ышкый сөрттеләр дә урынына илтеп салдылар. Мин градусник китереп бирдем. Температурасы утыз җиде ярым иде.

— Әллә врач чакыртабызмы соң? — диде Гөлдәр.

— Врач чакыртып та инде...

Салаватның бер бүген генә чирләве түгел, врачын да чакырткан бар.

Ләкин сиңа бернинди врач та, килү белән, баланы терелтә алмый, карап рецепт кына язып китә. Күп вакыт рецебының да кирәге булмый: кичтән ут янып яткан бала иртәнгә инде көлеп уянган була, аптекалар дару ясап та бирә алмый кала.

— Ярый, көтик алайса,— диде Гөлдәр.

Әби сөт кайнатып китерде. Чәй дәмләп, аны баллап эчерде. Салават берсенә дә карышмады, гүя аның үзенең дә авырып китәсе килми иде.

— Инде шулай тирләп кенә ятсын, бәлкем үтеп тә китәр, боерган булса,— диде әби. Аның үз хәле дә яхшыдан күренми иде.

— Әллә үзең дә ятып карыйсыңмы, әби?

— Кая ул! Булмаганны! Хәзер аш салырга кирәк. Кайнар шулпа да эчсә, кук итеп торыр әле менә.

— Ашны үзем салырмын,— дип, Гөлдәр дә әйтеп карады.

— Юк, ятмыйм әле,— диде әби.— Сез миңа карамагыз. Карт кешенең шул инде аның: әле генә таза, икенче карауга — юк. Сөякләрнең дә мае беткәндер инде.

Аның безгә чирен әйткәне юк. Авырып китсә дә, болай гына дип, бер ара ятып алгандай итә дә торып тагы эшенә тотына. Гүя ул эшне, без башлаганчы дип, бездән куркып-көнләшеп эшли иде. Магазинга ул йөри, базарына ул йөри... Базардан ул көн саен сарык итенең симезен алып кайта. Мәгәр үзе андый ит ашамый, ул аны безнең өчен генә алып кайта, үзе берәр ужау шулпа белән бер-ике бәрәңге генә капкалый иде. Бу айларда шулпаны да өресеннән аерып эчә башлады. Җан асраганы — чәй белән коры ипи. Ак майны авызына да китерми иде.

Ул көнне ул ашлар пешереп йөрде. Ашагач-эчкәч, кашык-аякларны юып куйды. Тик шуннан соң гына ятты, анда да әле:

— Бала дип борчылмагыз, төнлә үзем карармын,— дип чишенми генә ятты.

Без, көндәгечә, сәгать унбергә кадәр утырдык. Салават та, әби дә йоклый иде булса кирәк — алар бүлмәсендә тавыш-тын юк иде.

Төнлә безне бала елавы уятты.

Әби инде торып, аны кулына алган, «җә-ә... җә-ә... җә-ә...» дип, талгын бер көйгә иелә-сыгыла тирбәтә башлаган иде.

— Тәне ут инде менә — ут! Сипсәң сулар кибәр! — диде ул, аннары кинәт: — Ай аллам! — дип караватка башына сөялде. Мин тиз генә кулыннан Салаватны алдым.

— Уф, исем авып китте, егылам дип торам...

— Син ят кына, әни,— диде Гөлдәр.

Әби ятты.

— Әллә ни булды әле миңа, балалар... Бер дә болай озакка киткәне юк иде ләбаса. И ходаем, авыр чирләр салып, түшәк хастасы гына итмәсәң ярар иде! — Бу аның мин белгәннән бирле беренче кабат чирен әйтүе иде.

— Юкны сөйләп ятма әле,— диде ана Гөлдәр.— Сиңа кем йөрергә куша? — Күңеле йомшак булса да, теле катырак иде аның. Ул малайны урынына иләп салды да, градусник куеп, сүзсез генә караватка читенә утырды күз яшьләре тулып, бала өстенә тамарга тора иде.

Салават инде, безне уяткандагыча, өзгәләнеп еламый. Елар хәле дә юк иде, сузылып кына төшкән дә өзлексез сыктый гына. Хәтта безне дә танымады кебек. Градусникны алып карасак — тәне кырык градус белән яна иде!

Шунда кинәт төнге лампаның зәңгәр яктылыгы, көзге төннең кара тынлыгы, чирле баланың ямьсез сыктавыннан йөрәгемә кара шом килеп ятты. Гүя улымның яна сауган сөттәй җылы, тәмле гомеренә кы-

зыгып, иңсәм аша гына үлем карап тора иде. Мин тетрәп киттем. Шушы үлем тынлыгы белән үлем зәңгәрлегеннән йолып калырга теләгәндәй, Салаватның йөзенә иелдем.

— И улыкаем! Ниләр булды соң әле сиңа, былбылым!

Аның будай эссе тыны битләремне пешереп алды. Ул бөтенләй телдән калган, җилсенеп кабарган күзләре белән миңа туп-туры карап, нидер әйтә сыман иде. Кара үлем баш очына килеп баскандай булды. «Әллә... әллә?..» дип котларым очып китте.

— Паку!.. — диде ул кинәт.

— И улым, бу вакытта нинди «паку» ди инде?

— Кая, дару эчереп карыйк әле, бәлки оныттыр,— диде Гөлдәр. Аптечкадан норсульфазол эзләп алып, ярты урынына бөтен бер таблетканы йоттырып җибәрде. Салават чәчәп елый башлады.

— Паку!..

— И йөрәккәем! — диде әби.— Хыяллана инде шул «паку»ы белән. Сүзен дә каян тапкан диген. Уйнатыгыз әйдә, тыңласын.

Мин икеләнә калдым: үзе төн уртасы, үзе әби авырый. Аңа мондый чакны түгел, таза чакны да тавыш ярамый. Без радиоланы күп вакыт шул Салават өчен генә уйнатабыз, анда да әле әби чыгып киткәндәрәк уйнатырга тырыша идек. Пластинка уйный башладымы, Салават «Паку!» дип бөтенләй бу дөньядан китә, башларын кыек салып йотыла торган иде. Мин бер Гөлдәргә, бер әбигә карап алдым.

— Уйнатыгыз, уйнат,— диде әби.

Мин әкрен генә радиоланы куйдым. Көмеш тәңкә тавышлары түгеп симфоник оркестр уйнап җибәрде, ана сыздырып кына концерт гармуны килеп кушылды. Караңгы тынлык эченнән, дулкыннары тәгәрәшеп, ерак Идел чайпала башлады — «Идел буенда» дигән музыкаль әсәрдән «Фәйрүзә ариясе» иде бу. Иңрәп яткан бала, чиренә дулкынга юылып төшкәндәй, изелеп кенә йоклап китте. Булган-булган инде дип, мин тагы бер-ике көй уйнатып алдым. Шуннан соң гына тынычланып радиоланы туктаттым. Теләнә бассам, шарт итүдән малай уянып китәчәк, шуңа күрә розеткадан штепселен генә тартып алдым — радиола бер тавышсыз сүнде. Инде ятарга да мөмкин иде. Ләкин башым мендәргә тиеп тә җитмәде, тагын:

— Паку!..

Сикереп торып малай янына килдем.

— Болай булмый бит инде, улым. Нәнәйнең дә башы авырта әнә: уфәй булган. Йокла, иртәгә туйганчы уйнатырбыз...

— Паку!..

— Уйнат, кияү, уйнат,— диде әби.

Ул вакытта әле озак уйный торган татар пластинкалары юк иде. Булганы — кыска. Минут эчендә әйләнеп, җырлап та чыга. Шалт та шолт пластинка куюдан да бушамыйсың. Мин берәр озак әйләнә торган пластинка эзли башладым. Алар безнең күп түгел — дуртме, бишме генә. Шунда исемә кылт итеп Эдвард Григ килеп төште. Аның бездә «Пер Гюнт» сюиталары бар бит! Григ музыкасы йөрәккә бик ягымлы. Сандугач тавышы белән Сольвейг та җырлап җибәрсә — үзәгенне өзә дә сала инде! Әби колагына да каты бәрелмәс дип, Григны куйдым.

Менә табадай зур пластинка да әйләнеп бетте. Салават йоклый иде. Мин юри көтеп торам. Ләкин малай, пластинка алмаштырып куяр вакыт үтү белән, кыштырдый да башлады. Инде барыбер йоклап булмаячак иде, мин якты утларны сүндердем дә бер туктаусыз Григны уйнатырга керештем. «Сольвейг җырын» гына да мин бер егерме кат уйнатканмындыр! Ул көй минем бавырларыма үтеп төште. Инде үтерепйокы килә башлады. Мин башларымны селкеп карыйм,— юк, китми, баса гына. Шулай интегүемне күреп яткан әби берсендә түзмәде, әйтте:

— Ай, үзем уйната белсәм шуны!..

Салават сәгать өчләрдә генә йоклап китте. Радиола кызып, өйгә резин исләре чыккан иде инде.
Соң ятсам да, бер өйрәнгән вакытта уяндым. Кухняда әби кыштырдап йөри. Гадәтенчә, без торуга ашлар җылытып, чәйләр кайнатып куйган. Ләкин чырае бер дә юк иде.
— Нигә син торып йөрисең, әби? Ятар идең...— дидем мин. Гөлдәр дә кушылды:
— Әйткән идем дә, тыңламый бит.
— Бүген хәлем ару инде,— диде әби.
Салаваткa да бүген хәл кергән: утыз сигез градус белән, еламый гына ята иде. Шулай да врач дәшмичә ярамас: иртән утыз сигез булганны — кичкә нишләр? Гөлдәрнең бүген тугызга барасы икән, киенәкиенә миңа ниләр эшләргә кирәклеген өйрәтә башлады:
— Норсульфазол минем өстәлдә. Берсен икегә бүлеп эчер дә сәгать саен температурасын үлчәп тор. Сәгатен язарга онытма. Мин врач чакырып китәрмен.
Без әби белән икәүләп Салаватка дару эчердек. Ул аны кире чыгарды. Без тагын эчердек. Аннары әби кухнядагы эшләрен бетерде дә:
— Кая, базарга барып кайтаем әле. Һавага чыксам, бөтенләй хәлләнеп китәрмен төсле,— дип аптырабрак тәрәзә катына килеп басты.
Без шәһәр читендә торабыз. Бездән соң Салават урамы гына. Аннан соң шәһәр бетеп, башлар әйләнгеч таулы-ташлы яр киселеп төшә. Аста тасмадай Агыйдел. Чак кына өстәрәк салават күпередәй дугаланып менгән чуен күпер. Шуны чыккач та, биек дамба булып, һәр язны су баса торган «Чегән яланы» өстеннән Оренбург юлы башланып китә. Сул күздә Агыйдел, уң күздә Дим тугайлары җәелеп ята. Безнең кала үзе — җырларда җырланган биек тау өстендә. Безнең тәрәзәдән генә дә кырык-илле чакрым җир күренә! Барысы да бердәй соры төскә кереп, кара-күксел томанга өртелгән иде. Бу — әбинең туып-үскән, кыз булып җиткән яклары. Оренбург юлы алар авылына тия язып кына үтә икән.
Әби шулай җирсеп торды-торды да:
— И гомерләр!..— дип тәрәзәдән күзен алды. Ләкин шунда аңа нидер булды — тәрәзә яныннан китәм дигәндә генә, капыл: — Уф, алла!.. Уф, өзелде!..— дип эчен тотты да бөгелде дә төште. Килеп тотмасам, егылып, бер-бер җирен бәрми-имгәтми калмый иде.
Мин аны үзләре бүлмәсенә алып кердем. Ул шулай бөгелеп каткан көе генә урынына ауды.
— Әллә врач чакырыйммы, әби?
— Юк, кирәкми. Салаватка килә бит, шуңа күрсәтермен әле. Грелкага кайнар су салып бирсәң — булды.

Врач килгәндә безнең өйдә ике авыру ята, ә радиоладан ялгыз Сольвейг җырлый иде.
— Күнелле сездә! — диде врач.
Мин аңлатып бирдем.
— А-лай-мыни?! — диде врач.— Алайса уйнасын. Тик сезгә комачауламыймы соң, апа?
— Юк-юк, уйнасын,— диде әби.
Врач Салаватны бик җентекләп карады. Озын, нәфис бармаклары белән күкрәк авызларын, бөер, бавыр тирәләрен баскалап чыкты. Бик озаклап үпкә, йөрәкләрен тыңлады, үзен, тамагын тикшерде. Карамаган бер генә җире дә калмады.
— Үпкәсенә суык тигән,— диде ул.— Пневмония.
Аннары, балалар врачымын дип тормады, әби янына килеп утырды. Аны да әйбәтләп карады булса кирәк: эченнән рәхмәтләр укуы әбинең тавышына ук чыккан иде. Ниһаять, врач:

— Бөерләрегез авыртмый идеме, апа? — дип сорады.
— Анысы күптәнге авыруым инде, кызым, күптәнге,— диде әби.
— Ә грипп белән авырмаган идегезме?
— Шул грипп булды микән — томаулап алган идем алуын. Йөреп үткәрдем бугай инде анысын.
— Һм-м... Ятып та тормадыгызмыни?
Монысына әби җавап бирмәде, ишарә генә итте, ахры.
— Участковый врач чакыртмый булмас бит әле, апа,— диде врач капыл гына.
— Куй, кызым, кешене мәшәкатьләп йөртмә. Үзең генә берәр даруын бир дә...
— Юк, апа, алай гына булмый,— диде врач. Торып, безнең якка чыкты.— Сез борчылмагыз,— диде ул миңа,— участковыйны мин үзем чакырып китәрмен.— Шуннан, Гөлдәр өстәленә утырып, берничә рецепт язды да һәр кайсын аңлата-аңлата миңа бирде.— Барысын да, бигрәк тә менә бу пенициллинны бүген үк алырга тырышыгыз. Инде берәр сәбәп белән ала алмасагыз, сестрага әйтегез, үзенеке белән башлап җибәрсен.
Ул әбинең исем, фамилиясен язып алды да китәргә кузгалды.
— Я, Салаватик, хуш! Мин дүшәмбе тагын килермен. Ә музыканы — уйнатыгыз. Хәзер аңа иң кирәге — үз-үзен юату, үз күңелен үзе күтәрү. Ярый, апа, сез дә озак ятмагыз, терелегез,— дип хушлашып чыгып китте. Сүз дә юк, әйбәт, ягымлы врач иде.
Үзебезнең участковый сәгать уникедән соң гына килде. Монысы тулып җәелгән бер апа иде. Исәнләшү урынына:
— Авыру шушындамы? — диде дә пальтосын салып түргә узды.
Ул килер алдыннан гына әбигә тагы бер приступ булып, әби әле, агарып каткан көе, тынсыз-буынсыз ята иде. Участковыйның:
— Я, кай җирегез авырта? — дип соравына көчкә генә җавап кайтарды.
— Менә шушы җиремнән... тик торганда нидер өзелеп төшкәндәй булды... Күңелем болганып...
— Берни ишетмим,—диде врач.— Туктатыгыз әле шул музыканы. Бу нинди музыка бу авыру яткан җирдә?
Мин радиоланы баса төштем.
— Туктатса, бала елый...— дип, минем урынга әби җавап бирде.— Шул музыкага генә алданып ята да инде сабый, юкса хәле минекеннән дә авыр.
Врач соравын дәвам иттерде:
— Кайчан авырдыгыз?
— Бүген генә,— диде әби.— Башта менә шушы төшемнән тартып өзгән кебек булдылар... Әле инде сукыр эчәк ягыннан китереп тотты.
Врач:
— Шушындамы?.. Шушындамы?..— дип, ике куллап әбинең эчен баскалый башлады. Ул баскан саен әби ыңгырашып куя иде.
— Острый аппендицит,— диде ахырда участок врачы.— Хәзер үк «скорый помощь» чакырырга кирәк. Бүген үк операциягә! — Ул әбигә направление язып бирде.
Ул киткәч мин аның направлениесен алып карадым: диагноз янына бармак буйлыгы итеп сорау билгесе куелган иде.
— Нәрсә язган? — диде әби.
— Язмаган, аппендицит дигән...
«Скорая помощь» станциясе безгә ерак түгел — минем адым белән бер өч минутлык юл иде. Гөлдәр аптекадан кайтып керү белән шунда киттем. Дежурный хатын направлениене карады да, үзенә нидер язып, кире бирде.

— Машина тиздән барып житәр, кайтып, авыруны киендерә торыгыз.
Гөлдәр барысын да чистадан алып, әбинең өсләрен алмаштырды, «бик туңам бит әле, кызым»,— дигәч, кышкы пальтоларын, киез итекләрен кидерде.
Аннары әби:
— Кая, без чыга тораек, эзләп йөрмәсеннәр,— дип аягына басты.
Мин Салаватның бәләкәй урындыгын алдым да, икенче кулым белән әбине култыклап, күтәрмәгә алып чыктым. Гөлдәр озата барырга тиеш иде, ул киенә калды. Әби, чыгып утыру белән, ничектер капыл гына:
— Гөлдәрне какма инде, кияү,— дип сүз башлады.— Яшь ярымлык чагыннан карап үстердем бит мин аны!..
Мин моны белә идем инде. Гөлдәрнең этисе, ягъни минем бабай, заманы өчен зур гыйлемле кеше булган. Ул — «Казанның үзендә!» — Учительская школада укыган, бетереп кайткач, гомере буе татар балаларына рус теле укыткан. Тик — хатыннан гына бәхете булмаган: өч хатын алган — өчесе дә үлгән. Алардан өелешеп жиде бала калган. Бу әби шулар өстенә килгән. Аның үзеннән бала булмаган, шул жиде баланы түкми-чәчми, барысын бер тигез карап үстергән. Болары житмәсә дигәндәй, зур кызының да ике кызын карап, аларны да мәктәпкә жибәргән. Инде — безнеке...
Юк, әби әле боларны сөйләмәде.
— Хәзер аның синнән башка бер кеме дә юк, кияү.— Аталары кырыгынчы елны ук үлде. Биш абыйсы бар иде, алары да сугышта — бишесе биш жирдә югалып беттеләр. Рәфгатем Гөлдәр белән бөтенләй бер анадан иде, йөрәккәем... Харап булдылар. Жиде баладан ике кыз гына торып калды. Апасының үз семьясы, үз кайгысы... И кияү, хәзер кемдә кем кайгысы бар?.. Рәнжетмәскә тырыш инде, яме. Иркәрәк үссә дә, начар бала түгел ул...
Шунда, өй ишеге ачылып, Гөлдәр чыкканы ишетелде. Әби шым булды.
«Скорая помощь» машинасы килеп кергәндә, ул тын гына, бәләкәй генә булып Салават урындыгында утыра иде. Безнең агач өй үзе, ишек алдында ишек алды ясап, тагы бер кат койма белән әйләндереп алынган. Мин зур ишек алдына чыгып кул изәдем дә, машина безнең кече капка төбенә үк килеп туктады.
— Бәлки носилка кирәктер? — диде сестра.
— Юк,— диде әби.— Үз аягым белән...
Шулай да аны Гөлдәр белән сестра икесе ике ягыннан култыклап алдылар. Кече капкадан чыкканда, әби әйләнеп карады.
— Бар инде кер, кияү. Салават жылап ятмасын анда. Жә, исән бул...
Машина көзге пычрактан соң кантарланып каткан ишек алды буйлап, көймәдәй чайкала-чайкала, әкрен генә чыгып китте. Мин әле яңа гына әби утырып торган, инде суынып беткән урындыкны алып өйгә кердем. Ярый әле радиола туктамаган, мин кергәндә, «мүлмүлкинә дек мүлмүлки...» дип, шашып һинд артистлары жырлый иде.
Гөлдәр озак тормады, әйләнеп тә кайтты. Күршедәге мөфти мәчете кварталының өске ягында гына 1 нче клиник больница бар иде, әбине шунда салганнар икән.
— Икенче катта, тәрәзә буенда гына,— диде Гөлдәр.— Салкын булыр микән инде аңа тәрәзә буенда? Мендәрләре дә таш кебек.— Шулай да аның күңеле бераз тынычланып кайткан: ул больницада әби ягыннан чыбык очы тиешле бер абый эшли башлаган икән, шуны белгән.— Анысы әйбәт булды әле,— диде Гөлдәр.— Операцияне шул Айрат абый

ясаячак. Өеннән шалтыратып әйтте. Алтыда операция. Шуңа хәтле үзен күреп сөйләшергә иде.— Ул шулай сөйләнә-сөйләнә бер мендәр сайлап алды: — Илтеп бирим әле, ичмасам, баш астында йомшак булыр.

Бу юлы ул, бик озак торып, сәгать тугыз тулгач кына кайтып керде. Чишенмичә-нитмичә, уф дип, урындыкка килеп утырды. Мин инде көтә-көтә борчылып, ни уйларга да белми башлаган идем, сабырсызлык белән:

— Я ничек, булдымы операция? — дип сорадым.

— Булды...— диде ул. Шулай диде дә сыктап елый башлады.— И әнекәем, әнекәем!.. Бетте инде болай булгач...

Ул тегендә дә елаган булса кирәк: күз төпләре шешенеп беткән иде.

— Айрат абыен нәрсә ди соң?

— Нәрсә дисен — сабыр бул, ди. Эчен ачып кына япкач — нәрсә дисен.

Ул көн буе ашамаган да иде. Кичә кичтән калган итле шулпаны җылытып, ашарга итеп карады, ләкин тамагына үтмәде. Шулай ач көе, караңгы төнгә каршы больницага куна китте. Әбинең хәле авыр булу сәбәпле, аның янына теләсә кайчан керергә рөхсәт ителгән иде.

Гөлдәр иртән алтыда гына кайтты. Йончыган, талган иде.

— Әни төн буе күз дә йоммады,— диде ул.— Анда да әле үзен түгел, безне кайгырта. Интегеп утырма син, кызым, ди, бар инде кайт дип, куып дигәндәй җибәрде. Кияү Салават белән интегеп беткәндер, кайтып, ашарына җылы аш пешереп ашат, ди...

Гөлдәр икеме-өчме сәгать ятып алды да, отыры зиңкеп кенә торып, беренче яртыга дәресенә китте. Ул биштә генә кайтты: барышлый да, кайтышлый да әби янына кереп, азрак утырып чыккан икән. Мин шул бер үк соравымны бирдем:

— Я, ничек?

— Ничек булсын инде?.. Укол белән тоталар. Өшеткәч авыртуын сизми, ахры. Бераз йоклап та алган. Инде планнар корып ята. «Салаваттан соң бүтән балагызны карамам дигән идем инде дә, тагы бирәр малай карар идем әле», дигән була. И әнекәем...— дип, Гөлдәр авыз чите белән генә хәсрәт аралаш елмаеп куйды.— Инде табарга кирәк. Әни тавык шулпасы эчәр идем, ди.

Безнең ишек алдында күбесе тавык тота. Сорап керсәң, бирсе дә буш чыгармаячак. Ләкин мин суя, Гөлдәр тазарта белми. Кем суеп та, тазартып та бирер?

— Әллә Гайшә әбиләргә кереп карыйсыңмы? — диде Гөлдәр.

Гайшә әби минем әбинең бик якын ахирәте иде. Иңгә пинҗәк кенә салдым да шуларга кереп киттем. Олы улы Гыйлфан абый, хәзер дип, пычагын көйләде дә тавык кетәгенә чыгып китте.

Сәгать уннарга тавык шулпасы әзер иде инде. Гөлдәр аны мискигә состы да, барып җиткәнче суынмасын өчен, башта көрпәчәгә, аның өстеннән шәлъяулыкка төрде.

— Мин бүген дә иртәнсез кайтмам,— диде ул.

Мин дә, якты утларны сүндереп, радиола төбенә «дежурга» утырдым. Бүген дә кичкә Салаватның хәле начарайды. Пенициллин уколының әлегә файдасы юк — температурасы тагын кырыкка сикереп менде. Бар өмет шул музыкада иде. Музыка белән үткән авыр төннәрнең өченчесе керде.

Бер мәлне колагыма сагышлы көй аралаш бик ерактан моңлы бер кыңгырау өне килә башлады. Көчәя бара бу, көчәя бара — биш-алты

чана туй килгән сыман... Мин радиола төбендә оеп киткәнмен икән. Уяныл күземне ачсам, бер өзлексез звонок зеңли. Аң-тан калып ишеккә ташландым. Кем булыр бу, нәрсә булыр?.. Йөрәгемә әллә нинди шом төште.

— Кем анда?

— Мин...

Ачсам — ишек төбендә Гөлдәр тора. Үрелеп кнопкага баскан да шул килеш оныткан. Төнме бу, таң алдымы — һич аңларлык түгел. Шул хәтле дә караңгы, ямьсез, чоланнан төшкән ут яктысы ике адым җирне дә яктырта алмый иде. Кичләрен ялгызы өйдә калырга да шикләнгән Гөлдәр мондый караңгыда ничек йөрәге җитеп кайткандыр — белмим, аның өчен мин куркып куйдым. Телемә: «Нишләп кайттың?» дигән сорау килде. Ләкин култык астына тоткан мендәрен күрү белән аңладым, сорауның кирәге юк иде.

Мин аның кулыннан шул көе урап кайткан тавык шулпасын, мендәрен алдым. Минем алуым булды, Гөлдәр сулкылдап-сулкылдап елый да башлады.

— И әнекәем!.. И әнекәем!..

Әбинең үлеме мине дә аяктан екты. Өченче көн генә менә шушы күтәрмәдә утырып торган, сөйләшкән, үз аягы белән машинага кереп утырган кеше — инде бүген юк... Юк, юк, юк... Шунда мин, кулларым белән тотып карагандай, үлемне күрдем. Ул — бөтен ак дөньяны йотып алган менә шушы төн карасы кебек иде.

Минем бер кулымда мендәр, икенче кулымда әллә ничә кат төрелгән тавык шулпасы. Ул әле суынып та җитмәгән, шәлъяулык аша әле булса җылысы килеп тора иде.

Гөлдәр елый-елый сөйли:

— Күзләремә карап кына үлде бит!.. «Мин үлгәч, ул канатсыз калырсың инде, кызым», ди... И әнекәем, әнекәем... Ни күрде инде ул бу дөньяда? Гел без дип яшәде...

Пластинка әйләнеп бетеп туктаган иде инде. Шунда әнисенә кушылып малай елап җибәрде.

— Уйнат, ичмасам, ул җыламасын,— диде Гөлдәр.

Кичкә бетәсе эшләр бетеп, төнгә һәркайсыбыз үз урынын алды: Гөлдәр белән без Салават бүлмәсенә урнаштык, әбинең мәетен, больницадан алып кайтып, зур якка куйган идек, күрше карчыгы Гайшә әби шунда — зур якта — мәрхүмә янында калды. Аның янына тагын, пальтоларын киеп, төн кунарга әбиләр җыела башлады. Пластинка уйнатуның сәбәбен Гайшә әби белә иде инде. Ул башкаларга әйтеп тора, ләкин башкалар аңламый:

— Мәет өстендә нинди музыкә ул? — дип пыш-пыш килеп алалар иде.

Без радиоланы Гөлдәр белән чиратлап уйнатабыз. Малайның бар дәвасы — шул. Дөрес, без бик әкрен уйнатабыз. Ләкин барыбер төнге үле тынлыкта, бөтен өй эчендә, шул гына яңгырап тора, шул гына яши иде. Ул туктаган араларда әбиләрнең көйләп кенә нидер укыганнары ишетелеп китә. Ләкин күп тә үтми, тагын, өздереп, Сольвейг җырлап җибәрә — дога моңнары әллә кайда күмелеп кала иде...

Иртә белән, беренче булып диярлек, балалар врачы килеп керде. Янында сестра да бар иде. Бездәге хәлләрне күргәч, коелып төштеләр.

— И бахырым... И бахырым...— дип врач чак елап җибәрмәде.— Менә бит, әй! Нинди авыру булган инде бахырыма?

— Сез әйткән дөрес булып чыкты: бөердә,— дидем мин.— Грипп осложнение биреп, үлемен тизләткән генә.

Врач тагын:

— И бахырым... И бахырым...— дип, башын селкеп торды.

Салават, төнге өянәге җибәреп, йоклап киткән, сулыш алуы да беленми иде. Моны күргәч, врачның йөзенә нур кунды.

— Яхшы. Әлегә башка төрле дару кирәкмәс, уколны беткәнче дәвам итәрбез,— диде ул. Ләкин әле, баланы уятып, укол кадарга йөрәкләре җитмәде.

— Мин соңыннан килермен,— диде сестра.

Ул көнне бездән кеше өзелмәде. Әллә кайлардан мин белмәгән әллә күпме халык җыелды.

Әбине сәгать икедә чыгардык. Өйдә Гайшә әбиләр калырга булды. Килене мичләр ягып, идәннәрне юа, ә килененең кызы Салаватны караячак иде.

— Җылый башласа, менә шушыларны уйнатырсың,— дип, мин аңар пластинкаларны күрсәтеп киттем.

Төнлә ишеп кар яуган, җир өсте ап-ак иде. Без, әбинең иң якыннары, мәрхүмәнең гәүдәсе тирәли кузовка менеп утырдык, башкалар кемдер алып килгән автобуска тулдылар. Ә күрше-күлән койма буйларына тезелешеп, яулык очлары белән күз яшьләрен сөртә-сөртә, әкрен генә елап калды. Яшь кар өстенә кара булып төшкән машина үзе генә безнең арттан калмый ияреп барды.

Салават ике көннән соң гына терелде. Терелүенә үзе дә шатланып әйткән беренче сүзе «нәнәй» булды:

— Нә-нәй!..

Ләкин аңа җавап бирүче булмады. Салават моңа бик гаҗәпсенде булса кирәк: торып нәнәсе караваты янына килде. Тик анда да нәнәсе юк — әби үзе бардагыча җыеп куелган карават өстендә берсе бәйләнеп бетмәгән оекбаш кына ята иде.

*Ноябрь, 1968.*

## Сафа Сабиров

# ДУСТЫМНЫҢ ҮЛЕМЕ

хикәя

Безнен йөзмә форт «Сережа» — бөтен флотилиядә иң көчле кораб. Авыр туплары һәм пулеметлары күп булуы белән ул барысыннан да аерылып тора. Бездәге кебек ерак ата торган эре калибрлы туплар башка бер корабта да юк.

Сугышка хәтле «Сережа» ике мең тонна йөк күтәрешле гадәти бер тимер баржа иде. Урта Иделдә сугышлар башлангач, аны заводта диңгез корабларына куела торган эре калибрлы егерме ике туп белән коралландырдылар да, ике моржалы «Мария» исемле буксир пароходына тагып фронтка озаттылар. Гәрчә үз хуты белән йөрмәсә дә, «Сережа» Зөягә килгәннең иртәгесен үк үзен бик шәп күрсәтте.

Август урталарында Колчак адмиралы Старк флотилиясе безнең позицияләргә еш кына һөҗүм итеп борчый һәм безнең корабларны Казан — Югары Ослан рейдына якын да җибәрми иде. Бу юлы да нәкъ шулай булды. Безнең разведка катерлары дошман кораблары белән очрашкач, каршы тора алмыйча, кире чигенергә мәҗбүр булганнар. Әмма аклар моның белән генә канәгатьләнмичә, дөньяларын онытып, катерларны куа килгәннәр. Моның шулай буласы алдан ук билгеле, «Сережа» һөҗүмгә әзер тора иде. Менә артык кызып киткән дошман Васильево перекатын үтүгә, борылыш артыннан каршыга без килеп чыктык һәм барлык туплардан дәррәү ут яудыра башладык. Мондый хәлне һич тә көтмәгән аклар, кинәт таш кыяга барып бәрелгәндәй, шундук туктадылар һәм көчкә генә качып котыла алдылар.

Мин үзем — Балтикада дүрт ел хезмәт иткән комендор, теге кем әйтмешли, бераз диңгез тозын татыган, тупны күргән кеше. Йөзмә фортта аттырып карагач, мине тагын артиллериягә — туп командиры итеп куйдылар. Ә минем кулдашым — базык гәүдәле, чак кына кысынкы күзле чуваш егете Миколайның моңарчы корабны да, тупны да күргәне булмаган. Атарга мин аны үзем өйрәттем.

Без аның белән бик тиз дуслашып киттек. Өстәвенә, татарча да әйбәт кенә сөйләшә белә икән. Безнең фортка килеп кергәндә, егеткә карарлык та түгел иде. Өстендә иске киндер күлмәк, киндер ыштан: таушалып беткән ак киез эшләпәсе астыннан арыш саламы кебек сары чәчләре чыгып тора иде. Без аны шундук мунча керттек, чәчләрен алдык. Диңгез формасына киенеп алгач, егет менә дигән матрос булып китте. Үзенә үзе ышанмыйча хәйран калып, көзгегә озак кына карап торганнан соң:

— Рәмзи, карачы, хәзер мине Настя күрсә, ни әтер икән? — дип, кәефле генә елмаеп куйды.

Миколайның кайдадыр Сура елгасы буендагы бер авылда яшь хатыны һәм Петр исемле яңа туган бәләкәй улы бар икән. Хатынының хат килде исә, башта ул берәр аулак җиргә кереп, аны үзе генә укый. Аннары икебез генә калган бер арада минем яныма килеп утыра да бик мөһим хәбәр әйткәндәй:

— Рәмзи тус, күр әле, менә Настядан хат алдым,— дип, шатлыгын уртаклаша башлый.— Кара син аны, бик сагындым, бик күрәсем килә.. Петя инде көлә пелә, дип язган.

Хатынына җавап хаты җибәргәндә ул миннән дә сәлам яза һәм хатның азагына: «Синең ышанычлы дустың революцион матрос Миколай», дип кул куя. Кичә без эш белән Паратскига чыккан чакта бер уңайдан фоторәсемгә төшеп кайткан идек. Миколай бүген кич бераз бушагач, Настясына хат язып шул рәсемне дә җибәрергә җыена.

Әмма бу арада дошман белән бәрелеш көннән-көн ешрак һәм катырак була башлады, рәтләп тын алырга да вакыт юк. Бүген тагы иртән иртүк походка чыгарга приказ булды. Һәр группа үз тубы янында, барыбыз да Казан өчен яуга атлыгып торабыз. Форт коменданты Лепетенко һәр тупның яуга әзерлеген үзе тикшерергә тотынды. Үзе болай бик таләпчән командир булса да, юкка гына тел-теш тидермәс. Эшенне җиренә җиткереп үтәсәң, җылы сүз әйтеп күңелне дә күтәрә белә торган кеше. Менә ул безнең тупның йозагын, төзәгечен җентекләп күздән кичерде дә:

— Бар да төзек, молодцы!.. Шулай булырга тиеш,— дип, безне мактап алды.— Егетләр, бер нәрсәне аеруча искәртеп куям: дошман белән очрашканда артык кызып китәргә, кабаланырга һич тә ярамый. Һәр снарядны яхшылап төзәп атарга кирәк. Мондый зур тупның бер генә снаряды да җилгә китмәсен, аткан саен дошман көлен күккә очырырлык булсын...

Тиздән катерга утырып флотилия командующие ярдәмчесе комиссар Маркин килеп җитте. Ул да барасы булгач, билгеле инде, юкка гына түгел. Димәк, бәрелеш каты булачак.

Маркин ачык изүле, киң кайтарма якалы зәңгәр фланель күлмәк кигән. Башында кара бескозырка. Тышкы кыяфәте белән безнең ише гади матростан бер дә аермасы юк кебек, әмма шул ук вакытта күңелне үзенә җәлеп итә торган ихтыяр көче бар анда. Хәзер аның яуга ашкынуы күренеп тора иде. Лепетенконың рапортын тыңлаганнан соң, команда белән исәнләште дә безнең күршедә тора торган «Мария» мостигына менеп китте һәм шундук якорьларны күтәрә башларга приказ бирде. Бу вакытта башка кораблар инде кузгалган һәм, агым уңаена борылып, юлга чыгып баралар иде. Берничә минуттан якорьны күтәргәч, «Мария» безне фарватерга тартып чыгарды да, йөрешен тизләтә төшеп, алдан кузгалган кораблар артыннан китте.

Зөя елгасы турын үткәч, елганың уң ягында инде саргая башлаган куе урман каплаган биек-биек тезмә таулар башлана, текә таш кыялар, тауларны кисеп кергән тирән тарлавыклар күренеп кала. Бу җирләр бар да дошман кулында әле. Таулар арасында акларның яшеренгән батареялары бар. Сул як ярда Казан белән Васильево арасында тимер юл буйлап дошман бронепоездлары өзлексез йөреп тора. Ике яктан да безнең өскә менә-менә ут яудыра башлаулары бик мөмкин иде.

Без моны яхшы беләбез һәм, дошман ата башлады исә, шундук җавап кайтарырга әзер торабыз. Безнең унбер туп Иделнең сул ягына, унбере — уң ягына төбәлгән. Күбебез — төзәүчеләр дә, сигналчылар да — бинокль тотканбыз, яр буендагы һәр ноктаны, энә күзеннән үткәргәндәй, игътибар белән җентекләп карап барабыз.

Әмма хәзергә бер яктан да атучы юк әле. Әйләнә-тирәдә шомлы тынлык. Бер-бер артлы тезелгән кораблар киң елганы урталай ярып

алга бара. Минә еракта, күгелҗем томан аша, биек-биек мәчет манаралары, тәреле чиркәүләре, Кремль стеналары, мәһабәт таш пулатлары, бистәләре белән безнең күңелләрне җилкендереп Казан каласы күренә башлады.

Отряд һаман зур тизлек белән бара. Әле уң, әле сул яктан бер-бер артлы Моркваш, Аракчино, Печищи авыллары күренеп кала. Менә, соңгы борылышны үтеп, Маркиз атавы турына җитәрәк, кинәт каты гөрселдәп туп атылганы ишетелде.

Без аны шундук күреп алдык: дошман Югары Ослан тавындагы зиратка оялаган икән, аткан саен шундагы тәреләр һәм сирәк агачлар арасыннан очкыннар бөркеп чыга иде. Шулай да аның беренче снарядлары әле безгә тими, каядыр бөтенләй читкә, Маркиз атавына барып төшә дә, меңнәрчә киек-кошны куркытып, әрәмәләр арасында шартлый иде. Бу хәлгә аптырап калган Миколай, балаларча беркатлылык белән:

— Күрче, кая аталар... Ул мескеннәрнең ни каебе пар инде,— дип, кошларны кызганып алды.

Ул арада дошман тупчылары төгәлрәк төзәп атарга тотындылар. Шуны гына көтеп торгандай, Иделнең сул ягыннан бронепоезд да ут ачты. Куе имәнлек аша үзе күренмәсә дә, аның авыр снарядлары бик якын төшеп шартлый башладылар. Әмма безнең отряд монда тукталып тормады, безнең максат бу түгел. Без мөмкин кадәр түбәнрәк төшеп пристаньны утка тотарга омтылабыз һәм ике як ярга да туплардан туктаусыз ата-ата һаман алга ашыгабыз.

Су өстендә кабынып киткән атыш тиздән бөтен шәһәрне кузгатты: дошман батареялары пристаньнан, Бирге Устьедан һәм Кремльдән дәррәү ут ачтылар. Казанка елгасы тамагыннан безгә каршы өч кораб чыгып килгәне күренде. Алар да бар тупларыннан аталар, морҗаларыннан тузгып күтәрелгән куе кара төтен еракларга тарала һәм безгә бистәләрне күрергә комачаулый иде.

Кинәт безнең хәл бик хәтәрләнеп китте. Моңарчы каядыр читкә очкан дошман снарядлары тиздән янәшә генә ява башладылар. Авыр снаряд төшеп шартлаган саен, әле уң, әле сул яктан елга төбеннән ком һәм таш катнаш су баганалары бәреп чыга да, шарлавыктай каты гөрселдәп, тимер палубага төшә, безне баштанаяк коендыра иде. Баш очыннан гына шомлы ухылдап снаряд үткәндә мин ихтыярсыз сискәнеп куйдым һәм, нидер көткәндәй, «Мария» ягына карап алдым.

«Мария» бар куәтенә безне тартып һаман алга бара, аның тирәсендә дә снарядлар шартлый, мачтасыннан биек-биек су өермәләре күтәрелә иде. Мостигында бер нигә исе китмәгәндәй Маркин басып тора. Рубка алдындагы юан морҗа юлны күрергә комачаулый булса кирәк, комиссар уң як мостикның читенә чыккан да бинокльдән карап, яу белән идарә итеп бара иде. Менә ул буш кулы белән ишарәләп лоцманга ниндидер команда бирде, пароход та, аның артыннан безнең «Сережа» да сулга борыла башлады. Алдан баручы кораблар дошман судноларына каршы киттеләр, ә без, агымга каршы борылып, уңай позиция алу белән, пристаньга һәм Бирге Устьегә дәррәү ут ачтык.

«Сережа»ны тикмәгә генә йөзмә крепость дип атамыйлар шул! Моңарчы безгә болай каты ут ачарга туры килгәне юк иде әле. Бар туптан берьюлы атып җибәргәч, «Сережа» бөтен корпусы белән агымга каршы тартылып куйды һәм пристаньда нефть баклары шартлаудан һавага ялкын катнаш кара төтен бөркеп күтәрелде, ут өермәсе арасында складлар, ниндидер каралты стеналары җимерелгәне күренеп калды.

Тагын залп, тагын коточкыч шартлау һаваны гөрселдәтте һәм тиздән бөтен пристаньны кара төтен каплады.

Колак тондыргыч канонада тынган бер арада комендант Лепетенконың:

— Булды, болары тончыкты бугай... Хәзер, әйдәгез, тупларны Кремльгә борыгыз! — дигән боерыгы яңгырап китте.

Тау өстендә урнашкан Каз н Кремле безгә аермачык күренә. Без беләбез, аклар штабы шунда урнашкан, төп артиллерия көчләре дә шуннан бөтен әйләнә-тирәне тупка тота иде. Бинокльдән карасаң, батареялары кайда урнашканлыгын да чамаларга мөмкин: алар аткан саен биек стена артыннан һавага саргылт дары төтене күтәрелә иде. Менә без барыбыз да тупларны шул якка бордык һәм, сигналчылар араны исәпләп әйтүгә, төзәп атып җибәрдек.

Ике яктан да авыр туплардан атыш яңа көч белән кабынып китте. Безнең снарядлар, бистәләр өстеннән очып үтеп, Кремльгә ява һәм дошман батареялары арасында шартлый башлады.

Канонада көчәйгән саен без дә отыры кыза барабыз, бер-беребезне ашыктыра-ашыктыра тагын да ашкынып атабыз. Хәтта гадәттә каты сүз дә әйтә белмәгән сабыр холыклы Миколайны да танырлык түгел, хәзер ул тәмам ярсыган. Иелеп снаряд алып биргән саен, дошман белән бугазга-бугаз килгәндәй:

— Мә тагын персен, төмегегез әле!..— дип, ачу белән әйтеп куя.

Бу бәрелештә «Сережа» үзенең җимерткеч куәтен тагын бер мәртәбә күрсәтте. Берничә минуттан бөтен Кремль куе төтен эчендә калды, әле анда, әле монда янгын телләре күренә башлады, дошман туплары да тиздән басыла төште. Шул арада акларның безгә каршы чыккан кораблары да, чыдый алмыйча, кире борылдылар. Хәтта арадан берсе — «Ливадия» исемле кораллы пароходы качып та котыла алмады. Башка кораблар белән бергә тиз генә шылмакчы булып кирегә борылган вакытта, безнең снаряд шартлады һәм, батмас өчен тизрәк яр буенда сайга ташланып, дөрләп яна башлады. Без барыбыз да җиңү шатлыгыннан тирә-юньне яңгыратып көчле тавышлар белән «ур-ра» кычкырып җибәрдек. Бу — безнең дошманны үз оясында тетрәткән һәм тиздән шәһәрдән бәреп чыгарырга сәләтле икәнлегебезне күрсәткән беренче кыю һөҗүм булды.

Хәтәр көтмәгәндә килә диләр. Эшләр әнә шулай бик әйбәт кенә барган вакытта кинәт безнең янда гына авыр снаряд төшеп шартлады, шунда минем сул иңбашымнан нәрсәдер көйдереп үтте. Ни булганын абайларга да өлгермәдем, күккә күтәрелгән су ухылдап өстемә ишелде һәм мине, аяктан егып, үзе белән бергә палубадан тәгәрәтеп алып төшеп китте.

Миңгерәүләнгән булсам кирәк, өскә калкып чыккач, аңыма килә алмый тордым. Үзем шул арада тончыгып та өлгергәнмен, һич тын алыр хәл юк. «Сережа» миннән якында гына чайкала, тупчылары һаман ата бирәләр иде. Бераз хәл алгач та, баржага таба йөзмәкче булган идем, ләкин гаҗизмен, кулларымны һич кыймылдата алмыйм. Хәтта тел тибрәтеп кычкырыр хәл дә юк. Авызны ачтың исә, тамакка су кереп тончыктыра һәм төпкә тарта башлый.

Шулай да мин бер нәрсәне башыма сыйдыра алмыйм. Җан-фәрманга кызып атышкан иптәшләремнең суга егылып төшүемне абайламаулары да ихтимал. Ә Миколай янәшә генә иде, миңа снаряд бирел тора иде бит, ул күрергә тиеш иде ләбаса...

Әгәр «Сережа»дан бераз читтәрәк булсам, мине башкалар да күрер иде, әлбәттә. Әмма мин бик якында, баржаның бортына бәрелә-сугыла бата-чума агып барам, палубадан иелеп карамасалар, болай гына күрерлек тә түгел. Тын бетүгә һич түзәр хәл юк. Чак кына өскә калкып чыккан бер арада тын алмакчы булып авызымны ачуга, тончыгып тагын төпкә китә башладым. Сизәм, бу бөтенләйгә батуым, мин инде бүтән калкып чыгачак түгелмен...

Шул чак, якты дөнья белән мәңгегә саубуллашып су төбенә батып барганда, кинәт кемдер йөзеп килеп мине чәчемнән эләктереп алды һәм

упкын эченнән өскә тартып чыгарды. Минем инде күземне ачып карарлык та хәлем калмаган иде, ул кешене күрә алмадым. Ә ул култык астымнан алып үзе дә авыр сулый-сулый: «Рәмзи дус, пирешмә, эс кенә түс!.. Хәзер коткарабыз!» — дип әйткән сүзләрен ишеткәч кенә аның Миколай икәнлеген танып алдым.

Шуннан соң мин тагын һуштан язган булсам кирәк. Аңыма килгәч, бер мәл зиһенемне җыя алмыйча яттым. Кинәт сул иңбашым уттай яна һәм үтереп сызлый башлады. Мең газап белән күземне ачсам, биек түшәмле иркен каютада ятам икән. Әмма судан ничек чыкканмындыр, анысын хәтерләмим. Кемнәрдер эчемә тулган судан арындырган чакта буыла-буыла косып газаплануымны төштә күргән кебек кенә хәтерлим. Кайдандыр күңел болгаткыч дару исе килә. Баш очымда гына кемдер:

— Әһә, уяна матрос, күзен ача,— дип әйтте.

Без инде үзебезнең базага кайтканбыз, мин йөзмә госпитальдә, яраланган иңбашыма операция дә ясаганнар. Тел тибрәтеп сүз әйтерлек бераз хәл кергәч тә:

— Мине монда кем китерде? Миколаймы? Ул үзе кайда соң? — дип сорадым.

— Борчылма, егеткәем, тыныч бул.— Ак халат кигән житен чәчле яшь кенә сестра мендәремне рәтләп куйды.— Миколай дустың да монда, менә шушы караватта. Әмма аның хәле бик авыр, хәзер аңар операция ясыйлар.

— Ничек алай бик авыр? Ул да яраланганмыни?

— Әйе, каты яраланган. Җитмәсә сине коткарган арада бик күп кан югалткан.

Кара син аны, эшләр алай булган икән бит. Ә мин юләр ялгыш әнә ничек уйлаган идем... Оятымнан үземне әллә нишләтердәй булдым.

Миколайның операциясе никтер бик озак дәвам итте. Хәтсез вакыт үткәннән соң гына, ике сестра аны носилка белән китереп салды. Каютада икәү генә калгач, мин көч-хәл белән башымны шул якка бордым һәм, Миколайны күреп, йөрәгем жу-у итеп китте. Аның һәрвакыт шатлык балкып торган йөзендә җан әсәре дә юк, түгәрәк битләре ничектер кечерәеп, ябыгып калган; хәтта ул инде тын да алмыйдыр, йөрәге тибүдән бөтенләйгә туктагандыр кебек иде.

Ә Миколай, бик акрын гына булса да, сулый һәм аңы да ачык иде әле. Хәтта минем якында булуымны да белеп яткан икән. Медсестра чыгып киткән бер арада ул пышылдап кына ишетелгән зәгыйфь тавыш белән:

— Рәмзи тусым, син пирешмә, савык...— диде.— Ә мин... м-мин... Сау бул инде...

— Сөйләмәсәнә, ташла юк сүзне...

— Тукта, Рәмзи, әтеп өлгерим,— дип, Миколай мине туктатты да бераз хәл алганнан соң, сулышы кысыла-кысыла тагын сөйләп китте:— Песнең монда ничек сугышканны минем авылның комсомол ячейкасына яз, Настяга да яз... Үскәч, Петяга сөйләсеннәр, минем кебек пулып үссен... Аннан тагын менә нәрсә... Кубрикта минем мендәр астында синең пелән пергә төшкән рәсем бар... Аны да җибәр...

Миколайның бу сүзләренә башта мин һич тә ышанырга теләмәгән идем, болай саташып кына сөйлидер дип уйладым. Кызганычка каршы, ул әйткәнчә булып чыкты. Врачлар күпме тырышсалар да, аны саклап кала алмадылар. Үзе каты яраланган хәлдә мине үлем кочагыннан коткарган батыр матрос, якын дусым Миколай шул кичне вафат булды.

## Зөлфәт

### Ильич өмәдә

Бүрәнәләр синең иңдә, Ильич,
Алыпларның биле сынарлык,
Меңәр еллык халык хыялларын
Кара шулай чынга чыгарып!
Таулар ятсын синең күкрәгеңә —
Муромецның хәле бетәрлек!
Халык хакын хаклап,
Дау эчендә
Шул халыкны кара күтәреп.
...Ак яктылык Ирек мәйданында.
Казаныма ап-ак нур ява.
Туктаган да мәйдан уртасына,
Карап тора Ильич дөньяга.
Кешелекнең кояшыдыр бу җан —
Җирдә шундый якты лабаса!
Мин ышанмыйм синең иманыңа
Ильич төсендә ул булмаса!
Әйтерсең лә иңнән бүрәнәсен
Җиргә куеп ялга туктаган...
Гаҗәп тә бит, ничек сыгылмаган,
Авырлыклар ничек екмаган?
Ильич селтәп җиргә бәргән көннән
Иске гасыр ятып җан биргән,
Байраклар һәм карабиннар аша
Иркен сулыш җанга йөгергән.
Алыпларны уйлап тапкан халык
Таңга калмый сиңа нишләсен? —
Әкиятне чынга ашыр җирдә,
Шул ук җирдә туып үс тә син!
Өмә бара... Син өмәдә, Ильич.
Эпохада әле чуарлык.
Шундый бүрәнәләр синең иңдә! —
Алыпларның биле сынарлык.

### Көрәш сөлгесе

Томырылдык тормыш эченә без
Сабан туе атлары сыман —
Үзебезгә безнең үзгә мәйдан,
Без бит көрәшчеләр затыннан!
Нәкъ уртага аяк ерып бастык —

Күрсен халык безнең басканны:
Көрәшербез — сөлге өзелгәнче,
Билен сындырганчы дошманның!
Сынды билләр... Моабитлар сынды...
Инсә аша селтәп атканчы
Кысты халкым дошманының билен,
Ак сөлгесе канга батканчы...
Безнең кулда шул ук сөлге бүген,
Бу — көрәшче халык сөлгесе.
Сөлге таза! Гасырларны кичкән.
Көрәшченең кирәк җиллесе.
Шуның өчен җиргә томырылдык
Сабан түе атлары сыман.
Үзебезгә безнең үзгә мәйдан!
Без бит көрәшчеләр затыннан!

## Ориентир

Майор безгә ориентирлар атый:
— Һөҗүм юнәлеше — ак каен!
...Җырга күмде, юкса, ак каеннар
Кешеләрнең туган яккаен!
Бөдрәләрен сарган таң чыклары,
Төз биленә үлән үрелгән.
Сизми дә ул мушка төбәлгәнен,
Йөгереп төшә басу түреннән.
Ваемсыз ул сабый бала сыман,
Кызлар сыман исәп-хисапсыз!
Барып сарыласы иде шуңа
Автоматсыз, утсыз, пычаксыз.
Безнең каеннарның күргәннәрен
Кешеләр дә күрмәс бу җирдә! —
Каеннар шул берни сөйләмиләр,
Шаулыйлар тик гомер-гомергә.
Зәңгәр хыял булып чайкалды ул
Илкәеннән ерак кешегә.
Гестапоны, рейхларны ярып
Мусаларның керде төшенә...
Бу каеннар
жан аклыгы белән
Яратырга безне өйрәтте.
...Фронт аша Муса егетләре
Каеннарга кысып йөрәкне,
Ыргылдылар егылганга кадәр,
Сыкрандылар гильотиналар,
Һәрбер каен — хәтере бу намусның —
Шуңа ап-ак, шуңа тын алар...
— Дөрес сөйлимме мин, аппакларым?
Ак сеңелләр миңа баш кага,
...Каен сөйгән ак болытлы күкләр
Сыймый, майор, кара мушкага!

## Әни

«Мама, мама! Я помню руки твои...»
А. Фадеев. «Яшь гвардия».

Уң кулында урак сабы эзе,
Сул кулында учма җылысы.
Нечкә иләк була бу кулларда,
Уклау була, җиләк тырысы.
Чигү чигә күлмәк изүенә,
Я кер чайкый буа буенда.
Бохыр чикләвеге сала безнең
Кесәләргә сабан туенда.
...Кулларыңны хәтерлим мин, әни,
Мин аларга яшим елышып.
Уң кулында урак сабы эзе,
Сул кулында учма җылысы.
Аналарның уртак дине була,
Уртак кодексы, законы,
Шул законны бары кабул иттең
Син, оялчан татар хатыны.
Бер хикәят минем хәтеремдә
Борынгы моң булып яңара:
Сөйгәненнән фәрман алган егет
Әнисенең башын чабарга...
— Сөйсәң — дигән,— шул киселгән
башны
Сараема алып кил, егет!
Башны тотып кызга ашыкканда
...Егылган, ди, гашыйк сөрлегеп.
. . . . . . . . . . . . . . . . . .
Баш тәгәрәп китеп телгә килгән,
Сораган, ди, аяп, улыннан:
— Авырттымы тезең, балакаем?
Аһ, килсәче ярдәм кулымнан...
...Хәтеремдә минем шул хикәят —
Аналарның уртак законы,
Шушы дингә ничек табындың син,
Оялчан бер татар хатыны!
Кулларыңны хәтерлим мин, әни!
Маңгаемны куеп учыңа
Мин гыйбадәт бүген кылыр идем
Кешелекне юатучыга!
Яки тынар идем бер мизгелгә
Синең йөрәгеңә елышып...
Уң кулында урак сабы эзе...
Сул кулында учма җылысы...

## Кандалый турында баллада

Кандалыйның авылдашы бара
Минем белән бер үк вагонда.
— Олы шагыйрь яшәгән бит бездә —
Кара якта — Кандал ягында.
Бер вакыйга булган ул чорларда,
Сөйлим әле шуны, канатым.

Тик шагыйрь дип аны беләсеңдер,
Ә мин беләм башка талантын.
...Үләт чыккан Кандал авылында,
Габделҗаббар исән чагында,
Әй кырылган халык, йөрәк маем,
Белмәгәннәр хәтта санын да!
Ахшам вакытында бар мәхәллә
Кандалыйдан елап сораган:
— Җеннәрияләште мәллә безгә,
Коткар, хәзрәт, безне шулардан.
Елмаясың, бәгырем... «Әкият» дип
Уйлыйсыңдыр, бәлки... Бу бабай
Артта калган дини калдык, диеп,
Көләсең дә булыр... Көл, давай!
Мәхәлләгә фәрман биргән хәзрәт:
Һәркем ярга чуер таш җыйсын.
Һәрбер ташы алып килүченең
Йөрәк авырлыгы таш булсын.
Таш ташыган халык су буена.
Йөзә икән суда өч үрдәк.
Кандалыйның чапан чабулары
Кичке җилдән торган җилфердәп.
Таш аткан ул шушы өч үрдәккә
Күтәрелеп очкан икесе.
Савыкканнар шулчак авылдагы
Сырхауларның өчтән икесе.
Таш ташыткан тагын Габделҗаббар.
Таш аткан ул тагын үрдәккә.
Чалма тирдән юешләнеп беткәч,
Очып киткән соңгы чүрәкәй.
Үрдәк очып күздән югалуга
Соңгы сырхау баскан аякка —
Шул чагында әйткән Габделҗаббар
Таянган да имән таякка:
— Кулларымда бүген күтәрдем мин
Бөтен җәмәгатьнең йөрәген.
...Габделҗаббар белән булган хәлне
Шуның өчен, улым, сөйләдем:
Кулларыңа карап торам әле,
Куәт бар күк синдә, күрәмен —
Тик түзәрме алар бөтен халкың
Учларыңа салса йөрәген?
Андый кеше бездә яшәгән бит,
Кара якта — Кандал ягында!
...Гади мишәр карты белән шулай
Туры килдек без бер вагонга...

●

Беләктә — көч, безнең кулда — чүкеч.
Без — тимерче, әти, тумыштан:
Очкын булып безнең сандаллардан
Суккан саен чәчрәп җыр очкан.
Кайчак зәгыйфь суксам, ачуланма,
Тимер чыннарына күмелдем —
Төрле чагы була,
Ләкин керле...

Керле чагы булмас күңелнең!
...Без — тимерче, эти, без — тимерче!
Гомер ясыйбыз без чуеннан.
Тормыштан да без китәрбез бәлки,
Киткән кебек кыю бер көрәшче
Үзе җиңгән сабан туеннан.

## Чабышкыда безнең җиз йөгән

Чабышкыда безнең җиз йөгән,
Без китмәбез әле бәйгедән!
Ыргып алабыз без үрләрне,
Күз күреме җитмәс җирләрне.

— Даның артсын, малың артсын! —
дип,
Җан тартмаса — каның тартсын! —
дип,—
Үзең тәпи баскан урынга —

Озатканда әни орынган
Йөгәнемнең уң тезгененә,
Хәерле юл теләп үземә.

— Исемеңне сакла, егетем,
Таптама син авыл өметен,
Авылыңда сиңа зур өмет,
Үлсәң дә кайт кабат терелеп,
Тыңлат авылыңа җырыңны! —

Шулай диеп эти орынды
Йөгәнемнең сул тезгененә,
Хәерле юл теләп үземә...

Җайдакларның була үз дене,
Бер йөгәннең ике тезгене.
Ни күрсәм дә барган юлымда,
Ике тезген минем кулымда.
Тезгеннәрне өзгән юк әле,
Чабышлардан бизгән юк әле!

Чабышкыда һаман җиз йөгән,
Без китмәбез әле бәйгедән!

## Яңа Сәет

Кое сиртмәләре җырлап тора,
Яңа Сәет — татар авылы.
Бер соклану белән күзәтәм мин
Кызларының горур адымын.
Бабаларым монда чана бөккән,
Агаларым тәртә каерган.

Кул тотынып авыл әйләнәсен
Әйлән-бәйлән уйный карурман.
Дугадагы җиз кыңгырау белән
Озата бу авыл улларын.
Тик үзенчә тыйнак минем авыл,
Сиздерми ул ятка моң-зарын.
Тагор кыяфәтле картлар мина —
Гыйлем ягы, беләм, кыскарак —
Гыйльми лекцияләр укыдылар
Хатип Госманнан да остарак.
Өйрәттеләр хөрмәт итү фәнен,
Һәм төзәтү фәнен ялгышны,
Йөгәнләргә
башта усал тайны,
Тайлардан соң, усал язмышны.
Өйрәттеләр: чана табаннарын
Каерырга була, дип, улым,—
Тик һичкайчан бер гөнаһсыз җырның
Каерырга ярамый кулын!
Өйрәттеләр — утка төкермәскә,
Яратырга чиста йөрәкне.
Тимернең тик кызгач бөгеләсен
Алачыкта эти өйрәтте.
Агачыннан алма ерак төшми —
Монда, дуслар, шуны белдем мин.
Ярсыган ат авызлыгын тешли,
Ярсу атка сикереп мендем мин.
Яратсагыз мине, дус-ишләрем,
Авылыма килеп китегез!
Җырчыларны авылына карап,
Чын дус булып хөкем итегез.
Хыялымда шаулый киң кырлары,
Йөрәгемдә шаулый карурман.
...Бабаларым монда чана бөккән,
Агаларым тәртә каерган...

# КЫРГЫЗЧАДАН ИКЕ ХИКӘЯ

**Шабданбай Абдыраманов**

## СОЛДАТ

Синең сугыш кырында булганың бармы? Отрядның башында атакага чапкан солдатны күргәнең бармы? Шул солдатның, дошман пулясы тиеп, җиргә чалкан авып калганын күргәнең бармы?

Ул вакытта миңа унөч-ундүрт яшь булгандыр.

...Бик акрын атлаган кәрван кебек, сугышның икенче елы үтеп бара иде. Без, балаларның, учак янында тәмле итеп сөткә пешергән талканны ашамыйча нәзберекләнеп утыруларыбыз, әнинең, аз гына ашагыз инде дип, күз яше белән диярлек кыстап ялварулары бик күптәнге якты бер истәлек булып кына калды.

Бөтенесе үзгәрде. Кышлагыбызда хәзер ут кебек кыздырган кояш эссесендә ал-ял белмичә печән чабучы егетләр юк инде. Төз буйлы, таза гәүдәле Малабек та, маңгае тиргә батып, үгезләр белән җир сөрүче симез битле, аз сүзле Җапар да, атлы арбада җилдертеп чабарга ярата торган, дәү борынлы шук Саяк та юк хәзер. Халык телендә кара егетләр дип атала торган кыю, чая, таза егетләр берсе дә калмады инде.

Бик борын заманда бер таза егет җирнең тоткасын тапкан да шуны тотып, җирне селкетә башлаган, ди, һәм шуннан бирле ул җирне үзенең кулында тота икән, ди кыргызлар.

Ул егет хәзер фронтта инде. Сугыш аны бик ерак алып киткән. Әмма шулай да, биредәге кешеләр исән чагында, җирне алар үз куллары белән тотып торалар.

Әнә яшь кенә бер хатын, сабан тоткасын куллары белән ныгытып тоткан да җир сөрә. Ул калкулык тирәли әйләнеп килергә дә өлгерми, җилдә каралып, ярылып беткән кулларына маңгаеннан тузан катыш тир шыбырдап тама. Әнә икенчесе пар ат җиккән арбада аякларын аерып баскан да озын чыбыркысын баш түбәсенә күтәреп болгый. Атлары кушаяклап чабып бара, каршы искән җилдә хатынның күлмәк итәкләре кабарып җилферди.

Бик авыр заман. Бик кыенлык белән көн итәргә кирәк.

...Мин, соңгы имтиханымны да тапшырып, җиденче классны бетерү турында таныклык алдым. Иртәгесе көнне иртүк әни, ашыга-ашыга:

— Тор, урамда кеше көтеп тора,— дип, мине җилкәмнән селкеп уятты.

Күзләремне уа-уа сәкедән тордым да тышка чыктым. Кояш инде дөя үркәченә охшаган калкулык артыннан күтәрелгән. Карт өрек агачы өстендә чыр-чу килеп бер көтү чыпчык бөтерелә. Ала көчек, мине күргәч, башын калкытып, койрыгын селкеп куйды да озын телен чыгарып, янтауларын селкетеп сулый-сулый, яңадан ятты. Койма янында мине бригадир көтеп тора иде. Ул кешедән хатыннар бөтенесе куркалар, ә мине чакырыр өчен бу үзе безгә килгән. Бригадир атка атланган, атының, өшәнгәнлектән, хәтта колаклары салынып тора.

— Ә, Сәпәрбәк, я ничек, укуың беттеме? — дип сорады ул, атынын ялына карап.

Мин:

— Бетте,— дидем дә аның йомышын тыңларга җыендым.

— Яхшы булган ансы, син әле яшь булсаң да, инде ни...— дип бригадир, озын тешләрен ыржайтып, елмаеп куйды. Аның борын астында өтек кенә мыегы тырпаеп тора, чырае сытык, тавышы зәгыйфь иде.

— Бүген син Җомакадыйр карт белән тегермәнгә барырсың,— диде бригадир, җил кискән иреннәрен ялаштырып.— Ашлыкны төяшеп, тегермәнгә илтешерсең. Үгезләр белән ишәкләр ындыр табагында инде. Ашлыкны да шуннан төярсез. Җомакадыйр сине көтеп тора. Бар, тиз җыен.

Мин ни дип тә җавап кайтармадым, баш кына кактым. Аптырап калдым мин. Тегермән бигүк якын җирдә түгел шул. Чытырманлыклар аша борылмалы-сырылмалы сукмаклардан барасы. Аннан да яманрагы: мин Җомакадыйр бабай белән барырга тиеш булам. Авылда аны диванарак бер кеше дип саныйлар иде.

Җомакадыйр бабайның йорты безнең белән янәшә генә. Яше алтмыштан узган инде аның. Үзе ул озын буйлы, чәче ак сарык йоны төсле тоташ агарган, сакалы тузгып тора. Борыны тукмак чаклы, куе кашлары күзләре өстендә киртләчләнеп өелгән кар көрте шикелле асылынып тора. Күз алмалары кызарып, гел яшьләнгән булыр. Чапаны эченнән сөяклә‌ч киң җилкәләре төртеп тора.

Җомакадыйр бабай бер дә эшсез утырырга яратмый. Кышын булсын, җәен булсын, ул үзенә һәрвакыт эш табар, балта белән китмәннән бер дә аерылмас. Буынтыклы-буынтыклы юан бармаклы дәү куллары үткен пычак белән телгәләнгән сыман ярылып беткән.

Авылдагы диндар картлар Җомакадыйр бабайны яратып бетермиләр. Һәр җомга көнне алар авылның югары очындагы иске мәчеткә намазга баралар. Ә шул мәчеткә берәр тапкыр булса да керү турындагы уй Җомакадыйр бабайның башына да килми булса кирәк.

Бервакыт малайлар белән уйнап йөргәндә мин мәчет янына килеп чыктым. Башына ак чалма ураган мулла картлардан алгарак чыгып, кыйбла ягына карап утырган да кычкырып намаз укый иде. Ул ике кулын да күтәреп: «Аллаһе әкбәр»,— диде дә битләрен, сакалын сыпырды. Башка аксакаллар да шуны ук эшләделәр. Аннары алар, урыннарыннан торып, аркалары белән стенага сөялешеп утырдылар. Мулла, диннән язганнарны тәмуг газаплары белән куркытып, теге дөньяга баргач ниләр буласы һәм җәннәт турында вәгазь сөйләргә кереште.

— Безнең авылда да бер денсез бар,— диде бер карт.— Җомакадыйр ахирәттәниләр күрәсен уйлап карый микән?

— Э-э, аны ходай каргаган,— диде кәҗә сакаллы икенче берсе, чыраен сытып.

— Хода тәгалә һәммә адәмгә ирек куйган. Һәркем үз ирегенчә эш кыла,— дип аңлатырга кереште мулла.— Кем иманын онытып, ходайны истән чыгарса, аны шайтан аздырыр. Шул адәм, шайтан коткысынаияреп, иманыннан язганын сизми дә калыр... Корьәндә шулай диелгән.

Шуннан соң, Җомакадыйр картны күргән саен, кылт итеп әлеге сүзләр исемә төшә торган булды. Менә бүген дә тегермәнгә барганда юл буе уемда шул сүзләр бөтерелде. Күз алдыма дөрләп янып торган кыпкызыл тәмуг уты, шул тәмуг уты өстендәге кылдан нечкә, кылычтан үткен сират күпере килде. Җәннәткә керү өчен шул күпердән үтәргә кирәк икән. Ул турыда миңа әтинең күп тапкырлар сөйләгәне бар. Кич җиткәч, аның почмактагы сәкегә утырып, моңлы бер тавыш белән:

Каһәре төшкән бәндәсен
Казанга салып кайнатыр,
Авызында алтмыш ике тешле
Аждаһага чәйнәтер,—

дип җырлаганын да ишеткәнем бар.

Деннән язган адәмнәрне әнә шулай башта казанга салып кайнаталар, аннары алтмыш ике тешле аждаһа авызына ташлыйлар икән.

Минемчә, Җомакадыйр карт та тәмуг казаныннан котылмаячак. Алайса, нигә ул тәмугтан курыкмый икән соң? Гаҗәп кеше. Ә безнең укытучыбыз әйтә, тәмуг юк ул, ди. Укытучы мулладан күбрәк белә торгандыр. Шуңа күрә Җомакадыйр бабай да бер дә исе китмичә тыныч кына йөри торгандыр.

Былтыр бервакыт көз көне кинәт ишелеп-ишелеп кар ява башлады.

Инде төн җиткән, авыл халкы йокларга ята башлаган иде. Безнен өйдә керосин лампасы яктысында, фронтка киткән авылдашларны искә алып, бик озак сугыш турында сөйләшеп утырдылар. Минем андый әңгәмәләрне беренче тапкыр ишетүем булмаса да, монысында куркыныч нәрсәләр күп иде. Сугыш минем күз алдыма «Чапаев» кинокартинасындагы шикелле булып килеп басты: чатыр-чотыр китереп пулеметлар ата, пуля тиеп кешеләр авып кала, аларны атлар таптап китә, кан коела, кан ага. Үзем сугыш турында уйламаска тырышсам да, һаман уйланып яттым. Ничек уйламыйсың ди инде: минем абыйларым да фронтта бит... Әгәр алар пуля тиеп җирдә егылып ятсалар, тора алмасалар.

Шулай да мин, ята торгач, йоклап киткәнмен.

Төн уртасында ниндидер тавышка сискәнеп уянып киттем. Урамга карадым. Йокылы-уяулы хәлемдә бөтен урамга тоташ ут капкан кебек тоелды миңа. Анда халык шаулаша, куркыныч тавыш белән:

— Йортлары яна! Хәзер кая барырлар инде, мескеннәр!..— дип кычкыралар иде.

Кем йорты яна, кемнәр ул мескен кешеләр,— мин аларын белә алмадым, урамга чыгарга да курыктым.

Бераздан соң безнекеләр өйгә кайтып керделәр. Әти әрнүгә түзә алмыйча чыраен сыта, аның янгында куллары пешкән иде. Әни бәрәңге уып, әтинең ярасына япкан арада, эти йорты янган кешенең әйберләрен ничек итеп уттан коткаруы турында сөйләде. Җомакадыйр бабайның йорты янган икән. Кем ут төрткәнен белмиләр. «Бик авыр булыр инде аңа, бердәнбер улы да фронтта»,— дип, картны кызганып сөйләнделәр

эти белән ани... Мин Җомакадыйр бабайның йортын яндырулары турында ишетү белән дер-дер калтырана башладым: менә-менә үзебезнең йорт та дөрләп яна башлар кебек тоелды.

Бик озак йокыга китә алмый яттым. Күз алдымнан Җомакадыйр бабайның улы Орозбай китмәде. Ул минем абыйларның дусты иде, алар белән бергә комсомолда йөрде, аннары алар белән бергә сугышка китте...

Мин иртән торып урамга чыкканда бөтен җир ап-ак кар иде. Яфраклары да коелып бетмәгән өянкенең ботаклары беренче юеш кар авырлыгыннан сыгылып төшкәннәр. Моржалардан төтен бөтерелеп чыга иде. Мин шундук Җомакадыйр бабайлар йорты янына йөгердем.

Мин килгәндә Җомакадыйр бабай көрәк белән кар көрәп йөри иде. Төнлә янгыннан коткарып калган әйберләрен кар астыннан казып чыгара икән. Карт үзе берни булмаган кебек тып-тыныч. Шул тирәдә, бөгәрләнеп, борынын йоны эченә төртеп, этләре йоклап ята иде. Җомакадыйр бабай бер-ике көрәк кар алып эт өстенә ташлады. Эт сискәнеп сикереп торды да, кагынып алып, чәң-чәң өрә-өрә китеп барды. Җомакадыйр бабай, моны кызык тоеп, көрәгенә таянды да бөтен кышлакны яңгыратырдай булып көләргә кереште.

— Хәзерге этләр этмени. Менә шулай, улым...— дип куйды.

Мин аңа исем китеп карап тордым. Үзенең йорт хәтле йорты янган, энә кыш та җитеп килә, бөтен өмете-таянычы булган бердәнбер улы фронтта, ә үзенең бер дә исе китми.

— Чәнчелеп китсен йорты,— диде Җомакадыйр бабай.— Барыбер сүтәсе иде инде аны. Орозбай сугыштан кайткач, менә шушы төшкә яңасын салырбыз,— дип, ул, эре-эре атлап, саласы йортларының урынын үлчәп, көрәк белән сызып күрсәтте.— Ишеге менә монда була. Өйне ике бүлмәле итеп, уртадан керешле ясыйбыз.

Аның яныннан үткән-сүткән кешеләр, хәлен уртаклашкан кебек:

— Ут нидән чыккан соң? — дип сорагач, Җомакадыйр бабай:

— Моржасы ярык, шуннан чыккан,— дип җавап кайтарды.

— Бик гаҗәп инде,— дигәч, Җомакадыйр бабай, кул селкеп:

— Ничек чыкса да барыбер түгелмени? Бер-бер сәбәбе булмый калмагандыр инде. Кеше йортына кеше ут төртмәс! — диде.

Җомакадыйр бабайның йорты януы аркасында мин төн буе куркып, кайгырып, йоклый алмыйча чыктым. Шуңа күрә аның әнә шулай бер дә исе китмичә сөйләве миңа бик гаҗәп тоелды. Билгеле, аның үзенә алай дип әйтә алмадым инде.

Без он тартырга бара торган тегермән — он тузаны кунып беткән, тигезле-тигезсез балчык стеналы кечкенә генә бер йорт иде.

Җомакадыйр бабай капчыкларны тегермәнгә кертте дә миңа тегермән янындагы әрәмәлектә ишәкләр белән үгезләрне ашата торырга кушты. Мин, өй чаклы дәү бер таш өстенә менеп, малларны күзәтеп утыра башладым. Аргта, ташларга бәрелеп күбекләнә-күбекләнә, елга шаулап ага иде.

Кич җитеп, караңгы төшкәч кенә тегермән безнең ашлыкны тартып бетерде. Безнең егерме чакрым юлны кире кайтасыбыз бар. Өстәвенә, тирән генә бер елга да кичәсе бар. Көндез елга аша чыкканда үгезләрнең сыртлары гына суга күмелмичә калган иде, ә ишәкләр үрдәк кебек йөзеп чыктылар. Миңа калса, мин үзем тегермәндә генә кунып калыр идем дә бит. Урман-әрәмәлекләр, камышлыклар арасыннан кайта торган шул юлны исемә төшерсәм, котым алына.

— Җомакадыйр бабай, иртәнгә хәтле кунып калыйк булмаса шушында.

— Ә ни булды соң?
— Берни юк та... Иртәгә иртән кайтсак, әйбәтрәк булыр дим.
— Куркасыңмыни?
— Юлы яман, су аркылы да чыгасы бар.
— Һәй, куркак. Судан курыксаң, муеныма атландырып чыгармын.

Җомакадыйр бабай онлы капчыкларны үгезләр белән ишәкләргә төягәч, юлга чыктык. Төне дөм-караңгы, күзгә төртсәң дә берни күренми. Әле урман эченнән узабыз, әле тау битеннән, әле тауга менәбез, әле таудан аска төшәбез. Аяк астында биек куе үлән. Урман эче салкынча, дымлы, әчкәрәк кергән саен ул куера, серлерәк була бара. Якыннан гына ниндидер бер җан иясе килә, куак артына посып, менә-менә минем өскә ташланыр кебек. Ишәкләр кызу-кызу атлыйлар: аларның өсләрендә авыр йөк. Үгезләр салмак кына атлап арттан кайталар.

— Алга чыгып, кәрван башыннан бар,— ди миңа Җомакадыйр бабай.

Мин аның белән янәшә кайтканда да курка-курка гына кайтам әле: ничек алга чыгыйм инде?

Җомакадыйр бабайның исе дә китми: гырылдый-гырылдый үз алдына атлый бирә. Моңарчы минем аяк өсте йоклап йөргән кешене күргәнем юк иде. Вакыт-вакыт ул шундый гырылдап куя, хәтта үз тавышыннан үзе сискәнеп уяна, югыйсә йоклап китсә, туктый башлый.

— Җомакадыйр бабай, ник туктадыгыз, ишәкләр ерак китә бит,— дим мин.
— Китсеннәр. Өйдән ары узмаслар әле,— ди карт.
— Ә бүреләр...
— Бүреләрдән курыксалар, ашыкмасыннар...— ди бабай көлеп һәм шуннан соң сузып җырлап җибәрә:

Балкып янган йолдызның
Батар җире кайда икән?..

Җомакадыйр бабай бик озак җырлый, ул җырлаганда мин куркуымны онытып җибәрәм.

* * *

Эшкә йөри торгач, бригадир мине Җомакадыйр бабайга бөтенләй беркетеп куйды.

Бервакыт без аның белән берничә көн рәттән печән ташыдык. Ул печәнне чүмәлә тарткычка салып тора, мин эскерткә илтеп торам. Җомакадыйр бабай ат кебек эшләде. Мин, арып-талып, үгез өстендә йоклап китсәм, Җомакадыйр бабай ипләп кенә мине үгез өстеннән алып, чүмәлә төбенә сала да бер үзе эшли, үзе төяп, үзе илтә.

Бер көнне безнең колхоз арпа урырга керешә. Бригадир Абдыкар безгә килгәндә ул көнне дә гадәтенчә исерек иде. Абдыкарның битләре кып-кызыл; ул, иреннәрен ялый-ялый, кунычыннан камчысын суырып ала да, хатыннар алдында чайкала-чайкала, сүгенеп:

— Ник исәнләшмисез? — дип сорый.

Хатыннар бер сүз дә дәшмиләр, Абдыкарның моңа тагы да ачуы кабара.

— Дәшмисезме? — ди ул зәһәрләнеп һәм камчысы белән берәр хатынга янап ала. Безне сүккән чакта ул гел политикага таяна: «Син — Гитлер койрыгы! Син планга каршы киләсең! Безнең хәзер нинди авыр хәлдә икәнне беләсең бит!» — ди. Ни дисең инде аңа?

Хәрби комиссариатка барырга дигән повестка алгач, ул ләх булганчы эчеп исерә дә елый-елый:

Иртәгә алсалар солдатка,
Бикмәмәт улым ялгыз ла кала...—

дип җырларга керешә.

Тик ни өчендер аны армиягә алмыйлар. Ул район үзәгенә, һич булмаса, өлкә шәһәренә чаклы бара да кире әйләнеп кайта. Кайткач, зур бер батырлык эшләгән шикелле, күкрәк киереп, кукыраеп йөри.

...Ул көнне ни сәбәптәндер Җомакадыйр бабай эшкә соңгарып килде, ул килеп җиткәндә бригадир кырда иде инде.

— Әй, карт дуңгыз! Ник соңга калып йөрисең? — дип кычкырды ул, картны күргәч.

— Өч көн өйгә кайткан булмады,— диде Җомакадыйр бабай сабыр гына.— Өйдә карчыкның суы да, утыны да беткән. Аны кайгыртасы да булды. Аңа карап бернинди зарар булмагандыр,— дип, китә башлады.

Бригадир, тешен ыржайтып, ярсып, Җомакадыйр бабай өстенә ташланды, урак сырты белән аның күкрәгенә китереп төртте. Агачка суккан кебек, кызганмыйча, каты итеп. Мескен Җомакадыйр бабайны кызганып, күзләремнән яшь атылып чыкты.

Карт бераз басып торды да, кашларын җыерып, эшенә китеп барды.

Ул көннәрне без Җомакадыйр бабай белән ашлык тапшыру пунктына икмәк ташый идек. Ул пункт бездән егерме чакрым чамасында. Шунда барганда да, кайтканда да мин юл буе Җомакадыйр бабайдан, аның тузгыган чал сакалыннан күземне алмадым. Нигә ул бригадирга каршы кайтармады икән? — дип уйландым. Чынлап торып тотынса, Җомакадыйр бабай ул исерекне генә әйләндереп сала ала бит. Шул хәтле дә юаш булырга ярыймы инде?

Әмма миңа, бер дә көтмәгәндә, Җомакадыйр бабайның ачуланганын да күрергә туры килде.

Бер көнне кич безгә Молдакмат исемле озын буйлы, кара тут йөзле бер егет килеп, бездә куна калды. Кешеләрнең әйтүенә караганда, үзе шушы якныкы, тик соңгы елларда калада тора булса кирәк. Бер кулы аның гарип, шул сәбәпле аны солдатка да алмаганнар. Ул каладан ситсы алып килгән иде. Аны акчага сата яки кокнарга[1] һәм борын тәмәкесенә алмаштыра иде. Молдакмат товарын бик тиз сатып бетерде. Кич белән бөтен җыйган байлыгын янчыкларга салып текте, шуларга комсызланып карый-карый, кулына күтәреп авырлыкларын чамалап карады. Аннары стена буена әйбәтләп өеп куйды.

Шул Молдакмат бик күп кызык хәлләр белә иде, кич буе безгә шуларны сөйләде. Әти ул сөйләгәннәрне авызын ачып тыңлап утырды. Шулкадәр дә беркатлы, кеше җанлы бер адәм иде ул: көне буе эшләп арыган, аягын атлый алмас хәлдә булса да, ял итәсе урында, аны тыңлап утыра...

— Әх, экә,— ди Молдакмат,— ул герман дигәннәре дуңгыздан ярлаган булса да, бик көчле шул...— ди.

Әти бу сүзгә шаккатты. Аның үзенең уллары фронтта бит. Молдакмат әнә шулай дип безне гаҗәпкә калдырды. Күптән түгел өенә кайткан бер солдаттан ишеткән: фронтта чакта бер егет бер папирос тапкан. Шул папиросны авызына кабып кабызуга, папирос канга әйләнеп җиргә тамган да һәр тамчысы немец солдатына әйләнгән, ди. Болар шулхәтле күбәеп киткән, әлеге егет дошман уртасында чолганышта калган, ди.

[1] Кокнар — наркотик.

«Без сиңа тимибез. Үзегезнең якка кайт та иптәшләреңә әйт: алар безгә атмасыннар, безнең якка чыксыннар, югыйсә без сезнең барыгызны кырып бетерәчәкбез»,— дигән ди немец.

Әти, калтыранган куллары белән изүен тотып:

— Ай алла! — дип куйды.

— Ә-ә, әкә, немецләрнең икмәге дә катлы-катлы, ди... Бер каты май, бер каты ит, бер каты шикәр икән,— дип сөйли бирде Молдакмат...

Иртәгесе көнне пунктка ашлык илтә барганда мин боларны Җомакадыйр бабайга сөйләдем.

— Ах, аты коргыры ул ахмакның! Кайда ул сукбай, күрсәт миңа,— диде карт ачу белән. Ярсуыннан бөтен тәне калтырый башлады.

— Сездәме ул?

— Юк. Иртүк китте.

Җомакадыйр бабай беркадәр вакыт сүзсез генә атлап барды, аннары чапан кесәсеннән өч почмаклы хат алып, миңа сузды.

— Мә, менә укы!

Мин хатны ачып укый башладым.

— «Туган ягым Кыргызстанда бәхетле, матур тормышым калды, кадерле әти-әнием, туганнарым, якын дусларым калды. Бу хатны сезгә, гомерен дә кызганмыйча, кулына корал тотып, явыз дошман белән канлы көрәшкә катнашучы улыгыз Орозбай яза»,— диелгән иде хатта. Шуннан соң Орозбай үзенең сау-сәламәт икәнлеген әйткән, сәлам язган. Хатның бер бите сәлам тапшырылырга тиешле авылдашларының исемнәре белән тулган иде.

— Икенче ягын да укы,— диде Җомакадыйр бабай.

— «Әти, баштарак без аларның һөҗүмен туктата алмадык. Хәзер инде эшләр башкача. Без аларны бер адым да алга уздырмыйбыз, кирегә куабыз. Ходай кушса, алар озакламый табан ялтыратып элдертәчәкләр».

— Күрдеңме? Менә нәрсә дип язган Орозбай! Ә теге ахмак тузга язмаганны уйлап чыгарган... — дип, Җомакадыйр бабай миңа ачуланып карап алды.

Ә минем ул Молдакматка нинди катнашым бар соң?

* * *

Бер айлап вакыт үтте. Игеннәрне урып-җыю төгәлләнеп килә. Кешеләр, бөтен көчләрен куеп, ашлыкны тизрәк сугып бетерергә тырышалар. Иген суга торган таш та, үгезләр дә, ат, сыерлар да эшкә җигелгән. Аз гына җил исә башлау белән сугылган ашлыкны җилгәртергә керешәләр. Ә без Җомакадыйр бабай белән чиста ашлыкны амбарга ташыйбыз.

Беркөнне ындыр табагында суккан ашлык беткән, безгә эш юк иде. Үгезләрне тау битенә утлауга җибәргән идек. Җомакадыйр бабай: «Куып алып кайтыйм әле»,— дип, шунда китте. Мин аны бик озак көттем. Ашлык сугучылар безнең капчыкларны инде тутырып куйдылар. Җомакадыйр бабайга күптән әйләнеп кайтырга вакыт булса да, ул һаман күренмәде.

Мин, тау битенә менгәч, Җомакадыйр бабайны күрдем. Ул ташка сөялеп утырган да, ияген алга сузып, каядыр еракка караган иде. Аның чал сакалына, керләнеп каралган ак күлмәк итәгенә күзләреннән тәгәрәп-тәгәрәп яшь тама иде. Ерактагы көзге офыкка карап, аның янында мин дә беравык басып тордым.

Җәйге аяз көнне бу таш өстеннән Җәләл-Абадка чаклы, хәтта аннан даераграк булып, бөтен үзәнлек уч төбендәге кебек күренеп тора.

Ә хәзер шәһәр чак-чак кына шәйләрлек, шәһәрдән ары тоташ томан пәрдәсе иде. Шул чак күңелемә ни сәбәптәндер авыр булып китте. Җомакадыйр бабайга күз төшердем һәм беренче тапкыр аның бик нык ябыкканлыгын, коры сөяккә генә калганлыгын абайлап, исем китте. Картның куе озын кашлары тырпаеп тора, төссез күзләре эчкә баткан, яңак сөякләре йомарланган йодрык шикелле калкып чыккан иде.

Беркадәр вакыттан соң Җомакадыйр бабай урыныннан кузгалды.

Без арыган кәрванныбызны җитәкләп юлга чыкканда көн кичкә авышып бара иде инде. Малкайлар, аяк асларыннан тузан күтәреп, җайга гына алдан атлыйлар, ә без алар артыннан куе тузан эчендә барабыз. Җомакадыйр бабайның ансыз да кызыл күзләре тузан әчесеннән тагын да кызарып, утлы күмергә охшап калган.

Ашлык тапшыра торган пунктта һәрвакыт халык күп була, бирегә бик күп кышлаклардан ашлык китерәләр. Монда малайлар да, картлар да, хатыннар да бар.

Баш өстендә ут кебек кояш кыздыра, аз гына да җил әсәре юк. Түземсезләнеп чират җиткәнне көтәбез. Һәммә кешенең ашлыгын тизрәк тапшырасы килә, арбалар бәрелеп эләгешәләр. Баласы ындыр табагында калган бер дөя, елаган сыман, сузып акырып җибәрә. Койманың теге ягында маневр ясаучы паровоз кычкырта, вагоннар шалтыр-шолтыр килә.

Ә Җомакадыйр бабай һәрберсе бер центнер авырлыгындагы дәү-дәү капчыкларны ташый. Ул җиргә утыра да капчыкны аркасына салып бер кулы белән тота, икенче кулы белән җиргә таянып, әкрен генә күтәрелә. Чалбар балагы астыннан аның тузанланып беткән ябык аяклары, кабарып торган күксел кан тамырлары күренә.

Өстенә төсе уңып беткән күлмәк кигән, билен дөя йоныннан ишкән бау белән буган бер хатын, Җомакадыйр бабайны күргән саен, иске танышын очраткан кебек, эндәшә:

— Ә, әкә, ни хәлегез бар? — ди, тузан утырып каралган тешләрен күрсәтеп.

— Менә күреп торасың. Үзеңнең хәлең ничек соң? Бала-чагаң саусәламәтме? Иреңнең фронттан хаты киләме? — ди Җомакадыйр бабай.

— Менә ике ай инде — хаты юк, әкә,— ди хатын.

Җомакадыйр бабай башын ия.

— Балаларыгызның бәхете булып, ходай кушса, әйләнеп кайтыр,— ди әкрен генә.

Беркөнне без ындырга килгәндә бригадир да шунда иде. Гадәтенчә, ул хатыннарны сүгеп тора, тик бу юлы сәбәпсезгә түгел иде, ахры.

Борылча исемле карт кына бер хатын, гозерләгән кебек Абдыкарга таба кулын сузып:

— Бригадир, җаным. Бая төш чагында бер мескенгә бирәр генә уч бодай биргән идек,— диде.

— Мин ана әле кайчан гына авански ун кило чүпле ашлык бирдем бит! — диде бригадир.

Кояшта корып кипкән сыман, колгадай озын буйлы, ябык бер хатын:

— Дөрес, әкә, ансы өчен рәхмәт,— диде.

Аның алдында төшкелеккә дип жарма[1] салып килгән чәйнеге тора. Чәйнекнең капкачы юк, эчендә бөртек күренә. Бу хатын ул бодайны учына салып уган, сулышы белән өреп кибәгеннән арындырган.

— Нигә синең балалар башка кешеләрдән артык ашарга тиеш соң?

---

[1] Жарма — бодай ярмасыннан пешергән аш.

— Башка кешеләрнеке кебек, сөтебез булса иде. Бер жарма белән генә җан асрап булса икән. Балаларым ач... ашарга сорап елыйлар... Моннан ары алай эшләмәм инде.

— Юк, әйдә, конторга киттек, карак. Фронтка җибәрәсе икмәк бу, син шуңа пычрак кулыңны сузгансың.

«Карак» дигән сүзне ишеткәч, хатын кычкырып еларга кереште.

Бу вакытны Җомакадыйр бабай, бу хәлне күрмәгән сыман, бер читтә басып тора иде. Кинәт ул капыл гына борылды да бригадирга таба атлады.

— Ай, Абдыкар, җитте! Моннан ары алмам дигәнен ишеттең бит,— диде.

Бригадир аңа:

— Әй син тыгылма! Үз эшеңне бел,—диде дә иярләгән атына таба китте.

— Ах, бирән булгыры, җулик! — дип кычкырды кинәт Җомакадыйр бабай.— Син центнерлап читкә сатып эчкәндә ансы саналмыймы, фронтка җибәрәсе икмәккә син шакшы кулыңны сузмыйсыңмы?! Үз куллары белән көнөнә чирек гектар ашлык уручы бу мескен хатын ярты кило бодай уып җыйган икән, син шуның өчен тавыш чыгарып, аны карак дип атыйсыңмы?!

— Нәрсә мыгырдаган буласың, куу сакал [1], — диде Абдыкар.

Шул сүзне ишеткәч, Җомакадыйр бабай атына атланып өлгермәгән бригадирга ташланды да аны якасыннан эләктереп алып бер читкә атып бәрде. Бригадир аның янында мескен бер тычкан баласы кебек кенә иде.

Хатыннар, бөтенесе картка ташланып, аны аерып алдылар, югыйсә Җомакадыйр бабайның бригадирны әллә ни эшләтүе дә бар иде.

Мин теге көнне бригадирның урак сырты белән Җомакадыйр бабайның күкрәгенә сукканын хәтерләдем. Ул чагында кайда булды икән картның көче? Ә хәзер аны әллә ничаклы кеше көчкә тотып тора, ул ычкынмакчы була, үзен рәнҗеткән адәмгә арыслан кебек ташланырга омтыла.

Бригадир, куркынып карана-карана, атына атланды да:

— Күрсәтермен әле мин сиңа, карт тәре! Фронтка җибәрәсе икмәкне урлавыгыз өчен барыгызга да эләгер! — дип сөйләнә-сөйләнә, чаптырып китеп барды.

Инде тәмам көз җитсә дә, ашлыклар урып-җыелып бетмәгән әле. Моның өстенә тагын бригадирыбыз, аттан егылып, аягын сындырды. Аны больницага салдылар. Бригадир урынына минем әти калды.

Бер көнне әти белән икәү ындырда чакта, әти минем күземә карап, җиткән чәчләремнән сыйпый-сыйпый:

— Бик ябыккансың, улым,— дип куйды. Бераз уйланып торды да: — Бар, өйгә кайтып, ял ит бүген,— диде.

— Ә пунктка кем барыр соң?

— Җомакадыйр бабай белән икенче кешене җибәрермен,— диде әти.

Мин Җомакадыйр бабайга карадым. Ул пунктка бодай тутырып илтә торган капчыкларны юан энә белән ямап утыра иде. Эшенә шул хәтле бирелгән, шуннан башка бер нәрсәне дә искәрмидер кебек. Ни сәбәптәндер минем аны бер ялгызы калдырасым килмәде. Әти, минем уемны аңлаган төсле:

---

[1] Куу сакал — картларны мыскыллап әйтә торган сүз.

— Җомакадыйрга икенче бер иптәш бирермен. Бар, бар, юкса иртәгә бөтенләй аяктан егылырсың! — диде.

Иртәгесе көнне мин иртүк, ындырга килүемә, Җомакадыйр бабай ятып ял итә торган чүмәлә төпләрен карап чыктым. Карт анда юк иде. Ул әле өеннән килеп җитмәгән, күрәсең: килгән булса — безнең капчыклар шушында булыр иде. Әти төн буе ашлык җилгәргән, хәзер биш япьле сәнәк өстенә кырын төшеп йоклап ята иде.

Шунда миңа эш атларын утлатып йөрүче берәү:

— Әй, малай, кайда югалып йөрисең? Үгезләрегез, ишәкләрегез таралып бетте. Әнә, ике үгезегез тегендә, аста,— диде.

— Хәзер, хәзер алып киләм,— дидем мин. Үзем, Җомакадыйр бабайны эзләп, тирә-юньгә карандым.

Ул арада ындыр табагында йоклаучылар барысы уянып беттеләр. Аларның берсе дә Җомакадыйр бабайны күрмәгән.

— Өенә кайтып киткәндер,— диде берәү.

Мин юл буйлап тау түбән йөгереп төшеп киттем.

— Кая барасың? — дип кычкырды кемдер арттан.

Мин Җомакадыйр бабайның өенә кайтып китүенә ышанмадым, күңелемә нindидер шом төште. «Пунктта ашлыгын кабул итмәгәннәрдер дә шунда калгандыр»,—дип үземне-үзем юатырга тырыштым.

Бер чакрым чамасы йөгергәч, юлдан бер читтәрәк яткан Җомакадыйр бабайны күреп алдым. Кайта-кайта хәле киткәндер дә шунда ятып йоклагандыр, дип уйладым. Йөгереп янына килдем. Карасам, Җомакадыйр бабай йокламый, күзләре ачык, күккә караган...

— Җомакадыйр бабай,— дип эндәшеп аны уятмакчы булдым. Кулын тотып карасам, кулы таш шикелле салкын, авыр иде. Куркуымнан читкә тайпылдым.

Җомакадыйр бабай янында бик озак басып тордым. «Әллә мин бармаганга үлде микән?» — дип котым очып уйландым. Аның чак кына елмайган сыман булып катып калган йөзенә карап тордым.

Ул җиргә чалкан яткан, талгын гына искән җилдә чал сакалы селкенгәли иде. Шуңа карап торгач, карт менә хәзер терелеп, уянып китәр кебек иде.

Яныма кешеләр җыелганын да сизмәдем. Җомакадыйр бабайның кесәсеннән бер язу табып, миңа укырга бирделәр. Мондый сүзләр язылган иде анда:

«Кадерле Җомакадыйр ата, Сезнең улыгыз Орозбай, Ватанны саклап, батырларча һәлак булды...

Политрук Иванов...

1942 ел, 13 август».

Орозбайның авылдашлары бу кайгылы хәбәрне ишеткәч сүзсез калып, башларын иделәр... Җомакадыйр бабай бу хәбәрне күптән алган, тик кешеләргә белгертәсе килмәгән булса кирәк.

Шуннан бирле күп еллар узды. Мин бик күп кешеләр арасында булып, күп нәрсәләр белдем, әмма Җомакадыйр бабайны менә бүген генә аерылышкан кебек хәтеремдә саклыйм. Мин аның тау битендә чалкан ятканын да, чал сакалы җилдә селкенгәнен дә, елмайган сыман кыяфәтен һәм иртәнге зәңгәр күккә төбәлгән күзләрен дә күрәм.

Синең сугыш кырында булганың бармы? Отряд башында атакага чапкан солдатны күргәнең бармы? Шул солдатның, дошман пулясе тиеп, җиргә чалкан авып калганын күргәнең бармы? Ә минем... минем күргәнем бар. Ул солдат Җомакадыйр бабай иде...

*ЯХЪЯ ХАЛИТОВ тәрҗемәсе.*

**Мурза Гапаров**

# НАТАША РОСТОВАНЫҢ БЕРЕНЧЕ БАЛЫ

Иртәгә кич кызның туе булачак. Ил-күздән яшереп бирелгән калым инде алынган. Бирнә әзерләнеп беткән. Менә хәзер күрше кунак бүлмәсендә авылның чибәр дип танылган кызкиленнәре аның киеп китәсе кием-салымын ашыгып тегеп утыралар, икенче бүлмәдә дөнья күргәнрәк хатыннардан бер төркем, саесканнардай сайрашып, буласы кодагыйларга нинди кием кигезү турында гәпләшә.

Ә кыз исә, кыз үзе... боларның барысын исеннән чыгарып, кысан гына аш-су бүлмәсендә, әле яңа үзе юып-җыештырып куйган савытсаба арасында, гадәттә чиләк куела торган бүкәнгә утырган да өй артындагы куе бакчага караган уч төбедәй бәләкәй тәрәзәнең тонык яктысында бер ялгызы «Сугыш һәм тынычлык»ны укый. Ул инде үзенең кайда утырганын оныткан. Ул хәзер 1809 елның 31 декабрендә, яңа елга каршы кичтә Екатерина заманындагы ниндидер бер вельможаның өендә балда йөри. Бу җиргә ул Наташа Ростова дигән, үзе кебек үк япь-яшь, сөйкемле кызның гаиләсенә ияреп килгән.

О, нинди генә тамашаларны күрмәде ул бу балда! Кып-кызыл постау җәелгән подъезд, балкып торган заллар, ике читенә гөлләр тезелгән баскычлар, ак, зәңгәр, кызгылт күлмәкләр киешеп, муеннарына, ялангач кулларына энҗе-җәүһәр таккан ханымнар, мундир кигән, йолдыз һәм тасма таккан ирләр. Ләкин әле иң кызыгы алда. Хәзер бу җиргә патша үзе киләчәк.

Менә ул!.. «Бөтен халык хәрәкәткә килде, гүли башлады, бер алга омтылып, бер кире чигенеп, икегә бүленеп торып калган халык уртасыннан музыка тавышы белән бергә патша килеп керде. Патша артыннан өйнең хуҗасы һәм аның хатыны керде. Очрашуның бу беренче минутыннан тизрәк котылыйм дигәндәй, патша, уңга-сулга баш игәләп, тиз-тиз атлап килә иде. Музыкантлар махсус язылган сүзләре белән атаклы булган полькийны уйнап җибәрделәр. Бу җыр «Александра Елизавета, сокландырасыз сез безне» дип башлана иде. Патша кунак бүлмәсенә узып китте, халык аның артыннан ишеккә ташланды: йөзләре агарынган берничә кеше ул якка җәһәт кенә кереп, кире чыктылар. Хуҗа хатын белән сөйләшә-сөйләшә, кунак бүлмәсенең ишегеннән патша күренгәндә, халык тагын артка чигенде. Каушаган кыяфәттәге бер егет, хатыннарны кысрыклый-кысрыклый, алардан юл бирүләрен үтенде. Югары даирәнең кагыйдәләрен бөтенләй онытып җибәргәндәй, берничә хатын, киемнәре бөгәрләнүгә игътибар итмәстән, алга үтәргә тырышалар иде. Ирләр, хатыннар янына килеп, польский бию өчен пар-пар тезелешә башладылар.

Халык, кысылышып, юл бирде, патша, хуҗа хатынының кулыннан тотып, елмая-елмая, тактны саташтырып кунак бүлмәсенең ишегеннән биеп чыкты. Бию башланды. Бал кыза барды».

Менә шунда иртәгә кич туе төшәчәк кыз үзенең сөйкемле яшьтәше Наташаның, польский биюенә чакырылмыйча, стена буенда кысылып торган хатыннар рәтендә калганын шәйләп алды. Аның Наташа өчен йөрәге әрнеде. Мескен Наташа... Бу бит аның гомерендә иң беренче зур балы. Бу балга барам, бу балда биим дип ничек кенә сөенмәде ул.

Шул көнне иртән сигездән торып, җанын кая куярга белмичә, бизгәк тоткан кешедәй йөрмәдемени? Ә менә хәзер исә...

«...нечкә беләкләрен салындырып басып тора. Әле яңа беленә башлаган күкрәкләре бер күтәрелә, бер төшә. Ул, тынын кысып, зур куанычка да һәм зур кайгыга да әзер булып, куркынган күзләрен елтыратып алга караган. Аның патшада да, мондагы... башка шәп кешеләрдә дә эше юк — аны бер генә нәрсә борчый: «Минем янымa шулай беркем дә килмәс микәнни, беренчеләр арасында мин шулай биемәм микәнни, бу ирләр миңа шулай игътибар итмәсләр микәнни, әле алар мине күрмиләр дә кебек, карасалар да: «Әй, бу ул түгел бит, нәрсә аңарга карап торырга» дигәндәй генә күз төшереп алалар. Юк, болай булмаска тиеш!» — дип уйлады ул.— Минем никадәр биергә теләвемне, нинди әйбәт биюемне, минем белән бию нинди күңелле икәнен алар белергә тиешле бит инде.

Ярыйсы гына озакка сузылган польский көе Наташаның колагына, инде бер истәлек сыман, моңлы булып ишетелә башлады. Аның елыйсы килде». Бичара...

Кинәт иртәгә кич туе буласы кызның зур кара күзләренә яшь тулды. Хәрефләр тоныкланып, танылмас булдылар һәм, юл буена тезелгән агачлардай, бер-беренә охшашлы кара шәүләләргә эверелделәр.

Кыз башын күтәрде. Күз кырыйларыннан ташып чыккан яшьләре аша болай да караңгыланып барган аш-су бүлмәсе ниндидер бер тирән мәгарәгә охшап китте. Андагы әйберләрне күреп аерырлык түгел иде инде.

Кыз, күзен йомып, озын куе керфекләре арасыннан яшен сыгып чыгарды да, утны яндырырга дип, урыныннан торды.

Тәрәзә артындагы карт өрекләрнең кара кәкре ботаклары арасыннан кып-кызыл түгәрәк ай калкып килә иде. Кыз аңа уйланып бераз карап торды, аннан соң ак бәздән тегелгән пәрдәне акрын гынна тартып куйды. Бакча да, ай да күренмәс булдылар. Кыз тагын да караңгылана төшкән бүлмәнең стенасыннан капшанып кнопканы тапты, аны чык иттереп басты һәм яңадан урынына килеп утырды.

Ул тагын балга килде. Наташа әле һаман элекке җирдә, биюгә чакырылмыйча, стенага кысрыклап китерелгән хатыннар рәтендә тора иде. Менә рәнҗүнең кара болыты артыннан шатлык кояшы күренде. Наташаны биергә чакырдылар! Князь Андрей аңар бер тур вальс биергә тәкъдим ясады. Атаклы князь Андрей Болконский!

«Наташаның өметсезлеккә дә, зур куанычка да әзер торуын күрсәткән киеренке йөзен кинәт бәхет һәм разыйлык белән тулган самими елмаю балкытып җибәрде.

Тамам-тамам дип торган күз яше аралаш елмайганда һәм кулын князь Андрейның җилкәсенә салганда, бу куркынган бәхетле кызчык: «Мин сине күптән көтәм бит», дия кебек иде».

Иртәгә кич туе буласы кызның күзләре яңадан яшь белән тулды. Хәрефләр тагын танылмый башлады. Ансыз да йөрәге шатлык белән тулган кыз, укый алмыйча, башын күтәрде. Бу юлы ул, күзен йомып, яшен сыгып ташларга ашыкмады.

Шулчак аш бүлмәсенең иске ишеге каты шыгырдап китте, аннан юаш-йомшак кыяфәтле яшь килен килеп керде. Бу кызның җиңгәсе иде.

— Җиңги! — дип кычкырып җибәрде кыз, аны күреп.— Наташаны биергә чакырдылар!

Каен сеңелесенең шатлыктан болай итеп кычкырганын җиңгәсенең беренче кат ишетүе иде. Ләкин аның нәрсәгә шулай шатланганын төшенә алмады ул. «Наташаны биергә чакырдылар!» дигән сүздән ул берни дә аңламады. Шулай булса да, каен сеңелесенең бәхетле йөзен

күреп, аның куанычын бүлешәсе килде, ахры, үзенең оялчан, сөйкемле елмаюы белән елмаеп, басынкы, матур тавыш белән:

— Наташа дигәнегез кем була, сеңелем? — дип сорады.

Ләкин кыз аңар төшендереп тормады.

— Ай, җиңги, һич китап укымыйсыз, сез дә инде,— дип, үзенең ризасызлыгын гына белдерде.

Җиңгәсе гаепле сыман елмайды.

— Укый белмәгәч, ничек укыйм, сеңелем? — диде ул.

— Ә нигә белмисез?

— Сезнең кебек сигез класс бетермәгәч...

— Ә нигә бетермәдегез?

— Ой, сеңелем, сез әле һаман бала икәнсез,— дип көлемсерәде җиңгәсе,— мине укытмагач, ничек бетерим? Миңа мәктәп йөзен бөтенләй күрсәтмәделәр. Тау-таш арасында качырып йөрделәр... Ә уналтыга чыккач ук кияүгә, сезнең абыегызга биреп җибәрделәр...

Кыз, язу танымавына җиңгәсе үзе гаепле түгел икәненә төшенгәч, аны аяп, хөрмәтләп карап торды. Ул болай җиңгәсен ярата. Шулай да күңеленең төбендә аны бөтенләй үк аклап бетерә алмый иде.

— Ә сез ни өчен риза буласыз? Кияүгә чыкмыйм, дисәгез соң? — диде ул, элеккегә караганда йомшаграк итеп.

Җиңгәсе тагын көлемсерәде.

— Сеңелем,— диде ул аннан соң.— Кызык сөйлисез сез. Ата-ананың әйткәненә каршы чыгып буламыни? Аларның әйткәне әйткән, дигәне дигән бит. Аннан кала, безнең язмышыбыз ук шул түгелмени?.. Без иргә чыгарга тиешбез, бала тудырырга, бала тәрбияләргә... Ярый, сез мөгаллим буласыз ди, доктор яки артист — барыбер болардан качып котыла алмыйсыз... Бер риза булмассыз, ике риза булмассыз... барыбер язмыштан узмыш юк.

Җиңгәсенең әйткәннәре каен сеңелесенә ошамады. «Бөтен хатынкызны бер язмышка сала бит бу. Димәк, мине дә шулар эченә кертә җиңгәм», дип уйлады кыз. Шул вакыт ул кинәт, китап кызыгына биреләп утырып, онытып куйган нәрсәсен — иртәгә кич үзенең туе төшәсен хәтерләде. Наташа Ростова катнашып йөргән тантаналы бал, купшы дөнья шунда ук юкка чыгып, алар урынына үзенең иртәгә кич чишеләчәк үкенечле язмышы килеп басты.

Кыз, татлы төшен бүлдереп йокысыннан уятканы өчен әнисенә ачуланган һәм елап җибәрергә хәзер торган баладай, җиңгәсенә кырыс кына карап торды.

«Юк, юк»,— диде ул эченнән. Аннан кинәт, бар ачуын чәчрәтеп, җиңгәсенә:

— Юк! Юк! Юк! — дип кычкырып җибәрде.

Бичара җиңгәсе, ни булганына төшенмичә, куркып, каушап калды.

— Сенелем, сенелем! — диде ул, кабаланып.— Ни булды сезгә? Җаным, минем сезне рәнҗетим дигән уем юк иде бит. Әгәр бер яманлык уйласам сезгә, үлеп китим, илаһым.

Кыз, җиңгәсенә юкка кычкырганын, ул мескеннең бер гаебе юк икәнен уйлап, яңадан басыла төште.

Җиңгәсе, кызга якын килеп, аның яңакларын каплап торган бөдрә тал чыбыкларыдай нечкә итеп үрелгән чәчләрен сыйпый башлады.

— Сеңелем,— диде ул бераздан соң әкрен генә,— әйдә, кунак бүлмәсенә керик әле.

— Нигә?

— Киленнәр: керсен әле, тегелеп яткан киемнәрен буена үлчәп карыйк,— диләр.

Кыз башын күтәреп, җиңгәсенә тагын ачуланып карады.

— Акылыгызны җуймагыз,— диде җиңгәсе, каен сеңелесенең ачулы карашын күреп.

Кыз, җиңгәсенә ачуланудан барыбер берни үзгәрмәячәген төшенеп, акрын гына урыныннан торды да аның артыннан китте.

Кунак бүлмәсендә кыз-киленнәр күп иде.

Алар, чыр-чу килеп, кызны урап алдылар, аннары әле тегелеп бетмәгән камзул, җилән, күлмәк, туннарны аңар кигезеп карап, аларның тар я киң, озын яки кыска икәнлекләре турында талаша-тарткалаша башладылар. Шаярттылар, көлделәр. Кыз исә, боларның аңар аз гына да кагылышы юктай, битараф төстә, әйлән дигән якка әйләнеп, борыл дигән якка борылып, боек кына басып тора бирде. Үзенең хәзерге роле белән ул нәкъ магазиннарның витриналарында торган манекеннарга охшый иде.

Киемнәр үлчәнеп беткәннән соң, киленнәрдән икәве, кызык өчен дип, үзләре каеп утырган зур чаршауны кызның алдыннан тартып җибәрделәр. Кыз өй почмагы белән чаршау арасында бер ялгызы торып калды. Шунда ул, хәзер инде моннан бөтенләйгә чыга алмый калгандай, кыз чагы белән саубуллашу сәгате инде килеп үк җиткән кебек, каты куркынып куйды, күз аллары караңгыланып китте. Кыяга куып китерелгән тау кәҗәседәй, бераз каушап торды да, аннары, һич көтмәгәндә, чаршау тотып торган киленне ега язып, ишеккә атылды. Артыннан өйне дер селкетеп көлгән тавыш ишетелде. Кемдер бераү: «Тазагөл, Тазагөл!» дип кычкырып калды. Ләкин Тазагөл боларның берсен дә ишетмәде.

Тышка йөгереп чыккач, өйне әйләнеп үтте дә, аның почмагындагы карт өрек агачына барып сөялде, шунда гына ул бераз аңына килде һәм җиңеләеп киткәндәй булды.

Тышта тып-тын иде. Ай инде күтәрелгән. Аның ап-ак, салкын нурлары агач төпләрендәге яфракларга төшкән кырауда чагылып, төрле төсләргә кереп җемелдиләр.

Тазагөл, өреккә сөялгән килеш, үзенең борчулы йөзен, яңа гына калкып килә башлаган күкрәгең ай нурына таба куеп басты, аннан бераз уйланып торды да ялгыз тәрәзәсеннән ут яктысы күренгән күрше өйгә таба атлап китте.

Күршеләр — үткән ел өйләнешеп, шушы арада гына уллары туган яшь-яшь кешеләр иде.

Тазагөл яшь килен белән апалы-сеңеллеләй, сердәшләр. Хәзер дә ул, аңар барып, кияве өйдә булмаса, аның белән бераз утырып, моңзарын әйтеп, аз-маз кайгысын таратып килергә уйлаган иде.

Тәрәзә төбенә килеп, ул сак кына эчкә күз йөртеп алды. Ирлехатынлы икесе дә өйдәләр. Хатыны янып торган учак янына супурасын[1] җәеп куеп, камыр баса. Кияве түрдә, стенага сөялеп, ботларын җәеп утырган да, күзләре ярым йомык хәлдә, комуз дыңгырдатып утыра. Ә аның янында кечкенә юрганга төргән бала селкенгәләп куя, ачы елау тавышы ишетелә иде.

— Ой, дим,— диде шул чак яшь ана киявенә,— яныгыздагы баланы бер юатып куйсагызчы, ходай кушкыры.

— Балаң миңа юанмый,— диде ата, торышын үзгәртмичә.

— Ничек инде юанмасын ди? Кулыгызга алып, ә-ә дисәгез шунда...

— Барыбер юанмый. Баланы әнисе генә тынычландыра ала. Үзең ал.

— Ай, шул сез инде...

Яшь ана, урыныннан торып, камырлы куллары белән биләүдәге баласын алып килде дә, аны бер кулы белән кочаклап, икенче кулы белән камыр басуын дәвам итте.

[1] Супура — тиредән эшләнгән куна тактасы.

«О-о-ой»,— диде Тазагөл, учлары белән йөзен каплап.

Аннары, кире борылып, кая барганын үзе дә рәтләп төшенмичә, бакча эченә кереп китте. Җиргә калын булып түшәлгән яфраклар өстеннән, шәрә ботаклардан төшкән кулэгәләрне аралап, сүрән-сүлпән атлап, бакчаның аргы башына юнәлде һәм бераздан зур, бөкре буе белән айның түгәрәк күзен үзенә каратып, ике өрек арасында басып торган дөяне күрде. Дөя колхозныкы иде. Куптәннән бирле ул инде бу бакчадан китми йөри. Кызга бу дөя үзенең юашлыгы белән ошый иде.

Ул аның янына килеп туктады. Дөя, кушәвеннән бүленеп, күзләрен тутырып аңар бер карап алды да яңадан кушәргә кереште.

Кыз кечкенә учлары белән дөянең түш йоннарын бераз сыйпап торды, аннары, башын дөянең күкрәгенә куеп, үксеп елый башлады.

Менә ул кинәт башын күтәрде. Аның үз өеннән, сөекле әти-әнисеннән качасы килеп китте. Гомерендә беренче тапкыр килде аның күңеленә мондый уй.

Ул кискен борылды да бакчаның аргы ягындагы ай нурына манчылып яткан көзге далага таба китте. Башта ул икеләнеп, атлар-атламас барды, аннары кинәт, артыннан кемдер куып килгән кебек, йөгерә үк башлады. Ләкин... бу да озакка сузылмады. Көтмәгәндә ниндидер нык куллар аның нечкә җилкәләреннән кысып алып туктаттылар да кочлап кирегә бордылар. Шунда аңар иң әүвәл бакчаның теге башында кып-кызыл булып ачылып утырган япа-ялгыз гөл күренде. Бу гөл үзләренең аш-су бүлмәсенең кечкенә тәрәзәсеннән төшкән куе нур иде...

Тазагөлнең бар тәвәккәллеге югалып, бөтен гәүдәсе хәлсезләнеп, шәлбәрәеп төште. Ул бер мәлгә, кыймылдарга көче җитмичә, яшьле күзләре белән бакча түрендәге кызыл гөлгә тилмереп карап торды, аннары калтыранган, хәлсез аякларын сөйрәп, башын түбән салып, рухы сүнгән хәлдә кызыл гөлгә таба китте.

Гөл әле ерак иде. Ләкин ул, аңар якынлашкан саен, гөл кыяфәтен югалтып, бик гади бер тәрәзәгә әйләнә барды. Инде бу тәрәзә артындагы тормышка яңадан җан керде. Бүлмәләр, әйберләр, кешеләр сөйләшә башладылар.

Шунда кыз тагын айныды. Аяклары үзләреннән-үзе атламый башлап, йөрәгә куркыныч сизгән куян йөрәгедәй тынычсызланып тибәргә кереште. «Юк, юк, юк», дип пышылдадылар аның дерелдәгән иреннәре.

Кыз беравык үзләренең өй тәрәзәсенә, аның белән бәхәсләшкән кебек, тын гына карап торды да, аннан соң, дошманы белән күзгә-күз очрашкан куяндай, шарт борылып, йөгереп китте.

Тиз арада ул бакча кырыена килеп җитте. Бакчаны айлы даладан киң, тирән чокыр аерып тора иде. Аннары сикерде. Чак кына чокырга төшми калды. Яр читен кочаклап егылып, борынын канатты, куллары камылларга тырналды. Әмма аларга игътибар итмәде. Иплэп аягына басты да тагын йөгерергә тотынды.

Караңгылыкка чумган куе зур бакча, бакчаның аргы башындагы, ерактан кызыл гөлгә охшап күренгән ялгыз тәрәзә бөтенләй артта калдылар...

*Кыргызчадан Х. ХӨСӘЕНОВА тәрҗемәсе*

Габдрахман Әпсәләмов

# БЕЗ һӘРВАКЫТ ЛЕНИН БЕЛӘН [1]

## Дөньядагы беренче тау

Дөньяның түбәсе дип аталган таулар бар, ләкин мин әйтә торган тау алардан да биегрәк, тик аны дәреслекләрдән эзләмәгез. Ул — Беренче тау — Казан уртасында. Элек Казанда Беренче, Икенче һәм Өченче тау дигән урамнар булган. Хәзер аларның кайда икәнен казанлыларның яшь буыны белми дә торгандыр. Моннан бер гасыр элек хәзерге Ульяновлар урамын Беренче тау дип йөрткәннәр. Ульяновлар семьясы шунда торган.

Бу урамда Ленин белән бәйле ике йорт бар: берсендә Ульяновлар семьясы 1887 елның июль — август айларында торган, икенчесендә — Владимир Ильич инде Кокушкинодан сөргеннән кайткач, 1888—1889 елларда яшәгән. Монда хәзер Казан халкының мактанычы — Ленин музей-йорты. Ихтимал, яшел агачлар утыртылган, асфальт җәелгән тигез урамнан баручылар монда ни өчен Беренче тау дигәннәр, моның кай җире тау, дип гаҗәпкә калырлар. Ашыкмагыз, Свердлов урамы чатына төшегез, алдыгызда чыннан да биек тау булыр. Шул ук Свердлов урамы белән Суконныйга таба китсәгез, Икенче һәм Өченче тауларны да күрерсез. Уң якта Суконный фабрика калыр. Тик фабрика хәзер анда юк, тәбәнәк биналары гына сакланган. Монда хәзер — Татарстан хәрби комиссариаты бинасы.

Беренче йортта унҗиде яшьлек Володя Ульянов университетка керү хыялы белән яшәгән булса, икенче йортта ул инде бер кадәр олыгай-

---

[1] Ахыры. Башы 4 санда.

ган, җитдиләнгән, университетны да, төрмәне дә, сөргенне дә күргән, кабат университетка алуны сорап язган гаризасына мәгариф министры кире җавап биргән, өстәвенә Россиянең бөтен губерналарына ашерен язу җибәрелгән: Казан университетыннан сөрелгән, полициянең негласный күзәтүе астында торган ышанычсыз Владимир Ульяновны дәүләт хезмәтенә алу катгый рәвештә тыела, диелгән. Ихтимал, Суконный бистәсенә карап Володя шул турыда да уйлангандыр.

Ленин йортында экскурсиядә булган кешеләр хәтерлиләрдер: Володяның өстәлендә Маркс томы ята. Бүлмәнең яшерен артты ишеге дә бар. Әгәр чакырылмаган кунаклар килә калса, Володя шуннан шыпырт кына чыгып китә һәм тау астына төшеп яшеренә алган. Болар бит берсе дә очраклы хәл түгел, Владимир Ильич инде революцион хәрәкәткә актив катнаша башлаган, Федосеев түгәрәгенә дәртләнеп йөргән. Казанка буйлары әле дә яшь революционерларның кайнар эзләрен саклый торгандыр.

Казанда Ленин торган йортлар шактый: Комлев урамыннан яки Профессор тыкрыгыннан үтәсезме, Карл Маркс урамындагы Ленин йөргән шахмат клубын әйтәсезме. «1890 елның августында Самарадан Петербургка барышлый бу йортта В. И. Ульянов (Ленин) тукталды» дигән язуны укыйсызмы — (хәзер Чернышевский урамы) көнелдә горурлык туа. Ләкин аеруча кайнар хис белән Ульяновлар урамына — Ленин музей-йортына киләсең. Бу йортның ян күршесендә, тау башында, тагын бер истәлекле йорт бар: монда буласы атаклы пролетар язучысы, Давыл хәбәрчесе Алексей Максимович Пешков — Максим Горький яшәгән. Алар Володя Ульянов белән бер үк вакытта диярлек Беренче тауга менгәннәр. Шундый ике гигант — дөньяны таң калдырган гигантлар яшьлекләрендә йөргән тауны ничек инде дөньядагы Беренче тау димисең!

Кояшлы иртәләрдә мин монда уйланып йөрергә яратам. Уйлар канатлана, сафлана. Син тарихның өзлексезлеген тирәнрәк тоясың. Бу Беренче таудан даһи көрәшчеләр ерак юлга чыкканнар, җилләр-давыллар үткәннәр, утка кергәннәр. Алар алдында егылып калган турылыклы иптәшләренең кан төсе булган Кызыл Байрак җилфердәгән. Бу урамнан үткән саен, миңа ул шанлы Кызыл Байрак хәзер дә дөньядагы Беренче тау башында җилферди кебек тоела, мин шушы күренештән һич аерыла алмыйм. Бу хыял да, түгел дә кебек: хәзер Ленин байрагын дөньяның кай төшеннән генә һәм нинди генә халыклар күрмиләр, аның үзенә тарту көче бөтен континентларга җәелде бит!

Бу урам яшь Ленин торгандагыча диярлек сакланган, үзгәрсә, агачлар гына үзгәргәндер, картлары корыган, яшьләре бик үсмәгән әле. Аннары Ленин йорты тирәсендәге бер-ике йортны сүтеп алганнар. Ленин йорты — буыннарга истәлек булып калачак йорт — күз карасы кебек саклана. Бәлки, бу урамны гомумән иске Казанның бер почмагы итеп саклардыр. Мондагы бәләкәй генә йортларга да Ленин карашы тукталган бит, бәлки шул тәбәнәк йортларга карап Ленин бүгенге зур, матур, мәһабәт йортларны күргәндер. Ленин йортынын бакчасында утырганда ихтыярсыздан шул уйлар башка киләләр.

Менә автобуслардан бер төркем пионерлар шаулашып төшәләр. Алар Казаннанмы, районнанмы — белмим, хәзер элеккечә киемнәреннән генә аера алмыйсың, бар да бер төсле. Әлбәттә, балаларга якын килмичә дә, озаграк карап торсаң, кайдан икәнлекләрен төшенеп була, ләкин моны инде кием-салымнан эзләмә. Тик бу юлы мине ул мәсьәлә артык кызыксындырмый. Иң мөһиме: бу йортка бер өзлексез яшь буын килеп тора. Безнең, олыларның, күңеленә ни әйтсәң дә тормыш юшкыны әзме-күпме утырган инде, ә аларның күңеле чиста, кер кунмаган, ә Ленин йортыннан алар тагын да сафланып чыгачаклар һәм зур

эшләргә омтылачаклар. Алар без күрмәгән биеклекләргә ашкыначаклар. Ә биргә яшь буын килүдән туктамаячак һәм аларга да Ленин тормышы дәрт биреп торачак. Бу йорт — мәңгелек чишмә, әбелхаят урыны.

Бакчада яшь агачлар, гөл-чәчәкләр белән бергә карт каеннар һәм чыршы-наратлар да бар. Миңа калса, җәй көннәрендә Володя аларның төпләрендә уйланып утыргандыр, чокырлардагы тәбәнәк өйләрнең ишек алларыннан гармун тавышлары, җыр ишетелгәндер, русча-татарча аерым сүзләр яңгырагандыр, иртән булса, эшчеләр Суконныйга эшкә киткәннәрдер, кич булса, арып-талып, эштән кайткаәннардыр. Алар шунда, берничә адымда, яшь Володя Ульянов аларның киләчәк бәхете турында уйлануны белмәгәннәрдер.

Ленинның акылы да, хыялы да яшьтән үк бик зирәк булган. Ленин акылыннан, Ленин хыялыннан яңа дөнья, яңа гөл-бакчалар туган. Икенче яктан, Ленинның үзен дә эшчеләр сыйныфының зарурлыгы, көрәш ихтыяҗы тудырган бит. Революцион диалектика! Ленинның тарихи ролен белгәнгә, бер нәрсәгә дә гаҗәпләнмисең, шулай да япь-яшь егетнең акыл зирәклегенә таң каласың: ул бит башкаларның күңел күзе дә күрмәс нәрсәләрне күргән, кыюларның кыюлыгы, акыл ияләренең акылы җитмәс эшләргә тотынган, шуңа җаны-тәне белән инанган, иң кыен вакытларда да юлыннан читкә тайпылмаган һәм үз эшен, дөресрәге, бөтен дөнья пролетариатының иң зур эшен, тарихи миссиясен гаҗәеп гүзәл рәвештә башкарып чыккан. Нинди баш, нинди йөрәк булган аңарда!

Ленин йортында минем күп мәртәбәләр булганым бар, бу юлы кермим, пионерлар артыннан озак кына карап торам да урынымнан кузгаләм. Узышлый, музей каршында туктаган бу автобусларга күз ташлыйм, Горький яшәгән йортка карап алам. Тагын тарих. Ләкин нурлы, бөек тарих!

Мин Ульяновлар урамына килеп терәлә торган Комлев урамы буйлап барам. Бу урам миңа таныш, монда торганым да бар. Әнә мәһабәт хезмәт сарае, әнә чатта барыбызга да таныш ГИДУВ бинасы, каршыннан трамвай юлы үтә. Володя Ульянов моннан йөргән елларда бу трамвай юлы да, бу мәһабәт бианлар да булмаган, бу урам да болай дип аталмаган.

Ул чакта Казанда тууга караганда үлем-бетем күбрәк булган һәм статистиклар 66 елдан соң Казан бөтенләй үлеп бетәргә тиеш дип исәпләгәннәр. Хәзерге укучы бу юлларны укыгач, билгеле, елмаеп куяр. Казан халкы ул еллар белән чагыштырганда күп мәртәбәләр артты. Ләкин статистиклар үзләренең нәтиҗәләрендә күп ялгышмаганнар, тик 1917 елда Октябрь революциясе буласын, аңа Казан студенты Владимир Ильич Ульянов-Ленин җитәкчелек итәсен белмәгәннәр.

Трамвай юлын үткәч, бер катлы агач йорт алдында туктыйм: бу йорт казанлыларга шулай ук бик таныш: бу йортта 1887 елның 5 декабрена каршы төндә Владимир Ильичны беренче тапкыр кулга алалар, төрмәгә утырталар, аннары Кокушкино авылына сөргенгә озаталар. Аңарчы, 4 нче декабрьда, университетта студентларның зур демонстрациясе була, студентлар хәрәкәте дәүләткә каршы төс ала, алар түзеп торып булмаслык тормышны гаепләп күтәреләләр. Ленинны кулга алырга килгән жандарм: «Нәрсәгә дип сез бунт күтәрәсез, егет,— ди,— алдыгызда стена».

— Стенасын стена, ләкин черек: төртсәң җимерелергә тора,— дип җавап бирә Ленин.

Ленинның биографиясен һәм революцион эшчәнлеген язучыларга хронология бик кирәк. Ленин тормышындагы елларның түгел, айларның да, хәтта атналар көннәрнең дә әһәмияте бар. Мин исә Ленин

эзләре буйлап барырга тырышам. Минем өчен эзләр әһәмиятле, ә хронология ул хәтле түгел. Менә бакчалар — Эрмитаж һәм Горький бакчалары. Алар бер-берсеннән ерак түгел, бер үк урамда. Беренче таудан университетка барсаң, я тегесе, я монысы яныннан үтмичә булмый. Ленин аларның икесе яныннан да узгандыр. Бәлки, кайбер көннәрдә, вакыты иркенрәк булганда, Ленин шул бакчаларның берәрсендә озаграк утырып торгандыр, биек агачлар башына карагандыр, аннары Горький әсәрләрендә язылган Марусовкага төшеп киткәндер. Хәзер инде әүвәлге Марусовка юк, Горький китабын ачып карамасаң, аны күз алдына китерүе дә кыен. Тик мемориаль такта гына бу урында элек Марусовка булганлыгын әйтә. Монда инде Алексей Максимовичның җуелмас эзләре күбрәк, шулай да анда Володя Ульянов эзләре дә булырга тиеш. Нинди уйлар белән ул моннан үткәндер? Патша Россиясенең мещан базын күреп нәфрәтләнгәндер дә, халыкны шундый түбәнлеккә төшергән стройны нигезенәчә җимерергә, ватарга кирәклеген уйлагандыр.

Мин, студент Володя Ульянов һәйкәленә карап, университет каршында утырып торам. Нинди ямьле, күңелле, иркен биредә! Бу урамның иске рәсемнәрен караганым бар. Хәзерге кебек асфальт та, яшел бөдрә агачлар да, бакча да булмаган монда. Ак колонналар өстендә император университеты дигән язу һәм ике башлы бөркет кенә канатларын җәеп торган.

Хыялга чумсаң, әллә кая алып китә. Менә яшь Володя һәйкәлдән сикереп төшә һәм бер иңенә салган ялтыр төймәле кыска курткасын рәтли-рәтли «Alma mater»га — университетка кереп китә, ә анда...

Хәзер монда студентлар ел саен тарихи декабрь көннәрен билгеләп үтәләр. Борынгы студентлар җыры — «Гаудсамус» моңнары астында яшьләр, элекке император университеты студентлары формасын киеп, аудиторияләрдән атылып чыгалар да үзәк вестибюльгә йөгерәләр, аннары киң баскычлардан Актлар залына күтәреләләр. Һәрберсенең кулында — Казан студентларының ачуын белдергән мәгълүм петицияләр. Иң алда — Володя Ульянов. Биредә ул беренче революцион чынныгуын ала...

Володя Ульянов укыган аудитория хәзер — музей. Моннан тарих узган. Әйе, кайчак тарих без йөргән эзләрдән узып китә, ә без аны белми дә калабыз. Берәүгә дә үзе исән чакта һәйкәл куймыйлар.

Актлар залы стеналары яшь Ленинның дәртле һәм нәфрәтле тавышын ишетеп калганнар, ләкин алар берни дә сөйләмиләр. Сөйләсәләр, күп нәрсә әйтерләр иде. Вакыт аларны тышкы яктан гына бераз үзгәрткән: патшаларның рәсемнәрен стенадан алганнар, кәкре аяклы урындыкларны чыгарганнар.

Тарихтан без беләбез: университетның беренче гасырында монда Татарстанның төп халкы — татарлар бик аз укыган, татар яшьләренең җанлы тавышы монда яңгырамаган диярлек. Ә хәзер? Кайчакта бөтен Актлар залы татарлар белән тула. Үзләре белемгә сусап та университетта укый алмаган татар мәгърифәтчеләренең һәм әдипләренең Актлар залында хәзер тантаналы юбилей кичәләре үткәрелә. Бу залда бик күп борынгы һәм хәзерге язучыларның исемнәре яңгырый, рәсемнәре эленеп тора. Ихтыярсыз уйлап куясың: монда Владимир Ильичның революцион эше генә башланмаган, монда шул бинниһая зур эшнең бер нәтиҗәсе — интернационал дуслык та чәчәк ата. Ленинчыл милли политика безгә «Alma mater»ның ишекләрен киң ачкан, шул ишекләрдән меңнәрчә татар балалары уку йортларына ыргылганнар. Хәзер инде үз халкыбыз арасыннан чыккан профессорлар да, академиклар да аз түгел. Математика, физика, химия, медицина, астрономия, әдәбият, сәнгать һәм башка бик күп өлкәләрдә атаклы галимнәребез житеште.

Бу — хәзерге көннең гадәти нормасы булып китте, монда инде беркем дә гаҗәпләнми, чөнки совет тормышының асылы шул.

Хәзер илебездәге бар халыклар, Ленин юлыннан барып, дөньядагы Беренче тауга күтәреләләр. Хәерле юл!

## Үшнә буе тал-чыбык



Казанда торып та Кокушкинода булмаган кешеләр сирәктер. Тормыш никадәр генә ыгы-зыгылы булмасын, кеше башына төшә торган мәшәкатьләр аны никадәр генә интектермәсен, ул барыбер бу истәлекле урынга барып чыгарга җай таба. Казанга читтән килгән кешеләр дә анда барырга тырышалар, чөнки анда алырга мөмкин булган тәэсоратларны бүтән бернәрсә дә бирми, бирә алмый. Кечкенә Үшнә елгасы турында әллә нихәтле сөйләргә, язарга мөмкин, ләкин үзең шунда барып яр читендә утырып уйлануларны һич нәрсә алмаштыра алмый. Ихтимал, шунда Апакай крестьяны, башын кашып, бөтен зар-моңын җырга салып сузгандыр: «Үшнә буе тал-чыбык...» Ленин бу җырны ишеткәндер, мәгънәсен аңламаса да ярлы крестьянның хәсрәтен күңеле бик яхшы төшенгәндер. Хәсрәтнең тәрҗемәчесе кирәкми бит. Хәсрәт йөрәктән йөрәккә күчә.

Кокушкино — Үшнә буенда кечкенә генә бер рус авылы. Күршесендә, ике-өч чакрымда, зур татар авылы — Апакай. Билгеле, Володя аның мәгънәсен сорагандыр инде. Апакай апа сүзеннән алынганлыгын, житмәсә апа сүзенең иркәләп әйтелүен белгәч, ихтыярсыз елмайгандыр. Халык бит исемнәрне күктән алмый, Апакайның да үзенә күрә тарихы бардыр. Тик берәү дә язып алмагач, ул бүгенге көннәрдә онытылган. Һәрхәлдә, мин бу турыда төпле нәрсә укыганым һәм ишеткәнем юк. Апакайлылардан да сораштырганым бар, алар да кистереп бер нәрсә дә әйтә алмадылар.

Мәгълүм булганча, Кокушкинода Ульяновларның кардәш тиешле кешеләре — доктор А. Д. Бланкның кечкенә генә утары бар. Доктор үзе үлгәч, бу утар аның кызларына күчә. Әле Владимир Ильич бирегә килгәнче үк монда аның яраткан апасы — Анна Ильинична тора. Абыйсы Александр Ильич эше буенча аны биш елга Себергә хөкем итәләр. Әниләре Мария Александровна бик күп йөри торгач, кызын ерак Себер урынына Кокушкинога күчерүгә ирешә. 1887 елның җәендә Анна Ильинична Кокушкинога килеп тора башлый. Шул ук елның декабрендә Владимир Ильичны да бирегә озаталар. Патша хөкүмәте аны яшерен рәвештә бик нык күзәтеп тора, аларга килә торган һәм алар җибәрә торган барлык хатларны укый, кемнәр белән аралашуларын тикшерә.

Кыш көннәрендә Владимир Ильич Кокушкино тирәсендә чаңгыда йөри, ауга чыга, җәй көннәрендә әйләнә-тирәдәге урманнарда күңел ача, авыл халкы белән очраша, сөйләшә. Бу ачык чырайлы, ягымлы егетне авыл халкы бик ярата, онытмый, соңыннан аны «бөтен Россиягә бер генә» дип атый, ана авылдаш дип дәшәләр. Кокушкино крестьяннарының Ленинга язган хатларын хәзер бөтен ил белә.

Владимир Ильич һәм Анна Ильинична биредә вакытларын әрәм үткәрмиләр, бик күп китаплар укыйлар, киләчәк өчен көрәшкә әзерләнәләр. Бәхетләренә, биредә абый тиешле кешеләре — А. И. Пономаревның бай китапханәсе була. Соңыннан Владимир Ильич үзе дә мондагы кадәр күп китап укуны хәтерләмәвен әйтә.

Мин Кокушкино утарында (хәзер монда музей) иптәшләрем белән уйланып йөрим. Сөйләшәсе килми, шул гүзәл бакчаның бөтен һавасын, ямен йөрәккә сыйдырып Казанга алып кайтасы килә. Әгәр шулай итә алсак, без нинди бай булыр идек.

Ленин торган зур өй дә, флигель дә юк инде, ул янган. 1939 елда флигельне яңадан торгызганнар. Владимир Ильичның кардәшләре истәлекләре белән бик нык ярдәм иткәннәр. Владимир Ильичның һәм Анна Ильиничнаның бүлмәләре нәкъ үзләре торгандагы кебек итеп торгызылган.

Ленин Кокушкинода бала чакта да, гимназиядә укыган чагында да булгалый. Җәйге каникуллар вакытында алар бирегә Сембердән киләләр. Зур бакча, саф сулы Ушнә, яшел урманнар һәм кырлар, болыннар һәм авыллар балаларның күңелләрен тарткан. Никадәр истәлекләр. Кайчагында алар уенга бирелеп өйгә бик соң кайтканнар, балалар ишектән түгел, тәрәзәдән генә кергәннәр. Тавыш чыкмасын өчен, тәрәзә төбенә басма куйганнар. Музейда шул басма әле дә бар. Кечкенә генә деталь, ләкин шуңа карыйсың да бөтен нәрсә җанлана кебек, үзеңнең бала чакларың искә төшә. Иң мөһиме: син шаян Володяны күрәсең, тере итеп күрәсең — аңа балаларга хас бер нәрсә дә ят һәм чит булмаган.

Шул балалык елларында Володяның Бәһави исемле дусты булган. Бәһави — көтүче малай. Ушнә буенда болында маллары ял иткәндә, ул моңланып-моңланып җырларга яраткан. Ахрысы, ул күп җырлаган. Володя аны уйга калып тыңлаган. Татарчаны бераз төшенә дә торган булса кирәк, чөнки Ленинның кардәше, балалык вакытында һәр чак аның белән бергә булган Н. И. Веретенников Бәһавиның бер җырын истәлекләрендә татарча үк китерә. Менә ул җыр:

Сары-сары, сап сары,
Сары чәчәк саплары.
Сагынырсың, саргаерсың,
Килсә сугыш чаклары.

Бу җырны иң элек патша сугышларын башларыннан кичергән карт солдатлар җырлаганнардыр инде, Бәһави алардан отkандыр. Әмма үсеп җиткәч, Бәһави үзе дә сугышка киткән һәм, ихтимал, бу җырны көзге ачы җилләрдә юеш окопларда кабат җырлагандыр. Октябрь революциясе булгач, Бәһави йөз меңнәрчә солдатлар кебек, Кызыл Армия сафларына килеп кушыла һәм утлы давылларда аның эзләре кайдадыр югала. Бәлки, ул яшьлек дустының яшь совет дәүләте башлыгы булганлыгын белгәндер, бәлки, белсә дә мондый могҗизага ышана алмый башын кашыгандыр. Бернәрсә ачык: революциягә ул тулысынча ышанган һәм аның өчен гомерен дә кызганмаган.

Җыр югалмый, җырны атып та, үтереп тә булмый. Ихтимал, соңыннан сөргеннәрдә һәм эмиграциядә йөргәндә дә, яшь совет дәүләтенең ашыгыч, үтә ашыгыч мең төрле эшләре арасында да бу яшьлек хатирәләрен Владимир Ильич күп мәртәбәләр исенә төшергәндер һәм Бәһавиның язмышы турында да уйлангандыр. Ленинның хәтере гаҗәп үткен булган. Соңыннан, партиянең X съездында, халык шагыйре Габдулла Тукайны онытмаганлыгын әйтә ич. Ничек Тукай аның исендә калган? Ул чакта рус телендә Тукайның тәрҗемәләре бик аз булган бит. Әллә русчага тәрҗемә ителгән шул аз санлы Тукай шигырьләрендә дә Владимир Ильич халыкның ачы язмышын күргәнме? Ихтимал, кем булса да аңа Тукайның язмышы турында сөйләгәндер. Тукайның балалык еллары көтүче малай Бәһавиның авыр тормышына бик охшаган бит. Икенче төрле әйтсәк, аларның авыр язмышында хезмәт иясе татар халкының газаплы типик хәле чагыла. Гомумиләштерергә яраткан Ленин шундый нәтиҗә ясамадымы икән?

Бер тапкыр, СССР Верховный Советы депутаты буларак, Апакайга барып чыктым. Апакайга баргач, моңарчы булганың булса да, ничек инде Ленин музеена кермисең. Минем янымда Апакайның авыл Советы председателе Советлар Союзы Герое Галимҗан Камалиев та бар

иде. Без Апакай хәлләре турында, аның мәктәбе һәм Ленин музееның ихтыяжлары турында озак сөйләштек. Мәктәпкә халык күптән инде Ленинның әнисе — Мария Александровна исемен биргән. Бик дөрес эшләгән, апакайлыларга ул иң якын, иң кадерле ана. Рәсми карарны көтмичә, моны мәктәп коллективы, ата-аналар советы эшләгән. Шуннан халык теленә дә кереп киткән, хәзер бу мәктәпне бары тик Мария Александровна мәктәбе дип йөриләр. Мәктәп коридорында аның зур рәсеме тора. Укытучылар да, ата-аналар да, балалар да мәктәп каршында Мария Александровнаның таш бюстен күрергә телиләр. Авыл Советы председателе Галимҗан Камалиев та бу фикерне яклады. Мин Казанда тиешле кешеләре белән сөйләшергә булдым. Озакламыйча, өлкән художнигыбыз Бакый ага Урманчене дә күрдем. Ул Мария Александровнаның бюстен эшләү теләге хыялында күптән йөргәнлеген әйтте.

Хәзер бу бюст Апакай урта мәктәбе ишек алдын бизәп тора. Җәй көне ул чәчәкләр эчендә утыра. Ана карыйсын да күңел җилкенеп куя: безнең балаларыбыз да, Владимир Ильич кебек, бөек патриот булып тәрбияләнсеннәр иде! Бу кечкенә һәйкәл — зур хәрефтән язылган торган Анага — юлбашчы анасына халыкның тирән мәхәббәте һәм рәхмәте.

Кич белән клубта сайлаучыларның зур җыелышы булды. Мин халыкка СССР Верховный Советы сессияләре һәм анда кабул ителгән соңгы карарлар турында сөйләдем. Аннары Галимҗан Камалиев мине Казанга озатып куйды. Яз башы иде, кар әле эреп бетмәгән, юлда, карангыда, тонык кына су ялтырый. Төнлә бераз суытса да, тундырмаган, һава җылы, яңа туфрак исе сизелә. Тиздән-тиздән бу кырларга тракторлар чыгар. Кайчандыр рәтле атлары да булмаган, җирне сука белән тырнаган авыл халкы куәтле тракторларның иртәнге гөрелтесеннән уяныр!

Галимҗан машинаны үзе йөртә. Аның җитди йөзенә читтән генә карап Баһави турында уйландым: нигәдер Баһави миңа шушы Советлар Союзы Герое булып тоелды. Алтын Йолдыз һәм Ленин ордены белән бүләкләнгән батырлыгын күрсәткәндә, иске дус буларак, Владимир Ильич үзе дә аңа дәрт биреп торгандыр кебек, аннары, авыл Советы председателе булып сайлангач, я, туган, инде яңа авылны төзәргә җиң сызганып кереш, дигәндер шикелле иде.

Авыл Советы башлыгы булып эшләү — мактаулы дәрәҗә. Даһи юлбашчы яшәгән җирдә (хәзер Кокушкино белән Апакай бергә кушылган һәм Ленино дип йөртелә) авыл Советы председателе булып эшләү әйтеп тә бетергесез зур һәм җаваплы дәрәҗә. Ленин Васыятьларының үтәлүен монда халык беренче чиратта көтә һәм бу миллионнар күз алдында башкарыла. Ел саен Кокушкинога илебезнең төрле почмакларыннан күп меңнәрчә экскурсантлар килеп тора. Алар бит музейны гына түгел, тирә-як авылларны да, бигрәк тә Апакайны, күздән кичерәләр. Ә халык күзе күп нәрсәне күрә.

Апакайда инде күп нәрсә эшләнгән, ләкин эшлисе эшләр дә әле монда күзгә бәрелә. Апакай кидәчәктә Ленин истәлегенә багышланган ачык музей булырга тиеш. Үзәге — Ленин музей-йорты. Билгеле, бу кечкенә эш түгел, бик зур эш, ләкин безнең халкыбызның бөек юлбашчыга булган мәхәббәте шундый зур, киләчәктә бу эш, һичшиксез, эшләнер дип ышанасы килә.

Кокушкино музеенда мин әллә ничә тапкыр булдым. Барган саен, күңелдә яңадан-яңа уйлар туа. Соң шулай булмыйча! Яшьлегендә даһи Ленин шушы бәләкәй Үшнә буенда йөргән ләбаса, менә шушы беседкада, ихтимал, Чернышевскийның «Нишләргә?» дигән романын укыгандыр, уйлангандыр. Бу роман Ленинның Кокушкинодагы китапханәсендә булган. Аның никадәр көчле тәэсир ясавы турында Владимир Ильич үзе дә истәлекләрендә яза. Ихтимал, менә шушы сирень төплә-

ренә ятып, сирень чәчәк атканда «Современник» журналын укыгандыр,— бу журнал комплектлары да Кокушкинода булган бит. Бу сиреньнарны Ленин үзе утырткан дип сөйлиләр. Күр ничек купшы булып чәчәк аталар алар, исләре нинди хуш!

Аннан соң бик күп еллар үткән. Ихтимал, болар Ленин утырткан сиреньнар да түгелдер, болары бәлки Ленин утыртканнарның тамырларыннан гына киткәндер. Күзеңне чак кына йомсаң, бөтен илдә Ильич чәчкән гаҗәеп гөл-чәчәкләрне күрәсең. Алар яңа тормыш гөлләре.

Узган ел Татарстан дәүләткә 92 миллион поттан артык ашлык тапшырды. Бу кадәр байлыкны безнең кырлар гомердә күрмәгән. Бу бит очраклык та, күктән төшкән бәхет тә түгел. Бу — халыкның титаник хезмәте, Ленин партиясенең гүзәл һәм батыр эшчәнлеге нәтиҗәсе, күмәк хуҗалык эчендә яткан биниһая көчләрнең — Ленин хыялының чәчәк атуы. Әйтерсең, Кокушкинодан башлап бөтен ил кырлары буйлап Владимир Ильич үзе йөреп чыккан һәм игенчеләргә үзе киңәшләр биргән. Ахрысы, шуңа күрәдер, һәр игенче Ленинны иң өлкән агроном итеп саный һәм аның киңәшләренә колак сала.

Кокушкино музее хезмәткәрләре миңа сөйләгәннәре бар: карт игенчеләр монда бик еракларда киләләр икән, тын калып Ленин йөргән бүлмәләрдә йөриләр, бик сзак Ильич бүлмәсенә, аның өстәленә, өстәлдәге гади кара савытына, столяр станогына карап торалар икән. Хәзерге яшьләргә бу тормыш мәңге шулай булгандыр шикелле тоела, ә карт игенчеләр исә иске тормышны үз башларыннан кичергән, чыра яндырып, чыпта ябынып көн күргән, сука белән кырны сөргән. Аларга бу турыда сөйләү кирәкми, алар үзләре боларны башларыннан кичергәннәр. Аларга бүгенгене карау, киләчәккә күз ташлау кызыграк. Ленин әйткән икән, ул хыялланган икән, димәк, ул чынлыкта да шулай булачак, халык могҗизага да ышана — чөнки Ленин сүзе бер вакытта да чынбарлыктан аерылмый.

Шул уйлар белән Уфадагы Ленин музеенда да йөргәнем бар. Ленин булган урыннарда син үзеңне мәңгелек тереклек чишмәсеннән су эчкән кебек хис итәсең. Сафланасың, уйларың тирәннәнрәк куба. Ленин бар халыкларга бик якын булган. Кайдан гына үтсә дә Ленин — Ленин булып кала: гаҗәеп бөек, гаҗәеп кешелекле. Ил кайгыртучысы ул, яңа тормышка ыргылучы халыкларның даһи юлбашчысы. Язгы кояшка карап барлык үсемлекләр яфрак ярган шикелле, Ленин янында булып кайткач, яңа эшләргә омтыласың. Бу бит бәхет!

## «Сембер калалары һай Иделдә...»

Кайда, кайчан ишеткән идем мин бу җырны? Мөгаен, бала чакта булгандыр. Аннан соң дистәләрчә еллар үткән, җыр да, сүзләре дә онытылган. Бары тик соңыннан, алтмышынчы елларда, Иделдә сәяхәт иткәндә искә төште. Аннары, үз алдыма кабатлый-кабатлый, җырның сүзләре тагын үзгәргәндер. Була бит шулай: син бер үк җырны авыз эчеңнән күп тапкырлар тәкрарлыйсың, ниндидер тәэсирләр аркасында аның аерым сүзләре үзгәрә, ә син моны сизмисең дә. Кем дә булса әйтсә, искә дә төшәр иде, ләкин синең авыз эчеңнән нәрсә мыгырдавыңны кем ишетсен. Яхшы җырлый белмәгән кешеләр, авыз күтәреп, бар дөньяга кычкырмыйлар инде.

Акыл белән диңгез романтикасын бик яратсам да, диңгез буенда житәрлек күп тормагангамы, диңгез шаулавы, давыллы көннәрдә бик дәһшәтле һәм матур булса да, миңа артык тәэсир итми. Ә менә Идел бөтенләй башка. Билгеле, элекке Идел белән хәзерге Идел бер түгел. Идел турындагы барлык гүзәл җырлар, легендалар, парчалар аның ерак үткәненә карый, хәзер инде хан кызын суга ташлаган Стенька

Разинннар да, көзгә җил кебек моңлы җырлар җырлаган бурлаклар да юк, алар йөргән яр буйлары да су астында калган. Ләкин халык күңеле барысын да хәтерли, бер нәрсә дә онытылмаган, югалмаган. Ахрысы, шуңа күрәдер, Иделгә чыксаң, Идел синең күңеләңә бик хуш килә, анда рухың белән уртаклык табасың, аның бер туктаусыз тибрәнеп торган дулкыннары сиңа бик тирән мәгънәле сер сөйли кебек. Халыкның бөтен тормышы: маңгай тирен сыккан авыр хезмәте дә, канлы көрәшләре дә күз алдына килә, кинәт исеп киткән талгын җилдә гүзәл азатлыкны тоясың. Ул да булмый, Идел киңлегендә тагын моңлы җыр ишетелә — Идел беркайчан да җырсыз яшәмәгән һәм яшәмәстә — ерак үткәннәр дә, бүгенге көннәр дә бергә гәүдәләнә анда.

Иделне Россиянең үзәк урамы дип йөртәләр. Моннан Россиянең тарихы узган. Бөтен дөнья пролетариатының даһи юлбашчысы Владимир Ильич Ленинның Иделдән булуы тарихның шуклыгы түгел. Ленин чын мәгънәсендә Идел баласы, шуңа күрә ул халык тормышын, аның күңелен һәм хыялын бөтен нечкәлекләренә кадәр аңлаган.

Теплоход Ульяновскига — элекке Сембер каласына, Владимир Ильичның туган нигезенә якынлаша. Пристань биек яр итәгендә, шәһәр үзе тау башында. Ерактан ук аңа сокланып киләбез. Билгеле, Ульяновскины беренче күрүебез түгел, ләкин бу урыннар — тылсымлы бер китап кебек, килгән саен әллә нихәтле яңа, гүзәл сәхифәләрен ачасың, монда һәр нәрсә әһәмиятле, серле. Монда һәр урам, һәр йорт, һәр таш Ленинның бөеклеген янача, йөрәккә якын итеп сөйли, башта бик күп фикерләр туа. Әлбәттә, тарихка да күз саласың, ансыз мөмкин түгел, ләкин барыннан да элек Ленин киләчәккә омтылган. Шуңа күрә бу җирләрдә зур-зур галимнәрнең дә кат-кат йөрүләре бик табигый хәл. Ләкин биргә зур галимнәр генә килми, бирегә меңнәр, миллионнар килә, ачык кына итеп әйткәндә, бирегә халык килә һәм якын әйләнә-тирәләрдән генә түгел, бик еракларлан, чит илләрдән дә киләләр. Ленин исеме бөтен җир шарына таралган, Европадан килүчеләр дә, Америка халыклары да, Африка, Азия һәм Австралия кешеләре дә Ленин туган йорт алдында тын калып торалар. Дөньяның яңа тарихы, бөтен илләрдә эшчеләр сыйныфының азатлыгы нәкъ менә шуннан башлана бит.

Әчкә керәсең. Карыйсың. Сулыш туктала кебек: бөтен дөнья пролетариатының даһи юлбашчысы, героик Коммунистлар партиясен төзүче, беренче Совет дәүләтен оештыручы иң зур галим, иң бөек иҗатчы шуннан чыккан бит! Син юлбашчының балачагы һәм яшьлеге үткән бүлмәләрдә йөрисең, аның кулы тигән әйберләргә үз күзең белән карыйсың, ишек алдына чыккач, ул уйнаган мәйданчыкларга тукталасың. Җиңел аяклы Володяга ияреп урамга, бакчаларга чыгасың, Карамзин, «Обломов» авторы Гончаров һәйкәлләре алдына тукталасың — алар хәзер сиңа мең мәртәбә этрафлырак булып күренә, аннары тагын күңелең белән Ульяновлар өенә кайтасың. Менә Володяның сеекле энисе, этисе. Менә шушы рояльдә Мария Александровна гаиләнең яраткан көйләрен уйнаган, ул хәзер дә, кунак бүлмәсенә тавышсыз гына керер дә, уйнап җибәрер кебек.

Йөрәгендә борчулы уй: менә шушы бүлмәләрдә бит алар Александрның Петропавел крепостенда асып үтерелү хәбәрен алалар. Менә шунда инде яшь Ленин үзенең тарихка кереп калган беренче революцион сүзләрен әйтә: «Юк, без башка юлдан барырбыз»,— ди.

Экскурсантлар Ленин укыган гимназия бинасында. Күршеләрен белән дә пышылдашасы килми. Нигә сүз? Кирәкми. Менә күңелең түйганчы кара: Ленин укыган класс бүлмәсе, Ленин имтихан тоткан, алтын медаль алган зур зал.

Экскурсовод гимназиядә укыганда яшь Володяның тормышында булып үткән вакыйгалар, аның яраткан укытучылары турында сөйли.

Беренче килгәндә, син боларны бик зур игътибар белән тыңлаган идең, икенче, өченче килгәндә син инде күзгә күренмәгән вак, ләкин мөһим детальләргә игътибар итәсең, бәлки язучы булуың да роль уйный торгандыр. Син бит һәр җирдә үзеңчә генә күрергә тиешсең, шунда гына синең күзәтүләрең ни булса тора.

Мин экскурсиянең маршрутын бер вакытта да язып бармадым, аңа игътибар да итмәдем. Күргәннәремне үземчә хәтерләргә тырыштым. Менә зур яшел бакча, каршында Ленинның әтисе — Илья Николаевичның һәйкәле. Йөзенә карыйсың: бөтен гомерен халык мәгърифәтенә багышлаган, көче җиткән кадәр халыкка аң-белем нуры чәчәргә тырышкан карт укытучы йөзе. Аның һәйкәле кырыенда чабаталы, киндер күлмәкле бер малай сыны. Бу — чуваш халкының булачак атаклы укытучысы Яковлев. Мин, ирексездән, чуваш халкы турында уйлыйм. Безнең халыкларның ул чактагы ачы язмышы бер бит. Аннары тагын шатланып куям: нәкъ Владимир Ильич туган елны аның әтисе Илья Николаевич инициативасы белән Петракси авылында татар балалары өчен дә мәктәп ачылган һәм анда беренче дәресне Илья Николаевич үзе үткәргән...

Бу зур бакчада кайчандыр чиркәү һәм каберлек булган. Соңыннан Ульяновск кешеләре бу чиркәүне сүткәннәр, каберлекне күчергәннәр. Монда фәкать бер кабер — Ленинның әтисенең кабере генә калган. Без шул кабер янында озак кына басып торабыз. Ләкин күңелгә әллә нинди караңгы уйлар килми, киресенчә, Кеше эшенең бөек нәтиҗәсе монда ачыграк күренә һәм исәннәрне зур эшләргә ашкындыра. Чөнки халыкка багышланган зур эшләр югалмый, алар үлемсез.

Ленинның тууына йөз ел тулу көненә Ульяновск гаҗәп бер ачык музей булыр дип сөйли безнең экскурсовод. Яңа гүзәл биналар калкыр, бу кадерле урыннарны халкыбыз гасырларга саклар.

Ахырдан без биек яр буендагы гүзәл бакчага килеп чыгабыз. Монда Сембер каласын акгвардиячеләрдән азат иткән тимер дивизиянең батыр сугышчылары күмелгән. Аларның каберләре өстендә күз явын алырлык кызыл чәчәкләр үсә, мәңгелек ут яна.

Язучы кешегә, Ленинны тудырган калада булып, әллә нихәтле тәэсоратлар алып — монда аларның меңнән бере дә сөйләнмәгәндер — яңадан Идел киңлегенә чыккач, әдәбият турында уйламый булмый. Әдәбият һәм тормыш. Болар бит аерылгысыз бәйләнгән. Ленин акылы белән тамырдан үзгәртелгән тормышның әдәбиятка йогынтысы зур, икенче яктан, ленинизм идеяләре белән нык коралланган әдәбиятның тормышка да тәэсире көчле.

Шунысы бик кызык: Ленин анкеталарында үзен хезмәте буенча литератор-әдип дип атый. Бер сүз, ә никадәр уйландыра! Китап киштәләрендә Ленинның томнары күз алдына килә. Дөрес, Ленин шигырьләр дә, романнар да язмаган, ләкин аның хезмәтләре яңа дөньяның шигърияте һәм романнары туугa турыдан-туры ярдәм иткән һәм итә. Ленин хезмәтләре язучылар өчен кыйммәте бетми торган мәңгелек чыганак!

Уйлануларымны дәвам итәм. Ленин бик күп китап укыган. Ләкин кулына эләккән теләсә нинди китапны укымаган,— бу мөмкин дә түгел, кирәк тә түгел. Эшчеләр сыйныфы хакыйкатен ачкан китапларны исә укымый калдырмаган. Монда икенче нәрсә гаҗәпләндерә: Ленин никадәр әтрафлы галим булмасын, ул үзеннән башкаларның фикерләренә бик игътибарлы булган, ә үзләрен «дөньяның кендеге» итеп санап йөрүче абзыйларга җирәнеп караган.

Без Ленинны өйрәнәбез һәм һәрвакыт өйрәнергә тиешбез. Ләкин яңа Ленин булу өчен түгел. Бик күп акыллы, даһи кешеләр булыр — прогрессның чиге юк — әмма Ленин кешелек тарихында бер генә, тарих аны кабатламаячак. Ленин тәгълиматы, киләчәккә барган саен, үзенең тирәнрәк, киңрәк мәгънәсен ача, нуры да арткаsuccessful-арта.

Ленин каласы, Октябрь революциясе турындагы сүзләр, әгәр санаучы булса, безнең иң яратып, иң күп сөйләгән сүзләребездер. Ләкин көндәлек тормышның үз агышы бар, син ни кадәр теләсәң дә, Ленинградтан шактый еракта торгач, турыдан-туры эшең дә булмагач, әйт дигәндә анда барып та чыга алмыйсың. Ләкин өмет өзмисең: бүген булмаса, иртәгә бармын дип тора бирәсең.

Ниһаять, без Ленинградта. Безнең арада, язучылардан тыш, артистлар да бар. Аларга нәрсә, алар монда хәтсез күп мәртәбәләр булганнар, күп йөргәннәр, ә тавышлары, радио буенча, бөтен калага, хәтта өлкәгә дә яңгыраган. Язучылар уйчанрак. Дөрес, аларның да кайберләре монда булгалаган, ә кайберләренең Ленин каласына әле беренче килүләре.

Ленинградта искитәрлек, таң калырлык урыннар бик күп. Ләкин без иң элек Ленин эзләрен күрергә ашыктык. Бары тик шуларны күргәннән, алар янында тын калып басып торганнан соң гына атаклы Петр һәйкәле дә, Нева елгасы да, Петропавел крепосте да, Исаакий соборы да үзләренең бөтен гүзәллекләрен һәм дәһшәтләрен ачалар.

Ленин каласы...

Без генә түгел, безнең илдәге барлык хезмәт ияләре Ленинградта булуны, Ленин урыннары белән танышуны үзләренең намус эшләре итеп саныйлар. Бу коры кызыксынудан тумый, мәгънәсе тирәнрәк, зуррак. Чит илләрдән дә монда бертуктаусыз килеп торалар. Аларның төрлесе бардыр инде, ләкин кем генә булмасыннар, безнең ил турында ни генә уйламасыннар, алар да Ленин даһилыгына һәм бөеклегенә баш имичә булдыра алмыйлар.

Кешеләр төрле китапларда, атаклы художникларның картиналарында Разливтагы Ленин шалашын да, революция штабы — Смольныйны да күп мәртәбәләр күргәннәр, шулай да болар күңелдәге рухи сусауны басмаган, миңа калса, киресенчә, арттырган гына. Давыл алдыннан — 1917 елның июль — августында — бөек юлбашчы яшеренеп торган шалашка башыңны тыгып карасаң, ул утырып торган учак янында үзең утырып торсаң, аннары тарихи Смольный залларында йөрсәң генә күңелгә гаҗәп күп төрле яңа фикерләр килә, син шул чорның дәһшәтле һәм кабатланмас үзенчәлекләрен йөрәгеңнән кичерәсең кебек.

Югыйсә, хәзер нәрсә, Разливка автомобильдә генә барасың — асфальт юл, кеше кайный, бер дә шәһәр чите димәссең. Каршыда бик матур итеп бетон һәм пыяладан салынган ярым бөҗра формасындагы павильон-күргәзмә һәм уку залы. Читтәрәк гранит шалаш. Ләкин күзләр иң элек шунда ук торгызылган чын шалашка юнәлә. Күр инде — ярамаса да, безнекеләрдән кемдер шалаш эченә үк кереп китте. Шалаш каршында — учак, таганда — корымга буялып беткән калай чәйнек. Менә түмәр. Владимир Ильич шул түмәргә утырып революция өчен аерата әһәмиятле хезмәтләрен язган...

Әйләнә-тирәдә — кыргый урман, алан читендә — ялгыз шалаш, бер кеше юк, тик Разлив күле ягыннан салкынча җил генә искән. Владимир Ильич монда июль вакыйгаларыннан соң яшеренә. Караңгыда, шалаш янында бер үзе утырганда, Европаның зур шәһәрләре, якты утлары белән балкып, күз алдына килгәндер,— аның әле эмиграциядән кайтканына да күптән түгел. Ихтимал, язуларыннан башын күтәргәндә, Петроград өстеннән аккан болытларны күргәндер, завод капкаларыннан кызыл флаглар күтәреп чыккан эшче отрядлар чалынгандыр.

Каләм очыннан очкын чыкмый, ләкин Ленин дәфтәре битләреннән бөтен дөньяны шатландырган һәм тетрәткән кызыл ялкын күтәрелгән. Бу салкын шалашта Ленин Октябрь революциясенең иң кайнар доку-

ментларын иҗат иткән. Ә анда, Петроградта, таш урамнарны айкап, аяктан егылганчы, теле сузылганчы жандармнар революция башлыгын эзләгәннәр.

Владимир Ильич та, партия дә моны белгәннәр, әлбәттә. Ләкин шуны белгән хәлдә, ике адымда патшаның иң усал этләре һаулап йөргәндә, Ленинда никадәр рухи тынычлык, никадәр корыч нервлар һәм революциягә никадәр ышаныч булган! Иң кискен минутта, Зиновьевларның революцияне сатканлыкларын белгәч тә, Ленин, чиксез нәфрәтләнсә дә, эшче сыйныфның революцион дәртенә ышанычын югалтмый, чигенми, моментның гаҗәеп киеренкелеген һәм җаваплылыгын аңлап революцияне җитәкләп бара. Менә кайда ул революцион бөеклек һәм куркусызлык!

Октябрь революциясенең иң кайнаган һәм хәлиткеч урыны, штабы — Смольный. Бу — һәр совет кешесенең аңына яшьтән сеңгән, йөрәгенә яшьтән утырган исем. Безнең кешеләр аны октябрят чагыннан ук белә һәм гомер буена изге урын дип саный.

Вакыт үтү белән кайнар таш та, кызган тимер дә суына. Әмма революция эсселеге беркайчан да суынмый икән. Октябрь революциясе тиңдәшсез көрәшләрдә җиңгәнгә ярты гасырдан артык вакыт узган инде, әмма Смольныйга хәзер дә тирән дулкынлану белән керәбез. Моннан торып Ленин революция көрәшләренә җитәкчелек иткән, монда вакытлы хөкүмәтнең бәреп төшерелгәнлеге, Октябрь революциясенең җиңгәнлеге игълан ителгән. Монда совет хөкүмәтенең беренче тарихи декретлары яңгыраган. Бик күп китаплар, рәсемнәр, кинофильмнар буенча безгә таныш булган зур залга керәбез, тын калып торабыз. Ак колонналар артыннан Владимир Ильич ашыгып килеп чыгар төсле яки аның ташка сеңеп калган йөрәккә якын тавышы яңгырар кебек. Безгә калса, әле дә бу зал тарихи җиңүдән әсәрләнгән эшчеләрнең, матрос, солдатларның тавышыннан гөрләп тора шикелле, мылтыклы кеше дә кайдадыр шунда Ленин белән сөйләшә кебек. Күзләр зур ачылган, күңелгә төрле картиналар килә.

Менә тагын безгә таныш булган бүлмә — Ленин бүлмәсе. Ленин бүлмәләренең барысына да бернәрсә — тыйнаклык, гадилек хас. Ул бер вакытта да тышкы бизәкләр белән ялтырарга тырышмаган. Кокушкинода да, Казанда да Ленин бүлмәләрендә бер генә дә артык нәрсә юк бит, бар да тормыш өчен, эш өчен кирәкле нәрсәләр генә. Димәк, бу аның шәхси бер ягы. Смольныйда да бу шулай. Шулай булуы табигый дә: революциянең хәлиткеч беренче көннәрендә шәхси уңайлыклар турында революционерлар уйламаган. Ак чехоллар киертелгән гади урындыклар, гади солдат караватлары. Аннары ул көннәрдә Владимир Ильичка йокларга туры килдеме икән? Мин аның Мәскәү Кремлендәге квартирында да булганым бар. Монда да шул ук хәл: Владимир Ильич үзенә бер нәрсә дә таләп итмәгән! Әллә шуңа күрәме икән, Ленин бүлмәсендәге һәр нәрсә безгә чиксез кадерле. Музей залларында әйберләрне кул белән тотарга ярамый яравын, ләкин Смольныйда Ленин бүлмәсендәге түгәрәк өстәлгә кагылмыйча үтә алмадым. Аннары тәрәзә янына килдем. Шул тәрәзәдән карап революция юлбашчысы Октябрь таңын каршылаган!

Экскурсовод безгә бик тәфсилләп сөйли. Мин ул сөйләгәннәрне барсын да кабатламыйм, аннары махсус әдәбиятта болар барсы да бар һәм күп мәртәбә тулырак та. Мин бары тик үз тойгыларымны бирергә генә тырышам. Алар, минемчә, башкаларга да уртак. Монда барыннан да элек Ватанчылык хисе кузгала, ә ул хис — совет кешеләренең иң гүзәл, иң саф хисе.

Хәзер Смольный коридорлары тып-тын, сирәк-сирәк кенә эш кешеләре үтеп тора. Алар безнең кебек төркемләп йөрүчеләргә исләре китеп

карамыйлар, чөнки мондый төркемнәр бу озын коридорларда көн саен булып тора. Барыбыз да әкрен генә, шауламыйча гына йөрибез.

Разливта да, Смольныйда да без бер төркем татар һәм Ленинград язучылары бергәләп йөрдек. Ленинград язучылары, билгеле, монда әллә ничә тапкыр булганнар, безгә исә барсы да өр-яңа, ләкин иптәшләрнең барсының да йөзләре уйчан, күзләре каядыр эчкә карыйлар,— тирән кичерешләрнең мәгънәсен аңларга тырышканда кешеләрнең кыяфәтендә гел шуны күрәсең. Минемчә, Ленин урыннарында җыйган энҗе бөртекләре кайчан да булса бер аларның иҗатларында чагылыр, тик нинди формада һәм кайчан — анысы билгесез. Бу һәр язучының фәкать үзеннән килә, монда ашыгу да, өлгерлек тә файда итми.

Ленинградта юлбашчы белән бәйле урыннар бик күп, без эш арасында, барсын да йөреп чыга алмадык, моның өчен махсус килергә, махсус йөрергә кирәк. Карый алган кадәресе дә безне канатландырып һәм кабындырып җибәрде, эшләргә яңа дәрт тудырды.

Ленинградның тарихы да, бүгенгесе дә сине тыныч калдырмый. Мондагы гаҗәп музейлар, һәйкәлләр, Эрмитаж, Петергоф фонтаннары, күз явын алырлык сарайлар, сүнми торган Пушкин поэзиясе... Ленинград кешене канатландыра, аның бөеклеген аңларга ачкыч бирә, батырлыгын аңларга ачкыч бирә, батырлыгын аеруча калку итә. Бу көннәрдә мин Ленинград кешеләренә сокланып йөрдем.

Безнең өчен бу калалар каласының тагын бер кадерле ягы шунда: аның ташларына басып, Тукай, Мулланур Вахитов, Галимҗан Ибраһимов йөргән. Бу турыда да уйланмый булдыра алмыйбыз. Мулланур Вахитов белән Галимҗан Ибраһимов турыдан-туры даһи Ленин кул астында эшләгәннәр, ә Тукайны ул партиянең X съездында телгә ала. Безнең галимнәрнең бу фактларны барсын да бергә бәйләп, яңаларын да өстәп, тизрәк өйрәнүләрен көтәм. Бу безнең иң күренекле сәхифәбез булачак.

Ленинградта без бик күп җирләрдә, шул исәптән аның мактанычы — атаклы Киров исемендәге заводында да (элекке Путилов заводында) булдык. Бирегә бик күп татар эшчеләре эшләгәннәр һәм эшлиләр. Аның хәтсез цехларында, радиосы аша татар әдәбияты турында әңгәмәләр, татар шагыйрьләренең шигырьләре һәм безнең җырлар яңгырап торганда, мин тагын бөек Ленин турында уйландым: без аның үлемсез идеяләре тормышка аша барган илдә яшәгәнгә генә, тигез хокуклы булып, бирегә килә алдык бит. Иске заманда Тукай булып Тукайның да тавышы монда яңгырый алмаган.

Легендар Кронштадтка барганда, Нева сулары һәм диңгез дулкыннарына карап, тагын Ленин турында уйландым. Монда әле һаман да Октябрь җиле исә кебек, дулкыннар шаулавы арасында юлбашчының халыкка мөрәҗәгать иткән ялкынлы тавышы яңгырый кебек.

Смольныйда йөргәндә, безгә бер вакыйга турында сөйләделәр. Хәзер диңгез дулкыннарына карап барганда шул исемә төште. Ул чакта Смольныйда Владимир Ильичны Волын полкының бер солдаты саклаган. Бу солдат Башкортстанның иң караңгы бер авылыннан булган, моңарчы һичбер вакытта да зур шәһәрләрне күрмәгән. Примус кабызганда исе китеп спиртның дөрләп януына карап торган. Тамаша!

Ул солдат Ильичны бик яраткан, аңа бары тик ак күмәч кенә ашатырга уйлаган. Ә ул чакта ак күмәчне кайдан аласың. Ул солдат үзенең полкына бара, Ильичка ашатырга ак күмәчебез юк, дип әйтә. Анда бик тиз ак күмәч табып бирәләр.

— Ильич бу ак күмәчне иллә тәмләп ашады да,— ди ул ахырда...

Бу эпизод Надежда Константиновнаның истәлекләрендә дә бар. Тик үз алдыма уйлап та куям: бу язучы, бик вак детальләргә басым ясап, юлбашчының бинигһая бөеклеген түбәнәйтмиме, дип әйтмәсләрме

икән? Минемчә, Ленинның бөеклеге тирәннән, халыктан үсә. Әгәр Ильич халыкка, халык Ильичка якын булмаса, аның бөеклеге шунда тамырланмаса, ул бөтен дөнья пролетариатының танылган юлбашчысы да була алмас иде...

## Ленин иң якын киңәшче

— Аруландым, малай, аруландым,— диде бер иптәш Мәскәүдә Ленин музееннан чыгып килгәндә.— Адәм баласына алай ярамаса да сукыр песи баласы булганмын икән. Әнә ничек Ленин дөньяны әйләндергән. Безгә дөньяны әйләндерәсе юк, ә эшлисе эш дөнья...

Бу иптәш утызның өстендә, Ватан сугышында да катнашкан, яраланган да, купшы сүзләр белән мавыкмый, тормышы да көйләнгән, төпле — инженер. Миңа калса, аның тормышында моннан соң да тышкы үзгәрешләр булмас, ләкин эчке яктан ул зур үзгәрешкә ирешер, эшкә булган мөнәсәбәте яңарыр, ә бу инде гади кеше тормышында аз нәрсә түгел...

Бер вакыт мине партиянең XXII нче съездына делегат итеп сайладылар. Партия съездына делегат! Дөресен әйткәндә, мин моны көтмәгән идем. Бу шундый бәхет, сөйләп тә бирергә мөмкин түгел. Ул чакта мин Ленин турында, партия турында бик күп уйландым. Ленин музееннан «аруланып чыккан» кеше дә шунда исемә төште.

Съезд партиянең яңа Программасын кабул итәргә тиеш. Бу тарихи документның һәр сүзе тирән уйлануны сорый, чөнки съездан соң ул күп миллионнарча коммунистлар тарафыннан тайпылышсыз тормышка ашырылырга тиеш. Делегатлар, Программаны кабул иткәндә, аңлы рәвештә һәм тирәнтен ышану белән кызыл мандатлар күтәрергә тиеш. Ничек инде монда Владимир Ильич белән киңәшмисең!

Съездлар сараеның сәхнә пәрдәсендә көне буе Ленин рәсемен күрәсең. Ул меңләгән коммунистлар баш өстеннән киләчәккә йөзә кебек. Киләчәк — якты коммунизм. Аңа болай да, күзеңне кыса төшеп тә карыйсың, Ленин җанлана кебек. Аннары, Лениннан күзеңне алып, президиумда утырган бөтен дөнья коммунистлары вәкилләренең йөзләренә текәләсең. Алар Ленинны никадәр якын һәм үз итеп кабул итәләр. Ленин һәрвакыт коммунистлар белән, һәм коммунистларның һәрберсе аның белән. Дөнья даһи Ленин белән киңәшә, аның васыятьләрен ничек тормышка ашыруны күзәтеп бара!

Шул көннәрдә башка делегатлар белән бергә, Ленинның Кремльдәге эш бүлмәсенә, аннары шунда ук Ленинның Надежда Константиновна белән торган квартирасына бардык. Дөнья күләм әһәмиятле мәсьәләләрне хәл иткәндә дә, чит илләрдән килгән кешеләрне кабул иткәндә дә Ленин гаҗәп тыйнак, сабыр булган. Менә шул кечкенә кабинетта ул атаклы инглиз язучысы Герберт Уэллс белән сөйләшкән. Фотограф шунда аларны рәсемгә дә төшереп алган. Ленин уң кулын яңагына куйган, йөзендә чак кына беленеп торган гаҗәп елмаю балкый. Барыннан да бигрәк киң маңгае ялтырап тора. Бу маңгайга син сихерләнеп карыйсың.

Замандашлары Ленинның сөйләүчене тыңлап тору гадәтен язалар: ул бер күзен кыса төшә, икенчесе сиңа төбәлә, гүя синең иң тирән серләреңне капшап карарга тырыша. Уэллс белән сөйләшкәндә төшерелгән рәсемендә дә шул нәрсә ачык сизелә: Ленин гүя язучының иң тирән уйларын капшап карый. Бу 1920 елның 6 октябренда Мәскәүдә менә шушы кабинетта була. Аннан соң үткән еллар Ленинның мең мәртәбә хаклы булганлыгын гына раслыйлар. Мәгълүм булганча, шул әңгәмәдән соң, Уэллс «Россия караңгылыкта» дигән китап яза. Мәшһүр язучы караңгылык күргән урында Ильич якты нур күрә. Уэллс аны «Кремль

хыялчысы» дип атый. Монда хаклык та юк түгел, Ленин хыялланырга яраткан, ләкин бу кечкенә кабинеттан Ленин күргән киләчәкне берәү дә күрмәгән һәм күрә дә алмаган. Владимир Ильич мәшһүр фантаст уйлаган мәгънәдә хыялчы булмаган, Ленин хыялы бер вакытта да чынбарлыктан аерылмаган, юлбашчы баштанаяк реалист, тик аның еракка күрүчәнлеге кайберәүләргә тормышка ашмас алсу хыял булып тоелган.

Съезд делегатлары арасында йолдызлар дөньясында булып кайткан космонавтлар да бар. Ленин күңел күзе белән аларны да күргән, аларга чын канатлар бирергә кодрәте җитә торган социалистик илнең нигезен төзергә керешкән һәм аның төзеләчәгенә чын күңелдән ышанган. Менә бит Ленин хыялы нинди ул!

Космонавтларның галәмгә очып китәр алдыннан Кызыл Мәйданга Ленин янына килү гадәтләре бар. Зур эшләргә керешү алдыннан совет кешеләре Ленин белән киңәшәләр, аннан рухи ныклык алалар. Бу совет кешеләре өчен бик хас нәрсә. Җирдә башкарыла торган житди эшләрдә дә Ленин — безнең беренче юл күрсәтүчебез. Менә безне, иң гади кешеләрне — эшчеләрне, колхозчыларны, интеллигенция вәкилләрен СССР Верховный Советы депутаты итеп сайладылар һәм зур дәүләт эшләрен башкарырга Мәскәүгә җибәрделәр. Билгеле, дәүләт парламенты эшендә безнең тәҗрибәбез бик аз, җаваплылык бик зур. Безгә берәү дә Ленинга барыгыз дип әйтми, без үзебез беренче сессиягә килгәч үк, күңелләребезне Ленин рухы белән яраштырырга ашыгабыз. Билгеле, тыштан караганда бу бик гади итеп эшләнә, берәү дә зур сүзләр сөйләми, Кремльдә, Ленин кабинетында һәм квартирасында бу шапрыну юк та юк, барысы һәркемнең күңелендә. Без халыкның иң беренче депутаты — Владимир Ильич Ленин белән киңәшәбез, халык хезмәтчесе дигән зур исемнең мәгънәсен тулырак аңларга тырышабыз. Ленин кабинетын караганда да, Ленин квартирасында булганда да халык хезмәтчесе булу өчен барыннан да элек тыйнаклык кирәк дигән нәтиҗә ясала, экскурсовод кына түгел, мондагы һәр экспонат шул турыда сөйли һәм, әйтергә кирәк, бик тирән итеп сөйли.

Халык хезмәтчесе булу — җиңел түгел икән. Купшы сүзләрең дә, шапрынуларың да шомарган бер тиен тормый. Депутатка төрле мәсьәләләр буенча бик күп кеше килә, һәрберсенең йомышы үзенчә үтә әһәмиятле, кайгысы үтә зур. Шатлыгын сөйләр өчен кешеләр гадәттә депутат янына килми диярлек, менә кайгысын, хәсрәтен ачып сала, кайчагында нәфрәтләнә, әрни, килешә алмый. Барысын тыңларга, чарасына керергә, я киңәш бирергә, я турыдан-туры булышырга кирәк. Ләкин үзеңнең фикереңне әйткәнче кат-кат уйла, үлчә, чөнки синең сүзеңне сайлаучы совет хөкүмәтенең сүзе дип кабул итә. Ул гадел хөкемне табарга тиеш. Депутат йомшак күңелле кеше булып кылана алмый, үзе актан ак булып, кемнәрнедер бәгырьсезлектә гаепләү юлына да баса алмый. Вәгъдә итеп тә вәгъдәсен үтәмәү — бусы инде иң начары.

Депутат янына суд тарафыннан хөкем ителгән кешеләрнең якыннары да килә. Фаҗига һәм күз яше. Төрмәләрдән ярдәм итүне сорап язылган хатларда да — күз яше, үкенү, тәүбә итү. Монда инде «кызгану» хисе белән эш итәргә һич тә ярамый. Гадәттә төрмәдән язучылар үз гаепләрен бик кечерәйтеп, үзләрен хаксызга җәфа чигүчеләр итеп күрсәтергә тырышалар. Ихтимал, алар депутат үзләренең һәр сүзенә ышанып дип уйлыйлардыр. Юк, депутат аерым бер кешенең интересын түгел, халык интересын күзәтә.

Ленин белән киңәшү — аның булган урыннарында гына мөмкин дигән сүз түгел. Ленин әсәрләрен өйрәнү, уку — бу шулай ук юлбашчы белән киңәшү. Әгәр бөтен Советлар Союзын һәм анда яшәүче ике йөз миллионнан артык кешене күз алдына китерсәң, Ленин әсәрләре

аркылы Ленин белән киңәшү төп юл булып кала, чөнки бар кешенең дә Мәскәүгә, Ленинградка яки башка урыннарга барырга мөмкинлеге юк. Китапны исә ул теләсә кайда таба ала. Хәзер безнең илдә китапсыз бер өй дә юк.

Кремльнең Зур сараенда, сәхнәдә, Ленинның гаҗәеп скульптурасы бар. Ленинның кыяфәтендә тулы хәрәкәт, аңа озаграк карап торсаң, ул синең каршыңа килә кебек, тавышы да менә-менә яңгырар шикелле. Верховный Совет сессиясендә Союз Советы утырышларында Татарстан депутатларының урыны сигезенче рәттә була торган иде. Моннан президиум да, сәхнәдәге Ленин скульптурасы да бик яхшы күренә. Мин Лениннан күземне алмыйча утырам. Ул мәңге шунда булган кебек. Ләкин уйлагыз: бер вакыт бу скульптура булмаган, бары тик тере юлбашчы яшәгән. 1919 елның Беренче Мае. Ленин Кызыл Мәйданда чыгыш ясый. Мәскәүлеләргә бик таныш булган Лобный урын. Ленинның кыска пиджагын җил уйната, вакыт-вакыт ул кулын югары күтәрә. Якты күк фонында бу бик ачык күренә. Ленин гүя билгеләнгән максатына ашкынып оча...

Ленинның хәрәкәтләрен шунда басып торган скульптор С. Д. Меркуров та күзәтә, ә соңыннан әлеге шул Кремльнең Зур сараенда сәхнәдә торган атаклы скульптурасын ясый.

Иҗат кешесенә шунысы кызык: чыгышы вакытында юлбашчы бер генә төрле хәрәкәт ясамаган, ул җанлы кеше, хәрәкәтләре мең төрле. Ул үзе хәрәкәтләре турында уйламый да, әмма хәрәкәтләрендә мәгънә бар, алар аның речының эчке динамикасына буйсынып туалар. Шуннан бер дәкыйканы, Ленин өчен иң-иң характерлы булган хәрәкәтне тотып алырга кирәк. Илһамланган художник шуны тотып алган һәм ташка сеңдергән.

Таш һәм хәрәкәт! Бер караганда, болар ут белән су шикелле бит, бер-берсенә һич ярашмыйлар. Таш — оеган тынычлык, хәрәкәт — аның нәкъ киресе, үзгәреш. Художник таш табигатенең нәкъ киресен эшләтә: таш хәрәкәткә әверелә. Ләкин Ленин скульптурасына карап торганда, без моны уйламыйбыз да, күрмибез дә, бары тик юлбашчының җанлы образы гына кала һәм без аны гомер буе шулай күңелдә йөртәбез. Менә ул художникның илһамланган эше! Моның өчен, Маяковский әйтмешли, меңнәрчә тонна руда актарырга кирәк була икән, булсын, чөнки хәзер йөз миллионнарның күңеленә бөек Ленин шул әзер көенчә керә дә утыра.

Монда мин художникның бинихая хезмәте турында аерым сөйләмим. Талант һәм хезмәт бер медальның ике ягы гына. Талантлы әйберне тудырыр өчен никадәр хезмәт куярга кирәклеге бигрәк тә иҗат кешеләренең үзләренә бик яхшы билгеле.

Без, иҗат кешеләре, Ленин образын гомер буе җентекләп өйрәнәбез. Ләкин барыбыз да, Меркуров кебек, Ленин темасы өстендә эшләмибез. Ленин темасы бик киң, кайчак Ленин темасына эшләгәндә Ленин үзе анда күренмәве дә мөмкин. Әмма ләкин рухы булырга тиеш. Гомумән, совет кешеләренең образын тудырганда, Ленин рухы булмыйча мөмкин түгел. Ә аны сәнгать әсәрендә чагылдырыр өчен Ленинны өйрәнергә кирәк.

Һәр образның үзенә генә хас сыйфатлары, үзенчәлекләре, сүзләре, хәрәкәтләре бар, ул кабатланмый. Шул кабатланмас образда фәкать үзенчә генә Ленин рухы чагыла. Моны тотып алуы һәм әсәрдә күрсәтүе җиңел түгел, моның өчен, башка күп яклардан тыш, Ленинны да өйрәнергә кирәк, чөнки Ленин дигәндә без партияне дә аңлыйбыз, партия дигәндә үлемсез Ленин күз алдына килеп баса. Менә безнең тормышыбыз бердәмлегенә хас шушы диалектика — безнең иҗатыбызның юл күрсәтүче таң йолдызы!

Быел Владимир Ильич Ленинның безнең арадан киткәнлегенә кырык биш ел тулды. Күрсенсәң дә, күрсенмәсәң дә тарих туктамый, узган елларны саный бирә. Ләкин кешелек бер вакытта да Ленинны «үлгәннәр» исәбенә кертмәде. Владимир Ильич Ленин яшәгән, яши, киләчәктә дә яшәр, ул — үлемсез!

Башкалада еш булсам да Горкига барырга ничектер туры килмәде. Югыйсә, ерак та түгел, нибары 35 километр, автомобиль яки автобуска утырсаң, кырык-илле минутта барып та житәсең. Октябрь революциясенә кадәр бу һәйбәт утарның хужасы Мәскәү шәһәре начальнигы Рейнбот булган. 1918 елның 25 сентябреннән алып монда Владимир Ильич ял көннәрен үткәрә башлаган, аннары ял вакытларында да, авыргач та Горкида яшәгән. Бу йорт аның соңгы йорты булган: 1924 елның 21 январенда 18 сәгать 50 минутта ул шунда күзләрен мәңгегә йомган. Ә 1949 елның январенда КПСС һәм Совет хөкүмәтенең карары нигезендә Горкида Владимир Ильич Ленинның мемориаль музей-йорты ачылган. Горкида Ленин белән бергә Надежда Константиновна Крупская, Мария Ильинична, Анна Ильинична Ульянова-Елизарова һәм Дмитрий Ильич Ульянов яшәгәннәр...

Бу кадәресен һәр белешмәдән табып була, анда хәтта Горкида Ленинга торган таш йортның рәсеме дә бар. Ләкин болар әле синең күңелеңне кытыклый гына, рухыңа бер нәрсә дә бирми. Шуңа күрә мин Горкига бүген булмаса иртәгә барырмын дип, Ленин кергән бүлмәләргә керермен, ул йөргән бакчаларда йөрермен дип юанып яшәп килдем.

Ниһаять, алтмышынчы елларда бер-ике җәй рәттән Домодедово станциясеннән ерак түгел «Подмосковное» санаториенда ял итәргә туры килде. Горки күршедә генә диделәр. Озакламый экскурсия дә оештырдылар. Бик матур июль көннәренең берсендә без, ял итүчеләр, автобусларга утырып, сагындырган Горкига карап китеп тә бардык.

Ял итүчеләр күмәкләшеп автобуска утыргач, гадәттәгечә, күңелле сөйләшәләр, җырлашалар. Һәр төркемдә җырга, сүзгә оста кешеләр табыла. Безнең автобуста да шулай булды. Яңгыравыклы җыр әллә кайларга очып тирбәлде. Аннары киң кырларга чыккач, җыр ничектер үзеннән-үзе тынды. Асфальт юлда автобус әллә ни селкетми, тик кояш кына кыздыра. Әмма елга буйларына төшкәндә, тагын рәхәт салкынча булып китә. Шаулап, гөрләп торган станцияләр дә, поезд гөрелтеләре дә кайдадыр читтә, артта калды. Юл авылларга керми, каршыга бары тик автобуслар һәм автомобильләр генә очрый. Безнең автобустагы кешеләр уйга калды, күз карашлары житдиләнде, күрәсең, барсы да Ленин турында уйлый башлады. Билгеле, һәркемнең үз үзенчә. Ихтимал, берәүләргә тере Ленинны күрү дә насыйп булгандыр,— монда аппак чәчле олы, дәрәҗәле кешеләр дә, дәүләт оешмаларында зур-зур житәкче урыннарны биләп торган кешеләр дә шактый. Аларга инде уйларлык нәрсәләр, һәрхәлдә, бар, искә төшерүләре дә житәрлектер.

Менә Горкига да килеп життек. Бу урыннарны «тауачыклар» дип әйтергә урын бар икән. Монда кечкенә таулар шактый. Тирә-якта рәтрәт тезелгән карт агачлар. Ләкин бу табигый урман түгел, моны кеше утырткан, бу — парк. Менә шул агачларга карап моннан күп мәртәбәләр Ильич узган. Гомеренең соңгы көннәрендә дә, тәрәзәдән булса да, аның карашы аларга озак-озак туктала гандыр. Ул көннәрдә, ихтимал, кояш булгандыр, ихтимал, буран котыргандыр. Ильич үзенең көннәре санаулы икәнен сизгәндер. Нәрсә турында уйлаган ул? Партия турында, ил турында, әлбәттә. Яшь Совет иле канлы сугышларда җиңеп чыкса да, юлга саласы эшләр күпме әле! Алда давыллар да булыр,

исәннәр шул кыенлыклардан чыгу юлларын дөрес табарлармы, мең төрле мәшәкатьләр арасында аптырап калмасলармы? Ул үзе төзегән Коммунистлар партиясенә чиксез ышанган, ләкин партиядә, дәүләттә җитәкче урыннарга утыргач, аерым кешеләрнең акылы сүрелмәсме?

Ленин үзенең васыятьләрен кат-кат уйлаган. Ләкин күңелдәген барысын да әйтеп калдырырга мөмкинме?

Без зур музейны карап йөрибез. Барыннан да элек монда китапларның күплеге гаҗәпләндерә. Ленинның үз хезмәтләре күпме тагын. Аның һәр юлы, һәр мәкаләсе партия һәм совет халкы өчен дөнья бәясе бит. Горкидан Ленин телефон буенча гына 200 гә якын директивалар, хатлар, мәкаләләр, распоряжениеләр җибәргән. Шуның өстенә Ленин Горки авылы крестьяннары алдында доклад белән чыгыш ясарга да вакыт тапкан, Горки районы авылларын электрлаштыру буенча план-схема төзегән. 1921 елның җәендә Горки авылында беренче тапкыр электр утлары кабынган.

Без Ленин файдаланган телефонны һәм телеграфны карыйбыз. Ильич шул телефоннан Мәскәү белән, Үзәк Комитет белән сөйләшкән, илнең эчке һәм тышкы мәсьәләләре турында үзенең фикерләрен әйткән.

Менә Ленин торган бүлмәләргә керәбез, менә аның язу өстәле, урындыгы. Эшләп арыгач, ул өй артындагы зур паркка чыга торган булган. Һәр агачка Ленин халык байлыгы итеп караган. Бер вакытны монда ниндидер сәбәп белән бер карт агачны кисәләр. Мондый варварлыкка Ленин шундый ачулана, гаепле кешене судка бирергә куша... Урманда бер агач. Беренче карашка бу бик кечкенә нәрсә кебек, чынлап торып, халык күзлегеннән карасаң, бу зур нәрсә. Ә Ленин бары тик шул күзлектән генә караган, халык милке аның өчен мөкатдәс булган. Хәзер инде бу исәннәргә васыять, ләкин күп вакытта без моның шулай икәнен аңлыйбызмы соң?

Без гаражга керәбез, Ленин утырып йөргән автомобильне карыйбыз. Хәзер автомобиль атлаган саен, елдан-ел аның маркалары яхшыра бара. Ул чакта автомобильләр бик аз булган, Ленин өчен дә автомобильне эшчеләр махсус ясаганнар.

Менә өй каршында бакча. Ленин монда утырып ял иткән. Янында Надежда Константиновна, я туганнары булган. Тарих шундый рәсемнәрнең берсен безнең көннәргә кадәр саклаган. Владимир Ильич белән Надежда Константиновна сөйләшеп утыралар, яннарында бер малай белән бер кызчык та бар.

Шул бакчада утырган чагында Владимир Ильич янына бер яшь хатын килә. Совет хөкүмәте аның абыйсын кулга алган һәм иң каты җәзага хөкем иткән. Яшь хатын Владимир Ильичтан, күз яше белән, аны коткаруны үтенә.

Владимир Ильич игътибар белән хатынны тыңлый, аның кайгысын аңлый, ләкин ярдәм итә алмавын ачык әйтә. Хатынның абыйсы ак офицер, ул совет хөкүмәтенә каршы бик зур җинаять эшләгән. Ленин Совет хөкүмәтенең башлыгы булса да, суд эшенә тыгылырга хакы юклыгын әйтә. Суд аның гаебе расланган дип әйтә икән, димәк, ул гадел җәзасын да алырга тиеш. Никадәр принципиальлек һәм халык интересларына турылыклык! Бу эпизод Ленинга багышланган кайсыдыр пьесада бар. Драматург аны бик уңышлы тотып алып файдаланган.

Ленин бүлмәсе, караватт. Шул караватта Ленин вафат булган. Без башыбызны иеп басып торабыз, хатын-кызлар әкрен генә күз яшьләрен сөртәләр. Авыр, бик авыр. Экскурсоводның сөйләгәннәре дә ничектер читтә сыман яңгырый. Кешеләр моннан кырык биш ел элек булган хәлләрне кабаттан бөтен ачыклыгы белән кичерәләр. Ләкин кайгы никадәр генә тирән булмасын, ул синең күңелеңне капламый, син Ленин эшенең мәңге тере икәнен бик яхшы беләсең. Бу эшне миллион-

нар башкара, ил көннән-көн чәчәк ата бара. Билгеле, тарих өчен кырык биш ел бик кыска вакыт булса да, бу елларда безнең илебездә башкарылган гигант эшләрне уйласаң, горурлыгың бермә-бер арта, күңелдә тормышка яңа мәхәббәт, яңа дәрт туа.

Бездән берәү дә матур сүзләр көтми, алар кирәкми дә. Без ил намына эшләргә тиешбез, ә кеше, теләсә, бик күп, бик күп нәрсә эшли ала. Владимир Ильичның данлы тормышы моңа шаһит. Ленинча яшәргә һәм эшләргә! Бу бит безнең асыл девиз, төп юл.

Санаторийда буш вакыт житәрлек, уйлан да уйлан. Каен урманы буйлап тар сукмаклардан йөрисеңме, игеннәре өлгереп килә торган басуларга чыгасыңмы, су буйлап китәсеңме — сиңа берәү дә комачауламый. Син уйларың белән яңадан Горкига кайтасың, анда күргәннәрне, ишеткәннәрне тагын бер кат искә төшерәсең, ачыклыйсың. Әгәр синең күргәннәрең, ишеткәннәрең күңеләңдә якты бер очкын булып кабынмый икән, димәк, аларның кайчан да булса бер ярап куюы бик икеле.

Әгәр теге-бу кешене күз алдында тотмыйча, бөтен җәмгыятьне тулаем алсак, совет халкы бик зур эшләр эшли. Дөнья безгә соклана, безнең илне батырлар иле дип таный. Бу — дөрес тә. Салынмаган сукмаклардан алга бару, кешелеккә юл яру — батырлар гына эшли ала торган эш, моңа аларның гына кодрәте житә. Моннан икенче нәрсә дә бик ачык булып алга килеп баса: бөек миссиябезне тулысынча башкарып чыгар өчен без һәр кешене чын мәгънәсендә батыр итәргә тиешбез. Билгеле, бу бик кыен максат, ләкин Коммунистлар партиясе — ленинизмга турылыклы партия үзенең уллары һәм кызлары алдына кайчан жиңел бурычлар куйганы бар? Беренче булып Октябрь социалистик революциясен тормышка ашыру — бу иң авыр эшләрнең дә авыры иде. Әмма давыллы көрәшләрдә чыныккан эшчеләр сыйныфы, Россия халкы, Ленинның акыллы житәкчелегендә, моны гаҗәеп оста башкарып чыкты. Гитлер урдаларын тар-мар итү шулай ук жиңел түгел иде. Бик күп илләрнең житәкчеләре агрессорга каршы торырга үзләрендә көч тапмыйча, туган илләрен фашистлар аяк астына салдылар. Ә совет халкы, Коммунистлар партиясе житәкчелегендә, бер кешедәй булып фашизмга каршы күтәрелде һәм аны жиңеп чыкты. Космоска беренче булып юл ачу шулай ук чиксез тәвәккәллек сорый иде, совет галимнәре моны да башкарып чыкты: беренче булып галәмгә совет гражданины, коммунист Юрий Гагарин күтәрелде. Дөнья таң калды һәм коммунистларның канатлары бик нык икәненә ышанды.

Хәзер һәркемгә дә билгеле: Ленин идеяләре миллионнарның күңелен биләп алган, алар шул нурлы идеяләр өчен көчләрен аямыйча көрәшәләр. Партия халыкка рухландыру көче белән бергә чын белем дә бирә. Чөнки белемсез бер нәрсә дә эшләп булмавы гомуми хакыйкать, тикмәгә генә әйтмәгәннәр: беләге юан берне егар, белеме бар меңне егар.

Искитмәле эшләрне совет халкы күп башкарды, ләкин эшләнәсе эшләр дә аз түгел әле. Тормыш бит үткәнне генә кабатлап бармый, ул һаман өскә, югарыга күтәрелә, аның юлы — спираль, кичә икенче, өченче пландагы эшләр, бүген беренче планга чыга, ә иртәгә яңалары туа. Моны иллюстрацияләргә кирәкме? Рәхим итегез, күз алдыбызда Россия уртасында яшәүче күп халыкларның берсе — татар халкы. Аның революциягә хәтле ачы язмышы һәркемгә дә билгеле. Ул әкренләп үлемгә хөкем ителгән иде. Әгәр Октябрь революциясе үзенең савыктыргыч, терелткеч көче белән вакытында килеп житмәсә, ул үзенең ачы язмышыннан узып китә алмас иде. Хуҗалыгы аяныч, культурасы күптән яшәп килсә дә, идән астындагы гөл сабагы кебек, мескен, ә ислам дине патша строе белән бергә аның муенына билчән кебек уралган, бөтен яшәү көчен суыра иде. Октябрь революциясе халыкны буып

торган барлык кара көчләрне тар-мар итеп ташлады, аңа чәчәк атар өчен киләчәккә юллар ачты, ул бердәм совет халыклары семьясына керде. Татар халкы үз арасыннан гомуми эш өчен көрәшүче батыр интернационалистлар армиясе бирде һәм шуның белән башка халыклар арасында тиешле дан казанды. Бу хезмәт фронтында да, сугыш фронтларында да шулай булды. Кайчандыр безнең республикабыз аграр республика иде, хәзер ул иң алдынгы промышленность республикасы да.

Чит илләрдә Татарстанны бик аз беләләр, дип әйтәләр. Күзләренә ак төшкән бәндәләргә ни әйтәсең. Икенче яктан, монда, бәлки, үзебез дә «гаепледер», чөнки безнең табигый тыйнаклык мактанырга бер төрле дә юл куймый. Аннары культура работникларыбыз да әкренрәк кыймылдый шикелле. Республикабыз турында мактанмый да сөйләргә урын бар бит. Ленин милли политикасының чәчәк атуы турындагы мәсьәлә — хәзер иң актуаль мәсьәлә. Бөтен дөньяда халыклар милли азатлыкка омтылалар, Ленин илендәге үрнәкләргә алар аеруча игътибарлы, чөнки монда бернинди дә ялган, күз буяу юк.

Бер ай ял вакыты — әллә ни күп вакыт түгел. Ләкин шунда да мин үзебезнең Казанны бик сагынып кайттым. Ленин музеенда алган тәэсөратларны үзебездәге җирле материаллар белән ныгытасым килде. Тагын Казан урамнарына чыгып киттем. Кояшлы көн, бик эссе дә түгел. Һич арттырып әйтмим, совет илларында икенче — яңа Казан төзелде. Юлың кайда юнәлә: Ленин районынамы, Киров районынамы, Совет районынамы, Бауман яки Идел буе районнарынамы — һәр җирдә яңа гүзәл төзелешләр балкып тора. Яңа спорт сарае, яңа стадион, яңа цирк... Кайчандыр мин шул җирләрдә торган идем. Халык бу урынны каһәрләп Мокрый дигән. Монда Горький язган кувалда ночлежкалары яшәгән. Хәзер Мокрыйның эзе дә юк, ә берничә елдан бу урыннарны гомумән танымассың, монда Казанның эш үзәге булачак.

Бер Казан гына шулай үзгәрсә, әллә ни сөйләп тә тормас идем. Алыгыз Зеленодольскины, Чистайны, Алабуганы, Чаллыны, Түбән Каманы, Әлмәтне, Лениногорскины, борынгы Бөгелмәне... Алар бит совет елларында я юктан бар булдылар, я танымаслык булып үзгәрделәр.

Ленинның турыдан-туры катнашы белән төзелгән Татарстан республикасында халыкның рухи тормышы да бик югары. Культура, сәнгать, әдәбият, музыка һәм театрларыбыз ничек үсте. Бу гасыр башында гына бу халыкның үз художниклары да, үз музыкантлары да булмаган дип кем әйтә алыр, театрларында хатын-кыз рольләрен дә ирләр башкарган дисәң, бу гайри табигый хәлгә кем ышаныр? Әдәбиятыбызның тарихы мең еллардан бирле килә, ләкин ул да XX йөз башында гына нык юлга басты, ә хәзер инде Казан каласы уртасында борынгы әдәбиятның икенче яшьлеген гәүдәләндереп Тукай һәм Муса Җәлил һәйкәлләре басып тора.

Дөрес, безне бер вакытта да тулы канәгатьләнү биләп ала алмый, югыйсә без үсүдән туктар идек. Безнең эшләнмәгән эшләребез дә бик күп әле. Без киләчәгебезгә карап тагын да шатланабыз, күңелләрдә дәрт ташый. Материаль байлыклар белән берәттән безнең яңа кешеләребез үсте һәм үсә. Алар — безнең нурлы киләчәгебезнең яңа биеклекләргә күтәрелү җирлеге. Бу җирлек бөек Лениннан килә, шуңа күрә ул нык, җиңелмәс һәм какшамас.

Теләгәннәр карасыннар: Ленин иле шулай чәчәк ата!

*1968 ел.*

А. Мөслимов

# ЛЕНИН «ИСКРА»сы һӘМ КАЗАН

1900 елның декабрендә чит илдә — Лейпциг шәһәрендә «Очкыннан ялкын кабыныр» дигән эпиграф белән «Искра» газетасының беренче саны чыга.

В. И. Ленин, Себердә сөргендә вакытында ук, коллектив агитатор һәм оештыручы булырлык политик газета чыгару планын эшли. Владимир Ильич партия һәм революциянең киләчәген бу газета белән бәйли.

Ленин планы буенча, газетаның бөтен илгә җәелгән агентлар челтәре оештырыла. Шул профессионал агентлар-революционерлар «Искра» номерларын бөтен Россиядәге шәһәрләргә, торак пунктларына тараталар.

1901 елда ук инде Казан эшчеләре бу газета белән таныш була.

Свешников заводы эшчеләренең берсе болай дип яза:

«1901 елның җәендә безнең заводта социал-демократик түгәрәк барлыкка килде. Түгәрәкнең җитәкчесе бер студент иде. Ул безнең янга революцион әдәбият алып килә иде. Аны бер эшченең квартирасында, чардакта җыелышып укый идек. «Искра» газетасы килгән көн безнең өчен чын бәйрәм була иде. Без аны теткәләнеп беткәнче, анда язылганнар танылмый башлаганчы укый торган идек...»

«Искра» газетасын эшчеләр генә укып калмаган, ул Казан губернасындагы крестьяннарга да таратылган. 1902 елда Ядринск өязе[1] полициясе 18 сентябрьдә Полянка авылында крестьяннарның «Искра» газетасының 5 санын укулары турында Казан жандарм идарәсенә белдерә.

Патша хөкүмәте газетаның революцион ролен бик тиз сизеп ала. Жандарм идарәләренә җибәргән директиваларында ул «Искра» газетасын бик нык эзәрлекләргә боера. 1902 елның сентябрендә Казан губернаторы һәм Казан жандарм идарәсе «Искра»ның 13 саны Казанда күп данәдә таралуына борчылып, Петербургка, полиция департаментына бер-бер артлы депешалар җибәрә.

«Искра»ның һәр санына дип әйтерлек баш мәкаләне В. И. Ленин яза. Аның бу мәкаләләре укучыларда марксистик караш тәрбияләүдә зур роль уйный. Аларда РСДРПның бурычлары ачык күрсәтелә. Ленин «Искра» укучыларын, көндәлек тормыш фактлары мисалында, революцион көрәш мәсьәләләрен большевистик караштан чыгып аңларга өйрәтә.

1903 елның январь аенда Казанда РСДРП оешмасы төзелә һәм ул, үзенең «Искра» газетасы белән теләктәшлеген белдереп, карар кабул итә.

Газетаның шул елның 1 мартында чыккан 35 санында болай дип языла:

«РСДРПның күпчелек комитетлары һәм группалары арасында теоретик һәм практик характердагы бердәмлекнең булмавын икърар итеп, моның Россиядә социал-демократик эшнең үсешенә зур зарар итүен күреп, шул ук вакытта бары тик «Искра» программасын — социал-демократик принципларның сафлыгына һәм заманның практик таләпләренә туры килә торган программаны — танып, ниһаять, «Искра»

[1] Ядринск өязе хәзер Чувашиягә керә.

оешмасын хәзерге барлык комитетларны һәм группаларны РСДРП байрагы астына берләштерә алырга сәләтле дип санап, Казан комитеты «Искра» программасын бернинди үзгәртүләр кертмичә кабул итәргә һәм аны — «Искра»ны үзенең җитәкче органы итеп исәпләргә дигән карар кабул итә».

Газетаның һәр санында «Безнең иҗтимагый тормышыбыздан» дигән рубрика астында кыска гына хәбәрләр чыгып тора. Аларда политик вакыйгалар, җәмгыятьтәге төрле катламнарның патша хөкүмәтенә каршы көрәше тасвирлана. 1902 елда чыккан 29 санында «Искра» болай дип хәбәр итә:

«Казан. Полиция ни өчендер гел студентларга каныга. Аның кайбер башбаштаклыклары турында түбәндәгеләрне язалар: моннан өч атна элек Акшаева дигән бер кыз — төрмәгә утыртылган студент-технологның кәләше — агуланып үлә. Аны күмәргә әзерләү студентлар һәм кайбер профессорларның киң катнашы белән башкарыла. Ләкин полиция, бу турыда белеп алып, иртән клиникадан аның гәүдәсен ала да үзе каберг илтеп күмә. Студентлар, бу турыда белеп алгач, каберлеккә барып, аның каберенә венок куярга булалар. Аларны каберлек юлында полиция каршы ала. Пристав, венок куярга мөмкинлек бирмәячәген белдереп, аны үзенә тапшыруны таләп итә. Студентлар кабер өстенә кую өчен әзерләнгән венокның чиновникка багышланмавын әйтәләр. Шул вакыт сарайлар артыннан һәм каберлек каравылчысы алачыгыннан городовойлар йөгереп чыга һәм, студентларны камап алып, аларны частька алып китәләр.

5 ноябрьда университетта акт үткәрелә. Полицмейстер рестораннарны һәм сыраханәләрне ябарга боерык бирә. Кичен студентлар һәм полиция арасында бәрелеш була, университет, ветеринария институты студентларыннан һәм штатскийлардан 70 кеше кулга алына. Икенче көнне аларның бер өлеше чыгарыла, ә калган 20 кеше утырып кала.

9 ноябрьда, ветеринар студентлар файдасына үткәрелгән опера спектакленнән соң, полиция белән студентлар арасында каты бәрелеш була. Нагайкалар чыжлый, бик күпләрне кыйнап ташлыйлар һәм ат белән таптаталар. Бер ветеринар студентны аеруча рәхимсез рәвештә кыйныйлар. 50 кеше кулга алына, алар арасында хатыны белән поверенный Петропавловский, ике хәрби врач һ. б. була. Сигез ветеринар студент төрмәдә калдырыла, калганнары чыгарыла. Поверенный һәм хәрби врачлар штрафка тартыла — беренчесе 100 сумга, икенчеләре 50 сумга. Калганнарын нишләтерләр — билгеле түгел».

«Искра» үзенең һәр санында тегә яки бу шәһәрдә патша төрмәсендә җәзалана торган революционерларның хәлен сурәтләп яза. Шунысын да әйтергә кирәк: чит илдә басыла торган газетага хәбәрләр җибәрү гаять авыр була. Моңа да карамастан, «Искра» һәр нәрсәне үз вакытында укучыларга җиткерә. «Нижний Новгородта,— дип яза ул үзенең 21 санында,— апрель ахрында Казан ветеринария институтының элеккеге студенты, 1901 елның февралендә Казанда социал-демократик эшчәнлеге өчен кулга алынган Борис Иванович Рюриков йөрәге ярылудан үлде»...

Ә 1903 елның 15 мартында чыккан 36 санда түбәндәге юллар бар:

«Казанда 19 февральдә Свешников, Алафузов, Крестовников заводларында һәм башка урыннарда коммунистлар партиясе өндәмәләре таратылды. Өндәмәдә алпавытлар изүе һәм рус халкының хәзерге политик коллыгы параллель итеп китерелә». 1903 елның 3 маенда чыккан санда «Революцион көрәш хроникасы» рубрикасында мондый хәбәр урнаштырыла:

«Казан. 16 кеше кулга алынган».

45 санда «Крамола белән көрәш» дигән баш астында «Искра» Казан хәрби округы буенча чыгарылган приказ турында яза:

«Казан. Августның 5 көне, 1902 ел. Гаскәрләр командующие, өйрәнү командаларына кешеләр сайлаганда, түбән чиннарны бик нык сайлап алуга игътибар юнәлтергә приказ бирде. Чөнки алар арасына аңлырак һәм белемлерәк элементларның — фабрикалардан, шәһәрләрдән килеп, башлыча хезмәткә алынганчы ук бозылып беткән кешеләрнең бик җиңел эләгүе мөмкин».

«Искра» приказга шундый аңлатма бирә:

«Унтер-офицер хатыны тагын бер кабат үзен-үзе чыбыркылаган... Эшчеләр бөтенләй бозылып беткән, чөнки алар аңлырак һәм белемлерәк. Үзеннән-үзе шуңарга игътибарны юнәлтергә туры килә: өйрәнү командаларына бары тик кадан һәм аңсыз сала кешеләре генә алынырга тиеш икән. Хөкүмәт, ишертен генә булса да, үзенең аңбелем дошманы булуын таный. Ләкин инде политик аң авыл кешеләренә дә ят нәрсә түгел, һәм бу циркуляр безгә, социал-демократларга, гаскәрләр һәм крестьян-

нар арасында пропаганда һәм агитацияне көчәйтү, аны системалаштыру кирәклеген, биредә дә безнең хезмәтебезнең политик нәтиҗәсез калмаячагын күрсәтә».

«Искра» завод һәм фабрикалардан килгән хатларга зур игътибар бирә. Ленин бу хатларга аеруча әһәмият белән карый, аларның үзгәртелмичә басылуын таләп итә. Мондый хатлар «Эшчеләр хәрәкәте хроникасы» рубрикасында урнаштырылып барыла. Мәсәлән, «Искра» үзенең 35 санында Казандагы революцион тормышка кыскача күзәтү ясый.

«...Әлбәттә,— дип яза газета,— 1898 елга кадәр дә Казан эшчеләре арасында пропаганда алып барылган, ләкин ул, мөгаен, оешкан төстә булмаган, кустарь характерда гына булган: аны группалар түгел, аерым шәхесләр генә башкарган. Бары 1898 елда гына группа оешып, ул үз алдына Казан эшчеләре арасында социал-демократик идеяләрне пропагандалау бурычы куя. Бу группа заводларның берсе — Алафузов заводы һәм шәһәр типографияләре белән генә бәйләнештә булса да, составы күп санлы булуга карамастан, үзенең эшен шактый уңышлы башлап җибәрә: эшчеләр арасында сугышчан касса оештырыла, легаль һәм легаль булмаган китаплардан торган китапханә булдырыла, шул ук елның апрелендә бик үк зур булмаса да (кырыкка якын эшче катнашында) маевка үткәрелә. Анда гомумән эшчеләр хәрәкәте турында, аерым алганда, Казандагы башлангыч хәрәкәт турында речьләр сөйләнә.

1899 елның башында кулга алынулардан соң (40 кеше кулга алына), Казандагы хәрәкәт тагын кустарь форма ала. Ләкин мондый эш формасы инде хәзер эшчеләрне дә, интеллигентларны да канәгатьләндерми, һәм 1900 елның көзендә икенче мәртәбә социал-демократик группа оеша. Ул эшне элеккесеннән киңрәк җәелдереп җибәрә, Казандагы барлык заводлар һәм мастерскойлар белән бәйләнешкә керә. Аның эшчәнлеге башта бары тик пропаганда алып бару белән генә чикләнсә, 1901 елның башыннан, хәрәкәт торган саен киңрәк җәелә башлагач, пропагандадан агитациягә күчү мәсьәләсе туа. Шулай да... группа бу теләгән тормышка ашыра алмый, чөнки жандармерия Казан өчен гадәттән тыш булган кулга алулар үткәрә (100 кешене тентиләр, 70 кешене кулга алалар). Шуңа карамастан, булочниклар стачка ясый һәм аны уңышлы үткәрәләр, ә 11 мартта группа прокламация чыгара»...

1903 елның башында, әйтелеп үткәнчә, Казан РСДРП комитеты оеша. Комитет күп кенә прокламацияләр бастырып тарата. Менә аларның исемнәре: «Казан шәһәренең барлык эшчеләренә», «Студент иптәшләргә», «Казан җәмәгатьчелегенә», «Казан шәһәренең барлык эшчеләренә һәм эшче хатын-кызларына», «Укучы яшьләргә» һ. б.-лар. Бу прокламацияләрнең барысын да эшчеләр бик хуплап каршылыйлар. Прокламацияләрнең күбесе татар телендә дә бастырып таратыла. Бу турыда «Искра» газетасының 35 санында мондый хәбәр бар:

«Татарларның үз телләрендәге прокламацияне кайнар кабул итүләре комитет өчен листовкаларны ике телдә дә чыгаруның, татар эшчеләрен дөньяга чыгару белән бергә, Казан капиталистларына файдалы булган милли дошманлыкны да тамырыннан какшатыр дип өметләнергә мөмкинлек тудыра».

Әйе, Казан эшчеләре «Искра»ны яратып, кызыксынып укыйлар. Жандарм полковнигы: «Казандагы эшчеләрнең барысы да дип әйтерлек «Искра»ны укый, эшчеләр арасында тентү үткәргәндә, һәрвакыт дип әйтерлек «Искра» газеталары табыла»,— дип губернаторга юкка гына язмаган, әлбәттә.

Ленин «Искра»сының эзлекле һәм нык-лы көрәше экономистларның тар-мар ителүенә китерә һәм большевикларның пролетар партиясен төзүдә гаять зур роль уйный. «Искра» агентлары Ленин идеяләрен тарату буенча зур эшчәнлек күрсәтәләр.

Ленин «Искра»сы йогынтысында оешкан һәм аның рухында тәрбияләнгән РСДРПның Казан комитеты патша самодержавиесенең иң авыр шартларында массаларны азатлык өчен көрәшкә туплый алды.

## Ильбарис Надиров

# ХАЛЫКЛАР ШИГЪРИЯТЕНДӘ ЛЕНИН ОБРАЗЫ

Азатлык һәм бәхет китерәчәк геройны көтү, эзләү мотивы халыклар эпосында борын-борыннан килә. Ул мотив хезмәт кешесенең хыял күгендә мең еллар яшәгән, санаусыз күп мифлар, әкиятләр, дастаннарның идеаль герое төсендә гәүдәләнеп килгән. Үзендә реаль тормыш, реаль шәхес сыйфатларын тупласа да, идеаль геройның көрәш юлы әкиятләргә хас тылсымлы маҗаралар дөньясыннан чыкмый. Халык үзенә дошман булган төрле кара көчләрне, явыз затларны шул геройның эш-хәрәкәтен, көрәшен сурәтләү ярдәмендә җиңүгә ирешә. Шагыйранә хыял көче белән ялап алынган җиңүе аша халык үзенең үлемсезлеген, киләчәккә ышанычын, иҗат көчләренең чиксезлеген раслый, гел алга, гел яктыга омтылып яшәвен күрсәтә. Шуңа күрә чал тарих түрендә иҗат ителгән идеаль эпик геройның зирәк акылы, тиңсез батырлыгы һәм матурлыгы безне бүген дә сокландыра. Ләкин идеаль герой алып килгән азатлык һәм бәхет эпоста никадәр тантаналы төс алса да, чын бәхет хезмәт халкының реаль тормышыннан ерак иде. Аның өчен тарихи-экономик, социаль шартлар тумаган иде. Андый шартлар, мәгълүм булганча, тарих мәйданына ышанычлы, нык адымнары белән пролетариат сыйныфы аяк баскач кына туды.

Күп милләтле Россиядә пролетариат башлаган бөек азатлык хәрәкәте Октябрь революциясенең тантаналы җиңүе белән тәмамланды. Революция халыклар иҗатында гасырлар буе якты нур булып балкый торган азатлык һәм бәхет хыялын тормышка ашырды. Халыклар яңа чынбарлык тәэсирендә үзләренең тормышка ашкан өметләре, табылган бәхетләре һәм шатлыклары турында җыр башладылар. Төрле телләрдә, төрле төбәкләрдә иҗат ителә башлаган яңа фольклор китабының иң беренче битенә алтын хәрефләр белән Ленин исеме язылды.

Ленин образы СССР халыклары поэзиясенең иң күркәм казанышларыннан берсе. Борынгы идеаль геройлардан аермалы буларак, бу образ уйдырма образ түгел, ә реаль, тарихи шәхеснең поэтик гәүдәләнеше. Ленин — гасырлар буе изелеп яшәгән хезмәт ияләренең азатлык хәрәкәтенә юнәлеш күрсәтүче, рух бирүче бөек шәхес. Менә шуңа күрә үз шигъриятләрендә халыклар аны чын азатлык, чын бәхет китергән юлбашчы һәм остаз, революционер һәм кеше итеп сурәтлиләр.

Әйтергә кирәк, СССР халыкларының Октябрьга кадәрге поэтик иҗатында да ирекле тормыш өчен көрәшкә күтәрелгән кайбер атаклы, тарихи шәхесләрнең образларын очратырга була. Заманында рус самодержавиесен тетрәткән крестьян хәрәкәтләре башында торган Степан Разин, Емельян Пугачев кебек кыюлар турында рус халкының санаусыз күп легендалары, тарихи җырлары бар. Тугандаш башкортлар Пугачевның көрәштәше һәм якыны булып танылган милли геройлары Салаваткa дан җырлаганнар. Бу күтәрелешләрдә катнашкан татар халкының поэтик иҗатында да Пугачев һәм Салават исемнәре ихтирам белән телгә алына.

Әмма идея тирәнлеге һәм сәнгать камиллеге ягыннан халык поэзиясендә гәүдәләнгән бер генә тарихи шәхес тә бөек Ленин образы белән тиңләшә алмый. «Фольклор безнең көннәрдә Владимир Ленинны борынгы заманның Прометейга тиң булган герое югарылыгына күтәрде»,— дип күрсәтте Максим Горький. Бу сүзләренең хаклыгын Советлар илендә яшәүче халыкларның фольклоры чын-чынлап раслый.

Ленин турындагы фольклор жанрлар ягыннан шактый бай. Бу фольклорда, героик рухлы әсәрләр белән беррәттән, эпик һәм лирик әсәрләр зур гына урын тота. һәр милләтнең үзенә хас фольклор традицияләренә, шигъри сурәтләү һәм тасвирлау хәзинәсенә таянып, төрле жанрларда иҗат ителгән әсәрләр өчен бер фикер, бер хис уртак. Бөек юлбашчыга олы мәхәббәт һәм эчкерсез рәхмәт хисе ул:

Кошлар кунган имәнгә
Яфракларын игәнгә;
Рәхмәт Ленин бабабызга
Рәхәт тормыш биргәнгә,

— дип җырлый татар халкы. Үзбәк һәм мари, әрмән һәм белорус халык җырларында, сөйләкләр һәм поэмаларда да Ленинга рәхмәт авазы яңгырый. Рус халкының «Тылсымлы кошлар» дигән әкияте шулай ук юлбашчыга самими рәхмәт сүзләре белән тәмамлана. Бу әкияттә Ленин карт белән карчыкның бердәнбер улларын явыз үлем тырнагыннан коткаручы, аларга тыныч, бәхетле тормыш китерүче герой итеп сурәтләнә [1].

Ленин образының бөеклеген, хезмәт кешеләренә якынлыгын күрсәтер өчен, халыклар үз шигърияләрендә аны борынгы патшаларга һәм ханнарга, шаһларга һәм әмирләргә капма-каршы куеп сурәтлиләр. Абхаз халык җырында шундый юллар бар:

Акылың белән җиңдең, бөек Ленин,
Князьларны, патша-ханнарны...
Җәбер-золымнан без күптән азат,
Назлый безне хөрлек таңнары [2].

Бу үзенчәлек чечен халкының «Язгы үлән» җырына [3], үзбәк халкының «Иптәш Ленин» дигән поэмасына [4], саам халкының «Кояш турында легенда»сына [5] да хас. Аларда бер якта мәкерле ак патша, алпавытлар һәм байлар дөньясы торса, икенче якта Ленин һәм халык сурәтләнә.

Тормыш күренешләрен һәм образларны капма-каршы куеп сурәтләү алымы — антитеза — Ленин турындагы фольклор әсәрләренең бик күбесендә очрый. «Хафизлар яңа җыр башлады» дигән әсәрдә таҗик халык шагыйрьләре — хафизлар — үзләрен патша, ханнарны мактап яшәгән сарай шагыйрьләренә каршы куялар. Хафизлар ул шагыйрьләрдән өстен. Чөнки Ленин аларга җаннары ни кушса шуны җырларга иркенлек биргән. Хафизлар шуңа күрә иң тәүге җырларын Ленинга багышлыйлар.

Ленин әйтте: яшә, хафиз,
Йөрәк кушканны җырлап.
һәм хафизлар җыр башлады,
Бөек Ленинны зурлап [6].

Әкиятчеләр, акыннар, җырчылар, шаирләр борынгыны яңага, үткәнне бүгенгегә каршы куеп совет чынбарлыгын һәм Ленин эшенең үлемсезлеген күп һәм төрле буяуларда сурәтләүгә ирешәләр. Халык иҗат иткән поэтик әсәрләрдә сүз еш кына элеккеге батраклар, аучылар, җирсез-малсыз крестьяннар, ярлы эшчеләр һәм деханнар исеменнән алып барыла. Аларның узган гомерләре никадәр караңгы булса, кайгы-хәсрәт эчендә үтсә, бүгенгеләре шул кадәр якты, рәхәт. Әрмән халык җырында әйтелгәнчә, элек ач-ялангач көн күргән Хачо совет чорында профессор булу дәрәҗә-

---

[1] Фольклор Тункинской долины. Улан-Удэ. 1966 ел. 256 бит.
[2] Антология абхазской поэзии. Мәскәү. 1958 ел. 85 бит. М. Хәсәен тәрҗемәсе.
[3] Творчество народов СССР. Мәскәү. 1938 ел. 26 бит.
[4] Песни столетий. Ташкент. 1964 ел. 409 бит.
[5] Антирелигиозные сказки народов СССР. Мәскәү. 1939 ел. 114 бит.
[6] Творчество народов СССР. Мәскәү. 1938 ел. 45 бит. З. Нури тәрҗемәсе.

сенә ирешә [1], сука-китмән белән интегеп җир эшкәртүче дехкан тракторчы булып, үз җирен, халык милкенә әйләнгән җирне эшкәртә [2].

Якты көчләр белән кара көчләр көрәше — Ленин турындагы фольклорның лейтмотивы. Бу мотив һәр халыкның да милли сәнгать традицияләренә хас үз җирлекле сурәтләре аша чагыла. Эвенк халкының «Хәзер тайгада да якты» дигән әкиятендә гомере буе кыргый тайгада яшәүче аучы Долбөнәнең Ленин белән очрашуы тасвирлана. Байлар Долбөнәгә Ленинны үтерергә кушалар. Акчага кызыккан аучы Ленинны эзәрлекләп йөрсә дә теләгенә ирешә алмый. Тайгадагы кош-кортлар, киек җан иясләре, бай табигать дөньясы Ленинны саклый. Ахырдан Ленинның тайгага яктылык алып килгән кеше булуын аңлагач, Долбөнә вөҗдан газабы кичерә һәм байларга каршы көрәшүчеләр сафына баса [3]. Удмурт халкы үзенең бер әкиятендә Ленинны бөек аучы дип атый. Ленин кара урманда канәчкеч бүреләр белән көрәшеп яшәүче удмуртларга ярдәмгә килә, ярлы аучыларга ничек итеп ул бүреләрне кырып бетерү юлын өйрәтә. Халык үзен изүчеләрдән котылгач, караңгылык баскан урман өстендә таң ата, кояш балкый [4].

Ленин белән очрашу күп кенә әсәрләрнең сюжет җебен билгели. Ойрот халкының «Алтын таң» дигән озын легендасында сүз ярлы аучы Анчы турында бара. Аның тормышы искиткеч авыр. Ачлыктан аның балалары үлә. Ялгыз калган Анчы бәхет, хакыйкать эзләп ерак сәяхәткә чыга. Алтайдагы алты илне, җиде патшалыкны үтә. Ниһаять, ул уң кулына кояш, сул кулына ай нурлары тоткан мәһабәт гәүдәле бер баһадир белән очраша. Бу — Ленин. Ул Анчыга һәм халыкка революция, яңа тормыш турында куанычлы хәбәр китерә, аларны көрәшкә рухландыра [5]. Гомер буе газап чигеп яшәүче белорус крестьяны да, Ленин белән очрашып сөйләшкәннән соң, хакыйкатьнең кайда икәнлеген аңлый һәм эшчеләргә кушылып патша строен җимерүдә катнаша. Бу хакта белорус халкының «Ленин хакыйкате» дигән әкияте сурәтле итеп сөйли [6].

Фольклор геройлары Ленин белән кайда гына очрашмыйлар! Халык иҗаты стиленә хас шартлылык традициясе нигезендә Ленин тау халыклары арасына да, Урта Азиядәге кышлак һәм аулларга да, салкын тундрага һәм ерак тайгага да барып чыга. Ул булган җирдә болытлы көн аяза, коры ком сахрасында агым су челтери, казакъ акыны әйткәнчә, «кысылган сулыш юкәя». Дошманнар Ленин йөргән юлларга нинди генә киртәләр корсалар да, алар җимерелә. Чөнки бу юл — юлбашчының алдан күрүчән акылы сызган якты хакыйкать юлы, хаклык һәм дөреслек юлы.

Ленин белән очрашу мотивы бер мие әсәрләрдә шигъри фантазия сулышы белән өртелә, икенчеләрендә чынбарлык күренешләрен җанландыра. Рус халкының «Тылсымлы кошлар» әкиятендә шундый картина бар. Әкият герое Степан бабай тылсымлы кошка — самолетка утырып Мәскәүгә килә, Кремльдә Ленин белән күрешеп аңа бүләкләрен бирә, рәхмәтен әйтә. Бу картинада, һичшиксез, совет властеның беренче елларында төрле төбәкләрдән килгән крестьян вәкилләренең Ленин белән очрашуы да, аңа халыкның олы ихтирам билгесе итеп бүләкләр тапшыру күренеше дә сурәтле чагылышын тапкан.

Владимир Ильичның вакытсыз үлеме җир шарындагы барлык намуслы кешеләр өчен иң авыр югалту булды. Ул кайгылы көннәрдә халыклар күңелен биләгән кичерешләр сүз сәнгате иҗатында да тирән эз калдыра. Сөекле юлбашчының үлүе турындагы ачы хәбәрне ишеткәч, кешеләр генә түгел, «дала да җылый» (казакъ халык җыры), «диңгез ярсып ыңгыраша» (кырым татарлары җыры). Бу хәбәрдән соң «кошлар тавышсыз калалар» (грузин халык җыры), ә «йолдызлар күзеннән яшь ага» (кыргыз халык поэмасы) [7].

Ленинның ялкынлы йөрәге тибүдән туктагач иҗат ителгән фольклор әсәрләрендә кайгылы юксыну мотивы белән тыгыз үрелеп, икенче мотив яңгырый. Бу — Ленинның үлемсезлеге мотивы. Ленин үзе үлсә дә аның бөек эше, даһи тәгълиматы яши, дәвам

[1] Шунда ук, 99 бит.
[2] Шунда ук, 95 бит.
[3] Халык иҗаты. Казан. 1940 ел. 24 бит.
[4] Удмуртские народные сказки. Ижевск. 1948 ел. 16 бит.
[5] Творчество народов СССР. Мәскәү. 1938 ел. 15 бит.
[6] Антирелигиозные сказки народов СССР. Мәскәү. 1939 ел. 112 бит.
[7] Творчество народов СССР. 76, 79, 69, 101 битләр.

нтә, аның исеме, якты образы халыклар күңелендә мәңгелек урын алган. Рус халкының Ленин белән саубуллашкан көннәрдә чыгарылган мәтәм җырларының берсендә:

Син йолдыз булып яндың сүнмичә,
Яктыртып ярлы Россия юлын.
Ышан сөекле бөек юлбашчы,
Юлыңнан барыр һәр кызың, улың [1],

— дигән юллар бар.

Ленин бабай үзе үлсә дә
Исеме халык телендә,

— ди татар халкы үзенең бер җырында. Шул ук мотив кыргыз халкының «Мәйданда кибитка күренә» дигән әсәрендә яңгырый.

Онытмас, Ленинны онытмас!
Мәңгегә якын ул кыргызга.
Җирдә ул тиң кеше далага,
Кояшка, айга һәм йолдызга [2].

Лениның үлемсезлеге — халык үлемсезлегендә, халык эшендә, хакыйкатьнең җиңүендә. Бу фикер тирән һәм самими булып күп кенә әсәрләрдә яктырып тора.

Синең юлдан, иптәш Ленин,
Без барырбыз алга.
Синең хакыйкатең балкый
Охшап якты таңга.

Колхозлар үсәр һәр җирдә,
Тормыш булыр ямьле.
Онытмыйбыз, иптәш Ленин,
Сине мәңге-мәңге [3].

Табутында гомерлек йокыга талган юлбашчыга халыклар үз итеп, якын итеп эндәшәләр: тыныч йокла, урының кызыл гөлләр уртасында булсын, син күтәргән байрак ышанычлы кулларда, син оештырган Партия безне алга алып бара, диләр һәм юлбашчының якты исталеге алдында аның күрсәтмәләрен үтәргә, дөньяны ул әйткәнчә төзергә тантаналы вәгъдә бирәләр.

Изге Ленин, йокла бер дә хафаланма,
Омтылырбыз синең юлың белән алга! [4]

Ленин образын сурәтләгәндә, халыклар мең еллар буе тупланып килгән шигъри сүз сәнгате традицияләреннән чыгып эш итәләр. Бу традицияләр гаять бай һәм искиткеч төрле. Юлбашчыга багышланган фольклорда без Урта Азия халыкларының традицион риторик бизәкләрен, Кавказ халыкларының символик сурәтләрен күрәбез. Ерак Себер халыклары Ленин образын эпосларга хас буяулар ярдәмендә тасвирлыйлар. Әгәр казакъ халкының «Ленин карлы таулардай биек», саам халкының «Кояш турында легенда» кебек әсәрләрендә романтизм стиле сизелеп торса, рус халкының «Син үлдең, Ильич, мактаулы постта», лезгиннарның «Кызыл чәчәкләр шиңмәсләр» дигән җырларында реализм стиле өстенлек итә. Милли традицион образларга таянып, грузиннар Ленин мавзолеен сакляга, кыргызлар кибиткага охшаталар. Таҗиклар өчен Ленин «Гасырлар баһадиры» булса, казакълар аны «җир атасы» дип атый, украиннар

[1] Русские народные песни. 1950 ел. 39 бит. М. Садри тәрҗемәсе.
[2] Творчество народов СССР. 101 бит. З. Нури тәрҗемәсе.
[3] Творчество народов СССР. 83 бит. З. Нури тәрҗемәсе.
[4] Творчество народов СССР. 1938 ел. 75 бит. Н. Арсланов тәрҗемәсе.

6*

лачын белән чагыштыра. Кабардин җырында ул «ак күңелле бөек кеше», ә башкорт җырында:

Илебезгә нур балкытты Ленин
Мәң акыллы батыр ир икән,

— дип бәяләнә.

Татар халкы үзенең җырларында Ленинга бабай дип мөрәҗәгать итә. Бу һич тә очраклы түгел. «Бабай» сүзенең тирән поэтик мәгънәсе бар. Безнең халык «бабай» дип күп дөнья күргән, таянырлык киңәшләр бирердәй тәҗрибәле, акыллы, олы кешеләргә, аксакалларга әйтә. Бабай дип әйтү — ихтирам, олылау, хөрмәтләү билгесе. Татар халкының Ленинны бабай дип атавында да юлбашчыга булган зур ихтирам, ышаныч, мәхәббәт чагылган.

Ленин эшенең үлемсезлеген сурәтле итеп күз алдына бастырган һәм барлык халыклар шигъриятенә уртак булган өч образга аерым тукталырга кирәк. Аларның берсе — кояш, икенчесе — таң, өченчесе — якты юл образы. Кояш һәм таң образлары халыклар поэзиясендә элек-электән таныш традицион образлар булса, якты юл — яңа образ. Әмма алар эстетик функцияләре буенча бер-берсенә тыгыз бәйләнгәннәр. Совет кешеләре Ленинга яктылык чишмәсе, тереклек чыганагы итеп карыйлар. Шуңа күрә бу образларның поэтик мәгънәләре бер-берсен үстереп, куәтләп тора.

Әрмән һәм башкорт, ойрот һәм таҗиклар поэзиясендә Ленин образы алсу таң белән тиңләнә. Дунган халкы үзенең җырында Ленинны «Яңа кояш» дип атый.

Төндә, кап-караңгы җирдә кинәт таң атты яктырып,
«Бу нинди тылсымлы таң?»,— дип әйтте халык йокыдан торып.
Җил сызгыра, яңгыр ява, ә якты җәелә бара,
Кояштан да якты Ленин! Ленинга бит төн юк аңа! [1]

Шул ук фикер грузиннарның «Ике кояш» дигән шигъри әсәренә дә хас [2]. Ленин кояшы мордва авылы өстендә нур сибеп тора [3], тундрадагы халыкларга яшәү җылысы бирә [4].

Гел янып, нур сибеп тор, кояш!
Балкып тор Ленинның кояшы!
Көннән-көн яктырак яшәсен
Мәңгелек бәхетләр дөньясы,

— ди бурят халкы[5]. Шул рәвешле, традицион кояш образы Ленин образы белән аерылгысыз үрелеп яңа мәгънә, яңа эчтәлек ала.

Якты юл образы аша халыклар Ленин сызган юлның бәхетле киләчәккә алып бара торган бердәнбер туры, дөрес юл булуын раслыйлар.

Кояш нуры якты нур,
Дөнья балкый шул нурдан;
Ленин юлы — туры юл
Аерылмабыз шул юлдан,

— диелә үзбәк халык җырларының берсендә [6]. Ленин юлына турылыклы булу мотивы татар җырларында да яңгырый: «Ленин юлы безнең юл ул, яшәтербез мәңгегә».

---

[1] Творчество народов СССР. 32 бит. Н. Арсланов тәрҗемәсе.
[2] Творчество народов СССР. 81 бит.
[3] Мордовские народные песни. 1957 ел. 202 бит.
[4] Творчество народов СССР. 114 бит.
[5] Һәркемнең күңелендә. Казан. 1967 ел. 324 бит. М. Садри тәрҗемәсе.
[6] Үзбек халк кушиклари. Ташкент. 1959 ел. 106 бит. (Тәрҗемәсе безнеке — И. Н.)

Ленин юлының көрәш һәм хезмәт юлы, җиңүләр һәм казанышлар юлы булуын сурәтләгән мисаллар күп халыклар иҗатында очрый.

Тугандаш бер семьяга берләшкән совет халыклары Ленин сызган якты юлдан барып игдә социализм нигезен кордылар һәм коммунистик җәмгыять төзиләр. Ленин турында сүз барганда һәрбер халык та аның исемен, образын илдәге бөек яңарышка, ирешелгән уңышларга бәйләп карый. Бүгенге тормыш матурлыгы хакында сөйләгәндә, халыклар Ленинны кабат-кабат юксынып, сагынып телгә алалар: «Ленин бабай булсын иде колхозлар үскән чакта» (татар халык җыры); «Күрсәң иде, Ильич, уллрыңның гөлләр белән җирне бизәвен» (таҗик халык поэмасы).

Халыклар хәтерендә Ленин образы бөек юлбашчы, даһи фикер иясе булып кына түгел, акыллы һәм гади, тыйнак һәм ягымлы кеше буларак та саклана. Бу образда халыклар безнең чорның иң күркәм уңай героен, идеаль героен күрәләр.

Ленин турындагы фольклорның аерылгысыз бер өлешен илебезне яңа җиңүләргә алып баручы Коммунистлар партиясенә тирән мәхәббәт белдергән әсәрләр тәшкил итәләр. Ленин үзе булмаса да, аның васыятьләрен тормышка ашыручы, көрәшкә рухландыручы партия бар:

Без яктыга үреләбез,
Омтылабыз һаман алга:
Ленин юлы белән безне
Партиябез алып бара [1].

Беренче карашка гади генә күренгән бу шигъри юлларда тугандаш халыклар поэзиясенә уртак булган тормыш дөреслеге, безнең чорга хас хакыйкать гәүдәләнгән.

---

[1] Рус халык җыры. «Фольклор семейских» дигән китаптан. Улан-Удэ, 1963 ел, 357 бит. М. Хөсәен тәрҗемәсе.



ТАТАРСТАННЫҢ

ЕЛЛЫГЫНА

Сәгыйт Фәйзуллин

# ЛЕНИННЫ ТӘРҖЕМӘ ИТКӘНДӘ

*Тәрҗемәче истәлеге*

1918 елның җәй башы иде.

Миңа берничә көнгә генә Казанга килеп китәргә туры килде. Ул чакта поездларның йөреше хәзергечә түгел. Кукмара, Арча якларыннан Казанга килү өчен, башта Казан турысыннан узып китеп, Красная Горка (хәзерге Юдино) станциясенә килеп төшәсең. Шунда икенче поездны көтәргә туры килә... Поездлар исә хәзерге кебек тәртипле йөрми.

Әле дә хәтеремдә, Красная Горка станциясендә шулай Казан ягына поезд көтәбез. Юлчылар кем ничек урын тапса, шулай утырган, поезд юлына якын ук урнашкан безнең төркем янында берәү кулларын бутый-бутый сөйләнә: «Сез Ленин дисез дә бит, Ленинның үз сүзе бармыни аның! Ул бит,— ди бу,— Маркс сүзләрен тартып-сузып безнең Россия шартларына җайлаган да шуларны гына кабатлый ич. Нәрсәсенә исегез китәдер: Маркс сүзе дисәң, безнең ил шартларына көчәнеп кенә яраштырыла. Россия өчен, руслар өчен әле аз-маз яраклы төсле күренәдер, ә менә башка илләр, башка халыклар өчен бер генә дә яраклы түгел»...

Хәзер, бөек юлбашчының 100 еллыгы якынлашып килгән көннәрдә, Красная Горка станциясендә Ленинга каршы тел озайтып маташкан һәм шуның өчен кызылармеец һәм эшчеләр тарафыннан тиешле отпорны алган әлеге меньшевикның да һәм башка күп кенә дошманнарның да никадәр ялган сөйләгәнлекләре бик ачык күренә.

Ленин сүзе Россия өчен, руслар өчен генә түгел, ул бөтен дөнья хезмәт ияләре, социализм төзүче барлык илләр, коммунизм юлында көрәшүче барлык халыклар өчен яңгырый, тирән мәгънәле, чын бәхет юлын күрсәткән олы хакыйкать сүзе булып яңгырый.

Ленин әсәрләре татар телендә беренче мәртәбә 1912 елда — Хөсәен Ямашев оештырган «Урал» газетасында басыла. Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң исә Совет дәүләтенең Ленин кулы белән язылган беренче тарихи декретлары бик тиз арада илебезнең барлык халыкларына барып ирешә. Тынычлыкка, җиргә сусаган халыкның күптәнге теләкләрен чагылдырган бу декретларны, тел аермаларына карамастан, барлык халыклар үзләренеке дип кабул итәләр.

Совет хөкүмәтенең социалистик тормыш төзү юлындагы яңа законнары бер-бер артлы чыга торды.

Минем хәтердә бигрәк тә нык төпләнеп калганы — 1918 елның 27 маенда В. И. Ленин һәм Я. М. Свердлов кул куйган «РСФСР урманнары турындагы төп закон». 1918 елның җәй башларында чыккан бу закон илнең бик зур байлыгы булган, ләкин элек эксплуататор сыйныфлар тарафыннан рәхимсез таланган урман хуҗалыгына яңа, гадел, социалистик тәртип кертә иде [1]. Малмыж өяз советы каршындагы Мөселман комиссариатының штаттан тыш тәрҗемәчесе буларак, миңа аны татарчага тәрҗемә итәргә туры килде.

Ул чакта әле Вятка губернасының Малмыж шәһәрендә татар типографиясе юк иде. Урман законын һәм башка өндәмәләрне гектографта (җилем басмада) бастырырга туры килде. Ләкин яңа властьның халыкны оештыру һәм агарту юлындагы төрле чара һәм карарларын бу юл белән генә массаларга җиткереп бару мөмкин булмый башлады. Тиздән, Казаннан хәрефләр китертеп, татар типографиясе ачтылар. 1919 елның башыннан Малмыжда «Ярлылар тавышы» исемле газета чыга башлады. Әле яңарак кына партия сафларына кергән яшь кадр буларак, мине газетаның редакторы иттеләр. Бөтен редакциябез бер-ике кешедән тора, шунлыктан газетада бирелгән тәрҗемә материалларның да байтак өлешен миңа эшләргә туры килә иде.

Тәрҗемәчелек, әйтергә мөмкин, минем өчен нәселдән килгән профессия булды. Революция алдыннан минем тәрбиячем булган карт җизнәм Камал Мозаффаров китаплар җыярга бик ярата, аның өендә татар, рус һәм төрек китаплары күп була иде. Үзе дә, русчадан файдаланып, «Тәмәке зарарлары» исемле бер китап бастырып, бушлай таратты. Валтер-Скотт романнары белән беренче тапкыр аның китапханәсендә төрекчә тәрҗемәләр буенча таныштым. Туганнарымнан тагын заманының алдынгы интеллигентларыннан Харис Фәйзи — тәрҗемә белән дә күп шөгыльләнгән кеше. Әтиемнең энесе драматург Мирхәйдәр Фәйзи пьесалар тәрҗемә иткән кеше, минем тәрҗемәләргә карата да киңәшләре белән ярдәм итгәли иде. Әниемнең энесе Габделхәй Динмөхәммәтов 1920—1921 елларда Малмыжда җәмәгатьчелек тәртибендә үзе оештырган «Якты юл» журналында педагогик һәм политик мәкаләләр тәрҗемә итә иде. Журналда якыннан торып үзем катнаша алмасам да, аның тәрҗемәләре белән таныша бардым.

«Ярлылар тавышы»нда тәрҗемә эшенә чамадан тыш бирелеп киткән чакларым да булды. Шулай, авыл коммуналары турында русча чыккан бер брошюра миңа бик ошап куйды. Мин ул брошюраны тәрҗемә итеп, берничә номерга бүлеп газетада чыгардым. 1919 елның февраль азаклары дип хәтердә калган, малмыжда Вятка губернасының вак милләтләр съезды булды. Губернаның милләтләр бүлеге мөдире күренекле большевик Хөсәен Мәүлюдов минем бу чамасыз кыланышымны, ягъни урын мәсьәләсе киеренке вакытта газетаны тәрҗемә белән тутырып чыгаруымны бик каты һәм бик урынлы тәнкыйть итте.

Әнә шулай башланып, илле елдан артык дәвам иткән тәрҗемәчелек эшендә миңа әдәбиятның төрле тармакларында тәрҗемәләр эшләргә туры килде. Политик һәм фәнни-популяр әдәбият өстенә, кайбер әдәби тәрҗемәләрем дә булды (А. С. Пушкинның «Пики дама»сы, В. Г. Белинскийның тәнкыйть мәкаләләре, А. М. Горькийның фашизмга каршы мәкаләләре һәм Америка памфлетлары, Н. Г. Чернышевскийның «Нәрсә эшләргә!» романы). Ләкин бу чор эчендә иң күп көч куйган хезмәтем — В. И. Ленин әсәрләренең тәрҗемәләре. Авыру һәм инвалидлык сәбәпле берничә ел бүленеп торганнан соң, хәзерге көндә дә В. И. Ленин әсәрләрен тәрҗемә итү, редакцияләү һәм аларның тәрҗемәсе буенча консультацияләр — минем төп эшем. Бөек юлбашчыбызның 100 еллыгына якынлашканда, татар телендә аның әсәрләр җыелмасының 45 томнан торган 4 нче басмасын бастыру эшен тәгәлләү кузда тотыла. Бу эштә редактор һәм консультант булып катнаша алуымны чиксез зур бәхет саныйм.

Мәгълүм булганча, Совет властеның беренче елларында В. И. Ленин әсәрләренең татарча тәрҗемәләре күп түгел иде әле. Зуррак әсәрләрдән «Империализм — капитализмның иң югары стадиясе» (Гомәр Әлми тәрҗемәсе) һәм «Дәүләт һәм рево-

[1] Бу закон тагын шул ягы белән истәлекле: иске заманнарда минем бала чак үткән Шода авылы белән күрше Куныр авылы кешеләре арасында, урманнан дөрес файдалану юлын таба алмау аркасында, канлы сугышлар булгалап торган. Картларның сөйләвенчә, хәтта үтерешләр дә булып, каторгада җәзаланган кешеләр дә булган. Совет законы бу гаделсезлекләргә чик куйды.

люция» (Сәмат Шәрәфетдинов һәм Мортый Якуб тәрҗемәсе) чыкты. Ул чакта бу тәрҗемәләр һәм аларны эшләгән иптәшләр минем өчен буй җитмәслек югарылыкта булып күренәләр иде. Һәм менә күп тә үтмәде, мин үзем дә шул тармакта эшләүче тәрҗемәчеләр сафына бастым...

Мәскәүнең журналистлар институтында укыган чагым иде. Шулай бервакыт Галә Ходаяровның Казанда басылган бер китабын укып чыктым. Политэкономиягә багышланган бу китапның байтак урыннары миңа ошамады. Тоттым да китапны тәнкыйтьләп рецензия яздым. Дөресен генә әйткәндә, политэкономияне яңа гына өйрәнә башлаган бер егетнең күсәк тәнкыйте иде бу. 1924 елның җәй башында, каникулга кайткан арада, рецензияне «Безнең юл» журналының редакторы Галимҗан Ибраһимовка бирдем. Минем тәнкыйтьнә игътибар белән укып чыкты да мыек астыннан гына көлеп:

— Каты язгансың. Болай ярамый, Фәйзи иптәш,— диде,— Ленин үрнәгенчә эш итәргә кирәк. Дошманнарны аяусыз тәнкыйтьләп белгән Ленин иптәшләрдә күренгән кимчелекләрне иптәшләрчә төзәтә белә, аларга юл күрсәтә иде. Марксны яхшырак өйрәнгәч, Галә бу кимчелекләрне үзе дә күрде һәм хәзер шуларны төзәтү өстендә эшли. Ә менә сиңа мин бик файдалы эш күрсәтим әле. Хәзер бездә Ленин әсәрләрен татарча чыгаруның зур планы төзелде. Каләмең өметле күренә, һәм мин сиңа шул юлда эшләргә киңәш бирәм.

1925 елның гыйнварында Ленинның үлгәнә бер ел тулу уңае белән үзәк газеталарда 1905 елгы революция турында Швейцария яшьләренә боек юлбашчы сөйләгән доклад басылып чыкты. СССР халыкларының үзәк нәшрияты (Центриздат) тапшыруы буенча, мин аны тәрҗемә иттем. Студентлар тулай торагында тәнлә эшләгән бу тәрҗемәм аерым брошюра булып та, төрле җыентыкларда да күп тапкырлар чыкты.

1925 елның җәендә Казанга кайтып эшли башлагач, Ленин комиссиясенең (Ленин әсәрләрен чыгару өчен Г. Ибраһимов җитәкчелегендә Исхак Рәхматуллин һәм Латыйф Гомәров катнашында төзелгән редакция комиссиясе шулай дип атала иде) тапшыруы буенча, Ленинның «Коммунизмда балаларча «суллык» авыруы» китабын тәрҗемә иттем; соңрак басмаларында бу тәрҗемәне Я. Ярмакиев белән яңадан эшләдек. Тәрҗемәне эштән соң кичләрен эшләргә туры килде. Бу эштә минем иң зур ярдәмчем — тормыш һәм эш иптәшем Сәидә Фәйзуллина булды.

Ул чакта тәрҗемәне редакцияләү эше хәзергечә түгел иде. Хәзер бездә тәрҗемәне редакцияләүче иптәшләр күп очракларда, үзләрен тәрҗемәче хәленә куялар да, «мин үзем болай тәрҗемә итәр идем», дип үзгәртә бирәләр. Комиссия тапшыруы буенча бу тәрҗемәне редакцияләгән И. Рәхматуллин безнең арада иң белемле иптәш иде. Шулай да ул редакцияләү процессында үз вариантларын күбрәк кертү бурычын куймады, төзәтүләре бик аз булды. Ленинизмны беләсең икән дигәне хәтеремдә калган.

...Шулай башланып киткән эш туктаусыз диярлек дәвам итте. Бу чор эчендә мин тәрҗемә иткән Ленин әсәрләренең исемләреген генә бирсәм дә, укучыны ялыктырырлык озын чыгар иде. Кайбер зурракларын гына телгә алам: «Бер адым алга, ике адым артка», «Материализм һәм эмпириокритицизм», «Карл Маркс», «Совет властеның чираттагы бурычлары» (Я. Ярмакиев белән бергә эшләнде), «Яшьләр союзларының бурычлары», Ленинның әдәбият турындагы мәкаләләре һәм башка бик күпләр.

Ленин әсәрләрен тәрҗемә итү — ифрат катлаулы һәм җаваплы эш. Юлбашчы әсәрләренең тирән мәгънәле эчтәлеген бөтен дереслеге белән бирү өстенә, аларны укучы аңларлык, матур итеп тә бирергә кирәк була, рус теленең бөтен байлыгын Ленин ничек оста файдаланган булса, татар теленең байлыгы да шундый ук тулылык белән файдаланылган булырга тиеш. Иң оста тәрҗемәче дә берүзе генә чишеп чыга алмаслык авыр бурыч бу. Шуның өчен бу эштә коллектив тәҗрибә бик киң файдаланыла, профессиональ тәрҗемәчеләр өстенә галимнәр һәм язучылар тартыла, рецензияләр һәм консультацияләр оештырыла. Миңа да иптәшләрнең ярдәменнән күп файдаланырга туры килде.

Революциядән соң татар телендә чыккан философик әсәрләр арасында марксизм-ленинизм классикларыннан тәрҗемәләр аеруча күренекле урын тоталар. Ф. Энгельсның «Людвиг Фейербах һәм классик немец философиясенең тәмам булуы» бездә беренче тапкыр Бөек Ватан сугышы алдыннан гына чыгып калды. Русчага Г. В. Плеханов тәрҗемә иткән бу классик әсәрне татарчага Г. Камский тәр-

жома итте[1] [Бөек Ватан сугышыннан кайта алмады]. Шулай ук Ф. Энгельсның «Анти-Дюринг» тәрҗемәсен дә күрсәтергә кирәк [тәрҗемәчесе Х. Сәмигуллин, редакторы Х. Кәримов].

Минем тәрҗемә эшемдә исә иң зур урынны алган әсәр — Ленинның атаклы «Материализм һәм эмпириокритицизм» китабы. Ярдәмчем Б. Шәрәфетдинов, рецензентлар Ф. Семенов һәм С. Хафизов, редакторлар [төрле басмаларда] И. Гази, Я. Ярмакиев, Г. Камалиев иптәшләр булды. Тәрҗемә төрле басмаларда берничә тапкыр, аерым китап булып өч тапкыр һәм В. И. Ленин әсәрләренең XIV томында [гомуми тиражы 21 000 нән артык] басылып чыкты.

Философик тәрҗемә өлкәсендә соңгы хезмәтем В. И. Ленинның «Философия дәфтәрләре» тәрҗемәсен редакцияләү булды. Ленин әсәрләренең дүртенче басмасының 38 томына кергән бу дәфтәрләрне Г. Камалиев, Х. Кәримов һәм С. Хафизов иптәшләр тәрҗемә итте. Гыйльми редакторы — К. Фасеев. Әсәрдә классик һәм яңа заман философларының иң күренекле әсәрләренә Ленин төзегән конспектлар һәм шуларга карата аның искәрмәләре бирелгән. Беренче империалистик сугышның дәһшәтле елларында, эмиграция шартларында, партия эшләренә актив җитәкчелек итү өстенә, В. И. Ленин философик әсәрләрне өйрәнүгә шулкадәр күп вакыт бирә. Хәтта Гегель шикелле идеалист философларда да ул материализм ярагылары табa белә. «Гегельнең менә шушы иң идеалистик әсәрендә иң азы идеализм, иң күбе материализм. «Каршылыклы», ләкин факт!» [В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә. 38 том. 238 бит.]

Бу конспектлар буенча хөкем иткәндә, Ленинның диалектик материализм турында зур бер хезмәт язарга җыенганлыгы күренеп тора. Инде Совет хөкүмәтенең җитәкчесе булган заманында аның эш кабинетындагы китап шкафында Гегель әсәрләренең сакланүы бу фикерне раслап тора. Кызганычка каршы, В. И. Ленин андый әсәрне язарга өлгерә алмады. Ләкин шуңа карамастан, «Философия дәфтәрләре»нең философлар өчен генә түгел, гомумән идеология мәйданында эшләүчеләр өчен бик зур әһәмияте бар.

Ленин сүзен безнең халыкка ирештерү юлындагы 50 еллык хезмәт турында кыскача гына хисап биргәндә, иң элек шуны әйтәсе килә. Ленинизм — рус культурасының гына түгел, бөтендөнья культурасының иң зур казанышы. һәм бу казанышның бөтен халыкларга уртак хәзинә булуы бөтендөнья тарихында эз калдырырлык зур вакыйга булды. Заманында Маркс «Философлар дөньяны аңлатып бирәләр, ә бурыч — дөньяны үзгәртүдә», дигән иде.

Бу үзгәртеп кору чорында безнең милли культураның да чагыштыргысыз үсүе Ленин әсәрләренең киң күләмдә тәрҗемә ителүендә күренде. Бу тәрҗемәләр безнең культураның эчтәлеген киңәйттеләр, телне яңа төшенчәләр, яңа терминнар белән баеттылар.

## БЕРНИЧӘ ПРАКТИК НӘТИҖӘ

Тәрҗемә турындагы әдәбиятта иң үзәк һәм иң бәхәсле мәсьәлә — тәрҗемәнең нинди булырга тиешлеге, аның төп принциплары мәсьәләсе. Бәхеткә каршы, бездә инде сүзгә сүз тәрҗемәне иң дөрес принцип дип санау заманы артта калды. Хәзер сүзгә сүз урынына башка төрле алымнарны алга сөрәләр. Берәүләр моны адекват тәрҗемә, икенчеләр реалистик тәрҗемә, өченчеләр функциональ тәрҗемә диләр. Сүзгә сүз тәрҗемәгә караганда алга китеш сизелсә дә, принципка төгәл формулировка бирү ягыннан боларны бик уңышлы дип булмый. «Адекват» исеме тегәллектән бигрәк беркадәр якынчалыкны аңлата. Хәрефкә хәреф мәгънәсе — нәкъ үзенә якынлык. Ләкин мәгънә төгәллегенә әле күпме ара кала — анысы билгесез. «Реалистик» яки «функциональ» терминнары да безгә кирәкле принципны тулысы белән аңлата алмыйлар. Әгәр китапча хикмәтле сүзләрне бер читтә калдырып, «практик ярашлык» дип кенә атасак, уңышлы булмасмы! Ягъни сүз ярашлыгы түгел, грамматик категорияләр ярашлыгы түгел, ә телнең барлык элементлары җыелмасының оригиналда кулланылганга ярашлы булуы.

Кайбер мисалларга тукталыйк. М. Горький әсәрләрен күп тәрҗемә иткән С. Әдһәмова шундый бер факт сөйли. Бер урында нәкәс, тупас хәрәкәтле кешегә карата оригиналда «кобыла» эпитеты кулланылган. Тәрҗемәдә ничек алырга! Әгәр сүзен тап-

---

[1] Тәрҗемәнә редакцияләгәндә немецча оригиналга мөрәҗәгать иткәләргә туры килде. Аерым урыннарда Плеханов тәрҗемәсенә Ленин керткән төзәтмәләрне дә файдаландык.

тегэл итеп «бия» дип бирсәң, безнең тел практикасында бу сүзнең ул функциясе юк. Бу очракта тәрҗемәче «бия»не «сыер»га алыштырып дөрес иткән.

Бөек Ватан сугышы елларында «захватчик» сүзен күп тәрҗемә итәргә туры килде. Төрле вариантларны йөртеп карадылар. «Басkын» да булды, «басып алучылар» да. Эзләнә торгач, тәрҗемәчеләр «илбасар» терминын таптылар һәм бу иң уңышлысы безнең тәрҗемәләрдә берегеп калды, чөнки практик ярашлык ягыннан терминның тулы мәгънәсен бирә иде ул.

Сүз җаеныда терминнар турында тагын бер-ике сүз. А. М. Горький сүзләре белән әйтсәк, тел төгәллеккә омтыла, ә төгәллек җыйнаклыкны таләп итә. Бездә бик күптән йөргән бер термин — «җәмәгать фикере». «Җәмәгать» сүзе белән ясалган тезмәләр бездә аз түгел: җәмәгать милке, җәмәгать оешмалары, җәмәгать эше һ. б. Ләкин менә безнең практикада кайберәүләр бирелә «общество» түгел, «общественность» күздә тотыла дип уйлаганнар булса кирәк, «җәмәгатьчелек фикере» дип куллана башладылар. Алар кечкенә бер нәрсәне онытТЫлар: русчада «мнение общественности» дип әйтү әдәби тел кысаларыннан читкә чыга. Ә бездә, шуның өстенә, җыйнаксызрак та. Ә русча «мнение общество» тезмәсен шул ук философия дәфтәрләренең русча басмасында табабыз (т. 38, стр. 524).

Авыл хуҗалыгын социалистик үзгәртеп кору елларында бездә «колхозлашу» термины бик киң кулланыла иде. Ә менә соңгырак елларда «коллективлашу» дип яза башладылар. Ни өчен! «Коллективизация» булган өченме! Ләкин бит русчада «колхоз» сүзенең продуктив мөмкинлекләре бездәгедән таррак, анда «колхозизация» килешсез чыга, ә бездә «колхозлашу» практик ярашлык ягыннан уңышлы булган кебек, тарихи дәреслеге дә бик зур.

Соңгы 30—35 елларда бездә Европа телләреннән алынып, русча аркылы үзләштерелгән «стик», «мон», «ар» тибындагы сыйфат кушымчалары киң кулланыла башлады. Бик күп урыннарда уңышлы булган бу кушымчаларны кайбер очракларда шик астына алырга туры килә. 1917—1918 елларда Мулланур Вахитов җитәкчелегендә эшләгән Мөселман Социалистлар Комитеты турында язучы кайбер тарихчылар Мөселман Социалистик Комитеты дип кулланалар. Бердән, тарихта әһәмиятле роль уйнаган оешманың исемен бозу булса, икенчедән, телнең рухына бик үк туры килми («коммунистик партия» димибез, ә «коммунистлар партиясе» дибез бит). «Социализм ярышы» белән дә шул ук хәл. Беренче бишьеллыклар чорында туган һәм ярышның максатын тулы аңлаткан бу термин үзенең хезмәтен яхшы үтәде һәм аны пенсиягә чыгарып «стик» белән алмаштыруның да кирәге, бәлки, булмагандыр!

Гранат энциклопедиясе өчен язган «Карл Маркс» мәкаләсендә В. И. Ленин Маркс турында: «Провозгласил «критику оружия»,— дип яза. «Критика оружия» — моны ничек дип аңларга! Коралны тәнкыйть итү дипме, әллә башкачамы! Моны ачыклау өчен Маркcның яшь чакта ук Гегельнең хокук теориясен тәнкыйтьләп язган мәкаләсен актарып чыгарга кирәк булды. Нәтиҗәдә сүзнең кораллы восстание, революция турында барганлыгы ачыкланды һәм тәрҗемәдә «корал тәнкыйте» дип бирелде (4 басмадан тәрҗемә, 21 том, 31—82 битләр).

«Философия дәфтәрләре»ндә телләрнең үсешенә карата В. И. Ленин Гегельдән бер цитата китерә: «Тел халыкларның үсмәгән, борынгы хәлендә баерак була,— цивилизация башлану һәм грамматика барлыкка килү белән тел ярлылана» (322 бит). Бу цитата турысына Ленин кырыйда сорау билгесе куйган. Ә менә телнең грамматикасын башка телләр калыбына салып «үстерү» мәсьәләсенә килгәндә, Гегель белән килешергә дә була. Телләр арасындагы уртаклык (ягъни гомуми закончар) грамматикага кагылмый. Уртак нәрсә — фикерләү законнарының (логиканың) уртаклыгы һәм шуларның телдәге чагылышының бердәйлеге. Фикернең логик эзлеклелеген чагылдыру өчен һәр телнең үзенең грамматик мөмкинлекләре була: уртак грамматика юк.

Башка телләрдән сүзләрне бер чикләүсез алу һәм шул юл белән телне «баету» түгел, ә башка телдә әйтелгән фикер һәм хисләрне үз теленң чаралары белән әйтеп бирү, шул юл белән төрле халыкларның уй-фикерләрен уртак хәзинә итү кирәклеге В. И. Ленинның рус телен кирәксезгә чит сүзләр белән чүпләүдерүгә каршы сугыш игълан итәргә вакыт түгел микән дигән сүзләрендә ачык күренә.

Грамматика категорияләрендә уртаклык була алмауга һәм тәрҗемәдә моның чагылышына карата бер мисал. «Философия дәфтәрләре»ндә Маркс һәм Энгельсның «Изге гаилә» әсәренең конспектында В. И. Ленин Шекспир әсәреннән мондый сүзләрне китерә: «честность не пуританка»,

Шекспир әсәренең русча тәрҗемәләрен актарсак, без башка вариант очратабыз: «честность не пуритании» [1]. Бу тәрҗемәне Шекспир өстендә күп эшләгән Т. Л. Щепкина-Куперник биргән. Ике вариантның аермасы нидән килә! Инглиз телендә мондый очракларда «род» формасы кулланылмый, һәм тәрҗемәче Щепкина-Куперник бу инглиз үзенчәлеген русчада да күрсәтергә тырышкан. Ләкин бит рус телендә «род» формалары киң кулланыла, һәм В. И. Ленин «честность» сүзенә яраштырып, «пуританка» формасын алып дөрес иткән. Ә татарчада ничек итәргә! Бездә бит «род» категориясе юк. Шунлыктан безнең тәрҗемәдә: «намуслылык пуританлык түгел» диелгән [14 бит].

Тагын бер мисал. «Идеалист» сүзе бездә нык үзләшкән. Ләкин философик юнәлеш кешесе мәгънәсен түгел, идеалга омтылучы кеше мәгънәсен аңлатканда бездә «идеалчы» формасы уңайлырак [«Философия дәфтәрләре»ндә 540 бит].

Һәр телнең үзенә хас әйтем һәм тезмәләрен урынлы файдалану да бик кирәк. Маркс турындагы истәлекләрдә замандашлары аның бик яраткан бер әйтемен китерәләр: Geh' deinem Weg und lass die Zeute reden. Сүзгә сүз тәрҗемәсе: үз юлыңнан бар, ә кешеләр сөйли бирсеннәр. Ләкин моны болай да бирергә мөмкин булыр иде:

> Сөйләгәннәр сөйли бирсен,
> Үз юлыңнан бара бир.

Бу сүзләргә җыр калыбы бирелү аларның мәгънәсен бозмау гына түгел, көчәйткәнгә күрә матуррак та чыга.

Буржуазия партиясе булган кадетларга ярашучы меньшевиклардан көлеп, В. И. Ленин бер урында болай ди: «И хочется, и колется, и Милюков не велит». Безнең тәрҗемәләрдә ул болай бирелде: «дәрт бар, дарман юк, Милюковтан фәрман юк». Татарча әйтемне русчадан алынган текстта файдалануның уңышлы мисалыдыр бу, бәлки.

Шекспирның «Король Лир» трагедиясендә инглиз халык җырларына охшатып эшләнгән урыннар бар. Сүзгә сүз тәрҗемә ителсә, боларның халыкчанлыгы югалыр иде. Русча тәрҗемәсен эшләгән С. Маршак боларны рус фольклорына яраштырып биргән. Нәкый Исәнбәт эшләгән татарча тәрҗемәсендә бу урыннар болай бирелгән:

> Ата булып байлар булсаң,
> Балаң-чагаң мактый икән.
> Ата булып ярлы булсаң,
> Башыңа менеп таптый икән,
> Бәхет дигән бозык хатын
> Ялангачка бакмый икән!
>
> ...Акча барда барысы да яр,
> Хезмәтеңә бар да тәйяр.
> Акчаң бетеп ярдан тайсаң,
> Ярларың да яннан таяр.

Шекспирның бер каһарманы татар халкына карата «таш йөрәкле» дигән эпитет куллана [2]. Әгәр Шекспир безнең Исәнбәтнең бу тәрҗемәсен укый алган булса, безне, бәлки, бөтенләй киресенчә: «олы җанлы, сизгер йөрәкле, матур телле» дип әйткән булыр иде.

Гете үзенең «Фауст» трагедиясен немецча укып арган чакларында аның французча тәрҗемәсен укып ял итә торган булган. Күрәсең, французча тәрҗемәсе оригиналга биргесез көчле һәм матур чыккан. Шундый, оригиналга биргесез тәрҗемәләр бездә тагын да күбәйсен иде!

---

[1] В. Шекспир. Әсәрләрнең тулы басмасы. Рус телендә. I том. 1937 ел. 628 бит.

[2] В. Шекспир. Әсәрләрнең тулы басмасы. I том. Рус телендә. 1937 ел. 718 бит.

Җәмит Рәхимов

# ДУСЛЫК ТАУ КҮЧЕРӘ

ОЧЕРК

«Пазик», ипподром юлына чыккан юртак сыман, тизлекне киметми генә алга омтыла. Яшь урман баскан калкулыкларга килеп менә, ул да булмый, буровойлар, скважиналар тулы үзәннәр буйлап йөгерә. Автобус әле уңга, әле сулга борылып сазлыкларны, тирән-тирән чокыр-чакырларны урап үтә, бер ягында куәтле бульдозер белән кисеп төшерелгән тау, икенче ягында болай да текә битләүләре балчык өюдән тагын да котсызланган хәтәр урыннардан уза. Нефть районнарында яшәүче шоферлар бу якларның тау-ташларны, урман-сазлыкларны кисеп үткән юлларына күнегеп беткәннәр иде.

Автобуста баручылар цех начальнигы Иван Иванович Коноваловны урап алганнар да авызына керердәй булып нидер тыңлыйлар. Аның йөзе гадәттәгечә кырыс түгел, малайларча беркатлылык белән елмайган. Вышка төзүчеләр шуннан файдаланып калмакчылар күрәсең, һәркайсы янынарак елышып, Коноваловның игътибарын ничек булса да үзенә юнәлдермәкче. Тегесе исә инде кураена кадәр чәйнәлеп беткән папиросын тәмләп кенә суыра да, ләззәтләнеп сөйли:

— Шулай бервакыт артык кыздыра башлагач, сәгатькә карасам, төш җитеп килә. Ин кызу чак инде, укыганыгыз бардыр, күләгәдә илле градуска җитә, черт побери.

Бригадада шуклыгы белән дан тоткан Иван Боталев янында утырган Тәлгать Нуретдиновның кабыргасына төртеп алды, «сиптерә» янәсе. Коноваловның үткер күзенә чалынмый калмады бу:

— Төртмә, төртмә Боталев,— диде ул, шаяручыларга карап,— үзен анда булсаң, мәзәк сөйләп тормас идең, чалбарыңны салып күләгәгә качар идең.

— Ваня, бүлдермә әле,— диде берничә тавыш.

Коновалов хикәясенең бәһасын белгәнгә, бераз гына монтажчыларны көттереп торды да, тагы сөйләп китте:

— Ашыйсы килү дә җиткән. Пальма күләгәсенә авып азрак капкалап алыйм дип, культбудкага юнәлдем. Килсәм, сумкалар ертык, ипиколбасалардан җилләр искән. Безгә ияреп бер төркем маймыл йөри иде, культбудкага шулар һөҗүм иткән каһәр!

Боталев монда да сүз кыстырмый калмады:

— Крокодиллар түгелме? — диде.

Барысы да гөр килеп көлешеп алдылар, аннан тагын сөйләвен үтенеп Коноваловны йөдәтә башладылар.

Иван Коновалов әле берничә ел элек кенә үзләре кебек гади монтажчы иде. Шулай да тырышлыгы һәм тәҗрибәсе белән күпләрдән аерылып тора иде ул. Юкка гына бригадир итеп билгеләмәделәр шул үзен. Әмма бригадир булып озак эшләргә туры килмәде аңа. Империализм белән араны өзгән илләргә ярдәмгә бару турында сүз чыккач, беренче булып аның фамилиясен атадылар. Шулай итеп, ул Һиндстанга китеп барды. Ике ел буе һинд егетләрен вышкалар монтажларга, аларны күчереп йөртергә өйрәтте. Аннан кайткач, вышкомонтаж конторасының Лениногорскидагы цехына начальник итеп билгеләнде. Болай эше буенча ул шактый кырыс булса да, шарты килгәндә «портфеле» турында онытып, кабат гади монтажчы булып кала, егетләр белән шау-гөр килеп сөйләшә-көлешә.

Гаҗәп кешеләр бу вышка төзүчеләр. Аларны вахтага барганда, я кайтканда күзәтеп торсаң, бигрәк тә ваемсызлар икән, дигән фикердә каласың. Юл буе ду кубып ни турындадыр гәпләшәләр, бәхәсләшәләр. Бер тыңласаң, гөр итеп русча сөйләшәләр, шул арада татарчага күчеп китәләр. Берсе чувашча дәшсә, икенчесе җавапны мордвача кайтара. Үзләре ничектер аңлашалар тагы. Хәер, кайсы телдә сөйләшүнең әһәмияте юк аларга. Кызык булсын да, дөнья мәшәкатьләрен онытып бер көләрлек булсын. Бүген дә вышкачыларның әнә шулай дөнья ыгы-зыгысын оныткан чаклары.

Шофер артында ук йомшак утыргычның тәрәзә буена чүмәшкән Йосыф Әхмәтов кына катнашмый сүзгә. Аның йөнтәс кашлары күз өстенә үк төшкән, болай да чандыр гәүдәсе кечерәеп калган сыман. Ул, башын бер як җилкәсенә салып, күзләрен билгесез ноктага төбәгән дә оеп калган. Әйтерсең, нигәдер аның хәтерен җибәргәннәр. Вышкачылар мондый чагында дәшмиләр аңа. Бригадирның гадәтен яхшы беләләр: балтасы суга төшкәндәй утыра икән, димәк, нидер эзли, нидер уйлый. Исәбенең очына чыкса, җае белән фикерен һәркемгә белдерер, киңәшер әле. Башын ватсын әйдә, шуңа бригадир ич ул.

Йосыф бу минутта чыннан да уй дәрьясына баткан иде. Бүген алар Социалистик Хезмәт Герое Гәрәй Баһманов бригадасына бардылар. Азнакай вышкачыларының буровой тарттырганнарын, аны монтажлаганнарын карадылар. Җитез эшли Гәрәй егетләре. Көн авышканчы бер буровойны күчереп, корып ук куйдылар. Хәер, мондый темп аның үз бригадасы кулыннан да килә. Санап китсәң, Лениногорск монтажчыларының да бер смена эчендә аякка бастырган буровойлары байтак. Әле кайчан гына, тәҗрибә уртаклашырга дип, румын вышкачылары килгәч, әнә шундый җәһәтлек күрсәттеләр. Кичке буйда бораулаучылар яңа скважинаның беренче метрларын тишә башлагач, кунаклар башларын чайкап гаҗәпләнеп тордылар.

Шулай да Гәрәйнекеләр нык алдыра. Үкчәләренә бастырмыйлар. Үткән ел 114 буровой төзеп, вышкачыларның бөтенсоюз ярышында беренче урынга чыктылар. Әхмәтов егетләренә өченче бүләк белән канәгатьләнергә туры килде. Алар исәбендә бер дистә вышка кимрәк иде шул.

Юк, Йосыф та, аның егетләре дә күршеләрнең уңышларыннан көнләшмиләр. Шулай булмаганда бер-беренә ярдәм кулы сузып, эштәге һәр яңалыкны уртаклашып яшәрләр идемени! Киресенчә, Гәрәй бригадасының һәр уңышына куанып, шатланып бетә алмыйлар. Әйтерсең, ярышта үзләре җиңүче булган да, үз бригадирлары Алтын Йолдыз таккан. Әле теге чакны, Гәрәй партиянең XXIII съездына делегат итеп сайлангач, аны Мәскәүгә озатырга Йосыфның бөтен егетләре җыелды. Баһмановның үз бригадасы Азнакайда калган иде. Гадәтенчә, гади генә киенгән, сөттәй ак күлмәгенең изүен чишеп җибәргән, кепкадан иде

Баһманов. Вышкачылар аны, ай-ваена карамастан, кибеткә алып киттеләр, берсен-берсе зәвыксызлыкта гаепли-гаепли, галстук, эшләпә сайлаштылар. Шунда ук галстук тактырып, велюр эшләпәне кыңгыр салдырып кидереп тә куйдылар. Татарстан вышка төзүчеләренең базары төшәрдәй булмасын, янәсе...

Иосыф бригадасының бик таркау чаклары бар иде. Моннан өч-дүрт еллар элегрәк иде ул. Конторада эреләндерелгән комплекслы бригадалар төзелгәч килеп чыкты андый хәл. Коллектив алдына дәүләт планының өзелү куркынычы килеп басты. Моның сәбәбен һәркем үзенчә юрады.

Көннәрнең берендә чакырылган җыелыш төрле имеш-мимешләргә урын калдырмады.

— Хикмәт бригададагы кешеләрнең кырык ата баласы булуында түгел, элеккеге кырык хуҗа бергә җыелуда,— диделәр чыгыш ясаучылар.— Аннан соң таләп тә җитеп бетми. Әхмәтов тәҗрибәле, булдыклы монтажчы, ләкин юаш. Һәр эшкә үзе йөгерә,— дип Иосыфны да тәпәләп алдылар.

Вышкачылар төп сәбәпләрнең өстенә басты. Чыннан да, коллективка элеккеге вак бригадаларның барлык җитәкчеләре җыелган иде. Һәркем үзенчә күп белә, бердәм җитәкчелеккә баш бирми, үзе белгәнчә йөрергә тырыша иде. Иосыф исә, тумыштан сабыр холыклы буларак, кешеләргә каты бәрелми, хәтер калдырудан курка.

Ләкин мондый хәл озакка бармады. Көннәрдән бер көнне, автовокзалдан автобус кузгалырга торганда, бригадир янына Леонид Кулев килде. Аның күзләре кызарган, битләре ничектер шешенеп тора иде.

— Иосыф, биш кенә минут,— диде дә вокзал каршындагы сыра лавкасына йөгерде.

Әхмәтов аның хәмергә хирес икәнен белә, Леонид белән ныклап сөйләшергә дип ниятләп тә йөрде. Әмма ничектер кыюлыгы җитми иде. Бүгенге хәл аны чыгырыннан чыгарды.

— Тукта әле, тукта,— дип кычкырды ул урам аша чыгарга өлгергән Кулевка.— Кер автобуска, утыр.

— Бер генә кружка,— дип тарткалашты тегесе.

Әхмәтов йөгерә-атлый автобуска керде, ишекне япты да шоферга:

— Кузгалдык,— диде.

Башта моңа ышанырга да, ышанмаска да белми торган Леонид, машина кузгала башлагач, йөгереп ишеккә килде, кызулый башлаган автобусның калаен төяргә тотынды.

Вакыйганы калган вышкачылар да күреп торганнар икән. Кулев керүгә, элеп алдылар үзен. Буровойга барып җиткәнче башын күтәрергә дә ирек бирмәделәр.

Шул көннән башлап бригада сизелерлек үзгәрде. Иосыф һаман да шулай юаш, аз сүзле булып калса да, әкренләп дилбегәне тарта төште. Элекке бригадирлар да җайга килделәр, сүз көрәштерми генә эшли башладылар. Кайберәүләре исә, ике тәкә башы бер казанга сыймый дип, башка цехларга күчте.

Хәзер инде ул көннәр кайчандыр күргән күңелсез төш сыман. Егетләр кушканны көтеп тормый, алны-ялны белми эшлиләр. План яки йөкләмәнең үтәлмәве турында телгә алучы да юк. Җыелыш-киңәшмәләрдә сүз гел планнан тыш ничә буровой төзү турында бара.

Әйе, осталыклары да җитәрлек, тәҗрибәләре дә бай хәзер монтажчыларның. Өлкән вышкачы Алексей Мироновны гына алып кара әнә.

Салкын суларын Иосыф әчеп үскән Шушма буйларындагы тәүге буровойлар бу якларда искиткеч хәзинә барын бөтен дөньяга хәбәр иткәч, Татарстанга илебезнең төрле почмакларыннан «кара алтын» осталары агылды. Мәкерле девонның тәҗрибәсез татар егетләренә генә бирешмәячәген йөрәге белән тойган нефтьче ветераннар, кул күнеп беткән чыгыр рычагларын, күңел куйган промыселларын ташлап, Татар-

стан нефтьчеләренә ярдәмгә ашыкты. Чал Бакудан да, ерак Сахалиннан да, күрше Башкорстаннан да, күпне күргән Украинадан да, гүзәл Жигулидан да килделәр алар.

Татарстан хәзинәсен чыгарырга күп милләтле бөтен Совет халкы кузгалды. Алар арасында дөньяга эш өчен генә тугандай йөрүче Алексей Миронов та бар иде. Ул элек Кавказ таулары арасында буровойлар корган. Вышкаларны бөтенләй сүтеп, кабат аркан белән күтәрергә дә, аударып бүрәнәләр өстеннән шудырырга да туры килгән аңарга. Сыкранмый, зарланмый гына эшләп йөргән. Идел буйларында да «кара алтын» фонтаннары атылгач, шунда җибәрүләрен сорап гариза язган.

Буровой баскычларының өч йөз җитмеш басмасын санап ничә тапкыр өскә күтәрелгән дә, ничә мәртәбә төшкән бу кеше! Аңысын берәү дә санамаган, буровой корганда теләсә нинди эшне цирк артистыдай тиз һәм оста башкаруы гына аның кулыннан инде йөзләрчә вышка узганын сөйли.

Осталыклары белән Алексей Мироновтан калышмый торган егетләрне санап китсәң, бригададагы өч дистә кешенең барын да телгә алырга туры килер иде, мөгаен. Әнә Йосыф артындагы утыргычта электромонтер Әхәт Вильданов кайта. Иптәшләренең күтәренке халәтләренә кушылып китми, сабыр гына тыңлап утыра. Төпле, фикерле шаяртулар булганда гына авыз кырые белән бераз елмаеп куя. Эштә дә шулай ул. Беркайчан да алга сикереп төшмәс, мактанмас, әмма инде кулы тигән эшне җиренә җиткерми калмас. Әхәт теләсә нинди яңалыкның рәтенә тиз төшенә, сорамый-төпченми генә үзе белгәнчә ясап куя, ләкин бракка юл куймый.

Алексей Миронов һәм Татарстан нефть чирәменә тәүге тапкыр аяк баскан осталар беренче «фонарь»ларны аякка бастырганда, Әхәт армия сафларында иде әле. Туган ягына кайткач, солдат гимнастеркасын алыштырганчы ук, нефтьче кадрлар хәзерләү мәктәбенә керде, аннан электромонтер булып эшли башлады.

Кулы эшкә ятты егетнең. Хезмәтенең баштагы елларында ук исеме вышкачы осталарның фамилияләре белән рәттә санала башлады. Шуннан бирле телдән төшми.

Берничә ел элек контора яңа типтагы «БУ-75» бораулау установкаларын үзләштерүгә керешә. Алар монтажчылар һәм бораулаучылар өчен күп уңайлы, кору һәм күчереп йөртү өчен бик җайлы булып чыктылар. Яңа вышкалар иң элек Йосыф бригадасына тапшырыла. Ул һәм тиз арада иске установкаларны кысрыклап чыгардылар. Инде аларны башка бригадаларга кертү бурычы алга басты. Шул көннәрдә Йосыфны конторага чакырып алдылар һәм Азнакайга җибәрү өчен иң уңган вышкачыларны күрсәтүен сорадылар. Бригадир Әхәт Вильданов, Әсгать Хәмидуллин һәм Альберт Дерләрнең фамилияләрен атады. Алар Гәрәй Баһманов бригадасында ике ай эшләделәр, шул вакыт эчендә күршеләрне яңа буровой кору серенә өйрәтеп кайттылар.

Узган ел исә Йосыф егетләренә тагын да катлаулырак имтихан тотарга туры килде. Алар Мәскәүдә СССР Халык Хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе территориясендә «БУ-80» тибындагы камилләштерелгән бораулау установкасы монтажладылар. Ана кадәр Әхәткә һәм аның иптәшләренә бу вышка белән нибары бер генә тапкыр очрашырга туры килгән иде. Шулай да имтихан уңышлы булды, дәүләт комиссиясе монтажчылар эшеннән кимчелек тапмады. Әйе, Әхәт Вильдановның вышкачы оста икәне бригадада гына түгел, аннан еракларда да билгеле. Аның Лениногорск хезмәт ияләре тарафыннан Татарстан Верховный Советына депутат итеп сайлануы фидакарь хезмәтен тану, бәяләү түгелмени?!

Уйланып кайта торгач, бригаданың барлык членнары да Йосыфның күз алдыннан үттеләр. Менә Станислав Димаков, агалы-энеле Дмитрий һәм Иван Орловлар, чуваш егете Дмитрий Николаев, мордва Михаил

Буслаев һәм башкалар. Кем генә алар эшеннән гаеп табар да, тәҗрибәсезлектә битәрли алыр икән?!

Бар иде заманалар, тәҗрибәле булмау, техника җитешмәүдән интеккән чаклар. Бер вышканы сүтү, аны ташып икенче урынга монтажлау ел ярым, ике елга сузыла иде. Вакытлар үтте, республикада нефть промышленносте гөрләп үсеп китте, вышкачыларның осталыгы күзгә күренеп артты. Инде буровойлар төзүне айлар белән генә исәпли башладылар. Шул турыда газетачылар куллары талганчы язарга, радио кешеләре авыз тутырып сөйләргә өлгермәделәр, буровойларны атналар, көннәр эчендә төзергә өйрәнделәр. Бинидәя биек манара «аягында» килеш басудан басуга, таудан тауга күчеп йөри башлады. Авар дип тә шикләнүче юк, ичмасам, юан корыч аркан белән нәкъ очыннан алга һәм артка таба ике тракторга тагалар да, калган бер дистәсе белән сөйрәп тә китәләр. Әмма боларына да озак шаккатып торырга туры килмәде. Сигез сәгатьләк эш кәнендә буровойны яңа урынга күчерергә һәм монтажлап куярга гадәтләнеп киттеләр.

Тик монысы да чик булмаган икән әле. Соңгы елларда контораның әле бер, әле икенче цехында вышкаларны ике-өч сәгатьтә күчереп куючы рекордчылар күренгәли башлады. Йосыф егетләренең дә сер бирәселәре килмәде, рекорд турында уйлап йөри башладылар. Берваکыт моның җае да килеп чыкты. Көтмәгәндә Лениногорскига поляк вышкачылары килеп төште. Алар вышка күчергән җиргә алып баруларын сорадылар.

Шул көнне туды да инде яңа рекорд. Бригада өч сәгать дигәндә буровойны күчереп, яңа урында монтажлады. Әлегә вышкаларны өчәр ай кора торган поляк монтажчылары өчен бу чын әкият иде! Шулай. Ярдәмгә башка өлкәләрдән белгечләр чакырган көннәр артта калды. Безнең егетләр хәзер яңа нефть районнарын ачучыларга үзләре булышалар. Лениногорск вышкачылары тәрбияләп үстергән Социалистик Хезмәт Герое Тимченко бүген ерак Себердә буровойлар кора. Төмән нефтьчеләренә вышкалар төзү серләрен өйрәтә. Әфган һәм һинд егетләренә һөнәр бирүчеләр арасында да Лениногорск вышкачылары байтак...

Азнакайдан кайткач та Йосыф бригадасына яңа задание бирделәр. Аның бригадасы Зәй-Каратай тирәсеннән Бөгелмә янына, нефтьчеләр теле белән әйткәндә, Көньяк Ромашкино мәйданыннан Лениногорск мәйданына күченә башларга тиеш. Күченергә. Әйтүе генә ансат, илле-алтмыш чакрым ара. Буровойларны тигез, такыр юлдан гына тарттырасы булса бер хәл иде әле. Тау-ташлар, чокыр-сазлыклар аша кәҗә сукмагыннан үтеп кара син шул араны. Йөге-йөк булса иде әле аның. Шулай да кашлак-чагыллар әллә ни киртә була алмас. Тигез җирдәге ун трактор урынына дистә ярым, ике дистәне җигәсең, аларның барын да күреп барлап тору өчен ярдәмгә үзеңнән алгарак ике-өч монтажчы куясың. Кашлакка түгел, Урал тавына менә буровоең. Кыйммәтрәк һәм мәшәкатьлерәк булса да анысын аның эшләп булыр. Ә менә үрмәкүч пәрәвезе сыман нефть районнарын чолгап алган югары вольтлы электр линияләрен, телефон чыбыкларын кая куясың?! Кырык бер метрлы манараны әнә шул пәрәвез арасыннан алып барып кара син! Димәк, бер буровой күчерүгә көннәр түгел, атналар китәчәк.

Гәрәйгә нәрсә, аңа җиңелрәк. Азнакай якларында җир өсте дә тигезрәк, нефть мәйданнары да чагыштырмача яңа. Вышкаларны бүген монда, иртәгә тегендә сөйрәп чабасы түгел. Алдан төзелгән маршрутлар белән иплән кенә рәткә барасы да барасы. Мондагы сыман кайтып-кайтып борауламыйлар шул анда...

Нефтьчеләр шәһәрендә таңны беренче булып вышка төзүчеләр каршылый. Алар караңгылы-яктылыда автовокзалга җыелалар һәм, Кремль курантлары яңа көн башлануны хәбәр иткәндә, буровой юлында булалар. Бүген исә Йосыф гадәттәгедән дә алдарак кузгалды. Шәһәр өстендә әле иртәнге серле тынлык хөкем сөрә, автобуслар рейска чыкмаган. Ул җәяүләп кенә автовокзал ягына атлады.

Гаҗәп, төнне йокысыз уздыруына карамастан, күңеле күтәренке, кулларында куәт арткан кебек иде аның.

Йосыфның болай очынуының, әйе, үзенә күрә сере бар. Ул төне буе вышкаларны ничек итеп Бөгелмә янына күчерү турында уйланып ятты. Күз алдына нинди генә вариантлар китереп карамады ул, ләкин һаман бер нәрсә. Үзе кузгаткан, үзе тапкан нәрсә түгел ул түгелен. Эш андамени! Хикмәт шул яңалыкның зур кыенлыктан коткарып калырлык көчендә.

Соңгы елларда буровойларны электр линияләрен өзми генә ерак араларга күчерү турында бик күпләр баш ватты. Әле 1962 елда ук трестның һәм контораның бер төркем инженерлары вышкаларны яткырып күчерү буенча кыю тәкъдим ясаганнар иде. Хәер, ул елларда моның хаҗәте шул кадәр генә булды: әле алай еракка ташынырга туры килгәне юк иде. Хаҗәте чыкканда линияләрне өзеп торырга рөхсәт итәләр иде. Вышкаларны аударып ташырга дип әзерләнгән чылбыр тәгәрмәчләр өстендәге махсус прицеп үзәк усадьбаның аулак почмагында күгәреп ята бирде.

Дүрт-биш ел үтеп, ул тәкъдим инде онытылып барган көннәр иде. Йосыф Әхмәтов чираттагы буровоен тарттырып шәһәр янындагы подстанция янына килеп тукталды. Алда — биек тимер терәкләрнең ике мөгезенә эленгән калын чыбыклар. Ул подстанциягә юнәлде.

— Синнән алда зуррак абзаңнар килде инде,— диделәр аңа, линияне өзү турында сүз башлагач,— булмый, егет.

Эш Йосыф уйлаганнан катлаулырак булып чыкты. Линия өч район территориясе аша Бөгелмәдән Кәләүлегә үтә икән. Аны бер-ике сәгатькә туктату дистәләрчә цехларны, меңләгән электромоторларны туктату ягъни бик күп акчаны суга салу дигән сүз. Җитмәсә, урак өсте — шул төбәктәге бөтен ындыр табаклары тынып калачак. Үгетләү яисә ялыну урынсыз иде монда. Тизрәк баш инженер Вәлиевкә шалтыратырга: киңәшне ул бирсә бирер.

Телефон әйләндереп мәшәкатьләнәсе булмады, баш инженер үзе килеп чыкты.

— Линиягә якын куйгансыз, якын,— диде ул машинадан чыгышка.— Чигендерергә туры килер.

Йосыф аның тел төбен шунда ук аңлап алды:

— Аударабыз алайса?

— Башка чара юк, хәзер прицепны китереп җиткерерләр,— диде Вәлиев.

Беренче чирканчыкны шунда алдылар. Татарстанда гына түгел, бөтен илебездә вышкаларны яткырып күчерү буенча беренче тәҗрибә иде бу.

Аударуын тиз аудардылар. Тарттыру да кулны тотмады. Әмма кабат утыртканда җәфаланып беттеләр, вышканы аякка бастырганчы атна-ун көн үтеп китте.

Бара-тора корыч манараларны аудару, аларны күчереп күтәрү һәм монтажлау гадәти эшкә әверелде. Дмитрий Николаев белән Валерий Батрашкин бригадада яңа ысулның осталары булып киттеләр. Кыска гына вакыт эчендә җиде установканы әнә шулай аударып күчерделәр.

Лениногорск вышкачыларының теге яки бу яңалыкны сер итеп үзләрендә генә саклый торган гадәтләре юк. Сынау тәгәлләнүгә, Дмитрий белән Валерийны Азнакайга озаттылар: яңалыкны күршеләргә дә күр-

сәтеп, өйрәтеп кайтсыннар әйдә. Ел ахырына кадәр алар, Гәрәй егетләре белән бергәләп, тагын өч вышканы яткырып күчерделәр...

Шуннан соң бу турыда тагы беравык онытып торгандай булган иделәр. Ә узган төнне исә вышкаларны аудару мәсьәләсе тагын таңга кадәр Йосыфны борчыды. «Бөтен өмет, бөтен ышаныч шунда»,— дип тәкърарлады ул үз-үзенә һәм, үзенең сикереп торганын, киенгәнен сизми дә калды. Бөтен барлыгын бер омтылыш биләп алган иде аның: «Тәгәрмәчләр, резин баллоннар», дип пышылдады иреннәре. Шул кызулык белән хатыны Фәүзияне уятмый, уллары Илгиз, Инзир, Илдус белән саубуллашмый гына өеннән чыгып китте.

Ул килеп җиткәндә, автовокзал тирәсендә тәмәке утлары ишәйгән, бригада егетләренең дә байтагы биредә иде. Йосыф ярдәмчесе Михаил Жаков белән берничә монтажчыны читкәрәк алып, звеноларның кайсын кая озату, бүген эшне нәрсәдән башлау турында киңәшергә тотынды. Сүз Зәй-Каратай урманында кичә генә бораулanып беткән скважина вышкасы турында барды. Йосыф анда демонтаж эшләрен төгәлләп, вышка астына лафетларны куярга, гадәти көченү өчен кирәкнең барын да башкарырга кушты да, вахта машиналары кузгалганны да көтмичә, конторага ашыкты. Әзерләп куйсыннар, аударган тәкъдирдә дә, башта аны урман эченнән алып чыгарга кирәк ич, дип фикер йөртте ул.

Инженер белән контора болдырында очраштылар. Исәнләшеп алуга, Йосыф ашыга-кабалана үзенең фикере турында сөйли башлады.

— Тукта, син кабаланма,— диде Вәлиев,— әйдә миңа керик әле.

Бүлмәгә кергәч, инженер ашыкмый гына өстәл тартмасын ачты, аннан ниндидер кәгазьләр чыгарып, бригадир алдына җәеп салды. Башта моны нәрсәгә юрарга белми торган Әхмәтов, сызымнарны күрүгә, сагыздай ябышты. Аның алдында — резина тәгәрмәчләргә куелган озын прицеп сурәте иде. Шатлыгыннан чак кычкырып җибәрмәде ул. Вәлиев исә, бар сөенеч бергә булсын дигәндәй, өстәп тә куйды:

— Тәгәрмәчләр дә бар. Яраксызга чыккан самолет баллоннары. Бүген кичкә булмаса да, иртәгә прицепны үзгәртеп ясау төгәлләнәчәк.

Авылда туып үскән күп егетләр сыман Йосыф та шатлык-сөенечләрен, башка хисләрен тышка чыгарудан ояла иде. Баш инженерга чын күңелдән матур-матур мактау сүзләре әйтәсе килсә дә, ул гади генә итеп рәхмәт әйтү белән чикләнде.

Әхмәтов буровой янына килеп туктаганда, демонтаж һәм хәзерлек эшләре төгәлләнгән, монтажчылар белән тракторчылар учак ягып көлгә бәрәңге күмгәннәр һәм, гадәтләре буенча, берсен-берсе үрти-үрти тамак ялгап утыралар иде.

Ул килеп исәнләшергә һәм хәлләрне сорашырга өлгермәде, аланнын әле бер, әле икенче башында куәтле моторлар гөрли башлады. Йөзәр ат көчле тракторлар, сүлпән краннар буровой тирәсенә шуыштылар, монтажчылар шулар арасына кереп таралдылар.

Бригадир кул изәүгә, трактор үкереп куйды һәм корыч манараның бер ягы ыңгыраша-ыңгыраша югары күтәрелә башлады. Күнегелгән күз тиз чамалый: Йосыф тагын кулларын күтәрде, моторның ярсуы кимеде, буровой бер якка чалышая төшеп туктап калды. Алар вышканың икенче ягын да күтәрткән арада, калган вышкачылар көч блогы астына өченче арбаны кертергә өлгерделәр, вышка шушы өч тәрәккә утырып калган иде.

Кемнең дә булса кисәтүен көтмәстән, тракторлар ике рәт булып колоннага тезелделәр. Алар бер-берен, ә соңгылары лафетларга нык корыч арканнар белән тоташтырылды. Әхмәтов иң алга чыгып басты. Инде баягы үртәшү, уен-көлкенең эзе дә калмаган, һәркемнең күзе бригадирда иде. Аның һәр хәрәкәте, житди йөзендәге һәр кыймылдау монтажчылар өчен сугышчан приказ иде бу минутта. Менә бригадир

тагын кулларын күтәрде, тракторлар бердәм гөрелдәргә тотынды, аланны тәтен, сөрем басты. Ул арада Йосыф, давылга каршы җилпенгән бөркеттәй, ике кулы белән кискен хәрәкәт ясады һәм тракторлар дәррәү ыргылып, урыннарыннан кузгалдылар.

Алан буендагы ак каеннар гаҗәпләнеп башларын чайкап алдылар, шәмдәй усакларның яфраклары калтыранып калды. Корыч баһадир акрын гына урман авызына таба шуышты да шуышты!

Йосыф исә, әйтерсең, бинһая зур оркестрның дирижеры иде. Ләкин шунысы бар: дирижер хата ясый икән, көй бозыла, музыка тыңлаучылар йөзләрен чыта. Тик бу хәл озакка бармый, күңелләрне алгысыта торган көй барыбер җайга салына, аның шуннан артык зыяны юк. Ә буровой тарттыручы ялгышса, бөтенләй башка. Ярамаган нәни генә бер хәрәкәтнең дә төзәтеп булмаслык коточкыч фаҗигагә китерүе мөмкин.

Шулай бар дөньяңны онытып, кайчак көнгә дистәләрчә чакрым җир үтәсең. Хәрәкәтне күздән яздырмас өчен юл буе арка белән барырга, гадәтләнелмәгән адымнар белән юлсыз-нисез җирләрдән атларга туры килә. Аяклар өзелеп төшәрдәй булып арый, куллары тала. Тик моны үзең сизмисең. Вышкага күз-колак булып читтәнрәк атлаучы монтажчылар гына бригадирның хәлен аңлап, күреп торалар. Андый чакларда бригадир ярдәмчесе Михаил Жаков йөгереп алга уза һәм, юл өстенә басып, Йосыфны көтеп тора. Әхмәтов килеп җитүгә, Михаил, сизелерсизелмәс кенә кагылып, аны читкә этәрә, «дирижерлыкны» үз кулына ала...

Бу юлы исә кемнең дә ярдәме кирәкмәде. Урман алдына чыгуга, бригадир куллары белән кискен хәрәкәт ясады, тракторлар, кадаклагандай, тукталып калдылар. Монтажчылар яшел чирәмгә ауды.

Йосыф, сабакларына сары суккан бәрәңге басуына карап, бер мизгелгә тукталып калды. Каршысында — өстендә рәшә уйнап торган басу, артта һәм уңда — урман, сул якта — коры чокыр. Аларны күреп хәйран калуы түгел иде бригадирның. Бу якларда аның аягы басмаган җир юк. Эш шунда: бу аланнан буровой тарттырып басу аша гына үтәргә мөмкин. Өлгереп килгән бәрәңгене издерергә туры килер микәнни? Башка чарасы юкмы икән? — дип, ул урман буйлап китеп барды.

Әхмәтов әйләнеп килгәндә, монтажчыларның тартасы тарткан, ашыйсы килгәне капкалаган — алар эшсезлектән әкият сатып утыралар иде. Әхәт Вильданов белән Алексей Миронов аңа каршы күтәрелделәр.

— Йосыф, прицеп күренми бит.

— Хәзер,— диде бригадир һәм бер читтәге автомашинага борылып әче итеп сызгырып җибәрде.

Машина аның янына килеп туктады. Ул, аны-моны дәшмәстән, машина кузовыннан көрәк-чиләкләр бушатырга тотынды.

— Прицеп төнлә килеп җитә,— диде Йосыф аптырашып торган монтажчыларга.— Хәзергә шушы уенчыклар белән мавыгып алабыз.

Вакытсыз шаярта дигәндәй, вышкачылар бригадирга аптыраулы караш ташладылар. Тик шаяру Әхмәтовның исендә дә юк иде, ул тазарак көрәкләрнең берсен алып җир өстенә атлады. Егетләр аның уен шунда гына аңлап алдылар.

— Шул гына җитмәгән иде,— диде кемдер.— Из дә чык. Зыян өчен колхозга түләнә ич.

— Әлбәттә,— диде Йосыф,— тик ул чыгым бригада җилкәсенә языла, эшнең үзкыйммәте күтәрелә.

Ул зур гына төпне каерып ташлады, сабындай шома ак бәрәңгеләргә карап өстәп куйды:

— Шундый ризыкны ничек таптатасың инде.

Вышка төзүчеләр, көрәк-чиләкләр алып, басуга сибелделәр.

Икенче көнне, вахта автобусы килеп туктаганда, буровой янында прицеп тора иде инде. Аның иләмсез чылбырлы тәгәрмәчләрен спай

баллоннар алмаштырган. Вышкачылар бер дә исләре китмәгәндәй, аны бер-ике кат урап чыктылар. Ул арада контора директоры Михаил Троицкий, инженер Вәлиев һәм башка инженер-техник работниклар да килеп җиттеләр. Урман буенда тимер чыңы, мотор тавышлары яңгырады. Менә барысының да күзе, гипнозлангандай, бригадирга төбәлде. Вышка селкенеп куйды һәм ничектер җай гына янтая башлады, аннары бөтенләй чалышайды, арып егылган кешедәй, прицеп өстенә ауды.

Аны беркеткән, ныгыткан арада, инженерлар җыелып, киңәшеп алдылар.

Инде дистәләгән тракторның кирәге юк иде. Алар урман буена килеп тезелделәр. Бары тик бер генә трактор, авыр йөкне тартып, алга таба юнәлде.

Сәгать уклары төнге икене күрсәткәндә, вышка таккан ярсулы МАЗ белән насос блогы сөйрәгән «КРАЗ» асфальтка килеп менделәр. Тик әле бу «сәфәр»нең башлануы гына иде. Машиналарын туктатып, тросбауларны, баллоннарны һәм башка нәрсәләрне тагын бер кат караптикшереп чыктылар. Бөтен юлны иңләп барган җиде метр биеклектәге олау юлда нишләмәс дисең.

Каршыга машина-мазар килсә дип, буш автомобильләрнең берсен алдан җибәрделәр. Аннан соң хәтәр улап башкалары кузгалды. Корыч баһадир, туган илебездә беренче тапкыр, тигез, такыр юлдан «сәфәр»гә чыкты!

Иң артта — монтажчылар автобусы. Ләкин утырып бару егетләрнең уенда да юк. Әнә бер якта, җитдилеген саклаган хәлдә, Йосыф Әхмәтов бара. Аның янәшәсеннән Михаил Жаков, Алексей Миронов, чуваш егете Дмитрий Николаев, мордвалы Михаил Буслаев һәм башкалар атлый. Юлның икенче ягында да монтажчылар.

Төнге йокыга талган Лениногорск артта калды. Зәй күперенә җиттеләр. Анысы да хәвеф-хәтәрсез үтелде. Машиналар иләмсез үкереп Бөгелмә тавына менә башладылар. Алар иң хәтәр урыннарны үтеп тигезлеккә чыгуга, офык яктырып китте, ал шар булып кояш күренде...

* * *

Ерак юлга чыккан беренче буровой исән-имин генә яңа урынга барып утырды. Аның эзеннән башкалар да хәвеф-хәтәрсез килеп җиттеләр. Йосыфны һәм аның дусларын шиккә салган көннәр артта калды — бер буровойны күчереп монтажлауга киткән вакыт элеккегедән әллә ни аерылмый. Йосыф Әхмәтов җитәкчелегендәге бригада еллык планны ай ярымга алдарак үтәде.

Планнан тыш буровойларны кем күпме төзер? — анысын хәзергә әйтүе кыен әле. Тик бер нәрсә ачык: дуслык җепләре белән берекән коллектив бердәм һәм дәррәү. Ә чын дуслык вышкаларны гына түгел, тауларны да күчерә бит...

**Ибраһим Нуруллин,**
филология фәннәре докторы

# ИҖАТ МЕТОДЫБЫЗ ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР

Мәсьәләләрне гыйльми нигездә хәл итү, кара исәп белән чикләнмичә, теорияне эшкә җигү тормышыбызга аның саен тирәнрәк үтеп керә. Әдәбият өлкәсендә дә без шул ук хәлне күрәбез. Гыйльми нигезгә таяну, теорияне иҗади куллану һәм әдәби күренешне аның тарихи тамырларына бәйләп аңлату, билгеле, иң элек тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият белгечләренә кирәк сыйфат. Зәвыкчылыкка яисә шәхси симпатия һәм антипатияләргә бирелеп китмичә, әдәбиятның үсеш тенденциясен дөрес билгеләргә, яңача киенергә өлгергән искене яисә өстен алыштырырга өлгерә алмаган яңаны танып алырга телисең икән, теорияне компас итәргә кирәк була.

Шул ук нәрсә, ягъни теория белән кораллану, язучыларга — прозаик, драматург һәм шагыйрьләргә дә ифрат кирәк нәрсә. Дөрес, теория илһамны иркетә, ирекле иҗатка комачаулык итә дигән караштагылар да юк түгел. Янәсе, кырыгаяк турындагы мәгълүм мәсәлдәге кебек. Имештер, кырыгаяктан сораганнар: «Син ничек йөрисең? Башта кайсы аягыңны атлыйсың? Аннары кайсысын?» Бөҗәк аякларының атлау тәртибен тикшерә башлаган да йөрүен оныткан, имеш.

Ләкин бит язучы — акыл дигән нәрсәгә ия булган табигать патшасы, ул — Кеше! Әгәр ул **талантлы** икән, теория аның илһамын куркытып качырмаган кебек, талантына да аяк чала алмый, киресенчә, бу талантка юнәлеш бирә, иҗат көчен дөрес сарыф итүгә шартлар тудыра. Башлыча яшь каләмнәрне күздә тотып язылган шушы керештән соң, мәкаләнең исемендә әйтелгән мәсьәләгә кайтам.

Безнең иҗат методыбыз, мәгълүм булганча, социалистик реализм. Әдәбият белемәнең үзәгендә тора торган бу мәсьәләгә карата йөзләгән китап һәм мәкалә дөньяга чыккан булса да, бәхәсләр тукталганы, фикер төрлелеге бетеп җиткәне юк. «Кутәрә алмас куп кутәрер» дигән мәкальне истә тотып, алдан ук әйтеп куйыйм: мин ул бәхәсләрне бер селтәнүдә хәл итәргә җыенмыйм. Максатым шактый бәләкәй: социалистик реализмга кагылышлы берничә фикеремне ишеттереп уйлану рәвешендә әйтеп узу гына.

Иң элек социалистик реализм методы дигән нәрсәнең яшәвен үк шик астына алу очраклары турында берничә сүз.

Социалистик реализмны инкарь итү, аны кем тарафыннандыр уйлап чыгарылган һәм әдәбиятны чирләшкәгә әверелдерә торган догма дип белдерү безнең идея дошманнарыбызга — капиталистик илләрнең буржуа әдәбиятчыларына гына хас булса, бу турыда сүз озайтып торуның хаҗәте дә булмас иде. Чөнки аларның максаты ачык. Кызганычка каршы, чит илләрдәге кайбер дусларыбыз һәм халык демократиясе илләрендәге аерым әдәбият белгечләре, «иксез-чиксез реализм» концепциясеннән

чыгып, яисә новаторлык хакына классик мирасны инкарь итү юлына басып, реализмга, аерым алганда, социалистик реализмга һөҗүм итәләр. «Социалистик реализм пәри сыман нәрсә: һәркем аның турында сөйли, ә үзен беркемнең дә күргәне юк» рәвешендә фикер йөртүче кешеләрне хәтта үз илебездә дә очратырга мөмкин.

Дөнья әдәбияты тарихы соңгы дүрт гасыр дәвамында бер-берсен алыштырып килгән күп кенә иҗат методларын белә: яңарыш чоры реализмы, классицизм, мәгърифәтчелек реализмы, романтизм, критик реализм һ. б. Ә бит шушы вакыт аралыгында иҗтимагый тормышта шактый хәлләр һәм үзгәрешләр булса да, асылда изүнең бер формасы икенчесе белән генә алышынды. Эксплуатациянең үзен үк тамыры белән йолкып аткан Октябрь социалистик революциясенә тиңләшерлек вакыйга булмады әле ул дәверләрдә. Нәрсә килеп чыга? Пролетариат революциясенә чаклы әдәбият һәм сәнгатьтә күп төрле иҗат методлары туып, юкка чыккан икән дә, революциядән соң кешелек дөньясында яңа эра башлануга карамастан, иҗат методы ягыннан классик реализмга нисбәтән бернинди дә үзгәреш булмаган икән. Күренә ки, болай уйлау һичнинди акылга сыймый.

Совет әдәбияты тарихының беренче унунбиш елын искә төшерик. «Социалистик реализм» дигән сүзнең әле исе дә булмаган бер вакытта, язучылар һәм тәнкыйтьчеләр (Горький исә революциягә кадәр үк) үзен пролетариат белән бәйләгән әдәбиятның сыйфат ягыннан яңа рәвеш алганын һәм алырга тиешлеген ачык күрделәр. Бу әдәбиятның үзенчәлеген билгеләү һәм методына лаеклы исем эзләү белән бәйләнешле рәвештә «неореализм», «диалектик материализм методы» кебек терминнар телгә кереп чыкты. Дөрес, эзләнү процессы шома гына бармады. Практик иҗатта һәм тәнкыйтьтә утын вату, мөгез чыгарулар да булды. Ә тулаем алганда бу яңа заманның яңа алым, яңа стиль, **яңа метод** таләп итүен аңлаудан туган эзләнү иде, һәм ул матур нәтиҗәләр бирде. Ниһаять, 1932 елда яңа методка исем табылды: социалистик реализм. Әдәбиятның үзендә барлыкка килгән сыйфат үзгәрешенә туры килә һәм шуны чагылдыра торган термин булды ул.

Инде килеп, социалистик реализмның теоретик нигезләрен эшләүгә зур көч салган сүз художникларын һәм фикер ияләрен — А. М. Горький, А. В. Луначарский, А. А. Фадеев, Иоганнес Бехер һәм башкаларны хәтерлик. Бу затларны юк пәрине бар итеп күрсәтүдә гаепләргә кемнең генә теле барыр икән?! Йөзләгән совет галимнәренең, шулай ук илебез тышындагы белгечләрнең социалистик реализм проблемасына багышланган күп еллык хезмәтләрен кая куябыз?

Күренә ки, социалистик реализм кем тарафыннандыр уйлап чыгарылган директива да, әдәбият җилкәсенә тагылган догма йөге дә түгел икән. Әдәби юнәлеш һәм иҗат методы буларак, дөньякүләм әһәмияткә ия булган факт икән ул.

Соң шулай булгач? Ни өчен бүгенгә чаклы — бәхәсләр димим — социалистик реализмның булуын үк шик астына алу очраклары бетеп җиткәне юк? Минемчә, моның ике төп сәбәбе бар. Беренчедән, социалистик реализмны аңлау һәм аңлатуда аеруча кырыгынчы елларда урнашып калган догматизмнан һаман әле арынып җиткәнебез юк. Аерым кешеләр зәвыгы тәэсирендә шактый зәгыйфь әсәрләрне темасы өчен күккә чөеп, югары бүләкләр биреп, социалистик реализмның дәрәҗәсен төшерү дә, күрәсең, эзсез калмаган. Икенчедән, социалистик реализм методы әдәбиятның **спецификасы** яктылыгында һаман әле җитәрлек өйрәнелмәгән.

Беренче сәбәпкә без әле әйләнеп кайтырбыз. Хәзер исә икенчесеннән башлыйк.

Совет әдәбият белеменең социалистик реализм теориясен үстерүдәге хезмәтен инкарь итү, әлбәттә, гаделсезлек булыр иде. Социалистик реализмга караган күп кенә проблемалар нигезле һәм ышандырырлык рәвештә хәл ителде. Сүз дә юк, социалистик реализм әдәбияты ул — җәмгыятьне социалистик үзгәртеп кору өчен көрәшүче пролетариат белән үзен органик бәйләгән әдәбият. Социалистик реализм марксизм-ленинизмга таяна, коммунистик партиялелек исә аның җаны. Социалистик реализм социалистик гуманизм һәм халыкчанлык белән сугарылган. Социалистик реализм тормышны тарихи-конкрет рәвештә һәм революцион үсештә гәүдәләндерүне күздә тота. Икенче төрле әйткәндә, бу иҗат методына аңлы рәвештә үткәрелә торган тарихилык принцибы хас. Гадел җәмгыятьне раслаучы әдәбият булганга күрә, социалистик реализм әдәбиятында уңай герой алгы планга чыга.

Әйе, болар барысы да дөрес, боларны шик астына алу мөмкин түгел. Әмма безгә мондый сорау бирүләре мөмкин (андый сорау ишетелгәли дә): әдәбиятның спецификасы, иҗат принциплары ягыннан карағанда, ягъни тормыш материалын әдәби сурәт һәм картиналарга әверелдерү актын күздә тотканда, социалистик реализм белән башка иҗат методлары, әйтик, классик реализм арасында нинди аерма бар? Социалистик реализмның югарыда саналган сыйфатларын кабатлап чыгу белән котылыр идек — сорау бирүченең болай дип әйтүе мөмкин: идея этикетка түгел, әсәрнең өстенә ябыштырылмый. Коммунистик партиялелек принцибы шулай ук укучыга декларация төсендә җиткерелми. Тарихилыкка килсәк, бусы тегеяки бу дәрәҗәдә элеккеге реализмда да бар. Шулай булгач, типлаштыру законы критик реалистлар өчен дә, совет язучылары өчен дә бер үк түгелме? Әллә әдәбият арасындагы аерма тормыш материалына һәм тематикага гына кайтып калмыймы?

Боларны да мин тел кычытканнан гына бирелә торган мәгънәсез сораулар димәс идем. Ул сорауларның тууы исә, әлеге дә баягы, методның әдәби-эстетик якларына игътибарның җитмәвенә бәйләнгән. Социалистик реализмның әнә шул аз өйрәнелгән ягы турында уйланып карыйк. Әлеге сорауларга җавап табылып җитмәсә дә, ихтимал, эзләүнең дөрес юнәлеше ачыкланыр.

Моннан 80 ел элек Ф. Энгельс Маргарита Гаркнесска язган бер хатында реализмның асылын күрсәтеп биргән иде: детальләр дөреслегеннән тыш, типик характерларны типик хәлләрдә дөрес гәүдәләндерү.

Мәгълүм булганча, Ф. Энгельс пролетариат кулында корал булырлык әдәбият тудыру өчен тырышкан. Марксизм тәгълиматын үзләштерүнең язучы өчен әһәмиятен бик яхшы аңлаган. Шулай ук ул әдәбиятта партиялелек принцибының ярлгысы булган «тенденциозлык» мәсьәләсен ачыктан-ачык куйган. Икенче төрле әйткәндә, Ф. Энгельс реализмның идеологик нигезләрен һәрвакыт күз уңында тоткан. Ә шулай да, реализмга билгеләмә биргәндә, ул **саф** әдәби категорияләр белән **генә** эш итә: художество детальләре, типик характерлар, типик хәлләр, аларның үзара мөнәсәбәте.

Күренә ки, Энгельс реализм **методы** турында сүз алып бара. Нинди реализмны күздә тоткан соң ул? Билгеләмәдә сүз гомумән реализм турында барса да, башлыча критик реализм күздә тотыла. Реализм үрнәге рәвешендә Энгельсның Бальзак иҗатын мисалга алуы әнә шул турыда сөйли. Әмма шул ук вакытта Энгельс формуласы социалистик реализмга да күпер сала. Эш шунда ки, «Шәһәр кызы» романының төп кимчелеген Энгельс эшчеләр сыйныфының тарихи миссиясен дөрес күрсәтмәү белән бәйләп караган. Аныңча, романда эшчеләр сыйныфы пассив масса итеп тасвирланган, аңарда «үзен изә торган мохиткә» отпор бирү омтылышы аз гына да сизелми. Әнә шуны Энгельс типик булмаган **хәл** дип бәяли. Аның фикеренчә, пролетариатның үз хокукы өчен көрәше «реализм өлкәсендә үз урынын алырга тиеш» [1].

Минемчә, безнең әдәбият теориясе Ф. Энгельс идеяләреннән этелеп китеп, алга адым ясау, ягъни метод проблемасының иҗат принципларына караган якларына тирәнрәк үтеп керү урынына, һаман әле бер төштәрәк таптана, хәтта вакыт-вакыт элек яулаган позицияләргә чигенә, алда әйтелгәнчә, социалистик реализмның күбрәк идеологик аспектлары белән шөгыльләнә шикелле. Әлбәттә, соңгысы да кирәк, хәтта бик кирәк. Чигенүләр дә, ихтимал, социалистик реализм проблемасының әдәби-эстетик якларын хәл итү юнәлешендә алга сикерү өчен тылны ныгыту сыман бер нәрсәдер.

Күп кенә белгечләрнең фикеренчә, әлеге проблеманы хәл итүгә илтә торган чыгыш ноктасы — кеше концепциясе. Башкача була да алмый. Чөнки реалистик әдәбиятта тормышның мәгънәсен сәнгатьчә ачып бирү нәкъ менә кешене барлык төр иҗтимагый бәйләнешләрдә күрсәтү ярдәмендә башкарыла.

Реализмның өч этабын — «мәгърифәтчелек», «критик» һәм «социалистик» дигән «аергычлар» белән йөртелә торган этапларын алыйк та кеше концепциясенең ни рәвешле тормышка ашырылганын карап китик. Фикер аңлашылсын өчен, билгеле, чынбарлыкның үзендә катлаулырак булган күренешләрне беркадәр гадиләштерергә, схема төсендәрәк күрсәтергә туры килер.

Мәгърифәтчелек әдәбияты җәмгыятьне үзгәртеп коруда төп көч — кешенең аңы, кешенең акылы дигән мәгънәгә кайтып кала торган рационализм фәлсәфәсенә ни-

---

[1] К. Маркс и Ф. Энгельс об искусстве. I том. Мәскәү. 1957 ел. 10 бит.

гезләнә иде. Мәгърифәтчеләр шул ук вакытта кеше аңының, кеше гамәленең тышкы тәэсирләр нәтиҗәсендә билгеле бер рәвеш алуын күрәләр иде. Әнә шуңа бәйле рәвештә, мәгърифәтчелек реализмы вәкилләре дә кеше һәм тирәлек проблемасын хәл итәргә, кешене тирәлек җимеше итеп күрсәтергә тырышалар иде. Тик шунысы бар: мәгърифәтчелек реализмында тирәлек төшенчәсе өскормә күренешләрен генә, конкретрак әйтсәк, кешегә әхлак тәрбиясе бирә торган факторларны гына эченә ала.

Критик реализм формалашканда инде иҗтимагый аң алга таба зур адым ясаган иде. Алдынгы фикер ияләре җәмгыятьне яшәтә һәм үзгәртә торган куәтнең кеше аңыннан бигрәк, аерым шәхесләрнең теләгенә буйсынмаган объектив закончалыкларга кайтып калганлыгын аңлауга якын килделәр. Билгеле, әдәбияттагы реализм да элекке халәтендә кала алмады. Ул кешене иҗтимагый тирәлек җимеше итеп күрсәтергә тиеш иде. Тирәлек төшенчәсе хәзер инде экономик, социаль һәм политик мөнәсәбәтләрнең җыелмасын үз эченә ала башлады. Инде килеп, иҗтимагый аңда революция ясаган марксизм тугач, җәмгыятьне хәрәкәт иттерүче төп куәтнең ни икәнлеге ачылгач һәм аны кешегә бәхет китерә торган рәвештә үзгәртеп коруның фәнни дөрес юллары күрсәтелгәч, реализм да үзгәрешсез кала алмый иде. Дөрес, социалистик реализм да, критик реализм кебек үк, кешене иҗтимагый тирәлек — экономик, социаль һәм политик мөнәсәбәтләр җимеше итеп тасвирлый. Әмма соңгысыннан аермалы буларак, биредә кеше иҗтимагый хәлләрнең, тирәлекнең колы гына булып калмый. Ул актив көч итеп, иҗтимагый үсешнең законнарын танып белгән хәлдә, тирәлеккә йогынты ясый, аны тиешле юнәлештә үзгәртә ала торган көч итеп тасвирлана. Моннан инде Ф. Энгельснең югарыда китерелгән сүзләренең тирән мәгънәсе аерата ачык күренер. Эшчеләр сыйныфының үзен изә торган тирәлеккә отпор бирүе реализмда чагылыш табарга тиеш дигән иде бит ул [1].

Шулай итеп, без социалистик реализм әдәбиятында кеше концепциясе торышы белән таныштык. Соң ул принцип иҗат процессында ничек тормышка ашырыла? Тормыш материалы белән эш итүдә социалистик реализм методының үзенчәлеге нидән гыйбарәт? Реалистик иҗатның нигезендә яткан типлаштыруга бу метод нинди яңалык алып килде?

Бу сорауларга анык һәм тәгәл җавап бирү үзе зур гыйльми тикшерену эше таләп иткәнгә күрә, гипотеза тәртибендә генә кайбер фикерләрем белән уртаклашмакчы булам.

Хикмәт, әлбәттә, тормыш фактларын **сайлап** ала белүдә, чынбарлык күренешләрен тасвирлаганда, берсен калкытыбрак биреп, икенчесен күләгәдәрәк калдыруда, зурайту исә кечерәйтүдә һ. б. Ялгыш аңлауга урын калмасын өчен, кат-кат басым ясап, шуны әйтергә ашыгам: сайлап алу, калкытып кую, акцент ясау, зурайту дигәнне, икенче төрле әйткәндә **типлаштыруны**, гадиләштереп аңларга ярамый. Сүз биредә иҗади башбаштаклык турында бармый. Сүз шулай ук марксизм-ленинизм тәгълиматы белән өстән-өстән танышып яисә берәр карарны укып чыгып, тормыш фактларын шуңа яраклаштырырга азаплану турында да бармый. Иллюстрацияләү белән һичнинди уртаклыгы булмаган чын сәнгать әсәре иҗат итү өчен, язучы, әлбәттә, фактларның үзеннән чыгып нәтиҗә ясарга, үткәндәге классиклар кебек үк, догма һәм боерыклардан азат хәлдә эш итәргә, акыл контроленнән ычкынмаган хыялына һәм интуициясенә киң юл бирергә тиеш.

Хакыйкатькә илтә торган сайлап алу — иң әүвәл язучының бөтен гомере буенча өзлексез дәвам итә торган процесс ул. Максатлы сайлап алу исә конкрет әсәр турында уйланганда, язу һәм төзәтү процессында эшләнә. Бу очракта язучы, билгеле бер **проблемадан** чыгып, җыйган материалын тәртипкә сала, артыгын ташлый, җитмәгәнен эзләп таба, калкытып куя,

---

[1] Билгеле, әдәби практикада кешене **бер үк вакытта** тирәлек җимеше һәм шул тирәлеккә йогынты ясаучы актив көч итеп тасвирлау принцибын бозу очраклары да булып тора. Шәхес культы аеруча куәтләнеп киткән елларда күп кенә авторлар үзләренең уңай геройларын шул чорның объектив хәлләреннән аерып алып (ягъни тирәлек җимеше итеп күрсәтү принцибын онытып), тормышны күз ачып йомганчы үзгәртеп куя торган әкият батырлары итеп чыгаралар иде. Мондый «геройлар» хакында язылган әсәр тормыш дөреслегеннән ерак торган иллюстрация булып кала иде. Бу типтагы әсәрләр соңрак та язылды, хәзер дә күренгәләп куя. Әмма без, социалистик реализм турында сүз алып барганда, мондыйларны түгел, бәлки сәнгать ягыннан тиешле дәрәҗәгә ирешкәннәрен күздә тотабыз.

нисә арткарак чигерә, зурайта нисә кечерәйтә һ. б. Бу урында ассызымлап шуны әйтергә кирәк: **социалистик реализм методының рухына туры килә торган сайлап алу** тормышка ашырылсын өчен, язучы, ким дигәндә, дүрт нәрсәгә ия булырга тиеш. Беренчесе — талант; икенчесе — кешене бәхетле итүгә юнәлгән гражданлык пафосы; өченчесе — тормышны — аның үткәнен һәм бүгенгесен — бөтен нечкәлекләренә кадәр биш бармагың кебек белү; ниһаять, дүртенчесе — дөньяга иң дөрес караш, марксизм-ленинизмны иҗади үзләштерү нәтиҗәсендә **канга сеңгән** диалектик фикерләү. Әнә шул дүрт сыйфатка ия булган язучының күзе критик реалистка әһәмиятле тоелмаган, аның игътибарыннан читтә кала торган күп нәрсәне күреп алуга сәләтле була. Еракка бармыйча, кул астындагы бер мисалны гына китереп үтим.

Менә Ш. Камалның 1909 елда язылган «Козгыннар оясында» исемле хикәясе. Тормышның коточкыч шыксызлыгыннан үзләрен кая куярга белмәгән шахтерлар, күңел ачмакчы булып, Госман карт белән Мәрьямнең кечкентәй генә бәхетен харап итеп ташлыйлар. Хикәя — гади, тормышчан, ышандыра. Вакыйгада катнашучыларның һәркайсы билгеле бер характерга ия, һәркайсы үзенең характерынча хәрәкәт итә. Барыннан да әһәмиятлесе — аларның характерындагы тискәре яклар тумыштан килә торган сыйфат итеп түгел, бәлки авыр тормыш шартларының нәтиҗәсе итеп күрсәтелгән, ягъни эшчеләр шул чордагы социаль хәлнең продукты итеп тасвирланганнар. Хикәя геройларында әле сыйнфый аңның уянмаган булуы, алар йөзендә татар эшчеләренең әле үзен коткарырга сәләтсез булып, тик газап чигеп яшәүче сыйныф тәсендә күз алдына килеп басуы да беркадәр аклана. Реализммы бу? Әлбәттә, реализм. Әмма, күп дигәндә, критик реализм.

Мәгълүм булганча, хикәя язылган чорда күп кенә татар эшчеләре, рус пролетариаты белән берлектә, забастовкаларда катнашалар иде. Ул гына да түгел, татар эшчеләре стачканы оештыручылар арасында да була иде. Эшчеләр арасыннан чыккан ныклы татар социал-демократларын да беләбез без. Ышанып әйтергә мөмкин, 1905 елгы революциягә шатланып каршы алган һәм вакыйгаларны җентекләп күзәтеп барган Ш. Камал өчен дә болар җиде кат йозак астындагы сер булмый. Татар эшчеләренең революцион хәрәкәттә катнашуы тегеләйме, болаймы аның колагына килеп җиткән. Әмма пролетариат позициясенә баса алмаган һәм җәмгыятьнең үсеш законнарын дөрес, ягъни марксистларча аңлаудан шактый ерак торган язучыга әлеге фактлар очраклы күренешләр генә булып тоелган, киләчәктә ялкынга әвереләчәк очкынга ул бәя биреп җиткерә алмаган. Әнә шуңа күрә Ш. Камал татар эшчеләре тормышының күзгә аеруча ташланып торган якларын гына типлаштырган.

1931 елда Ш. Камалның шул ук хикәя материалына корылган «Козгыннар оясы» драмасы дөньяга килде. Татар сәхнәсендә шаулап бару белән бергә, рус сәхнәсенә күтәрелү шәрәфенә ирешкән бу әсәрендә инде Ш. Камал тормыш материалын бөтенләй башкача яктырта. Татар эшчеләре бигедә газап чигүче булып кына калмыйлар. Алар, актив көч рәвешендә, көрәштә күрсәтелгәннәр.

Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романының ике варианты, нисә шул ук Ш. Камалның «Акчарлаклар» һәм «Таң атканда» әсәрләре арасындагы аерма һәм башка кайбер әсәрләр дә социалистик реализмны критик реализмнан аера торган сыйфатлар турында фикер йөртер өчен шактый материал бирә алалар.

Социалистик реализмның әдәби-эстетик ягы һәм аның иҗат принциплары турында сүз кузгатып, укучыны тәмам канәгатьләндердем, аның сорауларына тулы җавап бирдем дип раслаудан мин, әлбәттә, ерак торам. Максатым аны уйландыру, аның игътибарын шул җавапның табылу ихтималы булган якка юнәлтү иде. Һәрхәлдә, бер нәрсә бәхәссез дип беләм: социалистик реализм методы **нәрсәне** сәнгатьчә чагылдыруы белән генә түгел, бәлки **ничек** чагылдыруы белән дә реализмның элекке этапларыннан аерылып тора.

Хәзер инде теориягә җитәрлек игътибар бирмәүнең иҗат практикасында һәм тәнкыйтьтә үзен-үзе акламый торган «чыгымнарга» китерүе мәсьәләсенә күчик.

Безнең тәнкыйтьтә, мәсәлән, мондый тенденция яшәп килә: кайвакыт без социалистик реализм капкасын киң итеп ачып куябыз да авыру нисә җитлекми туган малларны гомуми көтү эченә куып кертәбез. Нисә, киресенчә, капканы сызык кадәр генә ачып, таза, көр малларны тышта калдырабыз. Беренче очрактан башлыйк.

Шундый әсәрләр була, карап торышка, барысы да анда дөрес, һәр нәрсә үз уры-

нында Новатор консерватор белән әрепләшә һәм, парторгның акыллы сүзләрен тыңлый-тыңлый, җиңеп чыга. Әмма мондый әсәрләргә «кечкенә» генә бер нәрсә җитми. Ул да булса, сәнгатьчәлек, художестволылык. Кеше образлары схематик, художество алымнары тапталган, әйтергә теләгән фикере күптән билгеле хакыйкать була. Авторының совет кешесе булуын, изге нияттән чыгып, яңәсе, дөрес позициядә торып язуын искә алып, без мондый әсәрләргә — атап әйтмәсәк тә — социалистик реализм мөһере басабыз. Ул гына да түгел, әгәр берәр тәнкыйтьче андый әсәргә һөҗүм итсә, бердәм булып якларга керешәбез. М. Шәйминең «Безнең шәһәрнең утлары» исемле җыентыгына кагылышлы вакыйганы хәтерлик. А. Яхин, һичкем кире кага алмаслык фактларга нигезләнеп, китапны кискен төстә тәнкыйтьләп чыга, ә газеталарыбызның берсе, үзенең фикерен дәлилләү белән мәшәкатьләнеп тормастан, рецензентка бер кычкырып сала.

Бу, әлбәттә, хәттән ашып киткән очрак. Сүз сәнгать киртәсенә дә кермәгән гаять примитив һәм зәгыйфь китап турында бара. Шундыйларны яклаучылар да табылгач, остарак эшләнгән һәм беренче карашка чын сәнгатьтән аеру да кыен булган әсәрләргә, әйтик, М. Хәсәновның «Саф җилләр» яисә Ян Винецкийның «Тот, кто верит» романнары кебекләргә җил белән яңгыр да тимәскә тиеш була. Бу категориягә кергән әсәрләр бездә шактый булса да, кайберләре хәтта эталон урынында йөртелсә дә, бу ике романны телгә алуымның сәбәбе шул: Татарстан язучыларының VI съездында болар адресына бик үк татлы булмаган сүзләр әйтелгән иде[1]. Әмма сүз сүз белән калды, докладларда булсын, күзәтү характерындагы мәкаләләрдә булсын, бу һәм шуңа охшаш әсәрләр әдәбиятыбызның уңышы сыйфатында йөртеләләр.

Ачыктан-ачык һәм һичкемнең кәефенә карамыйча, түбәндәгене белдерергә вакыт җитмәгән микән? Авторларының яхшы ниятенә дә, әйтергә теләгән фикерләренең дөреслегенә дә карамастан, сәнгатьчәлеге шактый чамалы урта кул, иллюстратив әсәрләрнең социалистик реализм белән бернинди уртаклыгы юк!

Бер аналогия китерим. Безнең әдәбиятта 1908 ел датасы белән чыккан «Бичара Биби-җиһан» исемле пьеса бар. Әсәрнең төп герое, социалист буларак, хезмәт ияләрен эксплуатацияләгән өчен, зур корсаклы байларны эттән алып, эткә салып сүгә. Карашы ягыннан прогрессив позициядә торган Закир Сәетзадәнең әнә шул рәвешле сыйнфый каршылыклар мәсьәләсен куюы заманы өчен, әлбәттә, әһәмиятле факт иде. Әмма моңа карап кына без бу әсәрне критик реализм киртәсенә кертә алмыйбыз. Чөнки пьеса үгет-нәсихәтчелек белән сугарылган иллюстрациягә кайтып кала. Тукайның бу әсәрне ачы сурәттә тәнкыйть итеп чыгуы очраклы хәл түгел. Билгеле булганча, XIX гасыр рус әдәбиятында да карап торышка ярыйсы гына язылган фаш итүче әсәрләрнең саны шактый. Әмма әдәбият белгечләре андыйларны Гоголь, Салтыков-Щедрин, Гончаров, Тургенев, Толстой, Достоевский, Чехов һ. б. исемнәре белән бәйле булган критик реализмның тышында калдыралар. Әгәр шулай икән, әгәр эчтәлекләре ягыннан прогрессив характерда булган бик күп әсәрләр критик реализм таләпләренә җавап бирми дип санала икән, дөрес идея үткәрелгәненә һәм авторның язучылар союзы члены булуына карап кына, **барлык** әсәрләрне дә социалистик реализм үрнәге итеп күрсәтергә безнең ни хакыбыз бар? «Менә бит социалистик реализм нинди хәлгә җиткерә» дип, дошманнар авыз ера алмасыннар өчен, халтураны утта көйдерү белән генә чикләнмичә, урта кул, иллюстратив әсәрләр белән дә әшнәлекне бетерергә вакыт җиткәндер, шаять.

Икенче очракка килик. Болай да була: кайбер югары художестволы әсәрләрне тәнкыйть социалистик реализмнан читләштерә. Ник? Чөнки автор әсәренең үзәк герое итеп заманның иң алдынгы кешесен алмаган. Яисә тискәре персонаж үзәккә алынып та, аңа каршы уңай герой куелмаган. Тәнкыйтьчеләр күп кенә очракта мондый әсәрләрнең үзенчәлеге турында уйланып маташмыйлар. Ни өчен тискәре персонаж игътибар үзәгенә куелган? Моның белән язучы ни әйтергә тели? Бит әнә шул сорауларга җавап бирми торып, икенче төрле әйткәндә, язучы күтәргән һәм хәл итәргә омтылган **проблеманы** искә алмаган тәкъдирдә, әсәрне дөрес бәяләп тә, аның социалистик реализмга мөнәсәбәтен билгеләп тә булмый. Мисал өчен үзебезнең матбугатта да, үзәк матбугатта да күп бәхәсләр тудырган «Рәшә» повестена гына тукталып китик.

[1] «Совет әдәбияты» журналы. 1965 ел. 4 сан.

Ә. Еники үзенең яшәешен философик яктан нигезләргә азаплана торган акыллы обывательне повестеның төп персонажы итеп алган. Зөфәр Сабитов карашынча, кеше дигән мәхлук теләсә нинди формациядә дә үз-үзе булып кала: тәмле ашарга, матур киенергә, бай җиһазлы өйдә яшәргә тели. Моның өчен аңа акча яисә власть кирәк. Халыкка хезмәт итү турындагы матур сүзләр исә кешенең хәйвани йөзен яшерә торган битлек хезмәтен генә үти.

Әнә шундый фәлсәфәне фаш итү кирәкме? Әлбәттә, кирәк. Чөнки Зөфәр Сабитов кебек кешеләр сату-алу һәм тәэминат өлкәсендә генә түгел, бәлки бүтән сфераларда да очрыйлар. Димәк, язучы бу әсәре белән кирәкле һәм файдалы эш башкара.

Әмма Ә. Еникине тормышның тик күләгәле яклары гына күрсәтүдә һәм Зөфәргә каршы уңай герой куймауда гаепләделәр.

Әгәр язучы кайбер тәнкыйтьчеләр биргән рецепт кушканча эш итсә, нәрсә булыр иде? Әлбәттә инде, **бөтенләй бүтән** проблемага багышланган **бөтенләй бүтән** әсәр килеп чыгар иде. Үз проблемасына турылыклы булып калган тәкъдирдә исә автор Сабитовны бөтен тулылыгында күрсәтә алмас иде. Чөнки илаһи сыйфатларга ия булган уңай герой текәлеп, күзәтеп торганда, Зөфәр үз табигате кушканча хәрәкәт итә алмас иде.

Тормышыбызның якты якларына, Сабитовлар оясын уратып алган зур дөньяга килсәк, аның сулышы повестьта һәрвакыт сизелеп тора. Бик күп уңышлы детальләр һәм Сабитовның даими рәвештә үзенең чын йөзен яшерергә, бүтән кеше булып күренергә мәҗбүр булуы әнә шуны күрсәтә. Совет кешеләренең зур семьясында туып, буй үстергән артистка Рәшидәнең, Зөфәрне танып алгач, арадагы җепне өзеп ташлавы да шул турыда сөйли.

Сүз дә юк, социалистик реализм әдәбиятының төп герое чорның алдынгы кешесе булырга тиеш. Ләкин тулаем әдәбиятка нисбәттә шиксез дөрес булган бу кагыйдәне тулысы белән һәр конкрет әсәргә күчерсәк, А. М. Горькийның «Клим Самгин»ыннан башлап бик күп әсәрләрне социалистик реализмнан чыгарып ташларга тиеш булырбыз. Сатира турында инде әйтәсе дә юк. Социалистик реализмның мактанычына әверелү ихтималы булган югары художестволы әсәрләр белән, димәк, сак эш итәргә кирәк.

Билгеле, әсәрнең художество дәрәҗәсе аны социалистик реализм киртәсенә кертү яки кертмәүдә бердәнбер үлчәү була алмый. Талантлы авторның да кайбер очракта совет әдәбиятының төп иҗат методы таләпләренә җавап биреп җиткерми торган әсәр бирүе мөмкин. Моның ачык мисалы — Н. Фәттахның «Артта калган юллар» хикәясе.

Әйе, хикая оста язылган. Автор Бөек Ватан сугышы чоры авылында хөкем сөргән ачлык һәм ялангачлык күренешләрен күңелне тетрәтерлек итеп тасвирлый алган.

Менә алты айга эшкә җибәрелгән Хәмдия, ел ярымнан соң, авылына качып кайта. Киткәнче ул, Мидхәт исемле намуссыз егеткә тап булып, алданган, торф сазлыкларында бала тапкан, шактый вакыт бернинди ярдәмсез тәмуг газаплары кичергәч, чарасыздан әлеге хәтәр адымны ясарга мәҗбүр булган.

Атлыгып, ашкынып кайта ул. Хыялында — туган өй җылысы, анасының шәфкатьле карашы һәм... туйганчы бер ашау. Алай-болай гына да түгел, тавык шулпасы яисә каклаган каз ашау. Әмма аны бетәшкән анасының караңгы чырае һәм кайнар суга беркадәр бәрәңге һәм он сыман нәрсә салынган сыекча каршылый.

Әнә шул килеш, ач хәлдә, төрмәгә эләгүдән куркып, Хәмдия өендә качып ята башлый. Беркайдан бер грамм ярдәм юк. Башта Хәмдиянең сырган чалбарын һәм тупас ботинкасын азыкка алыштыралар, аннары сырмасын. Болар да күпкә бармый. Биредә, әлбәттә, әдәби иҗатка хас концентрацияләү, калкытып кую һәм **сәнгатьчә арттыру** бар. Шулай да Н. Фәттах тасвир иткән хәлне дөрес түгел дип булмый.

Яисә мондый күренешләрне алыйк. Хәмдиянең җиңгәсен бер кисә яшел кузак өчен биш елга утыртканнар. Ике сарык бәрабәренә эшкә китүдән котылып калган «ялганчы», «бирemчe» Сабира хисапчы булып алган. Тамагы тук, өсте бөтен. Ялкау Факия — бригадир. Факиянең абыйсы амбарда, атасы атлар тирәсендә булгач, ипи салу гына түгел, ит-майдан да өзелмиләр. Надан һәм ялагай Вәлиәхмәт, председатель булarak, авылда патша. Әшәке җан Мидхәт милициягә эшкә кергән дә авылның котын алып тора. Биредә дә сәнгатьчә арттыру бар. Әмма бу очракта да мин сугыш еллары авылында мондый хәлләрнең булуын инкарь итәргә җыенмыйм.

Әмма бөтен хикмәт тә шунда шул, әсәрдә без **ярым** дереслек белән генә очраша-

быз. Яртылаш кына дөреслек исә күп вакытта ялган була.

Иң зур, иң чын, иң олы дөреслек ул — халкыбызның Бөтен Ватан сугышында җиңеп чыгуы. Бу армиянең генә түгел, бәлки тылның да җиңүе иде. Бу халык рухының җиңүе иде. Бу Октябрь революциясе, гражданнар сугышы, халык хуҗалыгын торгызу һәм социализм төзү чорында халыкның күңелендә тәрбияләнгән яңа сыйфатларның, яңа тип патриотизм булган совет патриотизмының җиңүе иде. Әнә шул хакыйкатьне без әсәрдә бөтенләй диярлек күрмибез.

1943 елның көзеннән 1945 елның көзенә чаклы авылда яшәгән кеше буларак, мин шуны әйтә алам. Безнең авыл да бүтәннәрдән аерылып тормый торган гадәти авыл. Анда Н. Фәттах сурәтләгән кешеләрнең күбесен очратырга мөмкин иде. Әмма шул ук вакытта дүрт кешедән торган партия оешмасы бар иде. Аның җыелышларында, бүтән мәсьәләләрдән тыш, фронтовик семьяларына ярдәм күрсәтү мәсьәләсе куеп тикшерелә иде. Колхозда шундый семьялар өчен махсус фонд бар иде. Карчык-корчыкларның, тол хатыннарның бакчасын сукалау, өй түбәсен ябып бирү кебек хәлләрне яхшы хәтерлим. Спектакльләр куя идек без, докладлар сөйли идек, политинформацияләр үткәрә идек.

Социалистик стройның асылыннан чыга торган әнә шундый күренешләрне һәм кеше күңелендә яшеренеп яткан яңа сыйфатларның гәүдәләнеше булган детальләрне бөртекләп җыеп, сәнгатьчә зурайтып бирәсе урында, Н. Фәттах күзгә ташланып торганнарын да күрми уза.

Ни өчен язылган бу хикәя? Автор нәрсә әйтергә теләгән? Нәрсәне раслый ул, нәрсәне хөкем итә? Ярый, сугышны хөкем итә, ди, сугыш бәхетсезлек китерә дип әйтергә теләсен, ди. Ләкин бит бу бик билгеле хакыйкать: уңыш җыю кампаниясе түгел ул сугыш дигәнең. Хикәясен әнә шул фикерне әйтү өчен генә язган дисәк, авторны кимсетү булыр иде. Чынлап та, хикәядә тагын гаделсезлек темасы бар бит әле. Н. Фәттах тасвирлап биргән әнә шул тоташ гаделсезлекне нәрсә тудырган? Сугыш дип котылыр идең, социалистик ватанның бәйсезлеген саклау өчен күтәрелгән изге сугыш бу. Соң нәрсә? Хикәядә әнә шул сорауга анык җавап юк.

Әсәрнең төп герое Хәмдиягә кайтыйк. Хикәядә ул социалистик мөнәсәбәтләр җимеше дип әйтерлек бердәнбер шәхес: пионерда, комсомолда тәрбияләнгән, сугыш алдыннан «ударник Хәмдия» дигән исем алган, Мәскәүгә күргәзмәгә барырга җыенып йөргән. Хәзер дә ул, качып кайтуына карамастан, үзен хаклы сизә: ярты ел урынына ел ярым эшләгән, тагын эшләр иде — баласының һәлак булуыннан курыккан.

Әгәр Хәмдия ачыктан-ачык үзенең хокукын даулап барса, хаклык өчен көрәшсә, нәрсә булыр иде (образның да логикасы шуны таләп итә шикелле)? Җиңеп чыгып, тыл солдатлары арасында үзенең урынын алса, без моннан социалистик гуманизмның тантанасын күрер идек. Төрмәгә эләксә, фаҗиганең төп сәбәбе аңлашылыр иде, шәхес культы нәтиҗәсендә туган күренешләрнең социализм һәм гуманизм принциплары белән яраша алмавы ачыграк күренер иде.

Ә Хәмдия нишли? Куркудан дер-дер калтырап, өендә яшеренеп ята-ята да, түзәр хәле калмагач, серне председательгә барып чишә. Аннары, милиционер Мидхәттән коты алынып, авылны ташлап кача. Әлеге гаделсезлек социалистик стройның асылыннан чыгамы, әллә социализм принципларын бозу нәтиҗәсеме дигән кискен һәм рәхимсез дилеммага сәнгать теле белән әйтелгән җавап булмый кала. Ул гына да түгел, укучының, хикәяне укыгач, беренче нәтиҗәгә килүе дә мөмкин. Әсәрнең берничә урынында без, мәсәлән, түбәндәге сүзләрне укыйбыз. «Үз киемеңне үзең киеп йөрергә дә куркып яшә икән! Нинди тормыш бу!? **Нинди заман бу!!**» «Ялкау Факия — бригадир, ударник Хәмдия — теләнче... Менә ул нинди заман!» Бу ачынулы сүзләр, ихтимал, закон бозу хәлләрен күздә тотып кына әйтелгәндер. Ләкин соңгылары конкрет күрсәтелмәгәч, эш башындагыларның **барысы да** әшәке җаннар булып аңлашылгач, совет кешеләре күңелендә коммунизм идеалы кабызган очкын сизелмәгәч, ул сүзләр безнең тормышка, строебызга кизәнү булып ишетелә икән, — бер дә гаҗәп түгел.

Мин, әлбәттә, Н. Фәттах аңлы рәвештә шулай эшли дип әйтергә җыенмыйм. Минемчә, ул Ватан сугышы турында моңарчы язылган әсәрләрдәге кайбер фальшь авазлар яңгыравына эче пошып, чын дөреслекне язарга нияте иткән. Әнә шул полемик азарт һәм, чорны җентекләп өйрәнеп маташмастан, үзенең балачак истәлекләре белән генә чикләнү тормышның эчке мәгънәсенә үтеп керүгә комачаулаган, аны

натурализм кочагына ташлаган. Авторның сайлап алу һәм сәнгатьчә зурайту алымнары, димәк, типлаштыруы социалистик реализм принциплары белән каршылыкка кергән.

Ф. Энгельсның «Шәһәр кызы» романы адресына әйткән сүзләрен «Артта калган юллар» хикәясенә карата да кабатларга туры килә. Әйе, хикәя житәрлек дәрәжәдә реалистик булып чыкмаган. Чөнки Н. Фәттах үзенең героинясын типик хәлләргә куеп күрсәтә алмаган.

Ниһаять, шунысы гаять кызык: язмыш шуклыгыдырмы, «Шәһәр кызы» белән «Артта калган юллар» хикәясе, араларында 90 еллык гомер ятуга карамастан, берберсенә гаҗәеп аваздаш. Икесенең дә үзендә — эшчән кыз, икесендә дә кыз алдана, икесендә дә, бала табып, гаять авыр хәлдә кала, икесендә дә героиняның язмышы ясалма хәл ителә. Нелли Амброзга «коткару армиясе» дигән филантропик оешма кешеләре ярдәм кулы сузган булса, Хәмдияне ниндидер билгесез серле «начальник», арбасына утыртып, алга, «тормышка» таба алып китә.

Инде килеп, соңгы мәсьәлә. Совет әдәбиятында социалистик реализм методы белән янәшә бүтән иҗат методлары яши аламы, юкмы?

Декадентлыкның төрле «изм»нары, формализм һәм натурализм кебекләр турында ике сүз булырга мөмкин түгел. Алар — бакчадагы чүп үләннәр.

Романтизмга (прогрессив, революцион романтизмга) килгәндә исә, мәсьәлә катлаулана төшә. Әдәбиятның бурычы тормышны танып белү генә түгел, бәлки тәрбияләү һәм эстетик ләззәт тә бирү икәнлеген искә алсак, принципта романтизмның мөстәкыйль иҗат методы буларак яши алуы турында сүз алып бара алабыз. Бит романтизм, субъектив башлангычның зур урын тотуы белән характерлы иҗат методы буларак, чынбарлыкны анализлап, тегеяки бу хакыйкатьне ачып бирү бурычын үз өстенә йөкләмәсә дә, бөек идеалга — коммунизм идеалына хезмәт итә ала. Үзенең методы булган романтизм юнәлеше совет әдәбиятында чынлап та бармы, әллә ул, стиль күренеше буларак, социалистик реализм эчендә яшиме — бу мәсьәлә махсус өйрәнүне таләп итә[1].

[1] Бу турыда Г. Халитның «Реализмны һәм романтизмны яклап» дигән мәкаләсеннән укырга мөмкин («Казан утлары» журналы. 1967 ел. 8 сан.)

Критик реализм мәсьәләсенә кискәрәк тукталыйк.

Кайбер иптәшләр совет әдәбиятында социалистик реализм белән янәшә критик реализмның да урын алырга хаклы булуы турында сүз алып баралар. Әдәбият белгече А. Н. Овчаренко, мәсәлән, шул карашны яклап, С. Залыгин, В. Дудинцев, А. Солженицын, В. Войнович, В. Семин кебек язучыларны критик реализм вәкилләре итеп саный[1].

Татар совет әдәбияты белемендә дә критик реализм файдасына тавышлар ишетелгәли. Кайбер иптәшләр фикеренчә, егерменче еллар әдәбиятында, мәсәлән, критик реализм юнәлеше булган. «Татар хатыны нилэр күрми», «Кара йөзләр», «Шагыйрьнең алтын приискасында» кебек әсәрләр, янәсе, шуның мисаллары.

Бу мәсьәләне хәл итү өчен иң элек «критик реализм» төшенчәсен ничек аңлау турында бер фикергә килергә кирәк. Әгәр бу термин совет әдәбиятындагы критик башлангычны гына аңлатса, аның кирәге юк калмый. Чөнки коммунистик идеал хакына нәрсәнедер инкарь итү, тәнкыйть утына тоту һәм камчылау социалистик реализмның бер органик сыйфаты булып тора. Әгәр инде без критик реализм дигәннән яшәп килүче стройның үзен тәнкыйтьли, җәмгыятьнең нигез ташларын какшата торган реализмны аңлыйбыз икән (Көнбатыш Европа һәм рус критик реализмы, шулай ук үзебезнең критик реализм шундый иде), үзеннән-үзе аңлашыла, совет әдәбиятының бу иҗат методы белән берниндә алышбиреше була алмый. Икенче яктан килеп карыйк. Критик реализм үрнәге булуны дәгъва итә торган әсәр социалистик җәмгыятьнең үзенә кизәнә икән, ул гадел стройның асылын бозып күрсәтә дигән сүз. Димәк, бу очракта реализм турында гомумән сүз була алмый.

Әлеге мәсьәләгә кагылышлы хаталарның чыганагы кайда соң? Безнең татар әдәбиятчылары, мәсәлән, критик реализмның аерым алымнарын метод белән бутыйлар. Мәгълүм булганча, яңа метод тылсымлы таяк болгау белән кинәт барлыкка килми, акрынлап формалаша. Бер халәттән икенче халәткә күчкәндә, искенең бик күп элементлары яңа белән аралашып китәргә мөмкин. М. Гафури, Г. Ибраһимов, Ш. Камал һәм башка кайбер язучылар револю-

[1] «Вопросы литературы» журналы. 1966 ел. 12 сан. 23 бит.

циягә кадәр критик реализм методы белән иҗат иткәнгә күрә, егерменче елларда бу иҗат методының күп кенә алымнарын башлыча **революциягә кадәрге** тормышны яктыртканда кулландылар. Әмма шунысын да искәртми мөмкин түгел, бу типтагы әсәрләрдә дә революция һәм совет властеның ун елы тәҗрибәсеннән килә торган ниндидер яңа сыйфатларны шәйләми мөмкин түгел. Г. Халит рус телендә чыккан «Революция тудырган геройлар» исемле китабында моны ышандырырлык итеп күрсәтә алган.

А. Овчаренко һәм аның фикердәшләренә килгәндә исә, аларның хатасы югарыда күрсәтелгән тенденция — социалистик реализмны тарайтып аңлау тенденциясе белән бәйләнгән. Алар фикеренә кушылсак, совет язучыларын ике төркемгә бүләргә туры килер иде: берсе — уңай якларны гына тасвирлаучылар; икенчесе — тискәре күренешләр турысында гына язучылар. Әгәр соңгылары критик реализм юнәлешен тәшкил итсәләр, беренчеләренең бөтен эше мактауга һәм дифирамб җырлауга гына кайтып калырга тиеш була. «Социалистик реализм» дигән исем белән тәкъдим ителгән һәм совет әдәбиятының төп методына күләгә төшерә торган «прокруст ятагы»на авып төштек түгелме?!

Ә бит чынлыкта Овчаренко критик реалист ясаган язучыларның күп кенә әсәрләре, югары художество дәрәҗәсенә ирешкән булып, социалистик реализм яклый торган идеаллар өчен көрәшәләр. Арада методыбыз принципларына җавап биреп бетерми торганнары бар икән — андыйлар, әлбәттә, бар — аларны тәнкыйть итәргә кирәк.

Йомгаклау рәвешендә шуны әйтәсе килә: социалистик реализм иксез-чиксез бер нәрсә булмаса да, күп төрле стиль һәм индивидуаль талантларны үз эченә сыйдыра һәм аларның чәчәк атуына мөмкинлек бирә. Әдәбият белеме һәм тәнкыйтьнең бурычы, алдан уйланган схема һәм догмаларны читкә алып, катлаулы, чуар һәм каршылыклы әдәби процессны фәнни нигездә, объектив рәвештә өйрәнергә һәм социалистик реализмның асылын, аның үзенчәлеген ышандырырлык итеп ачып бирүгә кайтып кала.

Зәки Нури

# ТОРМЫШТАН ҺӘМ ТОРМЫШЧАН

Кешенең нинди генә катлаулы кичерешләре, нинди генә зур хисе дә дусларга мәхәббәттән, туган-үскән җирләрне яратудан башлана. Чөнки син аларны балачактан ук иң нечкә сыйфат һәм төсмерләре белән күреп беләсең, син аларга гомергә гашыйк. Бу исә — син алар турында кайгыртып яшәргә, һәр адымда шулар өчен җаваплы булырга, һәркайчан һәм һәркайда үзеңне шулардан аерылгысыз итеп санарга тиешсең дигән сүз.

Шагыйрь Нәби Дәүли бу изге хисне һәм хакыйкатьне үз иҗатында коры сүз белән әйтми, ә мартен мичләрендә ялкын дөрләтеп, кырларда мотор гүләтеп, болыннарда чалгы чыңлатып, бакчада чәчәк балкытып — ягъни бары тик конкрет эшләр белән генә расларга чакыра. Аның әсәрләре барыннан да элек кешенең туган ил каршындагы зур бурычын билгеле, укучыны коммунистик киләчәк хакына батырлык эшләп яшәргә рухландыра.

Ул язганнарның бары тик берничәсенә күз салсак та, без анда туган җир, Ватан һәм кешенең тормыштагы урыны дигән төшенчәләрнең аерылгысыз икәнен ачык күрәбез:

...Бәхетлеме кеше дөньяда
Туган җирен анам димәсә,
Шуның өчен янып-көймәсә?
Чишмә суын учлап эчкәндә
Йөрәгендә шатлык сизмәсә?

...Аякларым җиргә басканда
Йөрәгемә шундый көч алам:
Айга түгел, айдан арырак,
Арырактан ары очалам.

...Мин дөньяның армас хезмәтчесе,
Җирдә кирәк минем тормышым.

Бу юлларны уйлаганда шагыйрь күз алдында хәзерге Әлки районындагы Мәүләшә исемле туган авылы торгандыр шикелле. Таныш тау битенә сибелгән нәни өйләр. Тау астында Чирмешән сулары чептери. Тау артында — урманлык. Батрак Хәсән шул урманнарда имән төпләп көн күргән, ачлы-туклы тормышта өч бала асраган һәм улы Нәбигә әле дүрт кенә яшь чагында дөнья куйган.

Булачак шагыйрьнең күңел күзе шул Мәүләшәгә кайлардан гына торып карамый да, ничек кенә сагынмый шул ямьле Чирмешән буйларын!



Бәхет эзләп Кавказ якларына киткәч, аның үги атасы Ставрополь кырларында байларның сарык көтүен көтә. Нәби аның туган җир турындагы җырларын күп ишетә һәм йөрәгенә сеңдерә бара. Аннары үги ата дигәнебез, балаларын бай кулында калдырып, үз авылындагы йорт-җирен сатарга кайтып китә, ләкин, хатыны үлү сәбәпле, алар янына кире әйләнеп килә алмый. Ятим калган өч бала байның өч туганы кулына эләгә. Шуларның «Караколак» кушаматлысы Нәбине Царицын янындагы Чапурин авылына ук алып китә.

Эссе кояштан әлсерәп кипкән калмык кырлары... Плантациядә эшләп һәм «Караколак» көтүен көтеп үткәргән чиксез-чамасыз озын көннәр. Җан тетрәткеч ялгызлык газабы... Әнә шул чакта инде сабый күңеле якыннарын, кайчандыр чыклы үлән таптап ялан аяк чапкан болыннарны бер күрергә зар-интизар булып елый да, җырлый да башлый. Шуннан качып Царицынга килгәч, көймә асларында качып-посып яшәгән ятим Нәби бу хисләрнең йөрәкне изгеч кинди авыр таш икәнен аеруча үткен итеп сизә.

Ниһаять, аны һәм аның ише бик күпләрне, 1921 елда урамнардан җыеп алып, балалар йортына урнаштыралар. Язмыш кыерсыткан ятимнәргә Совет власте укырга, һөнәргә өйрәнергә, үз сәләтләрен сәнгатькә багышларга киң юл ача. Тырыш, һәр эшкә һәвәс Нәби күргән-белгәннәрен, тирә-юньнең матур күренешләрен рәсем итеп сызу, күңелендәге хисләрен һәм омтылышларын җыр итеп җырлау белән нәкъ шунда мавыга башлый.

Кем белсен, хәзер инде танылган шагыйрь Нәби Дәүлинең «Авыл дәфтәре»нә шигъри чәчәк булып керәсе кайбер юллар аның күңелендә, бәлки, шул чакта ук бөреләнә башлаганнардыр:

Баш өстемдә зәңгәр-зәңгәр һава,  
Кырлар, кырлар тирә-ягымда.  
Йөзәм кебек диңгез уртасында,  
Чыгып булмас кебек ярына.  
Җил тирбәтә көмеш башакларны,  
Бөртек йоклый ефәк бишектә.  
Тургай сайрый, кояш көлеп тора.  
Яз җырларын ул да ишетә.  
Карап торам мин дә исем китеп,  
Гашыйк булып арыш кырына.  
Бала көткән газиз ана кебек,  
Җир сулышын ала тын гына.  
Шул ананың мин дә бер баласы,  
Кочагында үстем мин аның.  
Хәлем бетсә, аңа башым куйдым,  
Йөрәк янса, эчтем суларын...

Шагыйрьнең үткәне турында уйлаганда, бүген инде чал чәчле өлкән каләмдәш Нәби Дәүлинең (1910 елның 14 июнендә туган) җиңел йөрешле, җор күңелле булуыннан һәм кайчакта ярыйсы ук дуамал кыланышларыннан чыгып, аны кечкенә чагында ук шактый усал һәм үз сүзле, тәвәккәл һәм йөгәнсез, кайчакта чыгырдан чыгарлык дәрәҗәдә тәртипсез һәм башбаштак малай булгандыр дип уйлыйсы килә. Шуңа күрә ул Такташ әйткән «тал чыбыгын» да аз «ашамаган» булса кирәк.

Ләкин бит болар берсе дә шагыйрь булып үсәргә тиеш кешене бик үк уңай яктан характерламыйлар әле. Кирәкле мөһиммрәк сыйфатлар нидән гыйбарәт икән соң! Әйе, андый сыйфатлары да булган малайның. Һәм, безнеңчә, алар түбәндәгеләр: Нәби дигәнебез, һичшиксез, үткер һәм чая булган, күңеле белән һәрвакыт кешеләргә тартылган, яхшыны яманнан аера белгән һәм, иң мөһиме шул: тормышка, үз тирә-юнендәге һәр нәрсәгә төпченеп карый торган зиһенле, күзәтчән «очлы күз» булып үскән.

Ә күргәне, кичергәне, киләчәктә әнә шулай җыр итеп язар нәрсәләре аз түгел аның.

Балалар йортында җидееллык белем алганнан соң, ул ФЗӨ мәктәбендә укый да, Донбасстагы абыйсы янына барып, паровоз ремонтлаучы булып эшкә керә. Ике ел үткәч, тагын бер ФЗӨ тәмамлап, тимерче була. Аннары тагын Сталинград. Шуннан Астраханьдагы Совет-партия мәктәбенә укырга китү. Ләкин, курсантларны кулаклар фетнәсен бастырырга җибәрү сәбәпле, уку бүленә. Нәби Дәүли яңадан Донбасска килә һәм мартен цехында шлакчы булып эшли. Нәкъ шул елларда Донбасста татар шахтерлары өчен чыгарылган «Пролетар» исемле газета эшенә катнаша башлый, шунда Мансур Крыймов, Максуд Сөндекле, Шәйхи Маннур, Рахман Ильяслар белән таныша, хәбәрләр, очерклар, шигырьләр бастыра. Бераздан аны, укый-яза белмәгән якташларын укытыр өчен, шахтага күчерәләр һәм соңыннан ул «Пролетар»ның үзендә дә ике ел эшли. Аннары — хәрби хезмәт. Менә ул Винницада, полковой мәктәп тәмамлап, старшина була. Менә ул — Ерак Көнчыгыштагы заставаларның берсендә 1935 елга кадәр чик буе сакчысы. Шуннан соң — Казан, яшьләр газетасы, шаулап торган әдәби агымга кушылып китү...

Тормышның бу аерым чорларын берсеннән берсе биегәя төшкән үрләр белән тиңләргә мөмкин. Үрдән-үргә менгән саен шагыйрьнең күз күреме ерагая, дөньяга карашы киңәя, иҗат уңышлары ишәя бара. Кыскасы, Нәби Дәүли әдәбиятка үзенең зур биографиясе белән тормыштан килә, аны тормышчан темалар һәм интонацияләр белән үзенчә баета.

Ул үзенчәлекне, барыннан да элек, шагыйрь иҗатының тематик юнәлеше белән билгеләү дөрес булыр. Шигъри букетка ул бер караутә үк күзгә ташланган теләсә нинди чәчәкне өзеп алмас, ә күңеленә хуш килгәнен генә сайлар. Аның сизгер йөрәге тормыштагы күп төрле тавышларның теләсә кайсын түгел, ә беренче чиратта, шул тормышны үзгәртү өчен актив көрәшүче батырлар авазын, хезмәт кешеләре сулышын ишетергә тырыша. Нәтиҗәдә, кеше һәм гражданин буларак тирән дулкынланып, илдәшләр һәм замандашлар язмышын кайгыртып, дөреслекне, югары идеалларны, саф мәхәббәтне яклап язылган әсәрләр туа. Андый иҗатка «вак тема» дигән яман чир йога алмый, андыйга ялган бизәкләр дә, ясалма купшылык та хас түгел.

Нәби Дәүлинең иң тәүге поэтик көймәсе заманында редакторы Муса Җәлил булган «Октябрь баласы» журналы битләренә 1929 елда йөзеп килеп керә һәм үзенә югарыда әйтелгән төп юлны сайлый. Утызынчы еллар азагында инде без аны, штурвалны ышанычлы куллар белән тоткан килеш, зур корабта күрәбез.

Поэзия бакчасына керү дигән чиксез җаваплы бу хәлгә аның соңгырак шигырьләренең берсендә әйтелгән бик табигый һәм зирәк искәрмә бар: «Керүен дә кердем, дусларым, чыгар өчен капка юк икән». Без моны: әдип таланты — халыкныкы ул, талантны, үз-үзеңне аямыйча эшләп, гомер-гомергә халыкка хезмәт иттерергә кирәк! дигән мәгънәдә аңлыйбыз. Нәби Дәүли шул вазифаны утәүгә бар дәрте белән, бөтен йөрәген биреп керешә.

Шагыйрьнең «Куптән язылган» (1936 ел) исемле бер шигырендә бик уңышлы яңгыраган символик мәгънә һич тә очраклы түгел. Анда Казан каласының «булачак бер иртәсе» күз алдына китерелә:

Менә шуннан китәр корабльләр
Ерак илгә Казан портыннан.
Диңгездәге маяк яктылыгы
Күренеп торыр минем йортымнан!

«Җирнең таянычы» булган Совет илендә («Архимедка хат») кешенең азат хезмәте Иделне диңгез итсенә дә, билгесез ташчының үзе күтәргән зур сарайлар нигезенә

мәңгегә керәсенә дә, «җиргә яңа яшьлек алып» ком чүленә сулар килүенә дә чиксез зур ышаныч белән карый шагыйрь һәм, илдәшләре белән бергә, «Мин горур кеше!» дип куана. Барыннан да бигрәк кешегә, үз замандашларына ышанычы зур аның. Чөнки кеше акылы — бөек нәрсә ул: «Йолдызларны капшый уе белән, үтеп чыга җирне аркылы».

Нәби Дәүли «үлек төсле күгәреп» гасырлар буе яткан ташка нәни чүкеч белән чокып җан өргән иҗатчыга гимн җырлый, «котыпка ишек ачып беренче булып кергән» Чкалов батырлыгын зурлый, яшьтәшләреннән бераүгә тормышта үзенә «Испаниянең батыр кызы» Ибаррурины юлдаш итәргә өндәп хат яза, әле бишектә яткан баланың «айга менеп бакча үстерәчәк» киләчәген күрә, туган кырларның яшел арышларына сыена һәм «шушы җирдә җырлап гомер итәм!» диган мактаулы миссияне белдерә.

Шулай башланып киткән иҗатта кешеләрне ярату, Ватан хисе һәм дошманга нәфрәт темасының әсәрдән әсәргә киңәя, тирәнәя, конкретлаша баруының тагын бер сәбәбе, дөресрәге, факторы бар. Анысы да шагыйрьнең үз биографиясенә бәйле.

Билгеле булганча, Нәби Дәүли безнең илебезгә 1941 елда немец-фашист илбасарлары һөҗүм итә башлауга, әйтерсең, үзенең яшьлек оптимизмын, җиңүгә тирән ышанычын да мотоцикл диган дырылдык арба «бишегенә» салып, фронтка китә. Ләкин Орша янындагы авыр сугышларда аның да язмышына шул елның авыр фаҗигасе тутык хәнҗәр булып кадала — фашистлар шагыйрьне әсир итәләр, аңа коллыкта һәм үлем лагерьларында 1945 елга кадәр коточкыч газаплы тормыш кичерергә туры килә.

Сугыш елларында тоткынлыкта интеккән, иҗат эшеннән бөтенләй читләштерелгән шагыйрьнең биографиясен яхшы белүче кайберәүләр аның турында, әйтик, менә болай да уйлый алырлар иде: сугыш хәтле сугыш, ул кичергән газап хәтле газап шагыйрьнең йөрәген дә туң итмәдеме икән! Ул инде, бәлки, тормышта матурлыкны күреп яки матур моңнар тыңлап ләззәтләнә алмыйдыр... Ул шигырь белән араны инде бөтенләй өзгәндер...

Алай уйлаучылар, һичшиксез, ялгышкан булырлар иде — чөнки Нәби Дәүли безнең арабызга: «Чыныктырды газап йөрәкләрне туган илгә тугыры булырга», дип җырлап кайтты. Чөнки шагыйрь күңеле үлемгә үч, дошманга нәфрәт, яшәүнең кадерен белү, илдәшләренең тиңдәшсез батырлыгы, кешеләргә тагын да көчлерәк ышана белү тәҗрибәсе белән ташып тулган. Аның бераз басынкыланган, ләкин кыюлык белән дөреслекне яклап сүз әйтер өчен элеккегә караганда күп тапкыр кырысрак, ачыграк һәм көррәк була алган поэтик тавышы бар.

Ул яза, өрөзлексез эзләнә, бертуктаусыз эшли башлый. Шигырь туса да яхшы, әмма баллада яки поэма — тагы да шәбрәк. Аяз тутырып җырлар өчен җыр да, кимчелекләрне камчылый торган сатира да бик кирәк. Ә балалар! Аларга бүләккә матур әкиятләр һәм кызыклы шигырьләр язасы иде. Аннары очерк, публицистика һәм хикәя язарга теләп куллар бик кычыта — чөнки алардан башка хәзерге тиз агымлы заманның чиксез зур үзгәрешләрен, катлаулы вакыйгаларын оператив рәвештә һәм тулы итеп чагылдыру мөмкин түгел. Төплерәк өйрәнеләсе һәм озаграк эшкәртеләсе материаллар исә булачак повесть, пьеса яки роман өчен туплана барсын...

Шагыйрь үзенең эш программасын шулай билгели, һәм аның язганнары көн саен да, ай саен да, ел саен да күренә торалар.

Иҗат принцибы да укучыга яхшы билгеле аның: поэзия — һичкайчан тынмый-туктамый дәвам иткән көрәш ул. Заман күренешләренә, кеше кичерешләренә шагыйрьнең ваемсыз карашы яки битараф булуы һич кичерелми!.. Бер минутка да истән чыгарылмаска тиешле шундый зур хакыйкать бар: дөньяда әле Азатлыкка атом коралы белән янаучы мәкерле фашизм яши. Совет шагыйре — шуңа каршы көрәшүче дөреслек лагере кешесе. Аның гражданлык хокукын да, поэтик йөзен дә барыннан да элек шул паспорт, шул прописка билгели.

Шуңа күрә дә, «язарга түгел, хәтта әйтергә авыр булса да», сугыштан соң шагыйрь Нәби Дәүли шул турыда ике зур проза әсәре язды: берсе — «Яшәү белән үлем арасында» исемле повесть, икенчесе — «Җимерелгән бастион» диган роман. Аларның һәркайсы татар һәм рус телләрендә зур тираж белән басылып чыкты. Фашизмның чын йөзен фаш иткән, Совет кешеләренең теләсә нинди сынаулар кичкәндә дә какшамас рухлы булып калуын раслаган ул әдәби документларны тетрәнмичә укырга мөмкин

түгел. Хәзерге һәм киләчәк яшь буыннарны сугышчан патриотизм рухында тәрбияләү эшендә андый китаплар чиксез зур роль уйный һәм уйнаячак.

Конкрет материал җирлегендә язылган һәм шактый уңышлы әдәби алымнар, иста кала торган образлар ярдәмендә яктыртылган бу теманы Нәби Дәүли поэзиядә үзенең «Өч тамчы су», «Коммунистлар турында», «Яр буенда шаулый нарат» исемле балладаларда, «Берлиндагы окоп» дигән поэмасында дәвам итә. Аларның һәркайсы төплəп-төпченеп анализланырга хаклы җитди әсәр.

Биредә, аларның поэтик сыйфатларын, эмоциональ борылышларын һәм шактый бай шигырь техникасын җентекләүдән бигрәк, авторның тормыш вакыйгаларына, кешеләргә заманча мөнәсәбәте нинди икәненә кыскача тукталып үтү урынлы булыр.

«Өч тамчы су» турындагы баллада, мәсәлән, «Сугышта бер тамчы су да солдатка гомер бирә» дип башлана. Кулына фляга тоткан командир яралы сугышчыларның берәвенә бер йотым су бирмәкче. Ләкин «әчмәде ул бер тамчы да, тик фляганы үпте». Чөнки аның канлы ярасы, әйтерсең, дуслык сүзеннән үзе төзәлде, чөнки бер тамчы суга сусаган бүтән яралылар бар... Флягага, нәкъ шул солдат кебек үк, бүтән яралылар да авыз тидермиләр һәм ул «хуҗага» кире әйләнеп кайта («кайда хәзер сезгә чират, әчегез, иптәш комбат»). Кайта... ләкин флягада өч кенә тамчы су булган икән...

Шушы өч тамчы суда, күргәнебезчә, дуслык, теләктәшлек, кыен чакта бер-береңә ярдәмләшү, җаныңны ярып бирергә әзер булу хисләре кояш булып чагыла!

Яки менә, «Кемнәр коммунист! Өч адым алга!» дип чакырып чыгарып, үлем лагерендә әсирләрне ату драмасы. Туры сорауга җавап бирмәгәч, фашистлар кабарынып-бүртенә, ярсып-җикеренә башлыйлар. Кемдер берәү «Барыбызны да коммунистлар дип язып куй, палач, безнең кабергә» дип әйтергә җыена. Ләкин нәкъ шул чакны арадан бер әсир өч адым алга атлый да кургашындай авыр сүзләрен дошманга төзәп ата: «Мин ул — коммунист, мине атыгыз!.. Көрәш сафында коммунистларга урын һәрвакыт — өч адым алда!» Моның белән үлемгә каршы һәрвакытта да коммунистларча алда торып көрәшә белергә кирәк дигән тирән фикер әйтелә.

«Яр буенда шаулый нарат». Ул да, сугыш дәһшәтен күргән тере шаһит буларак, шундый ук бер батыр турында «сөйләп тора шикелле». Елгада упкын төпсез, ә дулкыннар көчле, ди нарат, ләкин разведкага китәргә приказ алган совет солдаты, «җир сулышын тоеп» һәм «үлемнәр аша узып» (шул суны кичеп!), дошман оясына барып-бер барып керә, анда ике фашистны дөмектерә («ике үлек кабереңдә син ялгыз тора идең...»), безнекеләр һөҗүме өчен әһәмиятле мәгълүматны штабка рациядән хәбәр итәргә өлгереп һәлак була... Ул үзенең сугышчан дуслары, үз ватаны каршындагы изге бурычны үтәргә шулай ашкынды һәм аны шулай батырларча үти алды!

Нәби Дәүли балладаларында әнә шундый кырыс, романтик образлар ачыла, аларның әнә шундый тарихи һәм социаль җирлеге бар.

Героик фактны поэзиядә шулай күрсәтү өчен шагыйрьнең зур гомумиләштерүләр, баһадир образлар белән эш итүгә аеруча уңай, аеруча ятышлы булган баллада жанрын сайлавы, безнеңчә, бик табигый. Бу өлкәдә ул шактый күп эзләнүчеләрнең берсе булды һәм шулай булып кала да. Ә эзләнүнең, ачышлар ясауның, яңаны табуның сәнгать үсешендә төп закон икәне билгеле.

Ләкин эш жанрының уңышлы сайлануында гына түгел бит әле. Әгәр материал бармактан гына суырып алынган булса, әсәрнең геройларына җанлы тормышның үз таләбеннән чыгып конкрет иҗтимагый бурыч йөкләтелмәсә, нинди генә «шома» техника белән язылган, баш әйләндергеч сюжетлы баллада да чын әдәби иҗат булып танылмас иде. Иҗади уңыш теләсә нинди очракта да шагыйрьнең дөньяны художник буларак күрер өчен аны тыштан күзәтүе белән генә түгел, ә материалга мөнәсәбәтнең ни дәрәҗәдә ачык һәм максатка ничек юнәлтелгән булуы белән хәл ителә. Нәби Дәүлинең Әсгат Җиһаншиннар батырлыгына багышлап язган балладасы да («Диңгез һәм солдатлар») — моңа бик ачык мисал.

Шагыйрьнең «Берлинда окоп» дигән поэмасы — шулай ук балладага бик тартым әсәр. Ул фашизмга каршы аның үз оясында — Берлинда (шуңа күрә дә нинди көчле символика: «Берлиндагы окоп»!) торып көрәшкәндә һәлак булган Муса Җәлил һәм җәлилчеләргә поэтик һәйкәлләрнең берсе. Әйтергә кирәк, ул үзенең эшләнеше белән дә, образлар төзелеше ягыннан да шактый үзенчәлекле һәйкәл! Анда Гитлер Германиясе,

мәсәлән, менә ничек күз алдына китерелә: «Кошлар очмый хәтта ул якларга — куркп апар тоткын булудан... Байрагында аның кара елан — дүрт тарафка карый дүрт башы...» Совет патриотлары шул илнең нәкъ үзәгендә көрәшәләр, ә дошманга тезәп атар өчен исә «сүздән коеп корал ясарга» кирәк... Болар бар да, әлбәттә, балладә теле, балладә образлары!

Әсәрне чын мәгънәсендә художестволы иткән сыйфат — аның гражданлык пафосы. Күрәсең, «гражданлык» төшенчәсе әсәрнең укучы йөрәгенә тәэсир итә торган көче буларак та, художестволылыкның бер шарты итеп тә, ниһаять, шагыйрьнең халык тормышы белән бәйләнеше нинди икәнен раслый торган факторларның берсе дип тә аңлау дөрестер.

Һәр шагыйрьнең иҗатын нигездер бер төп сыйфат белән характерлый торган программ сүзләре бар һәм була.

Әйтик, Тукайның бөтен иҗатын берьюлы күз алдына һәр сулышта яңадан китерә торган «И туган тел, и матур тел»е бар. Муса Җәлил поэзиясенең байрагы булып «Мин җырымны илгә багышладым, гомеремне дә бирәм халкыма» дигән юллар күтәрелә. Фатих Кәримнең үлемсез җырлары безгә «Үлем турында уйлама, илең турында уйла» дигән лозунг буларак танылды. Һәркайсыныкы үзенчә һәм шул ук вакытта һәркайсы өчен уртак та. Нәби Дәүли иҗатының бәхетле үзенчәлеге, безнеңчә, барыннан да элек аның тематик юнәлеше белән билгеләнә. Аның программ сүзе түбәндәге юллардадыр дисәк, һич ялгыш булмас:

Сугышларда орден алмадым дип,
Кайгырасым булмас үкенеп:
Киләчәктә туар фашистларны
Мин бүген дә йөрим үтереп.
Шуңа күрә туган ил каршында
Солдат итеп саныйм үземне.
Киләчәктә туар көрәшчегә
Патрон итеп бирәм сүземне.

Үзенең шул тезисыннан чыгып, шагыйрь лирик геройларын һәм укучыларын тормышта мәгънәле итеп, файдалы: «эз калдырып» яшәргә өнди: «Дус-ишләрең, бәлки, онытырлар, дошманнарың оныта алмасын»... Нәни бала мәктәптә «икеле» билгесе алгач та юкка еламасын, чөнки әле алда тормыш дигән зур мәктәп бар — шунда «икеле» алучыларның хәле бик яман булачак. «Җирдә яшәү өчен, кулларыңда әгәр бетсә көчең, йөрәкне дә кирәк бирергә», дип йомгаклый шагыйрь. Аның кешеләргә мөрәҗәгате һәм таләбе шундый:

Дуслык өчен йөрәгеңне куй табынга,
Мин ашамый тук булырмын шул чагында.

...Яшәдеңме җирдә дусны табып,
Чын күңелдән сөя белдеңме?
Саф йөрәген аның үзеңә алып,
Йөрәгеңне аңа бирдеңме?

Теләсә нинди көчкә каршы тора алырлык, зур сынаулар кичәсе дуслык үзе дә зур, киң колачлы, җир шарының төрле почмакларында яшәгән бик күп кешеләрне берләштерә-бердәм итә торган дуслык булырга тиеш. Шагыйрь тынычлык өчен көрәшүчеләрнең бөтенесенең дә язмышын кайгыртып яши, шуларның барысы алдында үзенең шәхси җаваплылыгын тоеп иҗат итә, чөнки һаман болганып-тузгып торган бу дөньяда бүтәнчә булу һич мөмкин түгел:

Без үлемнән җирне сакламасак,
Сез, чәчәкләр, нәрсә әйтерсез?!

Йөрәкләрне бер-берсенә якын иткән, көчкә көч өстәгән шул дуслыкны яхлап һәм зурлап шагыйрь башкорт дусларына адресланган сүзен әйтә («Шушы җирнең бер бала-

сы итеп мин санарга телим үземне»), Корея кызын зур ышаныч белән юата («Уза алмас дошман синең йортка батыр дустың исән чагында»), Манолис Глезосны яклап судта сөйлисе шигырен яза («Акропольның биек гөмбәзендә дөнья күрер ирек байрагын!»), Хулиан Гримау турында җырлый («Туган халкыңа бирдең гомереңне, үзенә бәхет эзләмәдең син... Үлем каршында тезләнмәдең син»), Вьетнам солдаты белән сөйләшә («һәр башактан бирәр бөртек, һәр куактан бирәр алма — Вьетнам солдатына»).

Шуннан соң без аның изге дуслыкның явыз дошманнарына ачы нәфрәт яудырган әсәрләрен укыйбыз: Бонн генералларына хат («Бонн шәһәре — сезнең соңгы утрау, тирә-якта нәфрәт диңгезе»), президент Джонсонга адресланган сүз h. б.

Бер хулиган сындырып киткәч һәр яфрагыннан яшь тамызып елаган шомырт агачы язмышы да, Испания трагедиясе дә бер үк дәрәҗәдә борчый аны. Ул Бухенвальд капкасына язылган сүзләргә дә үзеннән нәрсәдер өстәргә тели... Шуңа күрә шагыйрь, аңа военкоматта отставка кәгазе тоттырылгач та, бәхет өчен җирдә көрәш бара, шул фронтта минем окоп бар дип, шул фронттан аңа беркайчан да отставка булмаячагы турында горурланып яза.

Солдат шагыйрь турында сүз барганда, бу урында хәрби бер җырның «Солдат — һәрвакыт солдат» сүзләрен «Шагыйрь — һәрвакыт шагыйрь» дип үзгәртәсе килә. Ә Нәби Дәүли иҗатындагы палитра һәм интонацияләр муллыгын, жанрлар һәм алымнар төрлелеген, бер ритмнан икенче ритмга бик оста күчүне күргәндә исә, ирексездән, поляк дустыбыз Януш Корчак сүзләре искә төшә: «Шагыйрь ул бик көчле куана, бик нык кайгыра, бик тиз ачулана, бик каты ярата, хисләрне бик тирән кичерә торган кеше». Бу зирәк сүзләр күп төрле материалга бәйле бай фикерне һәм зур хисләрне чын мәгънәсендә художестволы итеп сурәтләү өчен тирән эчтәлекле образлар муллыгы, күләмле һәм картиналы сүз байлыгы кирәк дигән законга ишарә.

Нәби Дәүли, әгәр кирәк икән, әгәр эчтәлек шуны таләп итсә, теге яки бу фактка яки предметка мөнәсәбәтле кыска фәлсәфи шигырьнең үзен тоташ бер образ итеп укучы күз алдына китереп бастыра ала.

Менә аның «Солдат турында» нибары дүрт юллы поэмасы:

Атакага барган чакта
Солдат егылды.
Йөрәге аның суынды,
Ә җир җылынды.

Яки менә башкарган эшенең бөтен зурлыгы, язмышның бөтен фаҗигасе белән күрсәтелгән Поль Робсон:

Әйтерсең лә, моңлы җыры белән
Тирбәтә ул балам бишеген.
Үз йортында аның полиция
Көне-төне саклый ишеген.

Мондый һәм шуларга охшаш бүтән миниатюралар («Игенче элифе», «Минем паролем» h. б.) шартлардай итеп тутырылган кислород мендәрен хәтерләтәләр. Аларда тормыш һавасы никадәр дә, яшәү көче никадәр!

Әмма шигырьдә образны үзмаксат итеп, экзотика өчен яки тышкы бизәк буларак кына файдалана башласаң, ул үзеннән-үзе үләр, кирәксез була башлар иде.

Нәби Дәүли үзенең иң зур күпчелек әсәрләрендә андый күз бәйләүле уеннар уйнап, кирәкмәгән фокуслар ясап мавыкмый. Аның зур тырышлык белән эзләп табылган яңа, оригиналь охшатулары, чагыштырулары һәм метафоралары, кычкырып тормыйча һәм еректан ялтырап күренергә һич тә теләмичә, шигырьне шигырь итү бурычын зур тыйнаклык белән үтиләр.

Мәсәлән, ялан аяклы бала чагында күрелгән кояшны ул, нәкъ балача самими иттереп, исте кала торган җанлы рәсем итеп сыза:

Кояш нурын тотып алам, диеп,
Түбәтәйгә тотып салам, диеп,
Тауга менеп күккә үрелдем.

Ә шаулап торган завод цехында аңа бөтенләй бүтән кояш күренә:

Кызган тимер чаткы ата,
Йөзгә кучә яктысы —
Әйтерсең, монда кояшның
Төшеп калган яртысы.

Иртә таңдагы кояшның да шундый күркәм сыйфаты бар:

Әнә офыкта учак яктылар,
Алтын казанны күккә астылар.

Шул ук «алтын канатлы» кояшка бер спекулянтны каратып исә шагыйрь гаять уңышлы сатирик образ иҗат итә:

Ул кояшны бикләп тотар иде
Кыш көнендә ваклап сатарга.

Чынлап торып эзләсәң, әдәбиятта күптәннән инде мәңгелек саналган теманы үзенчәлекле итеп яңача чагылдыру өчен дә һич көтелмәгән яңа чаралар табып була икән! Нәби Дәүлинең лирик герое яраткан кешесеннән «сөям» дигән сүз ишетер өчен әллә ниләр эшләргә әзер: болыннардан чәчәк җыеп келәм тукыр идем («хисләремне шуннан укыр идең!»), ташка чокып сырлар идем уемны («әгәр шуңар кулың тисә, сизәр идең җылымны!»), куяр идем кылыч корычтан («бусагаңны узмас иде бер дошман!»), сабакларын алтын кылга охшатып арыш үстерер идем («син кагылгач, шул алтын кыл әйтер иде минем теләкне!»). «Баскычлы» бу образның басмасыннан басмасына күтәрелгән саен саф мәхәббәт күрке ачыграк булып күренә, йөрәкләр тугрылыгына соклануың арта бара.

Беренче бала туу шатлыгын Нәби Дәүли түбәсе күкләргә тигән гиперболик образ ярдәмендә конкретлаштыра:

Туктармын һәрбер йортка,
Керермен парламентка.
Әйтермен: ил зурайды,
Җир тагын матурайды!
Нигә болай, дисеңме,
Парламентта сүз аламә
Әллә син күрмисеңме,
Җирдә бар минем балам!

Туган табигать турында язганда, тирә-якларыбызның яңартылган пейзажын сүз буяулары белән сызган чакта без аны берьюлы шагыйрь дә, рәссам итеп тә күрәбез:

...Карлыгач төннәр буена
Йокламый япты,
Оясына түбә итеп
Канатын япты.

...Яфрак ярган инде имәннәр
Гаскәр кебек озын сафларда.
Яшел калкан алар кигәннәр
Игеннәрнең гомерен сакларга...

Нәби Дәүли шигырь өчен сүзләрне дә, аларның шулай ук чын, дөрес, көчле музыкаль яңгырашлы булуын теләп, бик тырышып сайлый. Гомумән культура коралы да, ә аерым алганда кешеләрне ярату өчен дә корал булган сүз, аныңча, «иң кыйммәтле хәзинә», чынлап сөйли белүдән хәтта атом табу да ансатрак, ә яхшы, гадел һәм дөрес сүз кешегә «икмәк, күмер һәм тимер» кебек үк кирәк.

Сугыштан яраланып кайткан Хәсән ага, мәсәлән, шактый өлкәнәйгән һәм ярыйсы ук таушалган инде. Моны ул үзе дә сизә, күңеленнән «кайберәүләр а г а ч а я к белән

дөбердәтеп эшләп йөриләр, минекеләр хәтта таяк белән кузгалырга ирек бирмиләр» дип әрнүле сызлана да. Авылдашлары аңа хәтта сәлам селкетергә кушмыйлар. Ә ул һаман үзенең бер сүзен кабатлый: уч төпләрем кычыта!.. Ягъни аңа нинди дә булса эш бирсеннәр иде, чөнки ул һич кенә дә тик тора алмый... Бирәдәге агач аяк, дөбердәтеп, минекеләр, кузгалырга, сәлам селкетергә, уч төпләрем кычыта кебек сүзләрне бер үк юлы, әйтерсең, күрәсең дә, сизәсең дә, ишетәсең дә. Аларның бүтән синонимнарын бу очракта эзләп торулар да кирәкми, чөнки алар шигырьдә һәм җөмләдә, Толстой әйтмешли, үзләренә тиешле бердәнбер урынга куелган бердәнбер сүзләр.

«Мәхәббәт ул чибәр егетләрне бәйләп куя капка төбенә» дигән юллардагы «бәйләп куя» сүзе дә шигырьгә тирән мәгънә биреп, аңа (бәйләп куйгандай!) чат ябышып тора. Димәк, шагыйребез үзенең һәр сүзен уйлаганда, һәр юлын язганда Тукайның «шагыйрьдән сүз чыгар хикмәт белән» дигән таләбен яхшы ишетә икән!

Нәби Дәүли халык арасында күп йөри, китап укучылар һәм әдәбият сөючеләр белән еш очраша, язучыларның иҗат бәйрәмнәрендә актив катнаша. Аның берәр культура сараена яки авыл клубына, хәрбиләр янына яки мәктәпкә, китапханәгә яки эшчеләр торагына чакырылмый калган көне бик сирәк диярлек. Өстәвенә тагын ерак якларга да юл тотарга, читкә дә чыккаларга кирәк.

Азга гына булса да каләмне калдырып, язу өстәленнән аерылып торулары кыен, бик кыен, әлбәттә. Ләкин шагыйрьнең тынгысыз йөрәге әдәбиятны пропагандалау эшеннән читтә кала аламы соң! Агитатор булу, укучы белән даими сөйләшү ул шулай ук әдәби иҗатның бер өлеше бит!

Аның каравы, теге яки бу сәфәрдән, укучы белән теләсә нинди очрашудан ничектер яңарып, хисләргә һәм темаларга баеп, сугышчанрак рухлы булып, тагын да бирелебрәк эшләргә ашкынып кайта ул. Чөнки әлеге тынгысыз йөрәк чакматаш булып кагыла да аны тыңлаган бүтән бик күп йөрәкләрдә гражданлык, патриотлык хисе һәм илһам очкыннары кабына.

Шигырьләренең берсендә Нәби Дәүли болай дип яза: «Алып чыкты яшьлек уттан-судан җилкәсендә мине күтәреп». Без моны алда әле озак дәвам итәргә тиешле, җилкәсендә шагыйрьне бик озак тотасы иҗат яшьлегенә карата да әйтелгән сүзләр дип белик.

Икенче бер шигырьдә исә аның әдипләргә каратылган эндәш сүзе бар:

Кемдер йөри караңгы төндә —
Онытма, дустым.
Синең йортның тәрәз төбендә
Ут янып торсын!

Безнеңчә, моны да шагыйрьнең үзенә кире адресларга һәм аңардан кешеләрнең күкелен һәм юлларын яктыртасы утны үз поэтик йортының тәрәз төбендә һәрвакыт яндырып торуын зур ышаныч белән көтәргә, таләп итәргә кирәк.

≈≈≈≈≈≈



**Зәки Әхмәтҗанов**

# АЛТЫН ЙОЛДЫЗЛЫ ЛАЧЫН

ОЧЕРК

«1944 ел, 10 октябрь.

15 нче һава гаскәрләре армиясе командующиеның бик мөһим заданиесен үтәргә очты. Латвиянең Добеле-Луце районында сакчы истребительләрдән башка очып, дошман зенит артиллериясенең көчле уты астында 2 мең метр биеклектән немецлар оборонасының алгы сызыгын фоторәсемгә төшерде. Дүртенче тапкыр әйләнеп чыкканда, Гатауллин самолетына снаряд эләкте. Безнең алгы сызыктагы сугышчылар «Петляков-2» самолетының немецларның артиллерия һәм миномет позицияләренә төшеп шартлавын күреп тордылар. Гвардия өлкән лейтенанты Гатауллин һәм аның экипажы геройларча һәлак булды.

Гатауллин гомеренең соңгы минутында да, дошманның техникасына һәм тере көчләренә зур зыян китереп, Ватан алдындагы бурычын ахырына кадәр үтәде.

Немец-фашист басып алучыларына каршы көрәштә зур хезмәтләре һәм командованиенең махсус заданиеләрен үтәүдә күрсәткән куркусызлыгы, батырлыгы һәм тапкырлыгы өчен хөкүмәтнең иң югары бүләге — Советлар Союзы Герое исеменә лаеклы.

99 нчы гвардияче аерым авиация разведкасы полкы командиры — гвардия подполковнигы Н. Щенников.

15 нче һава көчләре армиясе командующие, авиация генерал-полковнигы Науменко.

Икенче Балтик буе фронты командующие, Советлар Союзы маршалы Говоров.

Икенче Балтик буе фронтының Хәрби Совет члены генерал-лейтенант Богаткин».

**«СССР Верховный Советы Президиумының 1945 ел, 18 август указы белән Советлар Союзы Герое исеме бирелгән».**

**«Өлкән лейтенант Әнвәр Гатауллин, сугышчан бурыч үтәргә очудан әйләнеп кайтмады».**

**«...Гвардия өлкән лейтенанты Әнвәр Гатауллинны мәңгегә ул хезмәт иткән полкның исемлегенә кертергә».**

Шундый батырлык эшләгән геройның исеме әлегә кадәр безгә билгеле булмавы чын-чынлап гаҗәпләнерлек иде. Исемен мәңгегә үлемсез иткән очучы турында, һичшиксез, сөйләргә, язарга кирәк дигән уйлар белән шул полкның документларын актара башладым.

Бәлки аның кайда күмелүе дә билгеледер дип, полкның һәлак булган сугышчыларын теркәп бара торган махсус журналны карарга керештем.

Бу журналның 13 битендәге юлларны укыгач, нәрсә уйларга да белмичә, аптырап калдым. Чыннан да ул юлларны укып карасаң, һәр кеше гаҗәпләнер иде.

Менә ул биттәге язманың тулы күчермәсе:

**«Звено командиры, гвардия өлкән лейтенанты Әнвәр Җиһангир улы Гатауллин сугышчан очыштан частька әйләнеп кайтмады. (1923 елда Пермь шәһәрендә туган. Гамщинская урамы, 4 йорт. Әнисе Гатауллина Тайфә, Максим Горький урамы, 22 йортта яши)».**

Бусы гаҗәп түгел. Бу сүзләрне мин инде шактый очраттым. Ә сугышчының кай җирдә күмелүен теркәп бара торган графадагы өч сүз гаҗәпләнерлек тә, уйланырлык та, шатланырлык та иде. Әйе, бары өч сүз. Күпме вакытлар үткәчтер, бөтенләй башка төсле кара һәм икенче төрле почерк белән язылган өч сүз: **«Частька әйләнеп кайтты».**

Дөрес, сугыш вакытында төрле көтелмәгән хәлләр килеп чыккалый. Һәлак булды дип саналган кешеләр дә исән булып чыга. «Фәлән урында җирләнде» дигән кәгазьләр килгән сугышчыларның да туган якларына исән-имин кайтып килү очраклары да булгалый. Ә бу — Гатауллин язмышы андый очраклы хәлләрдән аерылып тора. Аның үз полкына әйләнеп кайтуына ышануы да кыен. Чөнки очучының, Николай Гастелло кебек үк, ялкын чолгап алган самолетын соңгы минутта дошман техникасы өстенә юнәлтүен, машинаның анда төшкәч тә ут баганасы күтәреп шартлавын үз күзләре белән күргән шаһитлар да бар бит. Бүләкләү кәгазендә Гатауллинга Советлар Союзы Герое исеме үлгәннән соң бирелүе турында язылган. Ниһаять, аның исеме мәңгегә полк исемлегенә дә кертелгән. Бу өч сүз мине шулкадәр кызыксындырды, архивта башка эшләремне ташлап, шушы лачынның язмышын ачыклау белән шөгыльләнә башладым.

Иртәгесен үк архивтан Мәскәүгә, Оборона министрлыгының Кадрлар баш идарәсенә юл тоттым.

— Әйе, гвардия өлкән лейтенанты Әнвәр Гатауллин исән,— дип җавап бирде олы яшьләрдәге, чал чәчле полковник һәм геройның хәзерге адресы язылган картотека бланкысын тоттырды.— Мондый кешеләр турында күптән язарга кирәк иде,— дип өстәде аннары.— Татар егетләре ничек сугышканны яхшы беләбез без. Арсланнар алар. Әнә никадәр геройларыгыз бар,— полковник илебезгә татар халкы биргән геройларның шәхси карточкалары тезелгән бер тартмага күрсәтте.

Дөрес сүзгә җавап юк, диләр. Полковникның хак сүзләренә мин берничек тә җавап кайтара алмадым.

Казанга кайту белән, беренче эш итеп, дистәләгән сорауларга җавап бирүен үтенеп, геройның үзенә хат җибәрдем. Ул бик тыйнак һәм

тәгәл кеше булып чыкты. Җавап хатларын озак көттермәде. Менә хәзер «һәлак булган» очучының язмышы күз алдыма шактый тулы булып басты.

* * *

Әнвәр мәктәптә укыган елларда Чкалов, Байдуков, Беляков, Громов, Водопьянов кебек очучыларның моңа кадәр тиңдәше булмаган очышлар башкаруы бөтен дөньяны шаулатты. Әлегә кадәр кем булачагы турында уйлап та карамаган Әнвәр, бу лачыннар батырлыгы турында укыгач, очучы булам дигән ныклы карарга килде. Валентина Гризодубова, Полина Осипенко һәм Марина Расковаларның «Родина» самолетында, җиргә төшмичә, Ерак Көнчыгышка очып рекорд куюлары аның бу карарын тагын да ныгытты.

1938 елда, Пермьдә тулы булмаган татар урта мәктәбен тәмамлагач, ул авиация техникумына керде. Икенче курста укыганда, аэроклубка йөри башлады. Анда тулы курс үтеп, пилот исемен алды.

1940 ел башында 17 яшьлек пилот, комсомол путевкасы белән, Пермьдәге хәрби очучылар мәктәбенә кабул ителде һәм аны, бик яхшы билгеләренә тәмамлап, 1941 елның декабренә кадәр Новосибирск хәрби очучылар авиация мәктәбендә үз һөнәренең нечкәлекләрен үзләштерде.

1942 ел. Брянск фронты. Хәрәкәттәге армия. Сержант Әнвәр Гатауллин 15 нче һава армиясе составына кергән запастагы полкта «Петляков-2» бомбардировщигын сугыш шартларында куллану буенча күнегүләр алып бара, үзенең самолет белән идарә итү осталыгын арттыру өстендә эшли. Ләкин аның күңеле фронтка, сугышчан очышларга ашкына. Ул берничә тапкыр, үзен алгы сызыкка җибәрүне сорап, командованиегә мөрәҗәгать итә.

Ниһаять, 1943 елның май аенда сержант Гатауллин 15 нче һава армиясенең 99 нчы аерым разведка полкына китә. Шул полкта аның данлы сугыш юлы башлана.

Яшь очучы бу полк составында Орел — Курск дугасында булган барлык сугыш операцияләренә катнаша. Бу сугышларда Гатауллин үзен һәр куелган бурычны җиренә җиткереп башкаручы, курку белмәс оста очучы итеп таныта. Курск дугасында 50 көн дәвам иткән һөҗүм сугышлары вакытында күрсәткән батырлыклары өчен полкка гвардия исеме бирелә. Әнвәр Гатауллин исә һәр заданиене җиренә җиткереп үтәгәне өчен хөкүмәтебезнең беренче зур бүләге — Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

Орел һәм Курск районында немец-фашист гаскәрләрен тар-мар иткәч, очучы-разведчиклар полкы Икенче Балтик буе фронтына күчә. Бу фронтта очучы-разведчикларга эш бермә-бер арта. Дошман оборонасын күзәтү һәм фоторәсемнәргә төшерү өчен көненә өчәр, дүртәр очыш ясарга туры килә. Разведкадан буш вакытларда очучылар турыдан-туры немецларның алгы сызыгын утка тоталар, аларның тылдагы коммуникацияләренә бомбалар яудыралар.

* * *

...Сугышка кадәр дәүләт куркынычсызлыгы органнарында эшләгән кешеләрдән — чекистлардан оештырылган Денис Давыдов исемендәге партизаннар отрядын алар хәрәкәт иткән районнарда дәһшәтле өрәкләр дип атыйлар иде. Чыннан да, алар немецлар һич көтмәгәндә тын гына килеп чыгалар да тиз генә үз эшләрен эшләп эзсез югалалар. Тәҗрибәле чекист Александр Владимирович Назаров командалыгын-

дагы бу бригада фашистлар тылында бик кыю хәрәкәт итте. Алар үткән урыннарда күперләр, складлар, комендатуралар шартлап күккә оча, тимер юл эшелоннары яр астына мәтәлә, халыкның теңкәсенә тигән немец офицерлары, сатлык җан полицайлар тәмуг кисәвенә әверелә.

1943 елның декабрь башларында немецларның Псков шәһәрендәге коменданты фронттан яңа көчләр чакырта һәм Денис Давыдов исемендәге бригаданы юк итәргә приказ бирә. Бригаданың командирын тотып кайтучыга яки, һич югында, аны үтерүчегә зур сумма акча һәм утар вәгъдә итә.

1943 елның 9 декабрь көнне, Псков өлкәсенең Борисенки һәм Козельцы авыллары янында фашистларның «СС» солдатларыннан торган махсус җәза отряды белән Денис Давыдов исемендәге бригада партизаннары арасында каты бәрелешләр башланды. Фашистлар, артиллерия һәм танклар кулланып, сугышның беренче сәгатьләрендә үк Борисенки авылыннан партизаннарны чигенергә мәҗбүр иттеләр. Партизаннар, Козельцы хуторының көнбатыш ягына чигенеп, ачык кырда, кышкы салкын җиргә сыендылар. Сугыш кызганнан-кыза барды. Чекистларның хәле кыенлашты. Патроннары бетеп бара иде. Ярдәм көтәр урын да юк.

Нәкъ шул вакытта күктә көнчыгыш яктан кызыл йолдызлы самолет-бомбардировщик пәйда булды һәм дошман өстенә «пике»гә ташланды. Һәр йорты гитлерчылар белән тулган авыл өстенә бомбалар яуды. Берничә җирдә ялкын телләре күтәрелде. Партизаннар, тын да алмыйча, самолетның һәр хәрәкәтен күзәттеләр. Менә ул алар өстенә килеп җитте. Шул вакытта җирдән сигнал ракеталары очты. Соңгы ракета сүнгәч үк, ике йөк парашюты белән ташланган тыгызлап тутырылган каплар җиргә кунды. «Олы җир»нең бу күчтәнәче партизаннар өчен дөньядагы бар нәрсәдән дә кадерле иде.

Очучы үзенә тапшырылган эшне бик оста башкарды. Ләкин ул китәргә ашыкмады. Партизаннар өстендә аларны сәламләгәндәй канатларын кагып әйләнде дә, моторларын бөтен көченә үкертеп, күккә таба вертикаль курс алды. Берничә минуттан борыны белән яңадан аска ыргылды һәм, барлык пулеметларыннан ут ачып, фашистлар өстенә ташланды.

Кызыл йолдызлы машина моның белән генә чикләнмәде. Ул тагын дүрт тапкыр өскә күтәрелде һәм лачын кебек аска омтылып, фашистлар өстенә ут сиптерде. Нәтиҗәдә немецларның авыл кырыендагы берничә ут ноктасы атудан туктады. Авылда паника күтәрелде. Югалып калган гитлерчылар авыл эчендә әрле-бирле йөгерешергә керештеләр. Алар үзләрен кулга алып ут ачканда, самолет инде болытлар арасына кереп бара иде.


— Молодец, лачын, тагын кил,— дип, партизаннар аны бүрекләр болгап озатып калдылар.

— Аның очучысы кем икән, шуны беләсе иде,— дип куйды чекистларның берсе.

Бу бәрелештә бомбардировщик катнашуын немецлар да, партизаннар үзләре дә көтмәгәннәр иде. Кораллары һәм саннары ягыннан күп тапкырлар өстен булган башкисәрләр, сугыш кырында һәм урамнарда күп мәетләр калдырып, авылны ташлап китәргә мәҗбүр булдылар. Тездән карга батып, тәртипсез төстә йөгерүче гитлерчыларның күбесен партизан пулялары куып җитте.

Чекистлар контратакага күтәрелеп, аларның эзеннән үк куып киттеләр.

Атышлар туктагач, бригада командиры Александр Владимирович Назаровка офицер блокнотыннан ертып алынган бер бит кәгазь китереп бирделәр.


Здравствуйте братья партизаны!!! ....
Шлем вам наш гвардейский пламенный привет!!!
Мы, экипаж в количестве трех человек
Гатауллин, Устинов, Клименков, сбрасываем вам подарки с большой свободной земли народным мстителям русской земли.
Ждите еще придем Скоро.
Экипаж.
1 ком-р л-нт Гатауллин
2 гв. л-т Устинов
3 ст. с-нт Клименков

— Самолет ташлаган посылка эченнән чыкты, иптәш комбриг, — диде алып килүче чекист, укый-укый.

Бригада командиры ул кәгазьне игътибар белән укып чыкты.

— Кайсыгыз очучының кем булуын белергә теләгән иде,— диде ул, үз тирәсенә җыелган партизаннарга карап.— Менә тыңлагыз:

**«Исәнмесез, партизан туганнар!**

**Сезгә ялкынлы гвардия сәламе җибәрәбез. Без, өч кешедән торган экипаж — Гатауллин, Устинов, Клименков, сезгә, рус җиренең үч алучыларына, олы җирдән бүләкләр ташлыйбыз. Көтегез, без тиздән килербез».**

Язу астында экипаж члennары үз куллары белән имзаларын куйган бу кәгазь шунда ук кулдан-кулга китте. Аны һәркемнең тотып карыйсы, укып карыйсы килде. Бөек Ватан сугышы тарихында әле беренче тапкыр партизаннарның очучылар белән бергәләп үткәргән бу операциясеннән соң икенче көнне бригада штабына разведчиклардан донесениеләр килә башлады. Аларда 9 декабрь көнне, күп авыллар өстеннән, мөмкин кадәр түбәнгә төшеп, кызыл йолдызлы бомбардировщикның көнчыгышка очып үтүе турында язылган иде. Кайбер авыллар өстендә самолетның канатларын кагып әйләнеп йөрүе, листовкалар ташлавы, йөзләрчә кешеләрнең урамнарга чыгып, аны кул болгап озатулары турында да хәбәр иттеләр. Берничә көннән шул ук самолет тагын партизаннар лагерена килеп чыкты. Парашют куполлары яңадан кышкы салкын һава белән тулды. Күрсәтелгән урынга тагын сугыш кирәк-яраклары тутырылган зур-зур каплар төште. Чекистлар бу самолетны «безнең бомбардировщик» дип йөртә башладылар. Чыннан да, ул үзенең эшен нәкъ партизаннарча башкара иде. Бер дә көтмәгән яктан, астан гына килеп чыга да, сигналлар күрсәткән җиргә йөкләрен ташлап, немецлар тулган авыллар өстенә юнәлә. Югалып калган фашистлар өстенә ут сиптереп үтә дә, югарыга менеп, көнчыгышка китеп югала.

Моннан 25 ел элек гвардия лейтенанты Әнвәр Гатауллин экипажы партизаннарга ташлаган язуны Денис Давыдов исемендәге бригаданың командиры полковник Александр Владимирович Назаров әле дә үзендә саклый. Хәзер ул Ульяновск шәһәрендә яши һәм өлкә дәүләт куркынычсызлыгы идарәсенең начальнигы булып эшли. Тәҗрибәле чекист, сугышчан кыю командир үз эшен дәвам итә.

* * *

**«1943 елның 10 июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында катнашып, үзен кыю, тәвәккәл, көчле ихтыярлы очучы буларак күрсәтте. Үзенә буйсынган очучыларның һәм техник**

составның оста, белемле командиры итеп танытты. Олы тәҗрибәле һава разведчигы буларак, бу эшкә башка звеноларны һәм эскадрильяларны да өйрәтүгә күп көч куйды. Аның экипажы полкта беренче булып, «Петляков-2» самолетында, һава разведкасы вакытында еракган фоторәсемгә төшереп алу ысулын үзләштерде...»

(Геройның бүләкләү кәгазеннән)

Самолетның материаль частен яхшы белү һәм машинаны идарә итү техникасын отличнога үзләштерү яшь пилотка инде ышанычсыз дип саналган очракларда да җиңеп чыгарга ярдәм итә.

1944 елның 8 январь көнне дошман оборонасының Новосокольники — Идрица тимер юлының көньягындагы алгы кырыен рәсемгә төшергәндә, Гатауллин машинасы көчле зенит утына эләгә. Самолет тирәсендә шартлаган снаряд кыйпылчыклары фюзеляжны, канатларны күп җирләрдән тишкәләп бетерә. Штурман һәлак була. Шундый куркыныч һәм катлаулы хәлдә дә Әнвәр куелган бурычны тәгәл башкара. Фронт сызыгыннан 120 километр араны штурмансыз очып, бору җайланмалары ватылу аркасында көчкә идарә ителә торган машинасын үз аэродромына алып кайта.

Гвардия лейтенанты Әнвәр Гатауллинның сугышчан очышлар вакытында күрсәткән тапкырлык һәм батырлык эпизодлары мисалларын күп китерергә була. Шул ук елның 1 июлендә Касьяны — Жидейки — Подборово — Тукусново районы чикләрендә махсус задание үтәргә килгәч, фашистлар самолетны үзләре оборона сызыгына кертмәс өчен пушкалардан һәм дистәләрчә эре калибрлы пулеметлардан көчле ут ачалар. Шартлау дулкыны машинаны әле бер, әле икенче якка алып ташлый. Әнвәр төрлечә хәйләле маневрлар ясап, куркыныч зонадан чыга да, пулеметлардан ут сиптереп, фашистларның алгы сызыгы буйлап үтә. Бу вакытта фотоаппаратлар үз эшен эшлиләр. Һәр минутта бәреп төшерелү куркынычы астында очса да, Әнвәр, куелган бурычны үтәп, үз базасына кайта. Техниклар самолет корпусында ике дистәгә якын тишек санайлар. Төшерелгән пленкаларны эшкәрткәч, дошман оборонасының алгы кырые тирәсендә хәрби йөк төялгән 175 автомашина, 150 ат олавы, 18 танк, 4 кечү корылмасы, 75 артиллерия батареясы, 50 урында аерым торучы орудие, 70 данә танкка каршы ату орудиесе, 63 миномет батареясы, 80 аерым миномет, 86 җирдә ПТР, 125 дзот, 890 блиндаж һәм 1725 урында пулемет оясы барлыгы беленә. Фронтның кечкенә генә участогында шул кадәр көчне дошман тикмәгә генә тупламаган, билгеле.

Берничә сәгатьтән немецлар оборонасының бөтен мәйданы өстендә безнең штурмовиклар әйләнә башлый. Аста күп урыннарда ут баганалары күтәрелә. Алгы сызыктагы траншеялар һәм окоплар төтенгә күмелә.

1 август көнне Гатауллин экипажы зенит орудиеләренең шашкын уты астында, Мадона — Луксте, Цецава — Рига, Круспиле — Рембатене тоташтыручы шоссе һәм грунт юллардагы хәрәкәтне күзәтә. Рига, Орге, Скриверт һ. б. күп кенә тимер юл станцияләрендә торучы эшелоннарны пленкага төшереп, бик кыйммәтле мәгълүматлар алып кайта.

Калганын төнге бомбардировщиклар эшли. Гитлерчылар кулындагы юллар һәм станцияләр озак вакытка сафтан чыга. Станцияләрдә торучы эшелоннардагы сугыш техникасыннан янып кәкрәйгән металл өемнәре генә өелеп кала. 7 сентябрь көнендәге күзәтү очышында Әнвәр экипажы чын онытылмас истәлек калдыра. Аларга ул көнне Понури — Аватыни — Бренцапи районы чикләрендә немецларның алгы оборона сызыгын күзәтү һәм пленкага төшерү бурычы йөкләнә. Гитлерчылар сакчысыз самолетны көчле зенит уты белән каршылыйлар. Командир, төрле

катлаулы виражлар ясап, бу куркыныч зонадан чыга һәм яңадан әйләнеп керер өчен югарырак күтәрелә. Ләкин монда, болытлар өстендә, аның каршына ике «мессершмит-109» килеп чыга. Билгеле, авыр бомбардировщик зур тизлек белән очучы ике истребительгә каршы тора алмый. Шулай да Әнвәр югалып калмый, пулеметлардан көчле ут ачып, аларны үзенә якын җибәрми. «Җиңел табыш» дип, бик кыю атакага ташланган фашист очучылары, яңадан һөҗүм итәр өчен, самолетларының борынын өскә чөяләр. Өлкән лейтенант, шуннан файдаланып, аска, болытлар арасына ташлана. Ләкин, аннан чыгу белән, машина тирәсендә тагын снарядлар ярыла башлый. Куелган бурычны һәрвакыт төгәл үтәргә күнеккән очучының бу хәл бик ачуын китерә. Шунда ул куркыныч һәм кыю карарга килә. Башта машинасын вертикаль буенча өскә алып менә, аннары өзлексез атып торучы зенит батареясы өстенә «пике»гә ташлана. Җиргә якын ук төшкәч, горизонталь очышка күчә һәм пулеметлардан ут сиптереп, алгы сызыкның бөтен буена очып үтә. Самолет бу юлы да дистәләрчә тишек алып кайта. Шулай да куелган йөкләмә җиренә җиткерелеп үтәлә.

Фотография материаллары немецларның бу участокта 20 артиллерия батареясы, 5 миномет батареясы, 10 танкка каршы атучы пушка, 8 пулемет оясы, 45 автомашина, 4 корал складлары һәм башка күп кенә мөһим объектлар барлыгын раслый.

15 сентябрьдә дә гвардияче разведчик, үз алдында бары бер километр күз күреме мөмкин булган томанлы һава ерып дошман позицияләре өстенә 600 метрга кадәр төшә һәм бик кыйммәтле разведка мәгълүматлары алып кайта. Кыю очучы, куркусыз разведчик, гвардия өлкән лейтенанты Әнвәр Гатауллинның сугышта күрсәткән мондый хезмәтләренә, тапкырлыгына командование югары бәя бирде. 1944 елның көзендә инде аның күкрәгеен ике Сугышчан Кызыл Байрак, Александр Невский һәм Беренче Дәрәҗә Ватан сугышы орденнары бизи. Аңа күп тапкырлар Верховный Баш командующий үзенең рәхмәтен белдерә. Полкның гвардия байрагы янында фоторәсемгә төшерелә.

* * *

1944 ел, 10 октябрь.

Ул көнге кебек көзге болытлы көннәрдә истребительләргә дә, штурмовикларга да эш әллә ни күп булмый. Очучылар һава яхшырганны көтеп, аэродромдагы блиндажларда домино сугалар, шахмат уйныйлар. Туган якларына хатлар язалар. Кыскасы, һәркем үз эше белән мәшгуль. Ә очучы разведчиклар өчен алай түгел. Алар, һава шартларының нинди булуына карамастан, күзәтү очышларын дәвам итәләр. Һава «яктыргач» күккә күтәреләсе штурмовиклар, бомбардировщиклар өчен объект эзлиләр алар. Гатауллин экипажы ул көнне дә, бик астан гына очып, яхшы гына мәгълүматлар алып кайтты. Машинасын куйды да, полкка яңа килгән яшь очучылар белән тренировка үткәрү өчен, стартта торучы самолетлар янына атлады. Яшьләр аны күп төрле сораулар белән каршыладылар. Һәркайсының үзен кызыксындырган сорауга тәҗрибәле очучыдан җавап аласы килә иде. Ләкин Әнвәргә алар белән озаклап сөйләшергә туры килмәде. Старттагы телефон янында утыручы солдатның: «Өлкән лейтенант Гатауллин, полк штабына!» — дигән тавышы ишетелде.

Полк командирының приказы кыска һәм катгый:

— Текари — Чаймиш чикләрендә һәм Чулбыш поселогының көнбатыш өлешендәге оборона сызыгын пленкага төшереп алырга,— диде подполковник Щенников.— Яхшы карагыз, истребительләр озата бармый.

Бернничә минуттан «Пешка» («Петляков-2» самолетын фронтта шулай дип йөртәләр), күккә күтәрелеп, кирәкле курс алды. Штурвал

артында — күзләрен алга текәгән корабльның командиры Әнвәр Гатауллин, азрак артта Павел Хрусталев утыра. Ул әледән-әле картага һәм навигация приборларына карап ала. Артка, самолетның койрык өлешенә, укчы-радист Дмитрий Никулин урнашкан. Ул һаваны күзәтә һәм жир белән элемтә тота. Өч гвардияче, өч өлкән лейтенант, өч коммунисттан торган, күп сугышларда сыналган, чыныккан, чын дуслык белән береккән бу экипажны полкның өлкән очучылары да, яшьләре дә хөрмәт итеп, «дуслар экипажы» дип йөриләр иде. Әйе, алар бик күп сугышчан очышларны бергә башкардылар. Күп тапкырлар бергәләп үлем белән көрәштеләр һәм жиңүче булып чыктылар. Ничә тапкыр тишкәләнеп беткән ярым жимерек самолетта үз аэродромнарына әйләнеп кайттылар. Ләкин бер вакытта да куелган бурычны үтәмичә калмадылар.

Бу көнгә кадәр 108 сугышчан очыш ясаган гвардия өлкән лейтенанты Гатауллинның очышлар исәбен теркәү журналын карасаң, анда түбәндәге мәгълүматлар бар:

Өч тапкыр дошманның ерак тылдагы коммуникацияләрен бомбага тоткан; кырык өч тапкыр немецлар оборонасының алгы сызыгын фоторәсемгә төшерергә очкан; алтмыш дүрт тапкыр дошманның тылдагы көчләренә, алгы сызыктагы оборона корылмаларына күзәтү үткәргән; сигез тапкыр, турыдан-туры һава армиясе командующие заданиесе буенча, фашистларның оборона сызыгын 300—400 метр биеклектән пленкага төшереп алган.

Гатауллин экипажының бу мәгълүматлары Икенче Балтик буе гаскәрләренә зур ярдәм күрсәтә: фашистларның бик күп корылмалары һәм техникасы, һөжүм башланганчы ук, безнең штурмовиклар, бомбардировщиклар тарафыннан юк ителә.

Өлкән лейтенант Гатауллин үзе башкарган очышлар вакытында гитлерчыларның оборона сызыгына һәм төрле сугыш техникасы өстенә 9200 килограмм бомба ташлаган. Дошманның ерак тылында һәм алгы кырыйдагы позицияләренә 3 миллион данә листовка тараткан, зениткалар утыннан һәм истребительләр тарафыннан ярым жимерелгән, тишкәләнгән самолетын егерме тапкыр үз аэродромына алып кайткан. Ул очышларның һәркайсы батырлык һәм кыюлыкның олы үрнәге булып тора.

Һәм менә йөз дә тугызынчы очыш! Аеруча катлаулы һәм мөһим задание: дошман оборонасының бөтен тирәнлеген, бу полосада нинди көчләр тупланганын рәсемгә төшерергә кирәк. Балтик дингезеннән искән дымлы жил самолетка каршы кара кучкыл болыт өемнәре бөркә. Машина алар арасына кереп югалып тора да тагын килеп чыга. Ниһаять, аста орудиеләр атудан чыккан ялкыннар күренә. Бу инде — немецларның алгы сызыгындагы орудиеләр. Ә тегесе — пушкалардан алдагы бормалы-бормалы кара сызык — аларның иң алдагы траншеялары. Әнә шул позицияләрдән инде безнең сугышчылар өстенә бертуктаусыз ут явып тора.

— Башлыйбыз, Әнвәр,— диде штурман, кулы белән аска ишарә ясап.

Командир, машинаны кинәт борып, беренче әйләнешкә чыкты.

— Молодец, Әнвәр, шулай тот.

Приборларның уклары тиешле цифрлар өстендә туктап калды һәм фотоаппаратлар эшкә кереште. Самолет, туры курс белән, немецларның алгы сызыгы буйлап оча. Астагы һәр нокта пленкага төшеп бара. Аннан соң штаблар эшкә керешәчәк...

Беренче әйләнештән самолет әйбәт кенә чыкты. Гатауллин биеккәрәк күтәрелеп, янадан «пике»гә ташланды һәм оборонаның яңа участогын төшерә башлады. Шул вакытта укчы-радист Никулинның:

— Артта, сул якта, снарядлар шартлый,— дигән тавышы ишетелде.

— Ун яктан да аталар,— дип кычкырды Хрусталев.
— Барын да күрәм, дуслар, тыныч булыгыз.
Гатауллин як-якка карап алды да, штурвалны кысыбрак тотып, үз курсы белән очуын дәвам итте.
Командирның тынычлыгы иптәшләренә дә күчте. Түбәннән генә очучы машинага ату һаман көчәя барды. Снарядлар самолет тирәсендә якынрак шартлый башлады. Менә «пешка» шартлау дулкыныннан дерелдәп селкенеп куйды. Әнвәр, бермәлгә утыргычыннан кубып, һавада әйләнеп калды. Ләкин ул тиз генә яңадан штурвалга ябышты һәм, текә вираж ясап, югарыга омтылды. Аннан соң кинәт сул якка тайпылды да, моторларны бөтен көченә җигеп, аска ташланды. Фашистлар өстенә пулеметлардан озын-озын очередьлар җибәрде һәм, үз курсына ятып, яңадан эшкә кереште. Снарядлар шартлаудан хасил булган төтен бүрекләре еракта, артта калдылар.
Очучының бу хәйләсеннән дошман зенитчылары югалып калдылар. Алар яңа прицелга күчкән арада самолет позиция өстенә өченче тапкыр әйләнеп керде. Төрле фигуралар белән очып, немецларның ату зонасыннан Әнвәр бу юлы да бик оста гына чыкты.
— Булды, егетләр,— диде, ниһаять, командир, иптәшләренә борылып,— хәзер кайтырга да була!
Штурман Хрусталев Гатауллинга карап елмайды да, маңгаендагы тир тамчыларын сөртеп, алдындагы картага иелде. Укчы-радист сүзгә кушылмады. Ул бөтен игътибары белән тирә-якны күзәтә иде...
Экипаж алдына куелган бурыч аеруча мөһим булгангамы, аэродромда самолетны полк командиры үзе каршылады.
Гатауллин уставча кыска гына итеп рапорт бирде:
— Куелган бурыч тулысынча үтәлде. Машина снаряд ярчыкларыннан биш җирдән тишелде. Экипаж очышларны дәвам итәргә әзер.
Немец зенитчылары белән атышуы, нинди авыр шартларда очып, куелган йөкләмәне үтәве һәм экипажның чиктән тыш аруы турында бер сүз дә әйтмәде ул.
Икенче самолетка ягулык салып, пулеметларны һәм фотоаппаратларны корганчы, экипаж самолет канаты астында бары ун минут ял итәргә өлгерде. Көндезге 1 сәгать 32 минутта «пешка» яңадан күккә күтәрелде һәм шул ук районга юнәлде.
Сугышта икенче тапкыр шул ук урынга очуның нәрсә икәнен очучылар үзләре генә беләләр. Алдагы юлы бәреп төшерә алмавыннан ярсыган дошман самолетны бөтен хәзерлеге белән көтеп тора. Нинди биеклектән һәм нинди фигуралар ясап очуы таныш булган машинаны, позициягә якынайганда ук, дистәләрчә орудиеләр, пулеметлар каршылый. Андый вакытларда самолетның да, экипажның да язмышы корабль командирының идарә итү осталыгына бәйләнгән.
Фашистларның «почеркын» яхшы белгән Гатауллин оборона полосасы өстенә бер дә уйламаган, көтелмәгән яктан барып керде һәм астан гына траншеялар өстеннән сызгырып үтте. Аптырап, югалып калган зенитчылар ата башлаганда, Әнвәр инде икенче әйләнешне тәмамлады. Өченче тапкыр кергәндә, машина тирәсендә, дистәләрчә снарядлар шартлый башлады. Ян-якта да, алда да, артта да санап бетергесез ак һәм кара төтен шарлары хасил булды. Командир шулар арасында үзенә бер коридор табып, очуын дәвам итте.
— Тагын бер әйләнеп чыксак, эш бетә, егетләр,— дип кычкырды Әнвәр иптәшләренә.— Тыныч булыгыз!
Һәм менә дүртенче әйләнеп, моторларын бөтен көченә үкертеп, зенитчылар өстенә пулеметлардан ут сиптереп, ул тагын алгы сызыкка ташланды. Окоплар һәм орудиеләр яшерелгән позицияләр өстеннән үтте. Шуның белән эш бетте. Задание тулысы белән үтәлде. Хәзер снаряд ярчыклары һәм пулялар белән тишкәләнеп тырналып беткән,

кечкә «сулаучы» «пешка»ны аэродромга гына алып кайтасы калды. Бу юлы командир һәрвакыттагыча уен-көлке сүзләр әйтеп тормады, киеренке, арыган тавыш белән:

— Киттек әйдә, өйгә,— диде дә, көч-хәл белән ярым «тере» машинасын көнчыгышка борды. Шул вакытта самолет, көчле электр тогына тоташкандай, бөтен корпусы белән калтырап, селкенеп куйды. Тышкы яктан, кук күкрәгәндәй, көчле тавыш ишетелде. Бер мизгелгә күз аллары караңгыланып китте. Машина, командирны тыңламыйча, текә борылып сул якка ташланды.

Берничә секундка югалып торган күрү һәм ишетү сәләте кире кайткач, Гатауллин снаряд эләгүдән яртылаш умырылган мотордан чыккан ялкын белән катыш кара төтен ташкыны күрде.

— Янабыз, командир, ялкынны сүндер,— дип кычкырды штурман.

— Тыныч бул, Паша, хәзер сүндерәбез, машинаны гына тигезлим.— Командир тыныч кына шулай диде дә бөтен көче белән штурвалны алга, артка йөртә башлады.

— Дима! Никулин! Син исәнме анда, нишлисең?

Укчы-радист тавыш бирмәде.

Сул яктагы канат — төтен эчендә. Менә ут командир кабинасына да үрелә башлады. Чыдый алмаслык эссе кабинада төтенгә тончыгып, Гатауллин машинаны тигезләде, үз курсына чыгарды. Хәзер максималь тизлек белән ялкынны сүндерергә кирәк иде. Утны сүндермәсәң, берничә минуттан бензин бакларының шартлавы мөмкин. Ләкин нишләргә соң? Кулда штурвал, аяк астында педальләр бөгелсә дә самолетның тизлеге артмый. Эсселектән качып, командир уң як бортка сыенды. Үзе ул түземсезлек белән алга карый иде. Фронт сызыгына да ерак калмадылар инде. Шул вакытта штурманның карлыккан тавышы ишетелде:

— Командир, мин янам, сикерергә рөхсәт ит!

Аңа борылып карагач, өлкән лейтенант үз күзләренә үзе ышанмады. Баклардан чыккан бензин чәчрәгән булса кирәк, Хрусталевны ялкын чолгап алган иде. Битләрендә куыклар күпереп чыккан һәм каралган. Сугышчан иптәше бу минутларда командирга шул кадәр кызганыч булып тоелды, аңа дөньядагы бөтен назлы сүзләрне әйтеп бетерәсе килде. Ләкин вакыты андый булмаганлыктан, Әнвәр берничә сүз белән генә чикләнде.

— Молодец син, Паша, чын герой,— диде ул һәм соңгы тапкыр аның күзләренә карады.— Сикер тизрәк! Ләкин парашютыңны тиз ачма!

— Хуш, Әнвәр,— диде штурман һәм ялкынга уралган килеш өске люк аша аска ташланды. Шул минутта ук аның өстендә парашют ачылды. Аның ак ефәк куполын ялкын бер генә ялап алды. Штурманның язмыш иркенә калган озынча гәүдәсе метеор кебек утлы эз калдырып, җиргә таба очты.

— Эх, Пашка, әйттем бит сиңа тиз ачмаска,— дип пышылдады Әнвәр, үз-үзенә. Аның бите буйлап эре-эре күз яшьләре тәгәрәде.

Ялкын һәм төтен уралган самолетта командир үзе генә калды. Ләкин үзебезнең якка барып җитәрлек хәл калмады. Менә-менә ягулык баклары шартларга тора. Бармаклар бернәрсә дә тоймый. Күзләр төтен аша җирне һәм тирә-якны көчкә күрәләр. Ә ялкын телләре инде кабина эчен дә ялый. Нишләргә?

— Үләргә калгач, эз калдырып үләргә кирәк,— дигән карарга килде кыю офицер. Шул минутта аның күз алдына Николай Гастелло килеп басты.

— Минем дә хәзерге хәлем нәкъ аныкы кебек бит,— диде ул, эченнән генә, һәм бар көченә штурвалын кысып, бомбардировщикның борынын аска, немецларның шактый күп техникасы тупланган артиллерия һәм миномет позицияләренә турылады. Һәм ачу белән тешләрен

кысып, пулеметларның гашеткасына басты. Аста немецлар, орудиеләрен, машиналарын калдырып, төрле якка йөгерә, кача башладылар. Берничә секундтан алар өстендә көчле шартлау тавышы ишетелде. Дошман позициясендә ут һәм төтен баганалары күтәрелде...

* * *

Гатауллин, һушына килгәч, беравык үзен-үзе аңлый алмыйча аптырап торды. Аңларлык та түгел иде шул. Ул биек агачлар башына эләгеп уралган парашют бауларына асылынып тора. Күпме вакыт шулай эленеп торганын үзе дә белми. Тирә-якта сугыш уты белән сирәкләнгән урман. Кичке әңгер-меңгер чак. Әнвәр, парашют бауларыннан ычкынып, җиргә төште. Агач төбенә утырды да бөтен ваклыклары белән соңгы очышын тикшерергә тотынды.

— Ничек болай булды соң әле? Мин бит машинадан сикермәдем, киресенчә, дөнья, тормыш белән саубуллашып, дошман өстенә ташландым...

Озак уйланып утырды ул. Җиргә күпмедер калгач, самолетның бензин баклары шартлавын исенә төшерде. Ә парашютның ничек ачылуы Әнвәр өчен табышмак иде.

Дөрес, монда төрлечә уйларга була. Мәсәлән, шартлау дулкыныннан купол тутырылган ранецның ертылуы һәм парашютның үзеннән-үзе ачылуы мөмкин. Һәрхәлдә, Гатауллин самолеттан үзе сикермәде. Ничек булса да булгандыр, әмма ул хәзергә исән. Дөресрәге, ярым исән. Бармаклар самолеттагы кебек бернәрсә дә тоймый түгел, киресенчә, чыдый алмаслык булып авырта. Пешү куыклары сытылудан уң як битечи иткә чыккан. Кашлар, керфекләр көйгән. Кул аркалары пешеп, куыкланып беткән. Комбинезон һәм унталар яртылаш янган. Башы әйләнә, әледән-әле күзаллары караңгыланып китә. Кыйналган кешедәй гәүдә сызлый, тән кызыша.

— Нәрсә булса да түзәргә, тизрәк үзебезнең якка чыгарга,— дигән ныклы карарга килде ул. Чыгарга. Әйтүе бик җиңел. Ничек чыгарга? Бөтен тирә-якта немецлар, сатлык җан полицайлар мыж килеп тора. Юлларда бер өзлексез хәрби йөкләр төялгән машиналар, танклар, обозлар, җәяүле колонналар йөреп тора.

Караңгы төшкәч, Гатауллин, аякларын көчкә атлап, көнчыгышка, атышлар ишетелгән якка кузгалды. Караңгыда алгы сызыкны эзләп торасы юк. Ул бик ерактан күренә. Йөзләрчә көпшәләрдән чыккан ялкын, туктаусыз күтәрелеп торган ракеталар аның өчен маяк иде. Яктырткыч пуляларның энҗе кебек тезелеп күккә менүе алгы окопларның кайда икәнен күрсәтеп тора. Очучы туп-туры шуларга карап юл тотты. Исәнсау кешегә ул араны үтәр өчен бер сәгать вакыт җитәр иде. Ә Гатауллинның хәле авыр иде шул. Ул көч-хәл белән 40—50 метр бара да туктап ял итә. Игътибар белән тирә-якны тыңлый. Аннан соң тагын кузгала. Шулай итеп бара торгач, яктырганчы ике километр чамасы араны үтә. Иртән, тирә-якта хәрәкәт башлангач, Әнвәр, куаклар арасына кереп, ялга туктады.

...Авыр минутларда һәр кеше үзенең бөтен гомерен, тормышының иң бәхетле көннәрен искә ала. Ә иң бәхетле, кайгы-мәшәкатьсез көннәр кеше тормышында бары тик бала чакта гына була.

Уйлар Әнвәрне дә балалык елларына алып киттеләр. Менә ул беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап керә, әни, әти, туган илем дип язарга, укырга өйрәткән беренче укытучы... Соңрак пионер сборлары, абыйсы Абдулла һәм иптәш малайлары белән Кама ярында балык каптырып утырган җәйге таңнар... Аннан соң авиация техникумы, комсомол сафына кергән истәлекле көн. Сугыш... Әтисе аны: «Сынатма, улым, нәсел-ыруга тап төшермә»,— дип озатып калган иде. Бик яхшы

күңелле кеше иде аның әтисе Жиһангир абзый. Балалар ким-хур булып үсмәсеннәр, кеше булсыннар, дип, ул ачлык елны Әрә елгасы буендагы тау башында утырган Күгеш авылын (хәзерге Зеленодольск районы) калдырып, эш эзләп Уралга киткән. Үзенең дүрт баласына да белем һәм яхшы тәрбия биргән ул...

Төрле уйлардан башы авырта башлады Әнвәрнең.

Караңгылана башлагач, ул тагын юлга чыкты. Яралар сызлый. Аннан да бигрәк эчәсе килү теңкәгә тия. Иреннәр кипкән, авызда телне дә әйләндереп булмый башлады. Җан биргәнгә, юнь бирер дигәндәй, Әнвәр дә бер куак төбендә берничә каралып бөрешкән гөмбә табып алды. Сирәк кенә булса да нарат җиләкләре очрый башлады. Эчәсе һәм ашыйсы килү басылгач, хәле яхшырып киткәндәй булды. «Бүген булмый инде, иртәгә, һичшиксез, үзебезнең якта булачакмын»,— дип тынычландырды ул үзен. Фашистлар оборонасын кайда, ничек үтүе, очучы иптәшләре ничек каршылавы, ничек шатланулары бер минутка да аның күз алдыннан китмәде. Ләкин алдагы көн Әнвәрнең бөтен планнарын, хыялларын җимерде...

* * *

Фронт сызыгына километр ярымнар калганда, таң атты. Тирә-якта тагын хәрәкәт башланды. Юлларда да, шәрә калган көзге басу өстендә дә төрле маркалы машиналар йөреп тора. Алар барысы да алгы сызыкка сугыш кирәк-яраклары, солдатлар илтәләр.

Төне буе барудан чиктән тыш арыган, яралары сызлаудан җәфаланган Гатауллин яктыргач, үз-үзен онытып, җиргә сузылып ятты. Күпме яткандыр, ул анысын хәтерләми. Кинәт, артыннан ишетелгән: «Русь, ауф!» дигән тавышка сискәнеп башын күтәрсә, туры төзәлгән автомат көпшәләрен күрде һәм аңын югалтты. Кесәләреннән документларын алганын да, машинага салып алып китүләрен дә сизмәде ул.

Кичкә таба ниндидер авыл өендә аңына килгәч кенә Әнвәр үзенең нинди хәлдә булуын аңлады.

Әсирлек!..

Очучының һушына килгәнен көтеп кенә торган кебек, өйгә автоматлар аскан ике немец солдаты килеп керде. Алар Әнвәрне авыл уртасындагы таш йортка алып килделәр.

Зур тәрәзәле кечкенә бүлмәдә өстәл артында таза гына офицерны күргәч, Гатауллинның тыны кысылды. Шулай да ул үзен бик тиз кулга алды, фашистка тынычрак булып күренергә тырышты.

— Ну, өлкән лейтенант, утырыгыз, сөйләшик,— дип башлады офицер сүзен һәм Әнвәрне баштанаяк карап чыкты.— Бик яшь икәнсез әле сез, мин менә кырыкка җитсәм дә гауптманнан уза алганым юк.

Мөмкин кадәр тынычрак күренергә тырышып, Әнвәр дә сүзгә кереште.

— Хәрби званиене яшькә карап түгел, белемеңә һәм иленә күрсәткән хезмәтеңә карап бирәләр,— диде ул тәрҗемәче аша,— аннан звание алу фронтта җиңелрәк, анда барыгыз!..

— Оһо, сез чәнечкеле сүзләргә оста икәнсез. Димәк, очучы-разведчик?

— Минем бөтен документларым сездә, шуннан карагыз.

— Офицер кешегә тупаслык килешми, өлкән лейтенант, сорауларга җавап бирегез. Без сезгә яхшылык кына телибез.

— Яхшылык теләп безнең илгә басып кердегезмени? Бер гөнаһсыз балаларны, яклаучысы булмаган хатын-кызларны, хәлсез картларны үтерү, тере килеш җиргә күмү, сезнеңчә, яхшылыкмыни?

— Мин сезгә алар турында түгел, үзегез турында кайгыртырга киңәш бирәм, өлкән лейтенант.

— Юк, капитан, минем турыда сез кайгыртырга тиеш,— диде Әнвәр, ярсый төшеп.— Мин сезнең әсирегез. Бездә әсирләргә беренче чиратта медицина ярдәме күрсәтелә. Ә сез минем яраларны күрмәмешкә салышасыз. Шушымы яхшылык? Бу сүзләрне ишеткәч, офицер белән тәрҗемәче ни турындадыр сөйләшеп алдылар. Бүлмәгә ике солдат килеп керде.

Алар көчкә аягына басып торган Гатауллинны ябык машинада Тукумс шәһәренә төрмәгә алып киттеләр. Анда җиде тәүлек җәзалап та, һичнәрсә әйттерә алмагач, аны, ярым тере хәлендә, Латвиянең Виндава шәһәрендәге әсирләр лазаретына озаттылар. Анда Әнвәр тиз арада әсир рус врачлары белән танышты. Аларга фронттагы хәлләр турында сөйләде. Ә врачлар яшь очучыны аякка бастырырга тырыштылар. Яшьтән спорт белән чыныккан таза организм авырулардан тиз арынды. Тәндәге яралар гомерлеккә эз калдырып булса да төзәлделәр.

Азрак хәл керү белән Әнвәр әсир очучылар белән танышты һәм качарга әзерләнә башлады.

1945 елның март аенда, ике катлы чәнечкеле тимер чыбыкны кисеп, Гатауллин Саратов врачы Александр Иванович Кайроны һәм ике очучыны ирекккә чыгарды. Үзе икенче, зуррак группа оештыру өчен лагерьда калды.

Ләкин Гатауллин бу лагерьда планын тормышка ашыра алмады, тиздән кырык кешелек команданы немецлар, пароходка төяп, төньяк Германиядәге Росток шәһәрендәге лагерьга озаттылар. Совет очучысы бередә дә әсирлектән котылу юлларын эзләде. Әсирләрне көчле сак астында урман кисәргә йөртәләр иде. Ул ышанычлы иптәшләренә берәм-берәм үзенең качу планы турында сөйләде: урманда, җай туры китереп, балта белән сакчыны дөмектерергә...

Ниһаять, менә алар иректә. Унсигез тәүлек буена ачлы-туклы килеш көнчыгышка карап юл тоттылар алар. Шулай бара торгач, Польша җирендә һөҗүм итеп килүче совет гаскәрләренә кушылдылар. Гвардия өлкән лейтенанты Гатауллинга, офицер буларак, трофей командасына житәкчелек итүне йөкләделәр. Һөҗүм итүче гаскәрләр белән ул яңадан күп газаплар кичергән Росток шәһәренә барып житте. Җиңү бәйрәмен Әнвәр әнә шунда — ерткычларның үз оясында каршылады.

1945 елның ноябрь аенда, бер ел элек «сугышчан очыштан кайтмаган» звено командиры үз полкына, үзенең сугышчан иптәшләре янына әйләнеп кайтты. Һәлак булган сугышчыларны исәпкә алу журналындагы «частька әйләнеп кайтты» дигән сүзләр әнә шул вакытта, Әнвәр полкына кайткач язылган булып чыкты. Советлар Союзы Герое, гвардия өлкән лейтенанты Әнвәр Гатауллин 1948 елның сентябренә кадәр үзенең сугышчан полкында хезмәт итте. Бөек Ватан сугышы елларында алган бай тәҗрибәсе һәм иптәшләренең геройлыгы үрнәгендә яшь очучыларны тәрбияләде. 1956 ел башында герой очучы бомбардировщиклар полкыннан пенсиягә чыкты.

Хәзер ул Пермь шәһәрендә яши һәм Я. М. Свердлов исемендәге моторлар төзелеше заводының сынау станциясендә диспетчер булып эшли. Әнвәр Гатауллин укучылар, үсмерләр, студентлар һәм эшчеләр арасында бик еш чыгышлар ясый. Ул һәр чыгышында үзенең геройларча һәлак булган сугышчан дусларын — гвардия өлкән лейтенантлары Павел Иванович Хрусталевны һәм Дмитрий Егорович Никулинны, батыр полктәшларын искә ала. Аларның сугыш вакытында күрсәткән тиңдәшсез батырлыклары һәм үзе үткән канлы сугыш юлы турында сөйли.

С. Червонная

# ТУГАН ҖИР ҖЫЛЫСЫ

*Татар художниклары әсәрләренең*
*Мәскәүдә үткәрелгән күргәзмәсеннән репортаж*

Шушы елның январь аенда Казанның җиде художнигы әсәрләре Мәскәү тамашачылары хөкеменә күргәзмәгә куелды. Идел буе табигатенең үзенә генә хас матурлыгы да, Совет Татарстанындагы яңа төзелешләрнең куәтле ритмы да, хәзерге һәм борынгы Казанның шаулап торган көчле тормышы да, борынгы әкиятләр дә, республикабызның яңа җырлары да бу күргәзмәдә, гүя, бергә кушылып, РСФСР художниклар союзының күргәзмәләр залын үзенә бер төрле буяулар, аерым бер аһәң белән тутырып торды.

Һәркайсының үз стиле булган бу җиде художникның әсәрләрендә Татарстанның хәзерге сынлы сәнгате, графикасы, скульптурасы чагылдырылган иде. Ул күргәзмәдә сафларында кырыктан артык члены булган Татарстан художниклары әсәрләренең бары тик бер өлеше генә күрсәтелде. Шулай булса да, анда Татарстан сынлы сәнгатенең төп проблематикасы шактый тулы чагылды. Ул әсәрләрдә чынбарлыкны төрле яклап сурәтләргә, сәнгать культурасын баетырга, халкыбызның милли характерын ачарга, эстетик идеал тудырырга омтылыш бик ачык сизелеп тора.

Эмиль Ситдиков графикасында бу сыйфатлар аеруча ачык күренде. Аның «Советская Россия» күргәзмәсе буенча билгеле булган, линолиумга эшләнгән өч гравюрасына [«Кызыл байрак» кешеләре сериясеннән «Колхоз ветераннары», «Көн уртасы», «Бәхетле кыз»] хәзер «Көй» [1965] һәм «Гөлсем белән Тәлгать» [1968] исемле яңа әсәрләре дә өстәлгән. Аларның беренчесе сугыш елларындагы хатирәләр белән өретелгән, солдатларның авыр язмышына, аларның походлар һәм сугышлар арасында кыска вакытлы ялын күрсәтүгә багышланган. Сугышчы ниндидер көй уйный, ә иптәшләре тыңлап тора. Икенче линогравюра — «Кызыл Байрак» кешеләре сериясенең дәвамы. Бүгенге яшьләребезнең мәхәббәтен сурәтләгән бу әсәр аеруча уңышлы эшләнгән.

Ситдиков иҗатының төп сыйфаты — кешегә мәхәббәт һәм гуманизм. Ул турыдан-туры бүгенге социалистик чынбарлыкка, татар авылы тормышына, аның бәйрәмнәренә һәм эш вакытларына мөрәҗәгать итә. Ләкин Ситдиков графикасында сурәтләнгән образлар кыска гына мизгелнең иллюстрациясе түгел, алар гүя халыкның мең еллык акылын, үткәннең шигърияген, бүгенгенең асылын, киләсе көннең бәхет турындагы хыялын, тормышка актив мөнәсәбәтне үзләренә туплаганнар.

Күргәзмәдә катнашкан Елизавета Киселева һәм Ирина Колмогорцева бер-береннән нык аерылып тора.

Киселеваның күп кенә линогравюралары образлар төзелеше ягыннан политик плакатка якын. Героик революцион көрәш һәм Ватанны саклау темасына багышланган әсәрләре [«Кузгал, уян, ләгънәт ителгән», «Тугызынчы вал» [Потемкинчылар], «Штурм» экспрессия, гадәттән тыш монументаль масштаблылык, төсләрнең ачык чагылдырылуы белән аерылып торалар. Эшчеләрнең, матросларның тәвәккәллек һәм кыюлык белән балкыган йөзләре, гүя янгыннан кызарган 1905 ел яраклыгыннан, узган сугышларның өермәләреннән йөзеп чыгып, тамашачыга якынлашалар. Композицияләрнең динамикасында сыйнфый көрәшнең, революцион омтылышның көеренкелеге



*Э. Г. Ситдиков. «Гөлсем белән Тәлгать».*

белән бергә тупланган, кешенең корбан булуга һәм батырлыкка сәләтле икәнлеге уңышлы ачылган.

И. Колмогорцеваның графикасы тамашачыны күңелле һәм тапкыр халык әкиятләренең мавыктыргыч һәм серле дөньясына алып керә. Аның татар халык әкияте «Гөлчәчәк»кә ясаган иллюстрацияләре — гуашь белән ясалган зур рәсемнәр — аеруча нечкә һәм лирик булып тоелалар. Монда төсләр трактовкасы — шартлы, декоратив. Мәсәлән: «Соры мәче һәм кара мәче» әкияте башындагы рәсемдә мәче сары күзле, гәүдәсе шәмәхә төстә сурәтләнгән. Мәченең тешләрендәге тычканнар теземе кыйммәтле бизәнү әйберсенә охшатып эшләнгән, ә аның шәмәхә төстәге йонындагы орнаменталь бизәк бай һәм уңышлы табылган. Алсу төстә эшләнгән бизәкле келәм, зур сары икмәк, чүлмәкләр һәм кисмәк, ачык яшел өстәл, өйнең алтынсу агачы — болар барысы да ничектер кабатланмас матур һәм әкияттәгечә сурәтләнгән.

Колмогорцеваның балалар китапларына, әкиятләргә ясаган иллюстрацияләре нечкә юмор, балаларның китапны кабул итүен дөрес аңлау белән, төсләр гармониясе, ачык



*Е. В. Киселева. «Кузгал, уян, ләгънәт ителгән»... (төсле линогравюра).*

эре рәсемнәре, кызыклы композицияләр төзи белүе, сюжетларның мавыктыргыч үстерелүе белән отышлы чыккан. Бу художникның иҗаты балалар китабын сәнгатьчә бизәү дәрәҗәсен күтәрүдә, Татарстанда китап культурасын үстерүдә әһәмиятле роль уйный.

Иҗади хезмәтнең барлык төрендә дә, шул исәптән, катлаулы скульптура сәнгатендә дә Татарстанның хатын-кыз художниклары шактый зур урын алып тора. Скульптор Рада Нигъмәтуллинаның күргәзмәгә куелган эшләре — моңа ачык мисал. Аны скульптурадагы катлаулы композицияләр, фигураларның пластик чагыштырылышы, персонажларның психологик характеристикасы мавыктыра. Нигъмәтуллина иҗатына аеруча балачак, яшьлек, аналар темасы хас. Аның мәгълүм композицияләреннән «Әкият» (1962), «Бишек җыры» (1957) шул темаларга багышланганнар. Таган атынучы ике шаян кызчыкны сурәтләгән «Балачак» (1967) композициясендә юморны нечкә тою, нәфислек ачык сизелә. Ә «Студентлар» (1967) композициясе катлаулы ритмик төзелеше белән характерлы. Анда яшь кешеләрнең характер үзенчәлекләре һәм яшьлек хисләре табигый итеп бирелгән. Художникның саклык белән гепэ баласын күкрәгенә кыскан яшь ананы сурәтләүче «Хәерле төн» (1967) исемле скульптурасы хисләрнең сафлыгы һәм җылылыгы, кешегә тирән тәэсир итү көче белән сугарылган.

Күргәзмәдә скульптор Науфаль Адылов скульптуралары да югары бәягә лаек булды. Ул, уеп алынган агач кисәкләрен агач тамырлары белән бергә үреп, урман әкиятләрен, борынгы легендаларны, тарихи сөйләкләрне һәм күтәренке рухлы тормышны чагылдырган декоратив компо-




*Колмогорцева И. К. Татар халык әкияте «Гөлчәчәк» китабының тышлыгы.*



*Нигъмәтуллина Р. Х. «Беренче класстагылар».*

зицияләр тудыра алган. Кызыклы һәм аеруча пөхтә эшләнгән «Шүрәле» композициясендә хикмәтле кәкре тамыр яшел күзле, киереп ачылган авызлы сихри шүрәлегә әверелгән һәм теләсә кайсы бүлмәне урман хатирәсе белән бизи алырлык ачык алтынсу төстәге агач кисәге булып калган.

Адылов агачны стена рәсемнәре һәм вак статуар пластика өчен дә, тарихи портретлар һәм замандашларның портретларын тудырганда да куллана. Соңгылары арасында көрән агачка уелган «Кыз портреты» (1965) үзенең пластик матурлыгы белән аерылып тора. Кызның кысыграк күзе, борыны, шаян елмаюлы иреннәре рәсемне бик тәэсирле итә. Милли характерларның, рухи халәтнең һәм модельнең рухын нечкә ачу бу портретта скульптур форманың декоратив тәэсирлелеген, агачта матурлык мелодиясен таба алу мөмкинлекләре бик зур икәнлеген распап тора. Адыловның скульптурасы ачык чагылган миллилеге белән аерылып тора. Ул Россия Федерациясе сәнгатенең скульптура өлкәсендә дә, графика һәм сынлы сәнгать өлкәсендәге шикелле үк, Татарстанның әһәмиятле урынны алу мөмкинлеге турында сөйли.



*Адылов Н. «Пугачев».*

Татарстанда шактый алга киткән сынлы сәнгатьнең пейзаж жанры күргәзмәдә республикабызның ике художнигы — Николай Кузнецов һәм Андрей Прокопьев әсәрләрендә ачык күренде.

РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Н. Д. Кузнецов Мәскәү тамашачыларына республика һәм Бөтенсоюз күргәзмәләре буенча яхшы таныш. Шулай булса да, аның эшләренең экспозициясендә бу юлы бик күп яңа, көтелмәгәнрәк

сыйфатлар ачылды. Аның күләмнәре әллә ни зур булмаган 1967—1968 елгы полотнолары («Урман», «Апрельдә», «Бәйрәм көне», «Казан. Дегтяркада беренче кар», «Алтынсу агачлар») үзләрендә зур сынлы сәнгать культурасының яңа сыйфатларын, үткен эмоциональлекне, ачык тасвирлылыкны, табигатьне калку һәм саф, поэтик кабул итүне туплаган.


Үзенең палитрасын баету өчен, Кузнецов интернациональ традицияләргә һәм сынлы сәнгать техникасының хәзерге казанышларына мөрәҗәгать итә. Шул ук вакытта аның лирик пейзажларында Татарстанның милли үзенчәлеген чагылдыручы билгеләр: кабатланмас мотивлар, бу җирнең үз буяулары, тасвирлылыкны, декоратив гүзәллекне һәм матурлыкны халыкчан күзаллау — барысы да бар. Бу сыйфат «Юл» (1966) пейзажы мисалында аеруча нык сизелә. Ул кечкенә полотнода куе, интенсив, карасу яшеллек ефәк кебек ялтырап, янып тора. Алан тулы чәчәкләр. Үтә күренмәле пыяла кебек зәңгәр күк. Тауга сукмак сузылган һәм кызыл күлмәкле юлчының фигурасы бу сукмакта сусыл яшеллектәге ал җиләк шикелле, яшел бәрхет калфактагы ләйсәнле чигү кебек җемелди. Болар барысы да, җәйге табигатьнең бөтен тәсен күрсәткәндәй, матур һәм тәэсирле итеп бирелгәннәр.



Прокопьев А. Л. «Яз башы».

Кузнецов республиканың индустриаль төзелешләренә, табигый байлыкларына да мөрәҗәгать итә. Андый полотнолар пейзаж жанрында мавыктыргыч һәм сирәк очрый торган үзенчәлеккә ия. Мисалга «Татарстан. Миннебай газы» (1965—68) әсәрен алырга мөмкин. «Кара алтын» (1968) полотносы да тасвирлы һәм сәнгатьчә бай эшләнгән. Киндернең шактый өлешен биләп тора торган биек күмер тавы сынлы сәнгать өчен әйбәт материал булып чыккан, ә күк зәңгәрлеге белән аралашкан вак күмер тузаны атмосфераның үзенчәлеген тәэмин итә.

Кузнецовның «Нефть чыккан җирдә» (1965) картинасы, кечкенә булуына карамастан, җирнең мәһабәт киңлеген үзенә сыйдыра алган. Кичке әңгер-меңгер вакытындагы зәңгәр җирне еракка сузылучы юлның көмеш сыман тасмасы кисеп үтә. Завод трубалары, буровой вышкалары, күрелмәгән бил-



*Кузнецов Н. Д. «Кара алтын» картинасыннан фрагмент.*

гесез гаскәрнең күккә күтәрелгән кылычлары кебек, катып калганнар. Еракта өйләр, утлар җемелди. Җир киң панорама булып җәелгән һәм тирә-яктагы төзелешләрнең барысы да кешеләргә кирәкле әйберләр.

Кузнецов әсәрләре белән чагыштырганда, Андрей Прокопьев лирик пейзаж остасы, провинция һәм авыл шагыйре булып тоела. Аның полотноларын кайчак хисләр муллыгы, җирнең матурлыгына хәйран калу күмеп китә сыман. Ләкин аларда дөнья ачык, якты, тыныч булып чагыла. Прокопьевның пейзажы Идел буе мотивлары белән аерылгысыз. Ул Идел ярларын, аның кушылдыкларын, утрауларын, биек елгадагы шәһәрләрне һәм пристаньнарны яза. Аның полотнолары тамашачыга нык тәэсир итә, хәтердә кала.

«Идел өстендә»... Шәмәхә төстәге яр, яктылыкның суда көмеш кебек ялтыравы; күк юк, ләкин кояш, күзгә күренмәсә дә, һәркайда — койма күләгәсеннән дә, алмагачның алсу төсеннән дә сизелеп тора.

«Осташков шәһәре»... Су патшалыгы һәм суга охшаш күк. Шушы күксел зәңгәр су стихиясенә шәһәр үзенең борынгы соборлары, стеналары, балыкчы бистәсенең соргылт өйләре белән уелган.

«Тверца. Торжок»... Ялгыз көймә, коз, су, бөтен киндердә чагылган агачларның ялангач ботаклары...

«Май»... Яңадан шушы шәмәхә төстәге язгы җир, көмеш елга, канәфер агачы куаклары, алмагачларның нәфис алсу таҗлары, киң, иркен Идел...

«Язгы җирдә» — Прокопьевның мавыктыргычрак картиналары исәбенә керә. Сөрелгән кара җир дә, зәңгәр күк тә, хатын-кызларның кояш нурларында кабынып китүче ак косынкалары да, чишенеп ташлаган егетләрнең күлмәкләре дә зур темперамент, иркенлек белән язылган. Тегермәннең соры канатлары, нидер көткән кебек, күккә сузылган. Күккә эленгән тургай тавышын искә төшереп, алтынсу сыерчык оясы балкый. Дөнья яктылык һәм җылылык белән тулы.

Кыскасы, Татарстан художниклары Мәскәү күргәзмәсенә үзләренең әсәрләрендә туган җирнең яктылыгын һәм җылылыгын, аның кабатланмас үзенчәлекле төсләрен, матур җырларын алып килгәннәр иде.

Гариф Галиев

# БЕЗНЕҢ КУТУЙ

1941 елның 25 августында военкоматтан миңа повестка килде, ә икенче көнне караңгы төшкәч, без бик озын составлы эшелонга төялеп, Казан вокзалыннан кузгалып киттек. Төн урталарында Суслонгер дигән станциягә килеп җиткәч, командованиенең әмере буенча, вагоннардан төштек һәм тимер юл буеннан ук башланган кара урман эченә кереп киттек.

Иге-чиге күренмәгән урманда — тирән тынлык. Походка өйрәнмәгән кешеләрнең тәртипсез атлаган аяк тавышлары гына ишетелә. Һәр кешенең башын уй баскан: кичә җылы өйдә идек, ә бүген кара урман эчендә...

Берничә километр эчкә кергәннән соң, без такта түбәле, алты почмаклы бер бина алдына килеп туктадык. Соңыннан билгеле булганча, бу бинада әле моннан берничә көн генә элек лесхоз урнашкан булган, ә бүген ул безнең штаб икән. Озак та үтмәде, шушында ачык һавада кунарга команда бирелде һәм ут ягарга рөхсәт ителде. Учаклар яна, коры нарат ботакларыннан көчле ялкыннар күтәрелә башлады.

Әле дә хәтеремдә, без бәләкәй чакларда солдаттан кайткан кешеләрнең үзара сөйләшкәндә: «Мин әнтәрәлист булып хезмәт иттем», дип әйтүләрен ишеткәли идек. Бу төндәге хәбәрләргә караганда, без дә «әнтәрәлистлар» икәнбез, ягъни частебыз запас артиллерия бригадасы дип атала икән.

Икенче көнне безне подразделениеләргә бүлделәр. Санына чыкмаслык бу ишле гаскәр арасында баштарак кемнең кем икәнен дә белеп булмады. Ә тора-бара таныш-белешләр генә түгел, бергә эшләгән кешеләр дә очрый башлады. Мин урманда өйрәнүләр вакытында иң беренче Габдрахман Әпсәләмовны очраттым. Аның белән сөйләшеп торганда безнең янга минем белән бергә журнал редакциясендә эшләгән журналист Мөхәммәт Хәмитов килеп басты. Алар белән күрешүемнең икенче көнендә төш вакытында безнең батарея солдатларына агач чүмеч белән аш бүлеп торучыга күз салган идем, ул композитор Заһит Хәбибуллин булып чыкты һәм мин, тыела алмыйча, кычкырып җибәрдем:

— Заһит, син дә безнең белән бер батареядамыни!

Ул, гадәттәгечә, елмаеп җавап бирде:

— Монда артистлар да бар әле.

Аштан соң без кыска гына арада аның белән сөйләшеп алдык. Ул артист Габдрахман Уральскийның да шушы бригадада икәнлеген, ләкин кайсы подразделениедә торуын белмәвен әйтте.

Өч-дүрт ай үткәч, мин көтмәгәндә Сибгат Хәкимне очраттым. Ул көнне без, берничә солдат, посттан кайтып килә идек. Шулчак безгә таздан кар ерып үтеп баручы солдатлар төркеме очрады. Аларның

алдында кечкенә генә буйлы, какча гәүдәле командир атлый. Төбәбрәк карасам, ул Сибгат Хәким булып чыкты. Күрешү шатлыгыннан дулкынланып алдык. Ул минем нинди подразделениедә икәнлегемне сорап, блокнотына төртеп куйды һәм без тора торган землянканың кай тирәдә икәнлеген сорашты. Аннары:

— Алдагы якшәмбегә мин синең янына төнлә обязательно барып чыгармын, сөйләшеп утырырбыз,— диде.

Ул сүзендә торды. Якшәмбе көнне төнге сәгать уникеләр тирәсендә безнең землянкага килеп керде. Без башкаларга комачауламаска булдык һәм, землянкадан чыгып, нарат агачлары арасына киттек. Искиткеч көчле буран иде ул төнне. Ул алдан атлады. Мин:

Бурай бурай гына карлар яуса,
Боегадыр болан баласы.
Бер нужалар гына күрмәенчә
Ир булмайдыр ата баласы,

— дип җырлый-җырлый аның артыннан атладым. Ул көнне аңа хатыны Мөршидәдән бик кадерле күчтәнәчләр килгән икән. Без бер юан нарат төбенә басып гәпләшә-гәпләшә сыйланып алдык.

Бу үзенә махсус рәвештә каләм тибрәтүне сорый торган истәлек булганлыктан, мин биредә аерым детальләргә тукталмыйм. Күз ача алмаслык буранда бер сәгать чамасы сөйләшеп торганнан соң, ул үз подразделениесенә, мин үз землянкама кайтып киттем.

Инде февраль керде һәм фронтка бер-бер артлы маршевой роталар озатыла башлады. Көннән-көн таныш-белешләр дә сирәк күренә торган булды.

Шулай итеп, без Суслонгер урманнарында, Илет елгасы буйларында хәрби хәзерлек алып, тәмам чыныкканнан соң, бер-бер артлы төрлебез төрле фронтларга китеп бардык. Югарыда телгә алынган язучылардан, композиторлардан һәм артистлардан Габдрахман абзый Уральскийдан башкалары, һәрберсе бүгенге көндә исән-саулар һәм халкыбыз өчен яңадан-яңа әсәрләр биреп, иҗади күтәренкелек белән яшиләр.

Бая әйткәнемчә, без төрлебез төрле фронтларга китеп бардык һәм язмышларыбыз да төрлебезнеке төрлечә булды. Берәүләр Ватаныбыз өчен актык сулышларына кадәр көрәшеп, туган туфрагыбызда ятып калдылар, берәүләр Польша җиренә, берәүләр Германия территориясенә күмелделәр. Бу иптәшләрнең истәлекләре безнең йөрәкләребездә мәңге сакланачак һәм алар турында безнең җырлыйсы җырларыбыз, уйныйсы көйләребез бик күп әле. Моны без эшләрбез, чөнки без моны эшләргә тиешбез, бу безнең вөҗдани бурычыбыз. Бу мәсьәләдә үземне дә, Бөек Ватан сугышына башыннан ахырына кадәр катнашкан язучы буларак, бик җаваплы дип саныйм.

Ватан сугышы елларында миңа Мәхмүт Максуд, Әхмәт Ерикәй, Ибраһим Гази һәм Гадел Кутуйлар белән шактый вакытлар бергә булырга туры килде. Бу иптәшләрнең һәрберсе турында миндә, үземнең фикерем буенча, шактый бай истәлекләр саклана. Алар турында укучылар белән уртаклашуны киләчәккә калдырып, мин бүген Бөек Ватан сугышы елларында, солдат буларак, «Катюша»дан аткан, язучы һәм журналист буларак, үзенең каләме белән дошманга нәфрәт уяткан Гадел Кутуй турында тукталырга булдым.

Гадел Кутуй белән мин Бөек Ватан сугышына кадәр үк якыннан таныш идем. Сугышның соңгы елларында без, Гадел Кутуй, Ибраһим Гази һәм мин, өчебез бергә хезмәт иттек. Беренче Белоруссия фронты газетасы редакциясендә эшләдек. Бик авыр шартларда эшләгән вакытта Гадел Кутуй минем алдымда үзенең эчке матурлыгы белән яңадан ачылды. Ул бер кайчан да күңел төшенкелегенә бирелми торган, гаять дәрәҗәдә шат һәм дәртле кеше иде. Мин аның кул кушырып тик

торган чагын күрмәдем, кайчан гына карама, ул нәрсә дә булса эшли иде.

Кутуй кешеләрне ярата, бик ягымлы сөйләшә һәм ниндидер бер сихри көч белән аларны үзенә тарта иде. Ул кемне генә очратмасын, кем белән генә утырдаш булмасын, аңа күңел ачкычы таба һәм кешеләр аннан аерыла алмыйлар иде. Болар журналист өчен (мин бу язмада Гаделнең шул ягына тукталуны бурыч итеп куйдым да) аеруча кирәк сыйфатлар.

Частьларда командировкада йөреп кайтканнан соң, ул көне-төне яза һәм рус газетасы да, татар газетасы да аның материаллары белән тулып чыга иде. Иң кызыклы тирән эчтәлекле мәкаләләр, һәртөрле хәбәрләр, информацияләр, фельетоннар белән газетаны ул тәэмин итә иде. Аның мәкаләләренең исемнәре дә искиткеч тирән мәгънәле була иде. Мәсәлән, мин аның «Татар солдатлары Берлинда җырлыйлар», «Бер стакан кан» һ. б. шундый укучыны тартып тора торган үткен исем бирелгән мәкаләләрен хәтерлим. Үкенечкә каршы, кулыбызда фронт газеталарының подшивкалары сакланмаган. Хәер, Кутуйның эшчәнлеген өйрәнергә теләгән кешеләр моны архивлардан таба алалар. Ә Кутуй турында да һәм башка иптәшләребез турында да без әле кирәгенчә каләм тибрәтмибез. Ә бит без алар үткән юлларга кат-кат, каерылып-каерылып карарга тиешбез. Һәм бу мактаулы озын юлларны әдәбият аркылы аеруча яшь буын алдына сузып салырга тиешбез.

Әйе, Кутуй чын гражданин, чын язучы, чын журналист иде. Журналист буларак, ул газеталарның җаны иде. Безнең редакциянең, дөресрәге, безнең нәшриятның Польша урманнарында бер тупикка кертеп урнаштырылган махсус эшелонда торган вакыты иде. Ул чакларда газеталар бик иртә басыла иде. Бервакыт мин, вагондагы эсселеккә чыдый алмыйча, җиргә ятып йоклаган идем. Менә бер вакыт басу цехы урнашкан вагонда Кутуй тавышы ишетелде. Ул печатник белән сөйләшә. Кутуй аңа:

— Соң сез үзегез укып карагыз, бу бит хата! Дежурныйлар ничектер искәрмәгәннәр моны. Әйдә, төзәтик! — ди.

Аларның бу хатаны төзәткәннәрен мин аңлап яттым. Чөнки машина берничә минутка туктап торды да, аннан тагын эшли башлады.

Иртә белән сәгать уннарда рус редакциясендә летучка башланды. Шунда редактор полковник Н. С. Потапов хата җибәрүдә гаепле кешеләрне бик нык «кыздырды» да, аннары бөтенесенә берьюлы карап:

— Ә сез, офицер иптәшләр, басу цехына кереп газетага күз төшереп чыксагыз, ярамас идемени! Әле яхшы Кутуй бар, ул күреп алып төзәткән. Әгәр ул төзәтмәгән булса, адәм көлкесенә кала идек бит! — диде.

Русча газетада киткән бу хатаның нәрсәдән гыйбарәт булганлыгына тукталып тормыйм. Ул ниндидер бер чит ил министрының фамилиясенә бәйләнешле һәм бик көлке иде.

Кутуйның газета эшенә бөтен җаны-тәне белән бирелгәнлеген, гаҗәп оператив рәвештә эшләгәнлеген раслый торган фактлар бик күп. Мин шуларның тагы берсе белән укучыларны таныштырып китәргә телим. Сугыш вакытында газетаны күп кенә очракларда аяк өстендә килеш чыгарырга туры килә иде. Чөнки фронт бер урында гына тормый, частьлар алга ыргылалар, алар кичтән монда булсалар, төнлә белән инде әллә кайларга кадәр киткән булалар. Шунлыктан газетаны тиз эшләргә, тиз басарга һәм бик тиз озатырга кирәк. Бу барлык газеталар өчен куела торган гомуми таләп. Милли телләрдә чыга торган газета редакцияләренә аеруча киеренке эшләргә туры килә. Чөнки төп материалларны, приказ һәм һәртөрле политик документларны русчадан тәрҗемә итәргә кирәк. Эшнең шундый тыгыз чагында, төн уртасында, бер вакыт Гадел Кутуй вагонда кулына русча бер материал тотып, аны бик дикъкать белән укып утыра. Үзе сорый:

— Равил жыеп бетердеме әле? — ди. (Линотипист Равил Казаков турында сүз бара).

— Хәзер бетерә,— дим мин.

— Алайса мин диктовкага утырам,— ди Гадел Кутуй.

— Тәрҗемә итеп бетердеңмени? — дип сорыйм мин, аптырашка калып.

— Мин туп-туры линотипка, Равил янына утырып русча тексттан татарчага әйтеп торырга булдым,— ди.

Мондый хәлнең булуы турында беркайчан да ишеткәнем юк иде. Булдыра алыр микән, дип, шактый вакыт аптырап тордым. Ләкин булдырды. Кутуй ул материалны шул чаклы дөрес тәрҗемә итеп әйтеп торган булып чыкты ки, без, гранканы алып укыгач, шаккатып калдык. Берничә урындагы хәреф хаталарын төзәтү белән, ул материал шундук биткә салынды. Газета да графикта билгеләнгән сроктан ярты сәгать чамасы элек басылып чыкты.

Ул үзенә йөкләнгән эшне менә шулай ут өереп башкара иде. Аның бу гадәте безнең барыбызга да йогынты ясады. Мәсәлән, рус телендә язылган материалларны турыдан-туры линотипист янына утырып тәрҗемә итү методын соңга таба Ибраһим Гази да куллана башлады.

Кутуй теләсә кайда, теләсә нинди шартларда да яза, аңа бер нәрсә дә уңайсызлый алмый иде. Мин аның төнлә урманда төп башына фонарь куеп язган вакытларын да, вагон астына урнашып, шпал өстендә каләм тибрәткән вакытларын да, типографиядә утырырга урын булмагач, хәреф кассаларына таянып, аягүрә язган «Сагынам сине, Туган ил!» исемле нәсерен иҗат иткән төннәрен дә бик хәтерлим. Искиткеч патриотик рухта язылган һәм художество эшләнеше ягыннан тиңдәше булмаган ул нәсерне 1960 елларга кадәр артист Ширияздан Сарымсаков радио аша сөйләп тыңлаучыларны рәхәтләндереп килде. Ләкин соңгы елларда радио үзенең бу файдалы эшен ни өчендер онытты.

Кутуй шәхес буларак та бик күркәм кеше иде. Аның исеме дә Гадел, ул үзе дә бик гадел һәм намуслы иде. Юк-бар нәрсәгә тавыш куптаруны, вакланууны, кешене хаксызга кимсетүне һич кенә дә күтәрә алмый, исерткеч белән мавыгучылардан җирәнә һәм үзе дә бу яшел еланнан бик ерак тора иде. Аның әхлаклылыгын, кристалл кебек сафлыгын, кешеләрне бер үк дәрәҗәдә яратуын раслый торган мисаллар бик күп. Шуларның берсен генә булса да сөйләп үтәсем килә.

Польша территориясендә торган чагыбыз иде. 1945 елның яңа ел төнен эшелонда бөтен коллектив белән бик шәпләп каршы алдык. Бәйрәм тантанасы көндез дә зур күтәренкелек белән дәвам итте. Чөнки алдыбызда торган бу яңа елның безгә җиңү китерәчәгенә һәм ул җиңүнең инде якын икәнлегенә бөтен фронт, бөтен тыл ышанган иде.

Көн кичкә авышты. Халык арды һәм ял итү ягын кайгырта башлады. Гадел Кутуй исә, киресенчә, аруның нәрсә икәнен дә белми иде әле. Шунда ул минем янга килде дә:

— Крәстиян иптәш (ул миңа шаярып шулай дәшә иде), әйдә, икәү бер җиргә барып килик,— диде.

— Кая? — дип сорадым.

— Әнә ул якта бер хутор сыман нәрсә бар,— диде, кояш баешы ягына күрсәтеп,— берәр поляк семьясына кереп, аларның яңа елны ничек үткәрүләре белән, гомумән тормышлары, гореф-гадәтләре белән танышып кайтырбыз. Әгәр барырга риза булсаң, мин полковниктан рөхсәт алам.

Мин каршы килмәдем. Ул, вагонга кереп, бик тиз рөхсәт алып чыкты.

Әмма матур иде ул кич! Аяк астында юка гына ап-ак кырпак төшкән. Һава аз гына салкынча һәм бик коры. Без һәртөрле ашамлыклар тутырган солдат капчыгын әле беребез, әле икенчебез күтәреп, тыныч



*Г. Кутуй Юзефа ханым семьясында. 1945 ел, март.*



еллардагы истәлекләрне уртаклаша-уртаклаша атлыйбыз. Юка кырпак өстендә безнең итек эзләребез кала.

Ниһаять, кызыл черепица белән ябылган алты почмаклы йортка килеп туктадык. Аның алгы ягында зәгыйфь кенә ут яктысы күренә. Гадел әкрен генә өйалды ишегеп шакыды. Ишекне бик тиз ачтылар һәм бусагада өлкән яшьтәге ханым күренде. Ул аз гына куркынган кыяфәттә иде. Ләкин ягымлы гына дәшеп, безне эчкә әйдәде. Кердек. Анда тагы кемнәрдер бар, алар кечкенә өстәл янында утыралар иде. Кутуй, гадәттәгечә кулларын сузып, һәммәсе белән күрешеп чыкты да шунда ук сөйләшә дә башлады. Тегеләр аз-маз русча сукалыйлар. Кутуй исә аз-маз полякча белә. Шулай итеп, әллә кайчангы танышлар кебек, бик тиз үзләшеп киттек. Кутуй капчыкны чишеп андагы ризыкларны өстәл өстенә бушатты, аннары миңа:

— Син, Крәстиян иптәш, чәйне үзең хәзерләрсең, син пешергән чәй тәмле була, малай. Хәзер мичкә дә яктырырбыз,— диде.

Кутуйның кешеләрне яратуына, аларны рухи көч белән үзенә әсирлеккә алуына мин менә хәзер, шушы юлларны язганда да, таңга калып утырам. Ул поляк семьясына безнең килеп керүебезгә ун-унбиш минут та үтмәгәндер, Кутуй инде аларның иң якын кешеләре булып әверелгән иде.

Менә алгы яктан түр якка күчеп, хуҗалар мичкә дә ягып җибәрделәр. Кутуй урындык алып килеп беркадәр вакыт мич алдында кызынып утырды. Аннары, аның тәкъдиме буенча, өстәлне мич алдына күчердек.

Бик җанлы һәм җылы сөйләштек без ул көнне. Ишектән кергәндә беркадәр икеләнеп һәм шикләнебрәк каршы алган поляк гаиләсе безне соңга таба үз туганнарыдай якын күрде һәм хөрмәт итте. Кутуй мәҗлеснең башыннан ахырына кадәр рәхәтләнеп сөйләшеп, елмаеп утырды. Шушы сөйләшүләр вакытында без Польша крестьяннарының ничек яшәүләре белән якыннан таныштык.

Төн якты иде. Без килгән юлыбыз белән кайтырга чыктык. Кайткан чакта Гадел мондый сөйләшүләрнең кирәклеген кат-кат әйтте, үз күзең белән күргән тормыш картиналарының беркайчан да онытылмавын,

язучы-журналист өчен аларның һәр вакыт кирәк булачагын кат-кат искә төшерде.

Кутуйның тагын бер күркәм сыйфатына тукталмыйча үтә алмыйм. Ул кая гына бармасын, кем белән генә сөйләшмәсен, һәркайчан үзенең эзен калдыра иде. Бу уңай белән мин гаять дәрәҗәдә каты сугыш барган көннәрдә үземнең баштан кичкән фаҗигале бер вакыйганы сөйләп үтәргә телим.

Бер вакыт без үзбәк газетасының Исмаили фамилияле хәбәрчесе белән алгы сызыкка командировкага киттек. Юлда безгә берничә машинага утырырга туры килде. Ниһаять, алгы сызыкка якынлаштык. Машинаның кабинасында шофер белән бер капитан бара, ә без икебез кузовта утырабыз. Шулай кызу гына барган чакта без алда, әрәмәлек эчендә, пулемет төзәп яткан немец солдатларын күреп, шашып калдык һәм кабинаның стенасына аякларыбыз белән тибә-тибә капитанга кычкыра башладык.

— Немецлар!

Ләкин капитан да, шофер да безне ишетмәделәр булса кирәк, баруларында дәвам иттеләр. Без тагын кычкырдык. Тик нәтиҗәсе булмады, машина һаман алга таба чаба бирде. Инде без немецларга тәмам якынлаштык. Алар ут ачмадылар, безне эчкәре үткәреп җибәрергә теләделәр булса кирәк. Мин кискен карарга килдем һәм, машинаның югары тизлектә баруына карамастан, кузовтан асфальтка сикердем. Гәүдәмне көч-хәл белән сөйрәп, юл буендагы канауга төштем дә, үрмәлиүрмәли артка таба шуыша башладым. Артыма әйләнеп карасам, машина бөтенләй күздән югалган, ә Исмаили исә минем арттан шуышып килә. Нәкъ шул вакытта немецлар канау буйлап безгә ут ачтылар. Белмим, ничек исән калганмындыр, мин тәмам бетеп, бик юан иске имән артына килеп егылдым. Бераз көч кергәч, яңадан канауга төшеп алга таба үрмәли башлаган идем, үзебезнең танкларны күрдем һәм куанычымнан елап җибәрә яздым. Шуыша-шуыша танклар янына гына килеп җиткән идем, бер танк астыннан миңа төбәлгән револьвер көпшәсен күреп, каушап калдым. Танкист миңа кулларымны күтәрергә ишарә ясады. Ул, күрәсең, мине киемен алыштырган дошман солдаты дип уйлады булса кирәк. Мин револьверымны кабурага тыктым һәм, җиргә сеңеп яткан килеш, кулларымны күтәрдем. Ул үзенә якынрак килергә әмер бирде. Мин аңа таба үрмәләдем. Бу вакытта бөтен тирә-якта әллә нинди хәвефле тынлык хөкем сөрә иде. Танкист минем нинди частьтан икәнемне сорады һәм:

— Документың бармы? — диде.

Фронт газетасы редакциясеннән икәнлегемне һәм, ловушкага килеп кергәнебезне сизгәч, документымны ерткалап ташлаганлыгымны әйттем. Ул икеләнде һәм берничә сорау бирде:

— Редакциягездә язучылардан эшләүчеләр бармы?

— Бар, бар,— дидем.

— Кемнәр?

— Шагыйрь Евгений Долматовский, Борис Полейчук, Гадел Кутуй.

Танкистның йөзе яктырып китте:

— Адель Кутуй да алгы сызыктамы?

— Ул редакциягә кайтып кына калды, без чыгып киттек,— дидем.

Танкист дошман ягыннан шуышып килгән Исмаилине күреп алды да:

— Бу да безнең редакциядән диден инде? — диде.

— Әйе, безнең редакциядән.

Исмаили килеп җиткәч, кыска-кыска гына сүз алышу барышында ул Гадел Кутуйны яхшы белгәнлеген һәм күптән түгел генә аның шушы танкистлар частенда командировкада булып киткәнлеген әйтте.

Ул безгә обстановканы аңлатып бирде һәм танклар арасыннан бер солдатны чакырып алып, аңа безне кухня ягына озатырга кушты.

Без ашадык-эчтек һәм шунда кунып калдык. Ул көнне дә, икенче көнне дә дошман белән бәрелеш булмады. Чөнки бу алгы сызыкның шулай мәзәк бер тынлык кичерә торган чагы иде.

Берничә көннән соң без редакциягә кайтып төштек. Кырынып-юынып, өс-башны чистарткannан соң, мин баш редактор полковник Н. С. Потаповка кереп, үземнең кайтуым турында доложить иттем. Ул миңа кайбер күрсәтмәләр бирде. Аннары инде ял итәргә кушты. Мин аның яныннан кузгалганда ул:

— Безнең Кутуй авырып китте бит, син аны күрмәдеңме әле? — диде.

Мин Кутуй белән бер вагонда тора идем. Ләкин мин кайтып төшкәндә ул анда юк иде. Шунлыктан, аны күрмәгәнлегемне әйттем. Полковникның эче пошулы иде:

— Тешләре дә беткән, шуның өстенә радикулит белән дә җәфалана. Алай гына булса да хәл иде, үпкәсендә дә бар бугай,— дип өстәп куйды.

Бер Н. С. Потапов кына түгел, бөтен коллектив ярата иде Кутуйны. Потапов исә, баш редактор буларак, аны аеруча якын күрә иде. Чөнки Г. Кутуй татар газетасы редакциясендә эшләргә җибәрелгән булса да, асылда рус газетасында эшли, оператив һәм кирәкле материаллар белән рус газетасын күбесенчә ул тәэмин итә иде. Мин болай әйтүем белән газета редакциясендәге башка хәбәрчеләрнең хезмәтләренә күз йомарга теләмим. Алар арасында Кутуй кебекләр аз түгел, ләкин Кутуй һәм татарча һәм русча мөкәммәл рәвештә яза алуы, Беренче Белоруссия фронтының бик күп частьлары, бик күп офицерлар составы белән якыннан таныш булуы белән башкалардан аерылып тора иде.

Н. С. Потапов мине яңадан үз янына утыртып шактый озак тотты. Авыру булуына карамастан, Кутуйның көн аралаш алгы сызыкка җибәрүне сорап керүен ярым шатлану, ярым кызгану белән искә алды:

— Тик торуны яратмый бит ул, метеор кеше... Командировкага җибәрергә мөмкин түгел. Әгәр аруланмаса, госпитальгә салырга туры килер инде,— диде.

Мин баш редактордан чыгып, үзебезнең вагонга килеп кергәндә Кутуй сул кулы белән яңагына таянып, тирән уйларга чумып тәрәзәдән карап утыра иде. Без кулларыбызны кысыша-кысыша күрештек. Мин аңа алгы сызыкта күргәннәремне сөйләп бирдем дә:

— Синең аркада бәла-казадан котылдым бит, Гадел,— дидем.

Сөйләшеп утырган вакытта аның әлеге танкистлар частенда моннан өч атна чамасы гына элек командировкада булганлыгы аңлашылды.

Аннары без татар редакциясе урнашкан вагонга киттек. Анда озак кына утырганнан соң, ашханәгә юнәлдек.

Ашханә дигәннән, мин шунда аш бирүче булып эшләүче Дуся исемле бер хатынны Кутуйга күрсәткән хөрмәтләре өчен һич кенә дә оныта алмыйм. Ул үзе Уфадан иде. Шунлыктан булса кирәк, аз-маз татарча да аңлый иде. Без аш өстәле янына урнашу белән алдыбызга Дуся килеп басты. Мине командировкадан исән-сау килеш кайтуым белән тәбрикләде дә, Кутуйның җилкәсенә йомшак кына кагылып:

— Адель абый, иң элек сездән башлыйм, нәрсә китерим? — диде.


Гәрчә авыру булса да, Кутуй гадәтенчә көләч йөзе белән аңа карап:

— Үзең бел инде, Дуся, сиңа яраган миңа ярар, тик йомшак булсын, какшамаган тешем юк, бер нәрсә дә чәйни алмыйм,— диде.

Берәздән безнең Дусябыз аңа тавык итеннән әзерләнгән бер тәлинкә холодец, ике стакан кисель, бер стакан каты чәй китерде.

Аштан соң инде без һәрберебез үзебезнең урыннарыбызга таралдык.

Бирегә телгә алынган менә шушы Дусяның Гаделне никадәр якын итүен, аны ни чаклы тәрбияләвен мин бер кайчан да оныта алмыйм. Хәер, аны бөтен кеше якын итә иде. Минем әле дә хәтеремдә, ул


18.III.
1945 е.

*Г. Кутуйның Юзефа ханымга язган шигыре.*

вакытларда безнең нәшрият урнашкан эшелонны бер группа зенитчиклар саклый иде. Менә шулар еш кына Гаделне үзләре янына алып китәләр иде. Гадел алар янынннан газәттә бик куанып, күтәренке күңел белән кайта иде:

— Әмма кешеләрнең язмышлары төрле дә инде... Алар белән бер сөйләшү үзе бер гомер. Исән калсак, Гариф, бик шәп әйберләр язар идек, — ди торган иде ул, зенитчиклар яныннан һәм гомумән командировкалардан кайткач.

Ләкин ул үзенең бу хыялларын, бу җитди планнарын тормышка ашыра алмады, котылгысыз үлем аны безнең арадан алып китте.

Мин Гадел белән соңгы тапкыр 1945 елның 18 мартында Позпань (Польша) шәһәрендә үзебез торып торган хозяйканың туган көне уңае белән җыелган мәҗлестә утырдым. Югарыда фотокопиясе урнаштырылган шигырьне Гадел хозяйкабыз Юзефа ханымны туган көне белән котлап шул кичне язды. Ә инде 16 апрельдә аның белән саубуллашуым соңгы тапкыр күрүем булып калды. Ул төнне Берлинны алу өчен хәлиткеч һөҗүм башланды һәм без, берничә кеше, алгы сызыкка киттек.

Берлин алынды, Рейхстаг стеналарына безнең флаглар эленде. Берничә көннән Познаньдагы безнең редакция Берлинга күчеп килде. Ләкин коллективта безнең Кутуебыз юк иде. Аның кыр госпиталенә озатылганлыгын әйттеләр. Ул көннәрдә госпитальләр көнгә ике-өч тапкыр бер урыннан икенче урынга күчеп торганлыктан, Гадел ята торган госпитальне тиз генә табу мөмкин түгел иде. Байтак вакыт үткәч, аның үлүе турында хәбәр алынды һәм редакция мәрхүмнең кайда күмелгәнлеген ачыклап кайту өчен мине Польшага җибәрде. Безнең кадерле Кутуебыз Лодз воеводствосына керә торган Згеж шәһәрендәге борынгы хәрби зиратка күмелгән иде.




Алексей Сурков

# ҖИРДӘ ЯШӘҮ ХАКЫНА

*Шагыйрь Валентин Португалов тарафыннан төзелгән бу җыентык «Биш обелиск» дип атала.*

*Китапның беренче битендә эре хәрефләр белән андагы биш авторның исеме һәм аларның яшәгән еллары язылган:*

*Георгий Суворов*
*(1919—1944)*
*Алексей Лебедев*
*(1912—1941)*
*Фатих Кәрим*
*(1909—1945)*
*Иван Рогов*
*(1913—1942)*
*Иван Пулькин*
*(1903—1941)*

*Бу җыентыкка Бөек Ватан сугышында һәлак булган шагыйрьләрнең шигырьләре тупланган. Ул шигырьләр күңелләрне гомер буена дулкынландырырлык зур эмоциональ көчкә ия.*

*Ватан өчен сугышларда корбан булган шагыйрьләрнең җыентыкларын бастырып чыгаруга керешеп, «Советская Россия» нәшрияты мактаурга лаеклы патриотик эш башлаган.*

*Түбәндә без Алексей Сурковның «Биш обелиск» җыентыгына язган сүз башын тәрҗемә итеп урнаштырабыз.*

**Европаның солдат итекләре белән тапталган юллары беркем тарафыннан да үлчәнмәгән. Бу юллар ургылып ага торган Теректән алып мул сулы Дунайга, Идел башланып киткән җирләрдән алып Эльбага кадәр сузылалар. Һәм аларның як-ягында исәпсез-хисапсыз каберләр, солдат каберләре. Кырык беренче һәм кырык икенче елларда дошманны хәлсезләндерә-хәлсезләндерә көнчыгышка чигенүчеләр дә, Сталинград һәм Моздактан, Ленинградтан һәм Мурманск яныннан кузгалып көнбатышка — Рейхстаг һәм тәтен сөреме белән капланган Берлин җимерекләре өстендә җиңү байрагы җилфердәячәк көннәргә карап барган сугышчылар да шул каберлекләрдә йоклыйлар. Һәм ул каберләрнең күбесендә, үзләренең укучылары һәм язган әсәрләренең геройлары белән рәттән, минем коралдаш дусларым — Советлар җирендә туып үскән әдипләр — шагыйрьләр, прозаиклар, драматурглар, тәнкыйтьчеләр йоклый. Совет әдәбияты бөтен кешелек өстенә алып килгән үлемне җиңгән халык исеменнән сөйләү хокукын патриот сугышчы-язучыларның кайнар каны бәрабәренә яулап алды.**

**Сугыштан үзенең язу өстәле артына борылып кайтмаган әдипләр арасында Евгений Петров һәм Аркадий Гайдар, Борис Лапин һәм Захар Хацревин, Юрий Крамов һәм Владимир Ставский, Иосиф Уткин һәм Джек Алтаузен, Муса Җәлил һәм Юрий Инге кебек күренекле язучылар бар иде...**

Аларның барысының да исемнәрен санап чыгу мөмкин түгел, чөнки аларның саны өч йөздән дә артып китә. Аларның күбесе иҗади очышта беренче биеклеккә әле яңа күтәрелгәндә тормышларын пуля өзгән яшь талантлар иде. Китапның беренче битендә без зур тормышка, киң колачлы поэзиягә керер алдыннан канатларын үлем сындырган әнә шул яшь шагыйрьләрдән бишесенең исемнәрен укыйбыз. Ул шагыйрьләрнең барысы да — руслар Алексей Лебедев, Георгий Суворов, Иван Рогов һәм Иван Пулькин да, татар халкының җырчы улы Фатих Кәрим дә — бер үк чорда яшәп, поэзиягә бер үк вакытта килгән кешеләр. Узган юлларына күз салсаң, безгә мирас итеп калдырган шигырьләре белән танышсаң, бер-берләрен белмәгән бу яшьләрнең, диңгезчеме ул, су асты көймәсендә хезмәт итүчеме яки безнең данлы пехотабыз офицерымы, Ерак Себердә туган русмы яки Идел суын колачлап үскән татармы, аларның кандаш туганнар икәнлеген, һәркайсына яшьтән үк яңа тормыш төзү шатлыгы биргән һәм иңнәренә авыр, әмма үзләренең киләчәк язмышлары өчен мактаулы бурыч йөкләгән бер үк Ватанның турылыклы уллары булуларын күрәсең.

Бу җыентыкка шигырьләре урнаштырылган авторларның икесен мин күреп белә идем. Алексей Лебедев шигырьләрен укыганда минем каршыма якташым — Иваново-Вознесенск егете, М. В. Фрунзе исемендәге Хәрби диңгез училищесының соңгы курсында укучы тыйнак һәм басынкы курсант килеп баскандай була.

1939 елның җәе. Без мәһшүр Адмиралтейск манарасының күләгәсе сузылган Александр бакчасы буйлап әрле-бирле йөрибез. Алеша, ашыкмыйча гына, үзенең шигырьләрен укый, аннан соң Кызыл Байраклы Балтик флоты корабльләренең әле яңарак кына тәмамланган әйрәнү походлары турында сөйли... Син аның шигырьләрендә дә, сөйләвендә дә без яшәгән тынгысыз гасырның утызынчы еллар азагында һәркайсыбызны берләштергән, кайгысы һәркайсыбыз өчен уртак булган хәвефле көннәрнең якынаюын тоясың.

Шуннан соң миңа Алеша Лебедев белән яңадан очрашырга насыйп булмады. Ләкин, иҗади чынлыгына ихлас күңелдән шатланып, аның матбугатта басылып чыккан һәрбер шигырен күзәтеп бардым. Озак та үтмәде, сугыш башланды. Чолганышта калган Ленинградтан килгән иптәшләр, штурман Лебедев йөзгән су асты көймәсе сугыштан бурычны үтәгәннән соң әйләнеп кайтмады, дигән кайгылы хәбәр китерделәр. Менә шул чагында мин Алешаның сугышка чаклы ук язылган шигырьләрен хәтерләдем:

Елама син, кыю яшәдек без,
һәм сугыша белдек куркусыз.
Бу хакта сез штабларда язган
Ак кәгазьдән хәбәр укырсыз.
...Тиздән әгәр минем улым туса,
Шул ук максат аңа, шул ук юл.
Минем бишек, минем кабер-диңгез,
Яшәр җирдә моряк булып ул [1].

Лейтенант Георгий Суворов белән язмыш мине кырык беренче елның ахырларында, безнең гаскәрләр Мәскәү янында җиңүгә ирешкән көннәрдә фронт газетасы редакциясендә очраштырды. Сугышта алган беренче ярасы төзәлгәннән соң яңадан фронтка, чолганышта калган Ленинградка юл тоткан бу егет, үзенең шигырьләрен укып, йөрәген басып чыгар өчен, безнең редакциягә килеп керде. Аның йөзеннән госпитальдә ятканда кунган сарылык та китеп җитмәгән иде әле. Ләкин аның тавышы көр һәм чиста, күзләреннән яшьлек чаялыгына хас очкыннар сирпелә иде.

Инде шактый таушалып өлгергән кечкенә дәфтәрен кыр сумкасыннан алып, ул безгә сугышка чаклы һәм сугышның беренче көннәрендә язган шигырьләрен укырга кереште.

Шушы кырлар уртасында
Бәлки ятып үләрмен мин,
Киң сулышлы матур җырлар
Җирдә күбрәк тусын өчен,
Җилләр аны иртә таңда
Илем буйлап кусын өчен.

[1] Шигырьләрне русчадан З. Нури тәрҗемә итте.

Тормышның кадерен белгән бу яшь шагыйрьнең күзләренә текәлеп, аны тыңлап торганда, әлеге шигъри юлларны кайдадыр Нарва артында патриот шагыйрьнең гәүдәсе күмеләчәк туганнар каберлегендәге мәңгелек язма булып калыр дип беркем дә уйламагандыр.

Иван Роговны да, Иван Пулькинны да үзләре исән вакытта миңа беркайчан да күрергә туры килмәде. Аларның шигырьләре белән мин «Биш обелиск» җыентыгының кулъязмасын укыганда гына таныштым. Ләкин шигырьләрен укып чыккач, мин үземне аларның икесен дә күреп белгән кебек хис иттем, чөнки мин Мәскәү янындагы сугышларда язмышы аларныкына охшаш булган эшче егет Вадим Стерельченконы белә идем һәм без аның белән якын дуслар идек. Ул да киң сулышлы, тормышны сөю хисе белән сугарылган шундый ук якты шигырьләр яза иде.

...Иван Роговның сугышка кадәр язылган һәм чик сакчыларына багышланган шигырьләрендә уяулыкка чакыру, җирнең иминлеге өчен борчылу мотивлары яңгырый:

— Ут! — диярләр безгә командирлар,
Һәм чакмага кулым тиз басар.
Әмер көткән көчле, давыллы ут
Күккә кинәт якты эз ясар.
Очып чыгар кысан кепшәдән ул,
Белмәс явым, белмәс җилеңне.
Әйтер ул ут: курыкма үлемнән син,
Җиңим дисәң җирдә үлемне!

Мәскәү янындагы авылларның берсендә туып үскән һәм башкаланы саклаганда батырларча һәлак булган крестьян егете Иван Пулькин якынлашып килгән сугыш турында уйланып, Ватаныбызның бәйсезлеген яклаучы буларак, үзенең тормыштагы урынын болай билгели:

Дуслар белән мин басармын сафка
Киртәләргә аның юлларын.
Дошманымны корыч белән кыйнар,
Кылыч белән торар кулларым.
Авызлыкпап аны җигешермен:
«Тарт! Тынычлык дигән арба бар!..»
Дошманнарның тешен кояр өчен
Бездә көч күп, бездә бар да бар!

Рус солдатының зур көчкә ия булган һәм тәвәккәллек хисләре белән сугарылган әлеге җырына татар халкының солдат шагыйре Фатих Кәрим җыры килеп кушыла. Ул җырлар, сугышчан туганлыкның гүзәл чагылышы булып, бик хаклы рәвештә бер-берләре белән үреләләр. Коралдаш рус туганнарына ничек булса, татар шагыйре өчен дә Ватан ул — тормыш символы, яшәү шатлыгы чыганагы:

Бик авыр бу тормыш, Ватан бүген
Сугыш ялкынында тын ала;
Авыр чорда, сугыш, ут эчендә
Улларының көче сынала.

Күңел ятлый изге мәхәббәтне,
Ак чәчәкләр сирпи талгын җил.
Авыр чорда халкың: «Улым!» дисен,
«Таянычым!» дисен Туган ил.

Бары тик чиксез кыюлыкка ия булган кеше генә мондый сүзләрне әйтә ала:

Үләм икән, үкенечле түгел
Бу үлемнең миңа килүе.
Бөек җыр ул — Бөек Ватан өчен
Сугыш кырларында үлүе!

**Гомерләренең әле яртысы да узылмаган биш шагыйрь. Әле яртысы да җырланып бетмәгән талантлы, тормышка, кешеләргә һәм кешелеккә мәхәббәт, бәхетле киләчәкне алдан тою һәм аңа ышану хисләре белән тулы, үзенчәлекле, кабатланмас җырлар...**

**Бу шагыйрьләр тормышны, яшьлеккә хас булганча, ашкынып, ялкынланып сөяләр. Менә шуңа күрә дә алар җирдә яшәү хакына үлемгә каршы күкрәкләрен куеп басар өчен кирәкле ихтыяр көченә дә, кешелеклелек әбруен биек тотар өчен таләп ителгән кыюлыкка да ия булдылар. Аларның шигырьләре риторикага да, мелодекламациягә дә корылмаган. Сугышчылар алгы сызыкта героик ашкынуның гына түгел, иреннәрне киптергән җәйге эсселәргә һәм тынны куырган кышкы салкыннарга, чиләклап яуган көчле яңгырлар һәм өермә давылларга каршы тору өчен көндәлек түземлелекнең дә кирәклеген бик ачык аңлыйлар. Фронт тормышының авыр минутларында солдат йөрәген җылыткан лирик шигырьләрне алар үзләре белән йөртәләр.**

Ә тышта җил. Күзгә моңсу болыт
Үкси-үкси коя күз яшен;
Кара кичнең пәрдәләрен ертып
Эзли күңел якын иптәшен,—

**дип яза Фатих Кәрим күзгә яңгырлар юган окоптан.**

Чәчәкләр, чәчәкләр. Һәр якта
Чәчәкләр елмаеп күренә.
Әйтерсең лачынның ал каны
Түгелгән кара кыр түренә.
Чәчәкләр, чәчәкләр балкыйлар —
Матурлар, яктылар, көчлеләр.
Чәчәкләр ил өчен баш куйган
Батырлар ядкаре төсле ләр,—

**дип җавап кайтара аңа Георгий Суворов. Алексей Лебедевның сугыш башында язылган һәм су асты көймәләрендә хезмәт итүчеләрнең походтан кайтуларына багышланган шигырьләрендә дә совет сугышчысының көн дә булып тора торган батырлыгы чагыла.**

Су астыннан чыктык. Сәер безгә
Якты җирне кабат күрүләре.
Күренә ал таң, күренә томанлы яр,
Күренә портта буксир йөрүләре.
Ә без керле, ә без кырынмаган,
Соляр исе бездән аңкып тора.
Ә күзләрдә: «Дошман безнең ярга
Үтәлмәде!» сүзе балкып тора.

**...Гомерләрен пуля өзгән бу шагыйрьләр үзләренең җырларын җырлап бетерә алмадылар. Аларның якты дөньядан китүләренә инде чирек гасыр вакыт узды. Ләкин аларның тормыш хакына, җирнең матурлыгы хакына язылган шигырьләре бүген дә яшь һәм әвәлгечә зур ышандыру көченә ия булып кала.**

**Бүгенге яшь укучы... үзенең йөрәге белән арабыздан иртә киткән шагыйрьләрнең йөрәк тибешен тыңласын һәм ил өстенә ябырылган кара афәткә каршы Ватаныбызның нинди корыч ихтыярлы каһарманнарны күтәргәнлеген, ул каһарманнарны үлемгә һәм җиңүгә нинди көч алып барганлыгын тоисын иде. Аларның кыска, ләкин данлы тормыш үрнәге безнең яшьләребезне, Иван Пулькин сүзләре белән әйткәндә, үлемне җиңә торган сафларда барырга чакырсын.**

Даннар даны булган хезмәт бар,
Якты юл бар җырлап үтәргә.
Хаклар хакы булган бер хак бар —
Яшәргә һәм иҗат итәргә.
Бер бәхет бар — туган илеңдә
Якты йолдыз күреп яшәргә,
Илең өчен үлеп, үлемне
Җиңә торган сафка басарга.

# АЧЫК ИШЕК

Латифа аз-Зайят — күренекле гарәп язучысы. «Ачык ишек» романы исә аның зур күләмле беренче әсәре санала. Гарәп халкының, бигрәк тә гарәп яшьләренең иҗтимагый-политик идеалларын, аларның теләк-омтылышларын сурәтләүгә багышланган бу роман киң катлау укучылар массасы арасында зур уңыш казанды.

Әсәрдә Мисыр халкының инглиз колонизаторларына каршы көрәшүе, хатын-кыз азатлыгы кебек актуаль мәсьәләләр күтәрелә. Һәм әлеге мәсьәләләрнең һәркайсы диярлек Мисыр кызы Ләйлә язмышына бәйләнешле рәвештә хәл ителә. Халыкның милли азатлык хәрәкәте Ләйләгә дә ирекле көннәр алып килә, илдә башланган шул хәрәкәт тәэсирендә кыз үзе дә якты киләчәк өчен көрәшүчеләр сафына баса.

Романның сюжет тукымасына күз салыйк.

Әсәр 1946 елгы мәгълүм вакыйгаларны тасвирлау белән башланып китә. Майларына чыдаша алмаган инглиз колонизаторлары Исмаил шәһәрендә бер төркем гарәп патриотларын җәзалап үтерәләр. Гасырлар буе җәбер-золым күреп яшәгән халыкны, чал тарихлы бу борынгы илнең кыю йөрәкле улларын кузгатып җибәрү өчен шул җитә кала: Мисырда көчле азатлык хәрәкәте күтәрелеп китә. Протест митинглары, зур-зур демонстрацияләр бөтен илгә диярлек җәелә. Демонстрантлар арасында без Ләйләнең абыйсы Мәхмүтне очратабыз. Күңеле белән Ләйлә үзе дә гел абыйсы янында. Тик әлегә бик бәләкәй шул ул...

Вакыйгалар бик тиз үзгәрә, катлаулана торалар. Менә 1952 елның җәе — илнең язмышы хәл ителер көннәр килеп җитә. Армия баш күтәрә, король илдән сөрелә. Әлеге зур вакыйгалар барган көннәрдә без кабат Ләйлә белән очрашабыз. Ул инде үсә төшкән, лицей тәмамларга өлгергән. Тик ничектер һаман да читтәрәк йөри әле кызыбыз. Илдә барган вакыйгалар сокландыра да, шул ук вакытта куркыта да аны.

Шул рәвешчә нишләргә белми аптырабрак йөргән көннәрнең берсендә Ләйләбез Әссам исемле бер егеткә гашыйк була. Кинәт кабынган кайнар мәхәббәт хисе аны үзгәртеп, канатландырып җибәргәндәй тоела. Тик бәхет китерми кызга бу мәхәббәт. Икейөзле, куркак һәм намуссыз бер бәндә булып чыга әлеге тәти егет. Ниләр генә килмәде икән 18 яшьлек кыз күңеленә бу кыен көннәрдә?! Әнә шулай романдагы драматик коллизияләр торган саен көчәя, куера бара...

Тагын күпмедер вакыттан соң Ләйлә Каһирә университетының философия факультетына укырга керә. Университетны тәмамлагач, аны Порт-Сәгыйд шәһәренә эшкә җибәрәләр. Нәкъ шул көннәрдә инглиз һәм башка илләрнең колонизаторлары Суэц каналын мисырлылардан тартып алу өчен сугыш ачалар. Ил өчен кыен һәм хәлиткеч көннәр башлана. Шундый шартларда Ләйлә нишләргә тиеш? Әтисе тәкъдименә күнеп, үзе яратмаган кешегә кияүгә чыгарга һәм, профессор бичәсе булып, тыныч кына яшәргәме?.. Бусы — иң җиңел юл. Ләкин мещаннар, обывательләр юлы. Икенче бер юл да бар. Бусы — абыйсы Мәхмүт, кыю йөрәкле Хөсәеннәр сайлаган юл, көрәшчеләр юлы. Иле, халкы язмышы хәл ителгән киеренке көннәрдә, авыр көннәрдә Ләйлә үз тормышын көрәшче Хөсәеннәр белән бәйли...

1956 ел. Халык җиңү тантанасын бәйрәм итә. Шул халык арасында без соңгы кат Ләйлә белән очрашабыз.

— Димәк, бу инде көрәшнең соңгысы, Хөсәен? — дип сорый Ләйлә.

— Юк, сөеклем, бу соңгысы түгел! Бу әле — башы гына,— дип җавап бирә Хөсәен.

Авторның иң зур уңышы — гарәп кызы Ләйлә образы, билгеле. Дөнья әдәбияты хәзинәсендә булган йөзләрчә хатын-кыз образлары янына Латифа аз-Зайят тагын бер гыйбрәтле язмышлы мөлаем образ өстәгән. Зур каршылыклар, һәртөрле икеләнүләр, шик-шөбһәләр аша узып, Ләйлә тормышта үз урынын, мәхәббәтен һәм киләчәген таба. Ул чын кеше өчен иң изге һәм кадерле юлга чыга, ирекккә, кояшка һәм киләчәккә алып бара торган ишекне ачу бәхетенә ирешә.

Романны Ә. Синегулов һәм Л. Антонова иптәшләр тәрҗемә иткән. Әсәр җиңел укыла. Тәрҗемә нигездә уңышлы эшләнгән, диясе килә. **Сәясәт, рисвай, гайре, халәт** кебек безнең телдә күптәннән яшәп килгән гарәп алынмаларын уңышлы куллану оргиналның милли колоритын татар укучыларына да җиткерергә ярдәм иткән. Күргәнегезчә, тәрҗемә ике автор тарафыннан башкарылган. Бу — тәрҗемәнең стилендә дә бераз сизелә. Әсәр бер генә кеше кулы белән тәрҗемә ителсә, әйбәтрәк булыр иде кебек.

Советлар Союзы белән Берләшкән Гарәп Республикасы арасында күп еллар буе дуслык мөнәсәбәтләре яшәп килә. Бу дуслых җитди сынауларны үтте. Батыр Мисыр халкы бүген дә Израиль басып алучыларына каршы аяусыз көрәш алып бара. Ләйләләр, Хөсәеннәр моннан дистә еллар элек башланган көрәшне бүген дә дәвам иттерәләр. Латифа аз-Зайятның «Ачык ишек» романы татар укучыларына гарәп халкы алып барган көрәшнең асылын аңларга, гарәп яшьләренең уй-хисләре, якты омтылышлары белән танышырга ярдәм итәр, дип ышанасы килә.

**Фатих МАКАЕВ**

## Шәүкәт Галиев

### Әнкәй белән бәхәс

Һәркемнең дә бит үзенә
Бик кадерле баласы —
Җай чыкканда иплəп кенә
Кила бер мактанасы.

Минем әнкәй дә бу эштән
Азат түгел, әлбәттә;
Мин акыллы, мин тәүфыйклы,
Мин уңган да, әйбәт тә...

Ә мин мактыйм үз баламны:
Иплəбрәк карачы, дим,
Яхшы яклары күбрәк бит —
Замана баласы, дим.

Әнкәй тагын үзенекен!..
Мин дә тормыйм аптырап:
— Ни әйтсәң дә минем малай
Синекеннән яхшырак!

### Балта

Берәү яңа фатир ала.
Мәгълүм инде — бик шатлана.
Бакчасына бер күз сала —
Алмагачлар бик жәл кала,
Алмагачлар бик жәл кала...
Әллә кемгә торып кала!

Хуҗа кара янып чыга,
Өйдән балта алып чыга,
Төпләреннән чабып чыга...
Чабып чыга берәм-берәм:
— Таки калдырмадым эрәм!..

### Бергәләп тотыйк

Акчаны урлый,
Вакытны урлый,
Саулыкны урлый,
Шатлыкны урлый!
Тотуын да мин
Тотам да бурны,
Әмма тоткачтын
Җибәрми булмый...

Әллә бергәләп
Тотып карыйкмы
Бурны-каракны?
Тануы ансат,
Табуы ансат,
Һәркемгә мәгълүм,
Ул бит атаклы,
Ул бит — аракы!..

### Мәхәббәт уставы турында

«Өчебезнең беребез
Кызлар сөя белмибез —
Ничегрәк сүз кушасы,
Ничегрәк танышасы?

Язмассызмы, дигәннәр,
Сез «Мәхәббәт уставы»?
Әйтерсең лә бу эшнең
Мин мәшһүр бер остасы!

Истә әле сөюнең
Беренче адымнары,
Мәгълүм түгел иде шул,
Безгә дә алымнары.
Белмәдек шул сөюнең
Теорияләрен дә,
Һыяр-кыймас әйләндек
Кызлар тирәләрендә.
Безне дә шул әлеге
Уставсызлык йөдәтте.
Мәхәббәт диңгезендә
Компас иттек йөрәкне.
Бигрәк мөһим мәсьәлә
Күтәрәсез, егетләр,
Фикеремне әйтергә
Этәрәсез, егетләр.
Мәхәббәт — мең-мең еллык
Стихия, дибез дә,
Вакыттыр шул куярга
Аны фәнни нигезгә!
Сөюнең мөһимлеген
Онытабыз гадәттә,
Хәтта сөю хаты да
Өйрәтмибез мәктәптә.
Кирәк булыр ВУЗларда
Егетләргә, кызларга
Һәм башка ялгызларга
Мәхәббәт укытырга!
Булсын стратегиясе,
Булсын тактикасы да,
Булсын җәйге айларда
Махсус практикасы да.
Гыйшык хатлары исә
Диплом эше саналсын.

(Ә көнлез эшләүчеләр
Кичләрен шөгыльләнсен.
Читтән торып ярату
Мөмкинлеге дә калсын...)

Булмый калмас, билгеле,
Докторлар, кандидатлар,
Бу темага бик күпләр
Диссертация яклар.
Инде болар һәммәсе
Озак дикючеләргә,
Өч айлык курслар җитәр
Янып сөючеләргә...

...Өч егеткә җаваплап
Шуны әйтәм, йомгаклап:
Икәүдән генә туа
Һәр мәхәббәт уставы.
Мондый эшнең беркайчан
Була күрмә остасы.
Бүтән тармакларда без
Кайчак файда күрсәк тә —
Күңелләргә, хисләргә
Биреп булмый күрсәтмә!
Качсын тән йокыларың,
Уйлан, борчыл, ян, дустым,
Кояшлы юлларыңда
Очратырсың җан дустың.

Без дә берни белмәдек,
Яшьлек үзе өйрәтте.
Мәхәббәт диңгезендә
Компас ит син йөрәкне!

## Гәрәй Рәхим

# ИПТӘШЛӘР ҮЗЕБЕЗНЕКЕ, БӘЛКИ ГАЕП ИТМӘСЛӘР

## Шайтан аздырган

*Элек шайтан күренеп йөргән, диләр,*
*Хәзер инде, мескен, үлгән, диләр;*
*Ялгышалар. Яшь шайтаннар,*
*Минә миндә личный шайтан бар.*
*(Г. Афзалның*
*«Шайтан» шигыреннән.)*

Гамил Афзал мена диган шагыйрь,
Аны бары тормыш аздырган.
Яхшы шигырьләрен үзе язган,
Калганнарын шайтан аздырган.

## Чуалган

*Куакка колмак чорналган,*
*Кадакка колмак чолганган;*
*Колмакка колмак чорналган;*
*Колакка колмак чолганган;*
*Колгага колмак чорналган;*
*Кулга да колмак чолганган -*
*Чолганып шундый чуалган,*
*Чуалып шундый чорналган*
*Колмакның очы югалган.*
*(Ш. Галиевның*
*«Колмак» дигән шигыре.)*

Куакка шигырь чорналган,
Кадакка шигырь чолганган;
Колмакка шигырь чорналган;
Колакка шигырь чолганган;
Колгага шигырь чорналган;
Кулга да шигырь чолганган;
Чолганып шундый чуалган;
Чуалып шундый чорналган —
Шигырьнең очы югалган.

## Аҗаган

*Равил Фәйзуллинның «Аҗаган» китабы басылып чыгар алдыннан кайбер тәнкыйтьчеләр шагыйрь иҗаты тирәсендә кирәгеннән артык шау-шу куптардылар.*

Бетерә бу, дия-дия,
Кайберәүләр яшен кетә,
Ут кетә,
Кетә дары.
Чынлап карасаң офыкта
«Аҗаган» гына бары,
«Аҗаган» гына бары...

## Мәхәббәт, сөю, гашыйк...

*Бәхәсләргә караганда, Р. Гатауллин җыентыкларының тематикасы бертөрлерәк.*

Алдан артка укып барсаң —
Мәхәббәт, сөю, гашыйк.
Арттан алга укып баксаң
Гашыйк, сөю, мәхәббәт.
Һәм укып чыксаң әйбәтләп
Күңелеңә сеңеп кала
Сөю,
    гашыйк,
        мәхәббәт
            һәм
Тагын бер кат мәхәббәт.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

* * *

Бары бергә җыелып, узган әдәби елга йомгак ясау Татарстан язучылар коллективында файдалы бер гадәткә әйләнеп китте. Язучыларның Тукай исемендәге клубы 25—26 февральләрдә язучылар һәм әдәбият сөючеләр белән шыгрым тулы булды. 1968 нче әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышны Язучылар союзы идарәсенең председателе И. Гази ачты.

Җыелышта проза әсәрләре турында доклад белән Ф. Хөсни, Р. Төхфәтуллин һәм Р. Мостафиннар чыкты. Поэзия турындагы докладны Алабуга педагогия институты проректоры, филология фәннәре кандидаты Т. Галиуллин һәм язучы Р. Харисов ясады. Драматургиянең торышы турында докладны СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми секретаре, филология фәннәре кандидаты А. Әхмәдуллин сөйләде. Филология фәннәре докторы И. Нуруллинның доклады тәнкыйть һәм әдәбият белеме турында булды. Язучы Р. Батуллин докладын балалар әдәбиятына багышланган иде. Тәрҗемәләр турында К. Миңлебаев һәм хәрби темага язылган әсәрләр турында Ә. Шамин чыгыш ясады.

Докладлардан соң кызып фикер алышулар башланды. И. Гази, А. Шамов, М. Әмир, Э. Касыймов, Ә. Еники, М. Шабаев, Ә. Маликов, С. Хәким һәм башка иптәшләр үзләренең чыгышларында язучылык осталыгын тагын да үстерү, нжатта җавaплылыкны күтәрү, тормыш куйган проблемаларны әдәби образлар аша хәл итү, язучылар алдында торган башка бик күп бурычлар турында сөйләделәр.

## ИНСТИТУТНЫҢ ФӘННИ СЕССИЯСЕ

Март башларында СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының III (XIX) фәнни сессиясе булды.

Сессияне ачып, институт директоры профессор М. К. Мөхәррәмов кереш сүз белән чыкты. Өч көнгә сузылган сессиянең пленар утырышларында түбәндәге докладлар тыңланды:

Институтның 1968 елдагы фәнни эшчәнлеге турында ИЯЛИнең гыйльми секретаре, филология фәннәре кандидаты А. Әхмәдуллин доклады.

Татарстанда ленинчыл кооператив планны тормышка ашыруда милли моментлар турында өлкән гыйльми сотрудник, тарих фәннәре кандидаты А. Җәләлов доклады.

Идел буе татарларында хәзерге заман этник процесслар турында кече гыйльми сотрудник, тарих фәннәре кандидаты Р. Мөхәммәдова доклады.

Урта Идел һәм Урал буеның төркиләшә башлаулары мәсьәләсенә карата өлкән гыйльми сотрудник, тарих фәннәре докторы А. Халиков доклады.

«Кыйссаи Йосыф» дастанының язылу вакыты мәсьәләсенә карата өлкән гыйльми сотрудник, филология фәннәре кандидаты Ф. Фасеев доклады.

Татар милләтенең формалашу тарихыннан дигән темага тарих фәннәре докторы Х. Хәсәнов доклады.

Филология фәннәре кандидаты Л. Мәхмүтова җитәкчелегендә эшләгән Тел секциясендә филология фәннәре кандидатлары Х. Курбатов, Ш. Ханбекова, Г. Ахунҗанов, Л. Смоляков һәм кече гыйльми сотрудниклардан А. Латыйпов, Д. Рамазанов, Р. Әхмәтҗановларның чыгышы тыңланды.

Әдәбият, халык иҗаты һәм сәнгате секциясенә филология фәннәре докторы М. Гайнуллин җитәкчелек итте. Бу секциядә филология фәннәре кандидатлары Н. Гыйззәтуллин, А. Әхмәдуллин, Ф. Урманчеев, А. Кәримуллин, сәнгать фәннәре кандидаты И. Илялова, кече фәнни сотрудниклар Р. Гайнанов, Х. Мәхмүтов, Н. Ибраһимов, И. Кадыйров, аспирант К. Дәүләтшин һәм әдәбиятчы З. Максудова иптәшләр тыңланды.

Тарих секциясенең җитәкчесе тарих фәннәре кандидаты Җ. Гыйльманов иде. Секция утырышларында тарих фәннәре кандидатлары К. Нәҗипова, С. Алишев, Ю. Смыков һәм кече фәнни сотрудник Ә. Мөхәммәдов иптәшләр чыгыш ясады.

Тарих фәннәре докторы А. Халиков җитәкчелегендә эшләгән археология һәм этнография секциясендә тарих фәннәре докторы А. Халиков, тарих фәннәре кандидатлары Т. Хлебников, Р. Фәхретдинов, Л. Старостин, биология фәннәре кандидаты В. Петренко, кече фәнни сотрудник Е. Казаков, аспирантлардан Ю. Мөхәммәтшин һәм В. Патрушев чыгышлары тыңланды.

Чыгып сөйләүчеләр күп кенә кызыклы фикерләр әйттеләр, сессия институтның бер еллык эшенә уңышлы йомгак ясады.

## МӘСКӘҮГӘ КИҢӘШМӘГӘ

25 мартта илебезнең башкаласы Мәскәүдә яшь язучыларның 5 нче Бөтенсоюз җыелышы ачылды. Бу зур җыелышта Татарстан язучыларыннан вәкил булып шагыйрь Гәрәй Рәхим, драматург Туфан Миңнуллин, балалар язучысы Роберт Батуллин иптәшләр булдылар. «Комсомолец Татарии» газетасы сотрудникгы, яшь язучы Дияс Вәлиев бу җыелышта кунак булып катнашты.

## ХАЛЫК ТАЛАНТЛАРЫНА СМОТР

В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга һәм Татарстан АССРның 50 еллык юбилеена багышлап, халык талантларының республика смотры игълан ителгән иде.

Февраль азакларында КПСС өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлегендә язучылар, шагыйрьләр, композиторлар, художниклар, артистлар катнашы белән шул турыда зур сөйләшү булды. Алар республикабызның үзешчән сәнгать коллективларына практик ярдәм күрсәтү турында фикер алыштылар. Шушы эш буенча драматург Риза Ишморат Азнакай районында, шагыйрь Зәки Нури Лениногорск үзешчәннәре белән, драматург Рәисә Ишморатова Питрәч районы Шәле авылы колхозчыларына ярдәм күрсәтеп кайттылар.

## ХУДОЖНИКЛАР СОЮЗЫНДА

Татарстан художниклар союзында «Хәзерге чор бизәү сәнгатенең бурычлары һәм үсеш юллары» дигән темага сөйләшү булды. Сүз ике бөек юбилей уңае белән республикабызның шәһәрләрен, авылларын төзекләндерү һәм бизәү турында барды.

Киңәшмәдә катнашучылар художник-оформительләр эшләреннән оештырылган күргәзмә карадылар. Күргәзмәгә кырыклап авторның 200 ләп эше куелган иде.

Бу күргәзмәгә Казан художникларыгына түгел, Түбән Кама, Бөгелмә, Зеленодольск һ. б. шәһәрләрнең художниклары да игътибарга лаеклы иҗатлары белән катнаштылар.

* * *

Татар һәм чуваш халыкларының дуслыгы бик борынгыдан килә. Бу матур традицияне ике халыкның язучылары да уңышлы дәвам итәләр. Ике республика арасында әдәби очрашулар, кичәләр бик еш булып тора. Чуваш язучыларының әсәрләре татар телендә, татар язучыларының китаплары чуваш телендә чыга.

Менә кадәр чуваш укучылары Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, Х. Туфан, К. Нәҗми, М. Әмир, Ш. Мөдәррис, Г. Әпсәләмов, Г. Гобәй, Л. Ихсанова, И. Юзеев әсәрләре белән танышканнар иде.

Әле соңгы көннәрдә генә чуваш китап нәшриятында «Татар хикәяләре» исеме белән тагын бер китап чыкты. Бу китапка татар язучыларыннан унике авторның әсәре тупланып, аларны чувашчага язучылардан М. Юхма, В. Максимов, А. Ерусланов, В. Игнатьев, Ю. Скворцов һәм Казанда яшәүче әдәбиятчылардан В. Юдин һәм К. Петров иптәшләр тәрҗемә иткәннәр.

«Татар хикәяләре» китабы татар һәм чуваш халыклары арасындагы дуслыкның тагын бер матур үрнәге.

## ИҖАТ БӘЙРӘМНӘРЕ

Шушы елның 2 мартында күренекле язучыбыз Әмирхан Еникигә 60 яшь тулды. Бу юбилей язучыбызның туган ягында — Башкортстан АССРның Дәүләкән районында үткәрелде. Якташларының чакыруын кабул итеп, Ә. Еники туган көнен үткәрергә Дәүләкәнгә килде. Механизаторлар хәзерләү мәктәбендә, өченче номерлы Башкорт урта мәктәбендә һәм татар сигезьеллык мәктәбендә үткәрелгән юбилей кичәләрендә әдипне котладылар, бүләкләр тапшырдылар, почетлы пионер итеп алдылар. Бу кичәләрдә әдипнең яшьлек дуслары, ТАССР язучылар союзы правлениесе члены Илдар Юзеев, БАССР язучылар союзының җаваплы секретаре Вәзих Исхаков, Дәүләкән райкомының беренче секретаре Б. М. Зубарев, райбашкарма комитеты председателе В. Равилов, райкомның пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Ә. Минһаҗов иптәшләр катнашты.

* * *

Шагыйрь Әнвәр Давыдовның тууына 50 ел тулды. Татар совет поэзиясенә зур өлеш кертеп, әле узган ел җәй көне генә арабыздан киткән талантлы шагыйрьнең туган көнен билгеләп үтү өчен язучыларның Тукай исемендәге клубына каләмдәш дуслары, аның шигырьләрен яратучы күп санлы укучылар, туганнары, якташлары килгән иде. Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында тәнкыйтьче Нил Юзиев бик җылы чыгыш ясады. Камышлы районының элекке партия эшчесе Зиннәт Әбдерәшитов иптәш Әнвәр Давыдовның район газетасы редакторы булып эшләгән еллары турында истәлек сөйләде. Камышлы сигезьеллык мәктәп директоры Абдулла Акчурин шагыйрьнең туган ягы Камышлы авылының соңгы еллардагы уңышлары белән таныштырды. Ул Камышлының бер урамына Әнвәр Давыдов исеме бирелачәген хәбәр иткәч, залда бик озак алкышлар яңгырап торды. Кичәнең икенче бүлегендә шагыйрь Әнвәр Давыдов иҗатына багышланган концерт булды.

* * *

Республикабызның сәнгать сөючеләре яраткан артистлары Хөсәен Уразиковның иҗат бәйрәмен билгеләп үттеләр. Хөсәен ага Уразиков күп кырлы талант. Ул артист та, режиссер да, драматург та, педагог та. Тууына 75, иҗат эшчәнлегенә 50 ел тулган көннәрдә Хөсәен Уразиковның язучы М. Гали белән бергә язган «Каюм Насыйри» әсәре сәхнәгә куелды. Бу спектакльдә Ибраһим бай Юнысов ролен РСФСРның атказанган һәм Татарстанның халык артисты Хөсәен Уразиков үзе башкарды.

* * *

РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Фоат Халитовка 60 яшь. Татарның талантлы сәнгать осталары иҗат иткән геройлар галлереясенә герой шагыйрь Муса Җәлил, көчле рухлы райком секретаре Гыйльманов, Ленин белән очрашу бәхетенә ирешкән мылтыклы кеше Шадрин, халыкның зирәк акылын үзендә туплаган Хуҗа Насретдин һ. б.ларның онытылмас образларын өстәгән гаять кызыклы, рухи яктан бай артист ул Фоат Халитов. Шуңа күрә дә

аның иҗат бәйрәмендә катнашырга Г. Камал исемендәге академия театрына бик күп кеше килгән иде. Юбилярга күп котлаулар әйтелде, бүләкләр бирелде. Кичәнең ахырында Фоат Халитов эшенә илһам биргән, сәнгать югарылыгына күтәрелергә булышкан туган халкына, Коммунистлар партиясенә зур рәхмәтен белдерде.

* * *

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, доцент Җәлал Садрыйҗиһановка 60 яшь һәм иҗат эшчәнлегенә 40 ел тулу көне билгеләп үтелде. Кичәнең художество бүлегендә Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсыннан пролог, М. Глинканың «Иван Сусанин» операсыннан 2 нче пәрдә, П. Чайковскийның «Пиковая дама» операсыннан 1 нче пәрдә күрсәтелде.

Кичәдә юбиляр Җәлал Садрыйҗиһанов дирижерлык итте.

* * *

Әлмәт татар дәүләт драма театрының эшли башлавына 25 ел тулды. Шушы еллар эчендә театр рус, татар, башкорт һәм башка тугандаш халыкларның 200 ләп әсәрен сәхнәдә күрсәтте. Әлмәт артистларын республикабыз тамашачылары гына түгел, Чиләбе, Свердловск, Ульяновск, Куйбышев өлкәләрендә дә Башкортстан һәм Удмурт АССРда да яхшы беләләр.

Театрның 25 еллык юбилее уңае белән Әлмәт шәһәрендә спектакльләр күрсәтү декадасы үткәрелде. Ә 5 апрельдә әлмәтлеләр театрларының туган көнен бәйрәм итәргә җыелдылар.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КЛАССИГЫНА БАГЫШЛАНГАН КИЧӘ

Илебезнең төрле өлкәләрендә яшәүче укучылар республикабызның үсеше, фән, әдәбият һәм сәнгать казанышлары белән һәрвакыт кызыксынып торалар.




И. А. Лихачев исемендәге Мәскәү автозаводының Культура сараенда татар әдәбияты классигы Фатих Әмирханга багышланган әдәби кичә булды. Язучының иҗаты турында А. М. Горький исемендәге Әдәбият институтының укытучысы, әдәбият фәне белгече Г. З. Хантемирова сөйләде.

* * *

Мәскәүдә, В. И. Ленин исемендәге СССР Үзәк китапханәсенең үзәк залларында күренекле татар драматургы Галиәсгар Камалның тууына 90 ел тулуга багышланган күргәзмә-стенд оештырылды. Биредә әдипнең иҗатын һәм тормыш юлын чагылдырган күп кенә материаллар — төрле чорда иҗат иткән драмалары, афишалар, әдипнең тормыш юлына багышланган хезмәтләр куелган.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Татарстан язучылары һәрвакыт үзләренең укучылары арасында. Төрле районнарда әдәби очрашулар, туган якларга иҗат отчетлары белән кайтулар инде гадәт булып китте. В. И. Ленинның тууына 100 ел, республикабызның 50 еллык юбилейлары уңае белән язучыларның иҗат активлыгы тагын да үсте, алар илебезнең төрле шәһәрләренә, республикабызның авылларына чыгып йөрүләрен тагын да арттырдылар. Мәсәлән, соңгы вакытларда язучылар түбәндәге урыннарда булдылар:

Драматург Риза Ишморат Минзәләдә иҗат командировкасында булды. Ул язылачак яңа пьесасына материал туплау өчен гражданнар сугышы ветераннары белән очрашты. Аларның күп кенә истәлекләре һәм рәсми документлар белән танышты.

* * *

«Литературная Россия» газетасы заданиесе белән язучы Гариф Ахунов Уфада булып кайтты. Тугандаш республикабыз Башкортстанның 50 еллык юбилеена карата очерк язып, аны рус һәм татар телләрендә бастырып чыгарды.

* * *

Татарстан язучылар союзы идарәсе районнардагы яшь һәм башлап язучыларга өзлексез ярдәм күрсәтеп тора. Шул уңай белән шагыйрьләрдән Илдар Юзеев һәм Шәүкәт Галиев Буа районында булдылар. Алар районның әдәбият көчләре белән очрашып, яшьләрнең әсәрләрен тикшерделәр, киңәшләр бирделәр, үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар.

* * *

Язучы Мәхмүт Хәсәнов Псков шәһәренә барды. Ул В. И. Ленин булган җирләрдән яңа материаллар туплап кайтты.

* * *

Шагыйрь Марс Шабаев әледән-әле якташлары — мөслимлеләр белән очрашып тора. Бу юлы аны Мөслим районының пар-

тия комитеты культура работникларының конференциясендә катнашу өчен чакырып алды.

* * *

Әлмәт шәһәренең көнкүреш комбинатында зур әдәби-музыкаль кичә булды. Кичәгә язучылардан Рафаил Төхфәтуллин, Фазыл Мостафин, Гамил Афзал катнашты.

* * *

В. И. Ульянов-Ленин исемендәге университетта да әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Анда Илдар Юзеев, Роберт Батуллин, Гәрәй Рәхим, Зөлфәт үзләренең әсәрләрен укыдылар.

* * *

Артист һәм язучы Абдулла Шамуков тамашачылар белән очрашып, аларга Н. Погодинның «Мылтыклы кеше» спектаклен сәхнәгә куйганда В. И. Ленин образын тудыруда ничек эшләве турында сөйләде. Очрашу җанлы һәм кызыклы үтте.

* * *

Язучы Газиз Мөхәммәтшин озак вакытлар Минзәлә районында йөреп, андагы партия работникларының эшләрен, районДагы хәлләрне, халыкларның көнкүрешләрен өйрәнеп кайтты. Шул материалларны файдаланып, ул «Казан утлары» журналына зур күләмле очерк язып китерде.

## ТУКАЙ ТУРЫНДА ЯҢА КИТАП

Бөек әдипнең тормышы, иҗат юлы, иҗтимагый эшчәнлеге турында диссертацияләр, монографияләр, мәкаләләр, истәлекләр язылып тора. Татарстан китап нәшрияты күптән түгел генә Г. Тукайның 80 еллык юбилее уңае белән Казанда һәм Мәскәүдә үткәрелгән фәнни сессия материалларын бер китапка туплап, рус телендә бастырып чыгарды. «Габдулла Тукай» дигән бу китапка татар әдәбияты белгечләре, галимнәре белән берләттән илебездәге бүтән республика әдәбиятчылары һәм күренекле язучыларының чыгышлары да тупланган. Китап КПСС өлкә комитеты секретаре, тарих фәннәре кандидаты М. В. Вәлиевның «Шагыйрь, көрәшче, патриот» дигән мәкаләсе белән ачыла.

## КУНАКЛАР ӨЧЕН

Шәһәребезгә килгән кунаклар кибетләребездән күп кенә сувенирлар, картиналар, альбомнар алып китә алалар. Казан белән танышасы килгән кешеләр өчен белешмә-китаплар чыгарыла. Менә шушындыйлардан «Казан» белешмә-китапчыгы матур эшләнеше белән аеруча күзгә ташлана. Аның беренче битен ачуга татар милли киемнәрен кигән бер кыз рәсеме күренә. Ялтыравыклы ак кәгазьгә төсле буяулар белән басылган Казан Кремле, студент Ульянов, Габдулла Тукайларга куелган һәйкәлләр, Алексей Пешков бюсты, шәһәр урамнарының күренешләре һ. б. игътибарны җәлеп итә. Казан шәһәренең үткәндәге тарихы, В. И. Ленинга бәйле истәлекле урыннары, архитектура үрнәкләре, кино-театрлары, аның уку йортлары, яңа төзелешләре, спорт корылмалары, елга һәм һава портлары, ял урыннары, шәһәребезнең фән, сәнгать, әдәбият эшлеклеләре һ. б. турындагы белешмәләр рус, инглиз, немец һәм француз телләрендә бирелгәннәр.

## ИСТӘЛЕК БҮЛӘКЛӘРЕ

В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу көненә һәм Татарстанның 50 еллыгына әзерлек уңае белән, шушы истәлекле вакыйгаларны тулырак чагылдыру, республикабызның халык хуҗалыгы һәм культура өлкәсендә ирешкән казанышларын күрсәтү максатыннан һәм югары сыйфатлы, сәнгатьчә эшләнгән бүләк-сувенирларны күпләп чыгаруны күздә тотып, КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы махсус карар кабул иттеләр.

Карарда күрсәтелгәнчә, юбилей бүләкләренең һәм сувенирларының иң яхшы үрнәкләренә конкурс-смотрлар үткәреләчәк. Предприятиеләр һәм оешмаларда ул шушы елның апреленә, районнарда 15 майга, республикада 1 июньгә кадәр узачак. Конкурска республика предприятиеләрендә һәм оешмаларында әзерләнгән, шулай ук аерым халык талантлары тарафыннан эшләнгән истәлек сувенирлары үрнәкләре тәкъдим ителә.


РСФСР художество фондының Татарстан бүлекчәсенә, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтына, Татарстан АССРның дәүләт музеена бүләк һәм сувенирларның проектларын, эскизларын һәм оригиналь үрнәкләрен булдыруда, шулай ук кирәкле материаллар сайлап алуда предприятиеләргә һәм оешмаларга ярдәм итү йөкләтелә.


## ГЫЙЛЬМИ СОВЕТ

Күренекле әдәбият галиме профессор Габдрахман Сәгъдинең тууына 80 ел тулуга багышлап, СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында Гыйльми совет утырышы үткәрелде.

# НИГӘ, НИГӘ СИН ҖЫРЛАДЫҢ МИҢА?

Ф. ӘХМЕТОВ музыкасы
Н. ДӘҮЛИ сүзләре






Ул чакта яз иде, исеңдәме?
Без утырдык каен төбендә.
Нигә, нигә син җырладың миңа?
Кайнар сагыш тулды күңелгә.
Шул җыр белән минем йөрәгемдә
Синең исемең калды гомергә.

Күзләреңә карап йолдызымны
Күргән кебек булган идем мин.
Нигә, нигә син җырладың миңа?
Сагынсын да, көйсен дидеңме?
Мәхәббәтнең таүге юлларыннан
Мине эзләп йөрсен дидеңме?

Яз килгәндә, ташкын гөрләгәндә,
Ялгыз йөрим елга буенда.
Нигә, нигә син җырладың миңа?
Истә калды авыр моң гына.
Яр буенда каен яфрак яра,
Яңгырамый синең җыр гына.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210